# Казан утлары



7

июль

1967

# КАЗАН утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ һӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК АЛТЫНЧЫ ЕЛ ЧЫГА

7
ИЮЛЬ
1967

## Бу санда:

ПОВЕСТЬ, ПЬЕСА, ШИГЫРЬЛӘР

Г. Бәширов. Туган ягым — яшел бишек. Автобиографик повесть. . . . . . . . . . . . 3
Г. Рәхим. Сагыш һәм шатлык; Сугышта югалган солдатлар; Вәгъдә; Сабырларга. Шигырьләр. . 49
Р. Мингалимов. Сөенечем; Очрашу; Әрсезләр; Шигырьләр. . . . . . . . . . . . . 51
Р. Закиров. Яшьлек эзләре; Юл буенда. . . . Шигырьләр. . . . . . . . . . . . . . . . . 52
Х. Вахит. Соңгы хат. Пьеса. . . . . . . . . . 53

СОВЕТ ВЛАСТЕНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

З. Әхмеров, Э. Касыймов. Н. К. Крупская Идел — Кама буйларында. . . . . . . . . 72

ДУСЛАР ИҖАТЫ

А. Тажибаев. Моң турында; Борчылма ярлы чагыңда; Кайнар булсын; Сөенечемнең чиге юк; Ак нурлар. Шигырьләр. . . . . . . 79

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

М. Хәсәнов. Эш сөйгәнне ил сөя. Очерк . . 81

СОВЕТ ВЛАСТЕНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

А. Әхмәдуллин. Татар совет мәдәниятының көндәлек дәфтәреннән. . . . . . . . . . 89
Ф. Ибраһимов. Без түбәннән күтәрелдек. . 94

ЯҢА ДОКУМЕНТЛАР

С. Габәши. Татар һәм башкорт көйләре турында. . . . . . . . . . . . . . . . . . 104

КПССның
ТАТАРСТАН ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА һӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ГАЛИМҖАН НИГЪМӘТИНЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

И. Нуруллин. **Киң карашлы галим.** . . . . 106
М. Фәйзуллина. **Тәнкыйтьче, педагог һәм фән эшлеклесе.** . . . . . . . . . . . . . . 112
М. Исхаков. **Безнең сафта.** . . . . . . . . . 113

ФОТОРЕПОРТАЖ

Н. Хәкимуллин. **Фотообъективта — Непал.** . . 115

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

М. Госманов, М. Мәһдиев. **XX йөз башы татар әдәбияты һәм матбугат тарихының кайбер мәсьәләләре.** . . . . . . . . . . . . 124

УКУЧЫЛАР СОРАВЫ БУЕНЧА

Р. Фәхретдинов. **Болгар тарихына яңа истәлекләр.** . . . . . . . . . . . . . . . . . 132

ТУГАНДАШ ХАЛЫКЛАРНЫҢ ЯЗУЧЫЛАРЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТУРЫНДА

Г. Голәм. **Шагыйрьнең мәңгелеге.** . . . . . 145

ТӨРЛЕСЕННӘН

Р. Хәйретдинов. **Татарстан тарихы буенча чит илдә чыккан бер китап турында.** . . . . 148

САТИРА һӘМ ЮМОР

Ф. Хөсни. **Бар иде Балтачта бер этәч.** . . . 151

**Укучылар сүзе.** . . . . . . . . . . . . . . . 154

**Укучыларыбызга җавап.** . . . . . . . . . . . 156

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары.** . . . . . . 157

М. Яруллин. **Яшьлек дустыма.** Җыр. И. Юзеев сүзләре. . . . . . . . . . . . . . .

---

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Гомәр Бәширов

# Туган ягым — яшел бишек



*Автобиографик повесть*[1]

## Кунак кызлар килде утырмага

### I

Югары очка да килгән кунак кыз, түбән очның Сабитларга да. Әти Казанга солы белән киткәч, безгә дә килеп төште. Ник дисәң, гадәте шулай. Көз көнендә аның үзенең бик сөйкемле бер вакыты бар.

Атналар буе көне-төне вак иләктән иләгәндәй тетәсләп торып үзәккә үткән, кибәннәрнең янтауларына яшел ямаулыклар үстергән бетмәс-төкәнмәс көзге яңгырлар туктаган. Әниләр елмаюы кебек ягымлы җылы көннәре, көмеш тожымнары, салкын төннәре белән әбиләр чуагы да узып киткән. Төнлә белән өй түбәләренә, капка башларына — бөтен җиргә җем-җем иткән ап-ак кырау төшә, агачларга бәс бәйләнә. Көзге пычракта бозылып калган урамнар, юллар, бөтен казылмалары, кисенте һәм чокырлары белән бер төн эчендә шакыраеп каталар. Урамнан узган арбаның дөбердәве бөтен авылны яңгырата.

Иртән торып тышка чыксаң, бөтен дөнья боеккан. Келәт кәрнизендә, кызыл тәпиләрен корсак асларына яшереп, күгәрченнәр бөрешеп утыра. Агач ботакларындагы кабарынкы йонлы мескен чыпчыклар тешенке тавыш белән:

— Суык-суык, суык-суык! — дип зарланалар.

Менә тагын берәр атна уза. Көннәр тагын да суыта төшеп, инешләргә боз ката, җиргә кырпак төшә. Картлар, бишмәт өстеннән биләрен буып, бияләй кияләр дә, озын таякларга таянып, уҗым басуына чыгып керәләр.

---

[1] Дәвамы. Башы 5, 6 саннарда.

— Ат аягы батарлык түгел инде, катырган, — диләр. — Уҗымның тамыры өзелмәс. Әйдә, ку мал-туарны уҗымга!

Хәзер инде «арба да түгел, чана да түгел». Арба җиксәң, тәгәрәми, чана җиксәң, шуммый.

Менә бер көнне иртән торып чыгасың — бөтен дөнья ап-ак! Йомшак кар өстенә каз-үрдәк тармаклы-җәпләкәле беренче эзләрен салып киткән. Кич-иртә урамнан шыгырт та шагырт аяк тавышлары ишетелә башлый.

Менә кайчан кузгала төрле өмәләр: каз өмәсе, сүс өмәсе, тула өмәсе. Шул вакытка турылап күрше авыллардан кунак кызлар килә. Байга да килә, ярлыга да. Кунактан кунакка гына, бәлештән коймакка гына йөреп өч-дүрт көннән үк китеп баручылар да, быелгы шикелле корылык булган елларны якты чырай, сөтле чәйгә дә бик риза булып, унар, унбишәр көн утыручылар да булгалый. Кунак кыз дигәндә, бары бергә, югы уртак, ничек туры килгәндә дә гаеп ителми.

Безнең кунак кызыбыз яшь кенә иде әле. Чәче, Яңа Сала кызларыныкы кебек, кара, я коңгырт түгел, бодай саламы төсле. Бите дә түгәрәк түгел, ак та, озынчарак та, күзләре дә күк төсле. Сөрмә тартмый, иннек-кершән сөртенми. Ник дисәң, ireннәре болай да бөрлегән төсле, бит урталары багъ алмасыдай, үзеннән-үзе алсуланып тора. Исле сабын белән бик матурлап битен юып, чаршау артында чәчен тарап үрә дә, мәрҗәннәрен асып, көмеш балдакларын киеп, чулпыларын чылтыратып, тик йөри бөтен өйне балкытып.

Беренче көнне иртән торгач, коймагын ашап, чәен эчкәннән соң, тәрәзә янынарак утырды да кунак кыз, урамнан узучы яшь-җилбәзәккә күз аткалап, пирчәткә бәйли башлады. Шунда өйдәгеләр белән тәмле генә әңгәмә куерып китте. Ике якның да нәсел-нәсәбе, әби-бабайлардан башлап яңа туган сабыйларгача, бөтенесе телгә алынды. Ерак әби күп иттереп сәлам әйткән. Җиденче дистә белән барса да әле, күз генә тимәсен, зерә дә таза, зиһенле икән. Фәлән түтиләр ат алган, кемдер башка чыккан, фәләннең улы солдатка киткән, кемдер кияүгә чыккан, кайсыдыр өйләнгән дә хәзер инде туп шикелле тупырдап кына торган балалары бар икән. Әмма шул ук вакытта берсе телсез-авызсыз калып, үлем түшәгендә ята, икенчесенә әҗәл хастасы эләккән дә, узган атнада гүр иясе булган. Кит аннан дисеңме? Синең яшьтәшең, ахирәтең инде югыйсәм, тәтәй генәм, әле җиләк шикелле чагы. Язмыштан узмыш юк диләрме, тәкъдиреңдә язганны нишләтәсең бит инде. (Шунда җиткәч, әни, йөзлек кырыена утырып, моңсу гына битен сыйпады.)

Инде иген-тарулар дип әйтеп әйткәндә, анысының куанырлыгы юк икән. Арыш белән арпа, бик үк дан булмасалар да, шулай да ачка үләрлек үк түгел. Әмма бодай белән солы бер дә куандырмаган. Борчак дигәннәре орлыгын гына кайтарган, карабодайны инде анысын әйтәсе дә юк: чәчәктә утырганда ук эссе куырган. Шулай итеп шул, бәйрәм-сәйрәм, кунак-төшем булганда, Кибәхуҗа кешесенә газиз кунакларны карабодай коймаклары белән сыйлаулар быелга насыйп булмыйрак тора икән әле.

Бер алдын күрсәтсә, биш артын күрсәтеп, гел айкалып кына тора дөньялары. Әле игеннәр уңмый, әле терлек үләте килеп баса. Тамакны туйдырырга кирәк, өс-башка, чәй-шикәргә янә дә кирәк. Ул инде имана түләтеп җан-бәгырьләргә төшүләрен әйтеп тә тормыйсың. Каян алырга, нишләргә? Ярты авыл тегүгә чыгып китә. Кайсыберсе, озын очка ялгый алмыйча, башын ташка орырдай булып йөри-йөри дә, өен бикләп, бөтенләй әллә кай җәһәннәмгә олага. Я күмергә анда, я Себергә. Тик әйтәләр бит: «Кая гына барсаң да, кара сакалың үзеңнән калмый», дип... Менә шулай инде Кибәхуҗа хәлләре, тәтәй генәм...

Таллыклар арасыннан чылтырап аккан инеш кебек, ашыкмыйча гына, тирбәлә-тирбәлә генә аккан бу татлы әңгәмә шулай да бер заман

тына. Кунак кызыбыз, көн урталары житкәндә, битен янадан юып, киенеп-ясанырга тотына. Озак та үтми, ул я апай, я әни белән, зур урамнан, буй-сын күрсәтеп, туган-тумачаларга чәйгә барып кайта. Я берәрсе аны каз өмәсенә дәшә.

Ул килгәннән бирле абый гел яңа күлмәк, яңа чалбарларын киеп, елмаеп кына йөри. Карап торганым бар: чыгар-чыкмас мыек сыман нәрсәсен ничә тапкыр көзге алдында сыпыргалап карады.

Кунак кыз килгәннән бирле ишек белән капкага да тынгылык бетте, һич кенә ябылып тормыйлар. Кичкә керсәң, тәрәзә тирәсендә гел кыштыр-мыштыр егетләр кайнаша.

Инде кояш бераз гына кичкә авыштымы, китә киенү-ясану, кичке су китерүләргә хәстәрләнү. Бер кереп, бер чыгып, тыз да быз күрше кызлары кайнаша башлый. Кузгала пышылдаулар, чыркылдаулар, китә дәртләнеп нидер көтү, нидер өмет итү, киңәш-табыш итү.

— Кайсы күлмәгеңне киясең? Башыңа нәрсә ябасың?

— Карале, кызлар! Ак катамны кисәм килешерме, әллә карасын киимме?..

Шул арада бер-берсенең колакларына үрелеп нидер пышылдап алалар, нәрсәгәдер ымлап берсенә-берсе күз кысалар. Ул да булмый, кесәләреннән ат күзе тикле генә көзгеләрен чыгарып, кершән ягына, сөрмә тарта башлыйлар...

## II

Шул көннәрдә күрше Гыйльми түтиләргә кергән идем. Аның улы, зурлар күрмәгән арада, кече яктан мине үз янына чакырды. Барсам да бардым, бармасам да. Бармас идең, яхшы түгел, хәтере калыр. Ни дисәң дә, күрше бит. Барсаң, бик тә имәнеч. Фазулланың муеннары, күкрәкләре, тамак аслары — бөтен җире бәйләүле. Үзе коточкыч ябык. Озынча күкшел битендә кан әсәре калмаган, күзләренә әллә сары йөгергән шунда, әллә нинди...

Фазулланы ниндидер «тамыр чире» белән авырый дип әйтәләр. Ул почмак яктан чыкмый, бүтәннәр белән бер табынга утырмый. Анасы Гыйльми түти, чит кеше керә башласа, кечкенә якның ишегендәге чаршавын хәзер тартып куя. Гыйльми түтинең үзенең дә әйткәне бар:

— Арча больнисенә алмыйлар. Казанга алып барырга хәлебез житми. Япь-яшь көенчә шушы почмакта сунә инде, балакаем...

Фазулла бу йортта тумаган. Гыйльми түтинең артыннан ияреп килгән малае. Бәлки, аны бик тырышып кайгыртучы да юктыр?

Сорый Фазулла миннән шыпыртлап:

— Хат башы ясый беләсеңме?

— Ник белмәскә?

— Чынкый матур итепме?

— Соң инде! Өске ягын дугалап, чәчәкләрен буйдан буйга яшел, зәңгәр, кызылларга буяп.

— Миңа берне ясап бирче, бик матурлап. Мин сиңа гармун кычкыртырга бирермен.

Ул бер кулын янында гына торган гармунына куйды.

Мин үзем сөялгән бүлмә тактасын тырнаштыра башладым. Эшем күп бит. Озакламыйча ат эчертеп менәсе, төнлеккә терлекләрнең ашарларына саласы, учакка утын, бәрәннәргә юка себеркесе кертәсе бар. Аннары әни кушкан йомышлар да бетәсе түгел: аръякның Чтапан кибетеннән коймакка күй мае, бер кадак клиндер, бер чирек чәй, бер әчмүхә йөзем җимеше, бер шешә крачин алып менәргә кирәк...

Мин риза булмый торгач, Фазулла баш астыннан чиккән янчык чыгарды, озын, ябык бармаклары белән аның төбеннән алып алтын төсле ялтырап торган өч тиенлек өр-яңа бакыр күрсәтте.

Кунак кыз белән эни чәйгә киткән арада, мин, җәзбә[1] белән сызып, карандашлар белән төрле төскә буяп, хат башын ясап та алдым. Дугайланып төшкән түгәрәк өсле матур капка сыман килеп чыкты. Аның өстенә һәр баганалары буйлап төрле төстәге түгәрәкләр, чәчәкләр тезелеп китте.

Фазулла хат башын әйләндерә-әйләндерә карады да янадан миңа сузды.

— Буш урыннарына язып та бир инде.

— Нәрсә языйм?

Фазулла, кинәт салкын суга килеп төшкәндәй, беравык авызын ачып сүзен әйтә алмыйча торды. Аннары күм-күк иреннәрен кыймылдатыр-кыймылдатмас пышылдап куйды:

— Кызлар хаты!

— Ә?? Нәрсә?!

Менә сиңа, мә! Нишләмәкче була бу? Аңардан кем хурланмыйча хат алсын?! Исем китеп йөзенә текәлдем. Ияк очында ике-өч сакал бөртеге тырпаеп тора. Муены чебешнеке шикелле нәп-нәзек, күзләре сабый балаларныкы төсле кыенсынып, куркынып карыйлар. Сакаллы сабый шундый буламы икән әллә?

Фазулла миңа таба иелде. Аның күгәргән иреннәре бөрешеп килде:

— Минем көннәрем санаулы, санаулы! Күрмисеңмени? Мин күпкә түзә алмыйм, үләм. Быел булмаса, яренгә. Егет көе үләм бит, егет көе! Төшенәсеңме син шуны? Минем кордашларымның балалары бар, ә минем кызларның кулларын да тотканым юк. Бер тапкыр да! Миңа атап, үземә әйткән бер генә сүзләрен дә ишеткәнем юк! Гел чирле, чирләшкә! Менә бит!..

Әллә чын булды, әллә ялгыш кына күренде, Фазулланың күзләрендә ачу очкыннары чәчрәп китте түгелме икән?

Баш тартырга көчем җитмәде:

— Кемгә язарга соң? — дидем.

— Теләсәң кемгә! Миңа хат кына булсын. Кемгә булса да барыбер. — Ул бераз уйланып торды да тагын әйтеп куйды: — Яз үзегезгә килгән кунак кызга! Минем үлгәнче бер хат аласым килә. Бер генә сүзле булса да! Бер генә тапкыр булса да! Тик кызлар кулыннан гына чыккан булсын.

Мин ул хатны яздым. Кечкенә яктагы су кисмәге өстенә куеп яздым. Аның сүзләрен, бер кулын гармуны өстенә куеп, артындагы мендәр-ястыкларга сөялгән килеш, башыннан ахырына кадәр Фазулла үзе әйтеп торды:

— «Әлхат, нисфелмәлакат»[2]. Сагынып яздым син җаныйга сәлам хат. Кабул күрсәң, укып бак, кабул күрмәсәң, ертып утка як. И җанымның җаны, йөрәгемнең пәрәсе, ике күзем карасы, һавадагы йолдызым, судагы кондызым — сиңа яздым бу хатны.

Тал чыбыктай зифа буйларың, камыштай бармакларың, көмештәй тырнакларың, карлыгач канатыдай сызылып киткән кара кашларың, шомырттай кара күзләрең, тулган ай төсле балкып торган йөзләрең, бөрлегәндәй кызыл иреннәрең, энҗе күк тезелеп киткән тешләрең, шул тешләрең арасыннан сандугач күк сайрап торган телләрең, балдин татлы сүзләрең — сиңа яздым бу хатны.

Энҗе күк тезеп, ефәк күк сузып, һавадагы йолдызлар, судагы кондызлар санынча, сиңа чукдин чук, күпдин күп сагынычлы сәламнәремне күндерәм...»

Шулай тезеп киттек-киттек тә ахырын, хат нинди дә булса хәвеф-

[1] Җәзбә — циркуль.

[2] Әлхат, нисфелмәлакат — хат язышу — ярты кавышу.

хәтәргә юлыкмасын өчен, «кыйтмир»[1] дигән тылсымлы сүзләр яздык, «бәдух» белән тәмамладык.

Бу хатны мин, аулак урында туры китереп, кунак кызга бирергә тиеш идем. Ләкин, ярый әле, вакытында тыелып калганмын.

Җавап хатны үзем язармын да, кунак кыз киткәч, аныкы итеп бирермен дигән уйга килдем. Шулай да Фазулланың бүтән үтенечләрен әйтмичә булдыра алмадым.

— Озакламый үләсе егет инде ул, апай, — дидем. — Яшь-яшь килеш бит. Бик кызганыч. Су китергәндә аларга да бирәр көянтә су китереп чыкмасларны дигән иде.

— Ай, энекәем, килешмәс ич ул. Анысы ни эшкә соң?

— Ерактан гына булса да күрәсе киләдер инде.

Кунак кызым борчылып ни әйтергә белми торды.

— Ай, Гомәр генәм! Кеше теленә кереп хур булсам, нихәлләр итәрмен?

Ул заманда «вәгъдә — иман» диләр иде. Минем вәгъдәгә хыянәт итәсем килмәде.

— Алайса кызлар су кертеп бушатканда, син ишек алдында гына торып торырсың, бәлки?

— Барыбер инде ул, җаным. Барыбер кергән атың чыга!

— Актык сүзен дә әйтим инде, апай! «Су кертмәсәләр, безнең өй түреннән үткәндә, ичмасам, тәрәзәгә генә карап алмасмы икән?» — дип тә ялынды.

Кунак кызым кинәт башын иеп битен каплады да йөгереп түбән өйгә төшеп китте.

## III

Менә көн кичкә авышты. Инеш буйларына үзенә бертөрле йомшак кына зәңгәрсу әңгер иңә башлады.

Тыкрыктагы борылмалы сукмактан, кыр казлары шикелле, берсе артыннан берсе тезелеп, чуп-чуар кызлар төркеме килеп чыга. Иң алда, билгеле, кунак кыз. Аның артыннан чибәррәк, чаярак, өлкәнрәкләре, иң арттан, зур атларга ияргән кырыкмышлар шикеллерәк, бөтенләй яшь кызлар. И чибәр киенгәннәр дә инде! Бигрәк тә кунак кыз. Башында кәшимир шәл, өстендә иңбашлары күпертмәле зәңгәр жикет, аягында сай гына кунычлы ак киез ката. Аның йөзен яшелле-зәңгәрле, аллы-бишниле дебеттән ясалган чәчәк сыман нәрсә матурлап тора.

Бүтән кызлар һәммәсе дә көянтә башларына бирәр, икешәр каз элгәннәр, ә кунак кызның куллары буш. Ул бәрән йонынынан гына бәйләнгән нечкә челтәр куныйчлы ап-ак пирчәткәсенең бармак очлары белән генә авызын каплаган. Күпереп торган сыек зәңгәр күлмәгенең итәкләре карга тиеп керләнмәсен дипме, әллә үзенә шулай килешлерәк тоелгангамы, сул кулы белән аз гына күлмәк итәген күтәргән. Вак-вак кына, чеметтереп кенә атлап, буен-сынын матур гына уйнатып төшеп килә, агай, без күзләребезне ала алмас булдык.

Башка кызларның да өсләрендә гел яңа күлмәк белән кешелеккә генә киелә торган яхшы бишмәт, я жикет, башларына күзеннең явын алырдай аллы-яшелле шәлләр бөркәнгәннәр. Исең китмәле!

— И малайлар, туктале! Безнең апайларны соң болар?!

— Шулар булмыйча тагын? Егетләр карап торганга шулай кая басарларын белмиләр алар.

Күпер төбендә җыелган егетләр башта тынып калалар, аннары җырлап җибәрәләр:

Өй түрендә бөдрә таллар
Иелә җил-давылга;

[1] Кыйтмир — изгеләрне саклаучы «изге» эт (дини).

Зифа буйлы кунак кызлар
Килгэн безнең авылга.

Без, малайлар, тау кырыеннан мэтэлэ-шуа, йомшак карга манчылып, чишмэ тирэсенэ тэгэрибез.

Кунак кыз, шэл яулыгын алгарак тартып, битен кулэгэлэп куйган. Кызларның берничэсе чишмэнең җиң юанлыгы булып аккан салкын суында каз тушкэлэре юарга тотынган. Бутэннэре кунак кызны уртагарак алганнар да егетлэр белэн суз көрэштерэлэр. Кем кемне ныграк тешли, кем кемнэн усалрак көлэ!

Менэ аргы яктан, гармун тартып, быел солдатка алынасы никрутлар килеп төште. Алар эллэ бераз кызмачарак шунда, эллэ никрутка шулай тиешле булганга, атлыга да, җэяулегэ дэ юл сапмыйча, урамның нэкъ уртасыннан килэлэр; бераз сатай-матайрак атлыйлар, ара-тирэ кулларын болгап, кычкыргалап та куялар.

Алар арасында юка гына булып кара мыек чыгып килэ торган, җыйнак кына гэудэле безнең абый да бар иде. Никрут булып йөри башлагач, эги аңа ак шарф белэн соры билбау алып биргэн иде. Билбавын бөтен иңенэ җэеп бэйлэгэн дэ шарфын муенына урап, очларын кыеклатып билбавына кыстырган.

Башка вакытта куп сөйлэшми торган иде. Хэзер ул эллэ кайдан ук авызын ера килеп, кызларга суз куштыз:

— Нихэл сездэ? Куллар туңдырып, мин эйтэм, казлар юасыз икэн!

Сэхипҗамалның теленэ шайтан төкергэн. Ул казын чишмэ суында арлы-бирле эйлэндерэ бирэ, узе такылдый бирэ:

— Эйе генэм, курше абый, менэ сыер савып ятам эле!

— Ай-яй, сыерың сөтне мул бирэ!

— Үзем дэ шуны эйтэм лэбаса! Казыбыз зерэ дэ симез чыкты, эче тулы май гына, сөяклэре шалтыр-шолтыр килэ.

Боларның шаяруын бер нечкэрэ, бер калыная торган керделе-чыктылы сэер тавышы белэн Сэлим булдерде:

— Туктале, сез арбан-тарбан эллэ кайларда чуалмагыз! Аны эйт тэ моны эйт, кич утырырга кертэсезме? Энэ анда кояш байый, кич була!

Кызлар өчен тагын элеге шул Сэхипҗамал эйтте:

— Кояш көн саен байый инде ул, беркайчан да Бишна урманына элэгеп калганы юк.

— Менэ безне кертмэсэгез, элэгеп тэ калыр, аллагыз да орыр!

— Юк, орып-нитеп тормас, куктэге эшлэрен ташлап, монда ук борынын сузмас. Алланың андагы эшлэре дэ, менэ минеке шикелле, кырыгы кырык җирдэ кым-кырыч килеп, кырылып ятадыр эле.

Төрле яктан шелтэле эндэшлэр ишетелде:

— Я инде, син тагын бигрэк!

— Картлар ишетсэ!..

— Ишетмэгэйлэре тагын! Куз курер өчен, колак ишетер өчен бирелгэн!

Казларны юып келэт киштэсенэ менгереп элгэннэн соң, кызлар эре көмеш чэчэклэр төшерелгэн яшел, зэңгэр чилэклэр белэн чишмэгэ су алырга төшэлэр. Китэ шуннан су ташу! Дурт тапкыр да, биш тэ, эллэ ничэ дэ төшэлэр. Өйдэге савытлар тулгач, мунча казанына, ул да тулгач, ат улакларына, сыер тагаракларына ташыйлар. Анда да салыр урын калмагач, куршедэге карчык-корыны, өлкэнрэк яшьтэге җиңгилэрне су белэн кумэлэр.

Купер төбендэге егетлэр һаман уйный да җырлый. Яннарыннан узган саен кызларга берэр шаян суз эйтеп, булмаса, куз кысып, каш сикертеп калалар.

## IV

Мин Фазуллаларга йөгердем. Нишләрләр икән, керерләрме икән кызлар, юкмы икән?

Фазулла өстенә өр-яңа зәңгәр сатин күлмәк, башына кара хәтфә кәләпүш кигән. Чәчен дә тарап җибәргән. Аның ягыннан мул булып исләмәй исе аңкып тора. Ишек ачылуга, әсәрләнеп миңа текәлде:

— Кермиләрме әле, юкмы?

Мин ике төрлерәк аңларлык итеп башымны селектем.

Гыйльми түти өйнең ике ягын да бик пөхтәләп җыештырып куйган. Түр яктагы мендәр-ястыклар өстенә бик матур чиккән япма каплаган. Үзе яхшы күлмәкләрен киеп, башына ак яулык япкан. Ул яшь килен төшерәсе каенанай кебек дулкынлана. Әле улының алдына япкан чуар юрганын, мендәрләрен төзәткәләп чыга, әле кече якның ишегенә элгән алсу эре чәчәкле чаршауны киңәйтебрәк ачып куя. Гыйльми түтинең йөзендә сүз белән генә әйтеп бетерүе мөмкин булмаган тирән хәсрәт һәм моң күләгәсе бар. Авыру улының тыштагы аяк тавышларын нинди омтылып, күзләрен нинди зур ачып, нинди дулкынланып тыңлавына күз салганда, аның авыз читләре бозыла башлый, ул күз яшьләрен көч-хәл белән генә тыеп кала иде.

Янымнан узышлый колагыма пышылдады:

— Ярабби, күңелләренә мәрхәмәтләр салып, кереп кенә чыксаларчы! Керә алмасалар, бигрәк тә нәүмиз була инде!..

Минем тамак төбем әллә нишләп куйды. Менә бит... Аңа кунак кыз сүзләрен ничек әйтим? Телем үзеннән-үзе бөтенләй бүтәнне тезәргә тотынды:

— Әйттем, Гыйльми түти, әйттем. Керми калмаслар, Гыйльми түти, тәгаен керерләр!..

Менә урамга шәфәкъ нуры иңә башлаганда, тыкрыкта бик күп аяк тавышлары шыгырдарга тотынды. Ул да түгел, капка ачылып китте, ишек алдына кызлар тавышы кереп тулды.

Фазулла тетрәнеп китте:

— Әни, утны яндыр!

Гыйльми түти кабаланып кучкардагы утырма лампага ут кабызганда, өйгә чиләк-көянтәләре белән берсе артыннан берсе биш-алты кыз кереп тә җитте. Алар белән бергә салкын саф һавага кушылып, яңа кием-салым исе, иннек-кершән исе килеп керде.

Кызлар һәммәсе берьюлы көр тавыш белән хәл белергә тотындылар:

— Исәнмесез, саумы сез?

— Әйбәт кенә торасызмы?

— Гыйльми түти! Шунда берочтан сине дә сулы итик дип йөрүебез инде бу!

Гыйльми түти, нишләргә белмичә, каушап арлы-бирле килде:

— И оланнар!Ниләр генә әйтим?! Нинди изгелекләр белән генә кайтарыйм?!

Авыл кызлары шаулап сөйләшә-көлешә су бушаткан арада, кунак кыз, кыюсызланып кына, почмак якка борылды. Кибәхуҗаларча ягымлы гына көйли төшеп, бәгырьләрне эретеп җибәрердәй йомшак тавыш белән, Фазуллага дәште:

— Нихәлләрең бар соң, Фазулла абый? Ходаем, шулай сырхаулап торасыңмыни? Менә син, ә? Тизрәк сихәтләнә күр инде!..

Почмак яктан җавап булмагач, мин, «Фазуллага берәр хәл булдымы икән әллә?» дип, чаршау кырыеннан эчкә күз салдым. Фазулла зур булып ачылган, тирәли зәңгәрләнеп торган коточкыч күзләре белән йотардай, суырып алырдай булып кунак кызның алсу битенә, зифа буй-сынына текәлгән дә катып калган. Аның кансыз иреннәре өзлек-

сез кыймылдый, әмма тавышы чыкмый. Хәзер тагын да озынаеп киткән ябык йөзендә гаҗәпләнүме, сокланумы, каушаумы билгесе булып, әллә еламсырау, әллә көлемсерәү шәүләләре уйный.

Өй эче тып-тын. Кызлар, кыенсынып, кайсы тәрәзәгә борылды, кайсылары пирчәткәләрен кияргә тотындылар.

Кунак кыз, почмак якка текәлгән килеш, бер сүз әйтә алмастан, арты белән чигенде-чигенде дә кинәт өй алдына чыкты һәм битен каплап инрәп куйды.

— Абау, ходаем, күзләре!..

Фазулланың шунда гына теле ачылды. Кызлар чыгып киткәнче әйтми калмагаем дигәндәй, каударланып:

— Әт-тә-тә! Менә бит, ә! Эээ, рәхмәт төшкерләре! — дип куйды.

## Кара урман, караңгы төн

### I

Мин авылдан чыкканда, кояш баеган, урман юлында куна баручы бер генә җайдак та күренми, һәммәсе китеп беткәннәр иде. Әти базардан шактый ук кызу кайткандыр, күрәсең, кара байталдан әчкелтем тир исе бөркелеп тора. Шуңа карамастан, ул, бер дә кудыртмыйча, ашыга-ашыга, үрчемле итеп атлый. Аланга барып җиткәч тәмле үлән ашыйсын, рәхәтләнеп ял итәсен алдан ук сизә хайван.

Әни минем арттан борчылып калды:

— Караңгыга каласың лабаса! Чүнник турысыннан ничек узарсың? Уч иткәндәй, болытлары да куерып тора тагын.

Тик әтинең генә исе китмәде:

— Ярар, бик нечкәртеп маташма. Беренче баруы түгел.

Әни белә ул. Бөтен курыкканым да шул — чүнник янынан үтү. Ул тирәләрдә өрәк шаяра дип сөйлиләр. Берәүләргә ап-ак кәфен бөркәнеп, икенче берәүләргә кара мәче булып чыга, ди. Кайчакларны ул үзе бөтенләй күренми дә икән. Тик шул турыга җиттеңме, атың, арбасын тарта алмыйча, кара тиргә бата, камыт баулары өзелә, тәртәң сына, ди.

Әллә кайчангысы анысы чәнчелеп китсен, анысына ышанмас та идең. Менә бит әле шушы араларда гына булып узган хәл. Аргы якның Сәйфулла, тарантас җигеп, Кибәхуҗага кунак алырга дип чыгып киткән. Урман авызына килеп керсә, каршысында өрәк! Инде нишләргә? Дога укыйсы да бит — булмый, ник бер генә сүзе искә килсен! Атны борып кирегә чабар иде, кул-аяк эшләми, көзән җыергандагы шикелле тартышкан да каткан. Сәйфулланың аты алай тартылган, болай сугылган, шул тирәдән узып китә алмыйча, манма тиргә баткан. Ахырында, бөтенесен ватып-җимереп, тарантасын аударып, кирегә борылып чапкан. Шуннан бирле Сәйфулла урын хастасына әйләнде.

Хәтәр урынны караңгы куерып җиткәнче үтим ди-ди, атны кудым да кудым. Менә Ышна тавын мендем, Марҗа елгасын да чыктым. Мин ашыгам, караңгы миннән дә бигрәк ашыга. Мин урман авызыннан кергәндә, күз бәйләнеп өлгергән иде инде. Барасы юл бик аз гына шәйләнә.

Шулай тын да алмыйча барам, ялт та йолт як-ягыма каранам. Менә нәрсәдер кытыршы куллары белән битемне сыпырды, сискәндереп муенымны кытыклап алды, нәрсәдер бүркемә сузылды. Котым чыгып ат өстенә сендем. Бөтен ышаныч атта, атта! Юлның як-ягында әллә нәрсәләр кыштырдый, аяк тавышлары килә, чатыр-чотыр куаклар сына. Әйтерсең, янда гына нәрсәдер миңа ташланырга чамалап бара. Шыпырт кына тезгенне тарттым. Ат туктауга, куак арасындагы тавышлар

да тынды. Кузгалып кына киткән идем, тагын шатыр-шотыр куакларны сындырып бара башлады.

Сул кулым белән чытырдатып атның ялына ябыштым, уң кулымда каеш камчы. Ул-бу күренсә, биягә бик каты берне сыдырырга да алып-биреп чабарга исәп. Анда инде ни булса да була! Мескен ат та бик курыкты. Берәр нәрсә кыштырдаган, я кош-мазар чыелдаган саен кинәт дерелдәп китә. Шулай да ул минем хәлне дә аңлый иде шикелле. «Тавыш чыгармагаем» дигәндәй, сагаеп кына атлый.

Бара торгач, атым кинәт бөтен гәүдәсе белән куырылып куйды да, колакларын шәмәртеп, баскан урынында катып калды. Карасам, алдарак бер соры нәрсә кыймылдый. Җан-фәрманга кизәнеп атка сугып җибәрсәм, теге соры гәүдә кеше тавышы белән дәшмәсенме!

— Чү, улым! Рәнҗетмә хайванны!

Үз колагыма үзем ышанмыйм. Сабит абзый тавышы түгелме соң бу? Ул арада күрше карты атның муенын сыйпап алырга да, минем кем малае икәнемне белергә дә өлгерде.

— Болай сукма, улым, атыңа! Караңгы лабаса! Агачка бәрелеп имгәнүең бар.

Минем иреннәрем сәер генә булып дер-дер киләләр иде.

— М-м-малайлар янына ти-тизрәк барып җитәсе иде дә...

— Җитәрсең, җитәрсең! Малайларың беркая да китмәс, әнә генә алар!

Умартачы картка нәрсә аңа? Исе дә китми! Авыл урамыннан атлыймыни! Йөткергәләп, кыштыр-кыштыр барды-барды да күренмәс тә булды.

Бераз гына киткән идек, алан ягыннан челтер дә челтер кыңгырау, шөлдер тавышлары ишетелә, агачлар арасыннан бүрек хәтле генә булып учак утлары күренә башлады. Кара биям үзалдына дәртләнеп, пошкырып куйды, башын чайкый-чайкый барды да, гайрәтләнеп, жирсенеп бер кешнәп җибәрде.

Агачлар куелыгыннан чыгуга, биткә җил үк түгел, юк, аланның җылымса коры сулышы, мең төрле чәчәкләр хуш исе белән төнәртелгән җылы һәм коры алан һавасы килеп бәрелде.

Мин көрсенеп куйдым. Өрәк чыккан булса, куркыныч инде дә. Шулай да кызык буласы иде... Менә хәзер малайларга сөйләрлек бер яңалык та юк бит.

## II

Малайлар учакны шәп итеп якканнар. Ара-тирә учак тирәсендә утыручыларның йөзләренә, бөтен гәүдәләренә ниндидер серле кызгылт нур сибелә. Иксез-чиксез төн караңгысында, учак яктысы үзенә күрә бер кызгылт утрау булып, әкиятләрдәге төсле серле булып күренә. Анда утыручылар да кеше аягы басмаган караңгы урманда каяндыр юл кисеп, мал басып кайткан юлбасарларны хәтерләтәләр иде.

Атымны учак яктысынарак китереп тышауладым да, мин дә малайлар арасына чүгәләдем.

Түгәрәкнең теге ягында ут аша иң элек Әхәт абый күземә чалынды. Ул миңа сөйкемле генә итеп бер күз сирпеп алдымы, әллә шулай күренде генәме, өзеп әйтә алмыйм. Малайлар мине «кайнеш» тә «кайнеш» дип әллә кайчаннан бирле үртиләр. Бик исем китә! Үзләренең шундый чибәр апайлары булмаганга көнләшеп кенә тел озайталар алар.

Минем янда гына, моңсу күзләрен йолдызларга текәп, Тургай Әхмәт кырын ята. Ул анасы үлгәннән бирле гел шулай хәллерәк кешеләргә ялланып эшли. Менә бүген дә Бикбулатлар атын алып килгән.

— Соңга калдың. Өрәк кумадымы? — ди.

Минем зур апаемның өлкән улы Закир абый кайдадыр юешләнгән

оекларын киптереп утыра иде. Әллә чынлап, әллә юри генә минем салпы якка сәлам кыстырырга тотынды.

— Шәкерт кеше ич ул Гумәр, дога укыгандыр.

— Төкерә өрәк синең догаңа!

— Ул төштә миңа Сабит абзый очрады... — дидем.

Әхмәт ышанмады. Миңа күзен елт-елт йомып сәер итеп карады.

— Әйттең сүз! Йөрер Сабит абзаң төнката! Ул әллә кайчан борынын сызгыртып йоклап ята инде.

— Түгел инде, әле генә яныбмнан узды. Билләһи менә! Өстендә казаки, башында ак эшләпә.

Безнең күрше Хисам абый нәрсәдер уйланып торды да:

— Ә-ә-ә, белдем! — дип куйды. — Гумәр, син ничәдә әле?

— Кыш көне унны тутырдым.

— Менә шул инде алайса! Ул сабый балаларга тими, ди. Шуңа күрә дә Сабит карт булып күренгән инде ул.

Мин эсселе-суыклы булып киттем. Әйтәм аны, җир астыннан чыккандай, кинәт кенә каршыма килеп басты! Сөйләшүе дә әллә нинди, йокымсыраган кешенеке шикелле, сәп-сәер иде түгелме соң?..

Сәлим абый көлгә күмгән бәрәңгесен актарып утыра иде. Ул шигәеп урман ягына карап алды да, миңа таба иелеп, өрәк үзе ишетә күрмәсен дигәндәй, шыпыртлап кына сорап куйды:

— Карале, син искәрдеңме? Эзе бар идеме Сабит дигәнеңнең? Өрәкнең эзе булмый ди бит!

Бөтенесе көлешеп алдылар.

— Син тагын бигрәк... Бу караңгыда аның эзен карап торсынмыни?

Әхәт абый Сәлимгә кырын күзе белән генә карап алды да читкә төкерде.

Мин урын бушаганны көтеп алдым да, бәрәңгемне очкынланып торган кайнар көлгә күмеп, өстенә коры ботаклар өстәдем. Учак кызыллы-сарылы ялкынын әле бер якка, әле икенче якка селти, битләрне ялап алырга чамалый, күзгә ачы төтенен җибәрә.

Атларның ачыкканнары, бигрәк тә колынлы байталлар, учактан әллә ни ерак итмичә, якын-тирәдә генә утлыйлар. Җитезрәк һәм комсызраклары ераккарак та китеп өлгергәннәр. Аланның төрле ягыннан аларның дөп тә дөп сикергәне, аякларындагы богаулар чылтырап куюы, ара-тирә пошкырып алулары, берсеннән-берсе көнләшеп, ашыга-ашыга керт тә керт үлән кимерүләре ишетелеп тора. Кайберләре, шушы киң аланга да сыеша алмыйча, берсен берсе куарга, тешләшергә тотыналар, бик яман чинашып, тибешеп алалар. Андый чакта учак яныннан олыракларның берәрсе кузгалып, сукрана-сукрана шул якка таба китә.

— Һи, үләт себергерләре! Нәрсә җитми тагын сезгә?!

Малайлар һәм егетләрнең кайсыберсе бәрәңге ашап утыра, бүтәннәре кырын яткан, утырган. Тәмләп кенә, ашыкмыйча гына күргән-белгәннәр, имеш-мимешләр, урмандагы төрле әкәмәтләр турында сөйләшәләр.

Безнең урман бик калын да, зур да икән. Ул Яңилгә таба сузылып бара да, аннан Мишә буена төшеп, тагын барып-барып, Идел ярларындагы урманнарга ук тоташа икән. Кеше аягы басмый торган караңгы урыннарында усал-унтагай да, юлбасарлар да яшеренеп ята, аю-бүре дә бетәсе түгел, ди.

Әхмәт, күзләрен елтыратып, урманга таба каранып алды:

— Шүрәле дә бар диме?

Олыраклар әйтәсе урынга, минем белән бергә мәдрәсәдә укыган Шәйхел чәчрәп чыкты:

— Бар, ди, бар, ди. Менә мондый озын бармаклы, менә мондый мөгезле!

— Кем күргән? — диде Әхмәт. — Әнә Кырлай урманында дисән, ичмасам, анда бар да бар инде. Шулай дип Тукай Габдулласы китапка да язган.

Сәлим аягын бөкләп учакка каршы утырган да шырпы тартмасыннан тоз сибә-сибә, авызын чапылдатып, бәрәңге ашый, үзе тыгыла-тыгыла өзлексез сөйләнә:

— Бар, жаныкайларым, барысы да бар. Шүрәлесе дә, өрәге дә. Бу тирә дә тыныч түгел бит! Әнә Сабит булып Гумәргә дә чыккан бит әле.

Мин сагаеп кына килгән ягыма күз салдым. Менә сиңа, мә!

— Исән чакта да халыкның үзәгенә үткән. Өрәк булып та азаплый!

— Анысы явызлыкка явыз булган инде, миһербансыз.

— Кая миһербансыз гына, кансыз! Ничек кенә иза чиктермәгән ул халыкны! Перкәшшек урманына җиләккә барма, чикләвеккә йөрмә! Штубы чыбыркы сабы да сындырып аласы булма! Һе, анасын эт ялаган нәрсә!

Сәлим абый сыек зәңгәр күзләрен елтыратып, ашыгыч кына битен сыйпагандай итте:

— Аның каравы, үзеннән дә ачуны алганнар. Үтереп кырмыска оясына салганнар!

— Шул кирәк тә! Син соң халыктан үч алмаганнар дисеңмени? Шул бер исерек струйлек[1] өчен алпавыт ничә кешене Себер җибәрттерде! Нинди асыл кешеләр катырда череде!

Мондый куркынычлар турында сөйләгәндә малайларның минем ише кечкенәрәкләре куркып кына караңгы урман ягына карап алалар. Агач башларында ара-тирә кошлар чутылдап куя. Урман куелыгында, кайдадыр эчтәрәк, «уһу-һу, һу-һу» дип ябалак зарлануы яңгырап китә. Әмма урманның иң куркыныч, иң серле төше өстә түгел, астагы караңгы куелыгында иде бугай. Ник дисәң, кайчакларны, учак янында тынып торганда, аннан ботак сынган, нәрсәләрдер кыштырдаган, авыр итеп мышнаган тавышлар ишетелгәндәй була. Икенче карыйсың, куаклар төбендә, я агачлар арасында нидер елтыр-елтыр итә, бер сүнгәндәй була да тагын күренеп кала. Кем белә, бәлки шүрәле күзедер ул? Агачларга ышыкланып, бәлки безнең берәребез белән «кети-кети» уйнарга кызыгып торадыр...

Урман үзе дә бик серле, сөйләгәннәре дә куркыныч. Тик безнең барыбер тыңлыйсы килә. Колагым гәпләшүчеләрне тыңлый, күзләрем учакта. Бәрәңге өстендәге көл су шикелле агып төшә, аның әле бер, әле икенче җиреннән «пыш» иттереп кайнар сулыш бәреп чыга. Монысы, көл астындагы кайнарга түзә алмыйча, «пуф» та «пуф» итеп бәрәңгенең сулыш алуы инде.

Әхмәт, минем бәрәңгемдә һич эше булмагандай, ваемсыз гына итеп:

— Пешкән инде бәрәңгең! Исе чыкты. Ышанмыйсыңмы? Әнә, чыбык очы белән тишеп кара, — диде.

— Беләм. Ул бит беравык кына, бер чынаяк чәй эчәрлек кенә артык тотарга түзә алсаң, кетердәп, бигрәк тә тәмле булып пешә.

Менә бәрәңгене берәм-берәм чирәмгә тәгәрәтә башладым. Аягымны бөкләп утырдым да, кулымны пешерә-пешерә, учымда әвәләргә тотындым. Көя язып каралган кабыгы астыннан иң тәмлесе — алсуланып торган юка гына кетердәвеге килеп чыкты. Хуш исе тагын! Урталай сындырып чеметеп кенә тоз сибәсең. Авыздан сулар килә, кулны пешерә, өрә-өрә суытасың...

Әхмәт бүрек эчендә парланып яткан эре-эре бәрәңгеләргә яны белән борылып, читкә таба карап утырды да малайлар белән сөйләшә башлады. Үги анасының Әхмәтне «Үз тамагыңны үзең туйдыр!» дип,

[1] Струйлек — стрелок, урман каравылчысы.

күрше авылга хәер соранырга куып җибәрүен дә, Әхмәтнең моңа бик хурлануын да белеп торабыз. Ләкин без Әхмәтнең үги анасыннан зарланганын беркайчан да ишетмәдек. Хәер соранырга йөрүен ул беркемгә дә сиздермәскә тырыша, юлда очратсаң, «Эш эзләдем...» дип җавап бирә торган иде.

Шулай читкә карап утыра торгач, Әхмәт сүз арасында:

— Нәрсә тәмлерәк? Бәрәңгеме, әллә күкәйме? — дип сорады.

Мин:

— Бәрәңге, — дидем.

— Булыр инде, һе, бәрәңге...

Әмма бераз гына утырды да тагын сорамыйча түзә алмады:

— Кайсы тәмлерәк? Ит калҗасымы, коймакмы?

Мин тагын:

— Бәрәңге! — дидем.

— Китсәнә аннан! Безнең әни аны чүлмәк белән сөттә пешерә торган иде. Менә ул тәмле, ичмасам!

Мин аңа да бәрәңге суздым. Ләкин Әхмәт алмады. Юри читкәрәк китеп утырды.

— Юк, мин бит болай, әни искә төшкәнгә күрә генә әйтәм...

## III

Кичнең байтак вакыты узгач, аланның аргы башында дөп-дөп сикереп ат чапкан тавыш ишетелде. Хисам абый нечкә муенын сузып, гүя, күрергә теләгәндәй, шул якка текәлде.

— Атларны бүре-мазар кумый торгандыр бит?

Закир абый дөпелдәгән тавышка бераз колак салып утырды да башын чайкады:

— Юк, иясез ат түгел бу, җайдак булырга охшый, — диде.

Озак та үтмәде, Каенлык ягыннан бер карамчык күренде. Ул аргы якның Сәлмән дигән кара мыеклы чибәр егет булып чыкты. Үзе ялан баш, күлмәк изүен чишеп җибәргән. Кулындагы камчысын сөйрәп килде дә, учак янына җиткәч, чирәмгә ауды. Кул-аякларын як-якка ташлап, бөтенләй таралып китәрдәй шулай бераз җәелеп ятты да иреннәрен ялмады:

— Үләм! Су бирегезче, су! — диде.

Нигәдер берәү дә дәшмәде. Хисам абый учакка чыбык-чабык өстәгән булып утырды. Әхәт, кашларын җимереп, бер Сәлмәнгә, бер Каенлык ягына карап алды да бик мәгънәле генә итеп төкереп куйды. Безнең эше малай-шалай учак тирәсендә тезелеп яткан килеш, күзләребезне елтыратып, бу төнге кунактан берәр мажара чыгуын көттек. Каян кайтып килә икән? Нигә шулай вакытсыз? Үз атына атланып кайтканмы? Әллә...

Сәлмән, башын күтәреп, үткен кара күзләрен як-ягына атты:

— Әллә җыен чукрак җыелган инде монда?..

Хисам абый, учакны дөрләтүен дәвам иттереп, берәүгә дә карамыйча гына:

— Су Каенлык буендагы күлдәвектә. Әнә малайлар алып килсә генә инде, — диде.

Әхмәт, теләр-теләмәс кенә торып, Каенлык ягына таба бара башлаган иде, Сәлмән камчысын селтәп аны кире борды.

— Йөрмә! Үзем...

Әхмәт минем яныма сузылып колагыма пышылдады:

— Җибәрми... — Аннары бер Сәлмәнгә, бер Каенлык ягына карапып нидер уйланып ятты.— Галишәсе дә анда микән әллә? Алар гел бергә була ич.

Бу ике егетнең кыш көннәрендә каяндыр бик баеп, шәһәрчә киенеп кайтулары, бөтен авылны шаккатырулары искә төште. Аларның өсләрендә кайткан саен җемелдәп торган яхшы якалы затлы пальто, озын каракүл бүрек була. Сәлмән үзе алсу чуар Кукмара итеге киеп җибәрә. Мамык шарфының бер башын арка ягыннан асылындырып, икенче башын алга сала да тамак төбе белән бездә ишетелмәгән сәпсәер бер көйгә әйттерепме әйттерә. Ә Галишә кулында алтын телле дәү гармун. Башын бер яккарак салып, уйнап торып җибәргәндә, бөтен авылның кызлары акылларыннан шаша. Безнең дәү абый әйтә, андый гармун бөтен Казан өязендә бер генә, ди...

Бераздан Сәлмән учакка таба борылып утырды да пинжәк итәге белән битен, муеннарын, тамак асларын сөртергә тотынды. Учак тирәсендәгеләрнең аңа каш астыннан гына, бераз шигәеп, бераз сәерсенеб-рәк карауларын шәйләгәч, аның кара тут йөзендә, үткен кара күзләрендә елмаю шәүләләре күренеп алды.

— Уф! — диде Сәлмән. — Теләчедән кайтып килеш тә... Соңгарак калынды, чәнчелгере. Нишлисең, дус-иш. Бер очрасаң, ычкынып кара син алардан... Шундый тартасым килде, чыдар әмәлләрем юк. Бармы бирәрегездә?

Арада Әхмәт белән Әхәттән бүтән тәмәкече юк иде. Әхәт абый Сәлмәннең аңа төбәп әйтүен белеп торса да, ичмасам, селкенеп тә карамады. Утка караган килеш бүкән шикелле тынсыз утыра бирде. Тургай Әхмәт бераз як-ягына карангалап, мыш-мыш килде дә үрдәк бүксәсе шикелле бүлтәеп торган бишмәт күкрәгеннән озын баулы кызыл янчык чыгарды. Сәлмәннең кара мыек астындагы ак тешләре тагын җемелдәп алды.

— Менә молодец. Арагызда бер егет табылды...

Бу төнге юлчының шулай арып-талып әллә каян кайтып төшүе, атын нигәдер урман эчендә калдырып килүе, аның турында әлек ишеткәннәргә өстәлеп, бик кызыксындыра башлады. Сәлмәннең бөтен килеш-килбәтен астыртын гына күзәтеп торсалар да, берсе дә сүз кушарга базмады. Бары Хисам абый гына ара-тирә сөйләшкәләп ала иде.

— Син атланып кына барганың ошай, базарга дим.

Сәлмән, аңа каш астыннан гына күз сирпеп, сизелер-сизелмәс кенә селкенгәләп куйды.

— Ә, ие, атланып...

— Әәә! — дип сүзды тегесе. — Мал белән алыш-биреш итмәгәч, онытылып та киткән. Бүген чәршәмбе, Теләче базары бит әле.

— Ие, Теләче базары.

Тәмәке суырган арада базар бәяләре, тегесе-монысы турында сөйләшкәләп утырды да Сәлмән, Каенлык ягына китеп, караңгыга сеңгән кебек, күздән дә югалды.

Никадәр тырышып тыңласак та, ул яктан «шылт» иткән тавыш та ишетелмәде.

Утыра торгач, Хисам абый үзалдына кет-кет көлеп җибәрде.

— Әллә чабата киертеп алып китте инде. Чынлап! Алай эзе дә калмый, тавышы да чыкмый диләр бит.

Сәлим абый коты чыгып Сәлмән киткән якка карады.

— Төннең колагы йөз дә бер, йөз дә бере дә бик үткен була, ди. Шапылдамагыз!

Ул кайсыдыр атның аягында богау чылтыраган тавышка колак салып авыр сулап куйды:

— Атны богаулап җибәрергә кирәк булыр.

— Нәрсә син шулкадәр калтырана башладың? Юньле карак үз авылына җәбер салмый ди бит!

— Ни пычагыма ярый ул богау? «Әһ» дигәнче каерып ыргыта ул аны.

Хисам абый кулындагы таяк белән учакның чыбык-чабыгын актарырга тотынды. Учак бераз төтенләп торды, чыбык башларыннан чыж да чыж иттереп салам юанлыгы гына зәңгәр төтен аттырды. Аннары, нидер исенә төшкәндәй, кинәт кабынып китте. Ут яктысында Хисамның озынча карасу коңгырт йөзе бакырдан койган төсле балкып, тагын да матуррак булып күренә башлады.

— Башкорт ягында йөргәндә без андыйларны күп ишеттек.

Нидер сөйләргә жыенуын сизеп, бөтенесе Хисам абыйга текәлде. Йокымсырый башлаган малайлар, күзләрен чекрәйтеп, яңадан торып утырдылар.

## IV

— Бөре ягында йөргәндә чибәр генә тормышлы бер кешегә толып тегәргә кердек, — дип башлап китте Хисам. — Йорт-җир, каралты-кура шундый — чыпчык очып кермәслек. Байлык — чутсыз. Түгәрәк кара сакаллы, мулла сымаграк, шомакай гына бер кеше. Хуҗабызны әйтәм. Өйдә күп тормый, чыгып китә дә югала. Өч-дүрт көн дә кайтмый, кайчакны берәр атна да югалып тора. Ашау-эчү бик шәп. Кайткан көннәрендә, бөтен дөньясын онытып, кымыз эчеп, симез калҗа ашап төне буе типтерергә, тегесен-монысын сөйләнеп утырырга бик ярата. Шул кич утырганда, сала-сала сөйләде. «Яшьрәк чагымда, — ди бу, — ат белән чуалгаладым. Бик яраттым атны, харап! Беләсең килсә, атта кеше акыллары бар анда. Нәрсәләргә генә өйрәтмәдем мин атны! Берсе эт шикелле артымнан йөрер, икенчесе «на» дисәң, туктар, «тыр» дисәң, чабып китәр иде. Шунысы үземне әҗәлдән алып калды. Тагын берсен кеше таларга өйрәттем... Һи, мин күргәннәр! — ди бу, — минем кулдан үткән асыл атлар! Кайда үзең тәпиләтәсең, кайда озатышасың. Кайчакларны төн буе кулдан кистән төшми»...

— «Бер барышник дусым бар иде. Шул әйтә миңа: «Фәлән авылның фәлән тыкрыгында йолдыз кашкалы дүрт яшәр туры айгыр бар. Миңа шул кирәк», — ди. Нәрсәгә? дим. «Мин аны бер әшнәмә вәгъдә иттем,— ди. — Түрә, аның да кечкенәсе түгел. Сиңа да кирәк булыр, абайла!»

— «Аллага тәвәккәлләп киттем. Аякта чабата, аркада йөгән. Янәсе, атым югалган да, мин шуны эзләп йөрим була. Караштырып, иснәштереп бара торгач, таптым йолдыз кашканы. Бер ярлыда икән. Тәрәшле иләге тикле өе бар, кечкенә генә араны бар. Бу хәерче андый затлы айгырны ни пычагыма асрый? Сабан туйларында чабышка жибәрә икән. Исләрем дә, акылларым да китте! Әстәгъфирулла! Шултикле дә сылу булыр икән! Ул буй-сын, төп-төз матур аяклар, ул дәп-дәү, зәңгәрсу күзләр, ул киң күкрәк, жилфердәп торган ял-койрык. Әйтерсең, кызлар чәче инде. Шунда әйттем үземә үзем: «Я бу тулпарны алам, я ир егет исемен кутәреп йөрмим».

— «Тик менә ничек тәпиләтергә? Айгырны аранга бикли дә хуҗасы төн буе эт урынына үзе саклап чыга. Көндез гел жигүле. Бер төн кундым урманда, икене дә кундым. Иртән авыл янындагы әрәмәгә посам да башны эшләтергә тотынам. Әллә, мин әйтәм, аллага тапшырып, аранныннан алып чыгаргамы? Үзен тончыктырып, йозагын ватып? Әллә бүтән хәйлә корыргамы? Ат печүче булып керәсе дә бит, шакмаклары. тагын бүтән струменнары юк. Вәгъдә көне дә житеп килә, түземлелек тә төкәнә башлады. Ике-өч көн буена урманда чебен-черки туйдырып ятуы да жиңел түгел...»

Шылт иткән тавыш та юк. Һәммәбезнең күзе Хисам абыйда. Ул әле учакны кузгаткалаган була, әле атларның пошкыра-пошкыра ашаганын тыңлап ала.

— Я, я, сузма! — ди Закир абый.

— Тамак кипте.

— Ә, хәзер!

Як-ягына каранганда күзе мина төште.

— Бар әле, Гумәр, йөгереп кенә! Бер аягын монда, икенчесе тегендә!

— Мин килгәнче сөйләми торамы?

— Юк инде, юк!

Кемнендер сөт шешәсен алдым да очтым гына. Азрак шурләтә дә бит, шомландыра да. Караңгы урманга керәсе, тар сукмактан кармаланып кечкенә инешкә төшәсе. Аяк астында әллә ниләр кыштырдый, баш очыннан, имәндереп, выж да выж ярканатлар очып йөри.

Мин менгәнче чынлап та сөйләмәгән, күрәсең. Мин ут яктысына килеп чыккач, «тотын да тотын» дигән тавышлар ишетелде.

— «Бер көнне күрәм, ди бу, көндез атларны эрәмә буена утларга чыгара башладылар. Иң ахырдан йолдыз кашка да күренде. Шунда гына исемә төште: җомга көн икән. Сакларга чыккан малайлар шаугөр килеп көрәшәләр. Йөгерешеп-тартышып уйныйлар. Мин куак астында күземне елтыратып, җомга вакытын көтәм. Бик озак тоелды. Манара тәрәзәсендә мәзиннең чалмасы күренүе булды, малайлар, берсен берсе куып, ашарга кайтып киттеләр».

— «Я, мин әйтәм, алланың рәхмәте белән, изге сәгатьләрдә...» — дигән иде, мин көлеп җибәрдем: — Һи, һи! Сәгъди абый! Ничек итеп аллаһе тәгалә ат урлаучыга рәхмәтен яудырсын икән? Юк, монысы батмый, гупчи дә ябышмый, — мин әйтәм.

— «Бик бата! — ди хуҗа, — чытырдап ябыша. Ул хәерче шундый атны тәрбияли аламыни? Хайванны шул ачлыктан коткару савапды эш түгелмени?.. Куак астыннан чыктым да акрын гына барам. Ятсына бит, каһәр суккырысы: пошкыра, читкә тайпыла. «Баһ, баһ!» дигән булдым, җил ягына чыгып, ипи исенә алдадым, ягымлы сүзләр әйттем, яшь чагында кызларга да әйтмәгән иркә сүзләргә кадәр кызганмадым инде. Ничек итсәм иттем, якынайдым. Тәки каптырып алдым мин моны! Богавын гына каерып ыргыттым да әйдә тегене урманга. Авызлыклап алдым, менеп атландым. Камчы аның белән бер тумаган, кабырганы каезлый башлагач, нибуч киреләнеп тора алмассын! Икенче көнне таң алдыннан йолдыз кашка, туксан чакрым араны узып, минем әшнәнен аранында керт-керт печән ашап тора иде инде...»

— Җәл бит теге бичара, — мин әйтәм.

— Ул аны, әзли торгач, тапкан бит.

Мин сөенүемнән кычкырып җибәрдем:

— Шулаймыни? Кайда, ничек тапкан?

— Минзәлә ярминкәсендә. Шәп тарантаска җигелгән, ди, көмеш сбруй, ефәк дилбегә. Күргән дә бу моны муенына килеп асылынган: «Өч ай эзләдем мин сине! Ашаганым аш, йоклаганым йокы булмады», — дип елый, ди.

— Җыелган халык, килгән урәтник. Атның хәзерге хуҗасы зур гына бер түрә кеше икән. Тарантасына менеп утырган да тегенәр башы белән ымлап әйткән урәтниккә:

— Бу йолкыш минем законный атыма ябышып халык алдында рисвай итмәкче. Күреп торасыз ич, биш йөз сумлык ат аңа каян килсен!? — дигән. — Теге ягын үзегез карагыз.

Шулай дигән дә киткән дә барган.

## V

Аты урланган теге ярлы бик тә кызгандырды. Хисам абый сөйли башлаганнан бирле ул минем һич күз алдымнан китмәде. Менә Әбүгалисина шикелле күзгә күренмәс була алсан? Башта теге түрә кешене

хатыннары, дус-ишләре алдында, күзгә күренмичә генә барып, уңлысуллы яңаклап хур итәсе, аннары ярлының йолдыз кашкасын үзенә кайтарып бирәсе иде. И, куаныр да иде, мескен!..

Минем хыялымны Закир абый бүлдерде:

— Иөгәнеңне баш астына салып ят. Ат исенә елан килми диләр.

Яныма сузылып ятты да өстемә япкан бишмәтемне күкрәк тирәсенә тартып мендерде.

Минем белән күрше яткан җырчы Әхмәт, күзен йомган килеш кенә (мин арада иң кечкенә малай булгангадыр инде), акыл өйрәтергә тотынды:

— Төшендә бик каты сусый калсаң, бернәрсә дә эчмә, яме!—диде.— Ник дисәң, су эчергән шикелле иттереп, эчкә елан керә. Шуннан гомер буе эчең авырта торган була, үзең ябыгасың. Селәүчән авыруы әнә шул инде.

— Абау, бик куркыныч нәрсә әйтәсең!

Мин, шомланып, баш асларын актара башлаган идем, шул ук Әхмәт мине тынычландырырга да сүз тапты:

— Син курыкма, керсә, чыгарып та була аны.

— Булмас ла! Бер кергәч, нишләп чыксын инде ул?

— Чыга ул, чыгара белсәң! Яман да кызу итеп мунча ягасың, имә? Мунча өлгергәч, утең сытылырдай тозлы әйбер ашыйсың да ләүкәгә менеп йоклаган булып ятасың. Янына бер тустаган сөт куясың. Менә шунда чыга да инде ул. Эчәсе килгәнгә түзә алмыйча, сөт эчәргә дип чыга. Шул чагында шалт тегенең башына кисәү агачы белән!

Закир абый, алдына гына караган килеш, ничектер бик чын күңелдән, бик рәхәтләнеп беравык көлеп ятты.

Хәзер йолдызлар, сыек кына томан белән өретелгәндәй, бераз тоныграк күренә башлаганнар иде. Закир абый шул йолдызларга карап уйланды да, гырылдап йокыга китүчеләр шактый күбәйгәч, үзе шикелле үк йоклар-йокламас яткан Хисам абыйга дәште:

— Абайламый калдым, Әхәт кайчанрак шыңкайды?

— Бая ук инде, Сәлмән артыннан ук.

— Өйләнергә йөри микән әллә?

— Кем белә? Шулайдыр, кызлар янына чапкандыр.

Мин сикереп тора яздым. Әгәр безнең апай янына киткән булса? Шундук эти белән әнинең Әхәт турында сүз барганда «теге дуңгыз» дип, ничектер шомлы итеп, чиктән тыш борчылып сөйләшүләре искә төште. Аларның сүзеннән мин апайны гына түгел, бөтен нәселне пычратырдай нindидер әшәкелек, әдәпсезлек булып ташламагае дип куркуларын сизенә идем.

Минем күршеләр шыпырт кына Әхәтне кайгыртып яттылар.

— Бик өйләнәсе дә бит. Кем килсен? Үз куышы булмагач, кая барам дип барсын? Нәрсә өмет итеп?

— Шулай инде. Менә бит: көч тә бар, сәләт тә юк түгел. Кулыннан эш тә килә. Болай кара акыл белән уйлаганда, өйләнергә дә келтерәтеп кенә көн итәргә инде югыйсә. Ихма!

— Һәммәсе дә бар, тик мал гына юк. Мал булмадымы, бәхет тә юк...

— Туры юлдан баручыга юк инде ул бәхет. — Закир абый күршесенә таба борылып ятты да тагын да пышылдабрак сөйләшергә тотынды. — Теге бая монда сугылган чекри күз...

Мин, никадәр тырышсам да, шуннан соңгы сүзләрен ишетә алмый башладым. Хисам абый, урыныннан сикереп тора язып:

— Алласы орган икән! — дип җибәрде. — Ничек күрдең?

— Ул аунап яткан арада шыпырт кына карап килдем.

— Ни төсле, нindирәк?

— Озын яллы акбүз ат. Инде, малай, ул дә кит янында.

— Имансыз да икән! Ну каера инде акчаны, ә!

— Акчасыннан да бигрәк малы ни тора аның, малы! Ну тапкан да инде затлысын! Ничек кенә әйтергә сиңа. Киң күкрәкле, озын торыклы. Ут инде, ут! Күзләре караңгыда җондыз төсле елтырап торалар. Кай җирләрдән куып кайткан инде ул аны, әмма ник, ичмасам, чылт иткән тамчы тир чыксын! Менә җен!

Мин түзә алмадым, Закир абыйның колагына пышылдадым:

— Их, ник миңа да әйтмәдең, Закир абый! Ник әйтмәдең! Муены нинди?

Закир абый минем мыштым гына олылар сүзен тыңлап ятуымны ошатмаган шикелле тоелды. Шулай да ул теге атка шулкадәр соклан-ган икән, рәхәтләнеп сөйләде:

— Нәкъ аккош муены инде, менә шулай булып дугайланып төш-кән!..

Җилфер-җилфер килгән озын яллы акбүз ат, колакларын торгы-зып, күзләрен елтыратып күз алдымда уйнаклап тора. Аннары мин аны, аякларын салмак кына бөгеп, һавада оча итеп күрә башладым. Ялла-ры дулкын шикелле булып ишелеп-ишелеп бара. Әллә өнемдә, әллә тө-шемдә мин хәтта аның урманның әллә кай төшләрендә, бөтен тирә-якны яңгыратып, кешнәп җибәрүен дә ишеткән кебек булдым...

Күпмедер вакыттан соң атлар чинашканга уяндым. Ул арада ай баткан, төн бераз агара төшкән. Әрәмәлектә, берсеннән-берсе уздырыр-га тырышып, бик яман сандугачлар сайрый.

Сүнеп беткән учак янында Әхәт абый башын иеп уйга баткан иде.

## VI

Авылга кайтып, этине басуга озатканнан соң, тамак ялгарга да өл-гермәдем, тыны-көне бетеп, бәрелеп-сугылып Хәкимҗан килеп керде.

Байтак кына вакыт күзен челт-челт йомып сүзен әйтә алмыйча ты-пырдап торганнан соң:

— Тотканнар! — диде.

Минем: «Әһә, теге акбүз ат белән тотканнар инде алайса!» дип кыч-кырасым килде, ләкин шулай диясе урынга мин үзем сорадым:

— Кемне тотканнар? Нәрсә белән?

Хәкимҗан, баскан урынында тыпырдый биреп, сул кулы белән аргы якка таба күрсәтте:

— Нине, Сәлмәнне, тагын нине... Каравыл өенә алып килделәр!

Моны ишетүгә, почмак яктан куркынып әни килеп чыкты:

— Ай гөнаһ шомлыгы! Алайса харап итәләр икән! Ата-аналары ни-хәл түзәр, мескеннәр, аналары!

Хәкимҗан белән чыгып йөгерергә җыенумны күргәч, әни минем иң-башымнан эләктереп алды.

— Туктале! Аларны кыйныйлардыр бит, үтермәсәләр әле. Төшеп йөрмисезме әллә, бакча башыннан гына карап торасызмы?

Кая инде ул! Андый эшләр малайларсыз узамыни? Чабабыз гына. Тыкрыкта безне Нимҗан куып житте.

— Галишә дә капкан! — диде.

Исемнәре белән атап әйтсәләр дә, күңел һаман ышанмый иде әле.

— Булмас ла! — дидем мин. — Шундый фартавай егетләр...

Нимҗан миңа усал итеп, күзенең агы белән карады:

— Фартавайның әче бал эчәсе килмимени? Я берәр шәп ат чәл-дерәсе!..

Нимҗан йөгергән көйгә ишеткән-белгәннәрен аудара барды. Бәл-ки, ул ялганлый торгандыр?

— Иң башта Хәйрулла абый күргән. Таң белән торып чүннигеннән

кайтып килә икән. Чәбе елгасы инкелендә ниндидер шәүләләр кыймылдый, ди. Сыныйрак караса, болар! Зур-зур кисмәкләр белән бал алып кайталар, ди. Тентү белән кергәннәр икән, өстенә үк бастырганнар!

Кара син, әй! Сәлмән төнлә теге атны алып кайтканнан соң әле умарта басарга да өлгергән!

— Ат та урлаганнар диләр түгелме?

— Дисәләр соң? Урлаганнар шул!

Минем боларга кичәге хәлләрне сөйләп бирәсем килсә дә, вакыт калмаган иде.

Бара торган көйгә, каравыл лапасы ягына күз салдым. Теге кичәге акбүз атны да тотып китермәделәр микән? Әллә кайлардан, Идел аръякларыннан, ди, бит. Я башкорт ягыннан. Йөз чакрымны тынын да алмыйча кайтып җиткән, ди. Әй, менә шундый атың булса! Шуңа атланып йөрсәң!..

Әмма каравыл сараендагы хәлләрне күрүгә, акбүз ат төтен булып очты.

Монда колагың тонарлык шау-шу, коточкыч орышыш та кычкырыш иде. Бу тирәне төрле яктан халык сырып алган. Ярсып, бусарынып, һәммәсе кычкыралар, йодрык күрсәтәләр, кулларын болгыйлар; муеннарын сузып, аяк очларына басып һәммәсе дә лапас эченә, аның да җир идәненә карыйлар, берсен берсе этә-төртә шунда керергә ыргылалар.

Сарайдагы насос көпшәләре, арба тәртәләре, коргаксыган мичкәләр арасыннан, кырыкка бөгелеп, тиендәй сузылып, мичкә өстенә менсәк, телсез калдык. Галишә белән Сәлмән, куллары бәйләнгән килеш, аяк астында яталар.

Сәлмән, кырмыска оясына ташланган кәлтә кебек, өзлексез бөгәрләнә, йолкына, әмма кулларын ычкындыра алмыйча, әле яны, әле аркасы белән тузанга килеп төшә. Аның матур кара мыегына саламнар ябышкан, чем-кара чәче тузан белән аралашкан. Үзе:

— Нахак бу, нахак! — дип гырылдый. — Биз закун! Кая закун!

Халык шунда, мичкә ыргытылган арыш саламы шикелле, чатыр-чотыр кабынып китте, сүгенү, каргау, көлү ишетелде:

— Һа-һа-һа! Закун кирәк булган аңа, закун!

Чәрелдек тавышы белән Текер Ибрае кычкырып җибәрде:

— Күрсәтегез шул эттән туганнарга закунны!

Галишәне яны белән ыргытканнар. Аның юка гына саргылт мыегы, кала кешеләренеке шикелле итеп янга таба таралган аксыл сары чәче әле тузгып өлгермәгән. Яшел ефәк күлмәгенең изүе чишелеп киткән, чалбарының кечкенә кесәсеннән сәгать чылбыры асылынып тора. Халык аерата акыра башлаган вакытта аның зәңгәрсу күзләре еш-еш йомыла, көмеш балдак кигән имән бармагы, бик кызганыч булып, тыелгысыз дерелдәргә тотына иде.

Халык кызганнан-кыза бара, ярсый бара. Ачуларыннан зәһәрләнеп, баскан урыннарында бии-бии, йодрыкларын айкыйлар, кычкыралар, яныйлар, каргыйлар:

— Урлаган атларын таптырырга кирәк! Әнә малайлар кунардан күреп кайтканнар!

— Ата-аналары кайда? Даваегыз монда барысын!

— Ни эшкә чакырып торасың? Бөтен ыруы карак, бөтенесе бур, бөтенесен катыр җибәрергә! Ыштубы нәселләре корысын!

Безнең күрше Сарник Галимҗан тавышы ишетелде:

— Укыт арт сабакларын! Ел саен ни тикле каз-үрдәк югала, күпме баз гына басалар! Әммәсе шулар эше!

— Таптың сүз! — дип Гайнулла җизни гүли башлады. — Нәрсә ул каз-үрдәк? Тфү! Ни тикле тәкә-сарык югала! Шулар гына ашый безнең сарыкларны!

— Ә минем бозау? Сөт имезеп кенә үстергән тана хәтле бозау сәгать эчендә дөхетсез булды!

Кайсыныңдыр урам ягыннан чырыйлап кычкырганы ишетелде:

— Сарык тиресе ябындырып, чиләк тагып урам йөртергә кирәк! Бөтен халык күрсен!

Күбесенең акыра-акыра тамаклары карлыккан, күзләрен кан баскан. Шулай да беренче булып сугарга берсенең дә батырчылыгы җитми. Алла сакласын! Аларның кырыгына бер иман. Исән калса, эчеңә пычак кына тыгып чыгара, я йортыңа кызыл әтәч җибәрә. Бала-чагасы, мал-туары белән кемнең кычкырып янасы, кара җәяү каласы килсен?!

Шунда кайсыдыр үзе күренмичә генә арттан кычкырды:

— Нәрсә карап торасыз, аударыгыз йөзтүбән!

Ни булганын без күрми дә калдык. Халык кинәт үкереп куйды. Шундук янгын сараеның эче, ашлык суккандагы кебек, дөп-дөп иткән, мышнаган, сүгенгән, коточыргыч итеп чинап, акырып җибәргән тавышлар белән тулды. Арыганнары, маңгай тирләрен сөртә-сөртә, чыга торды, алар урынына бүтәннәре килә торды.

Кайсыныңдыр моңа гына күңеле булмады, күрәсең, арттанрак торып кычкырып җибәрде:

— Бурланып яталар! Әткә пычагым да булмый! Җәлләмә!

Шунда берсе, очынып, җан-фәрманга Сәлмәннең күкрәгенә типте. Тегесе ачыргаланып кычкырып җибәрде. Бу тавыш кыйнаучыларны тагын да котыртты. Һәммәсе берьюлы ашыга-ашыга, кая туры килә шул төшләренә тибәргә, өсләренә менеп сикерергә, изәргә тотындылар.

Безнең янда торган Закир абый башын чайкап телен чартлатты:

— Ай-яй-яй, ай-яй-яй!

Бу хәлләр барыбыздан да бигрәк Нимҗанга кызык тоелды. Ул үз алдына кыбырсып, баскан җирендә тыпырчынып тора иде. Нимҗан мина күз салды да кабыргама төртте:

— Һи, кыланчык! Җәлләгән була! Кызлар шикелле! Сезнең дә әллә ничә тәкәгезне суеп ашадылар бит!

Минем һич тә кызлар шикелле елак, җебегән буласым килми иде. Чыраема бөтен ачуымны чыгарырга теләп, кашларымны җимердем:

— Минме? Җәлләр, бар, җәлләми торсын әле!

Әмма аяк астында аунап яткан Сәлмән белән Галишәгә күз төшүгә, аркага боз кисәкләре коела, тән чымырдап китә иде. Алар хәзер кычкырмыйлар, аларның бите-күзе күбенгән, тоташ зәңгәр шешкә әйләнгән. Авыз кырыйларыннан кан саркый. Галишәнең теге көмеш балдаклы бармагы хәзер дерелдәми, җансыз нәрсә шикелле канга, тузанга манчылган иде.

Шул вакыт күкрәгенә зур сары калай таккан староста килеп чыкты. Үлек сыман ике гәүдә янына кереп җиткәч, ул, күзләрен акайтып, кире тайпылды:

— Әстәгъфирулла, тәүбә! Имансызлар, кансызлар! Катыр китәрлек эш ич бу! Харап иттегез башымны! Станавайга нәрсә әйтермен! Зимагурлар, башсызлар!

Гайнулла җизни шыңгырдавыклы калын тавыш белән яңгыратып көлеп җибәрде:

— Һа-һа-һа! Нәкъ төрҗәгуненә генә килеп әлгәште староста. Туйдан соң дөмбергә!

— Һи, безнең старостамы? Мондый чакта кайчан килгәсен аннан гына сора инде син!

Сәлмән белән Галишәне, өсләренә карамаска тырышып, каравыл өенә кертеп салдылар.

Халык, су сипкән шикелле, кинәт үзеннән-үзе сүрелде, сүнде. Әле генә кызарынып, бүртенеп йодрыкларын айкап акырган ярсу кешеләр

кинәт тып-тын калдылар, берсенә берсе күтәрелеп карарга оятлары житмәгән сыман, башларын түбән иеп, шыпырт кына таралып беттеләр.

## Скрипкә нәрсә дип җырлый

### I

Аргы якта бик ачык чырайлы, бик телдәр Бикә исемле карчык бар иде. Олы кешеләр үзенә якты чырай бирсәләр дә, үзе югында аннан еш кына көләләр, Сукыр Бикә диләр, аны «ике көймәнең койрыгын тотарга» җыенучы аумакай кешегә саныйлар:

— Ике яклы пычак... адәм хуры... — диләр.

Әмма бу сүзләр берничек тә минем күңелгә ятышмыйлар иде. Менә тамаша! Нигә ул «адәм хуры» булсын икән? Әти аны «дөньяда иң бәхетсез кеше» дип әйтә. Чиркәүгә дә йөреп, мөселманнарча булырга да маташкан өченме? Бу минем һич башыма сыймый иде. Ансыз ничек инде? Ул, Яңа Саланың тыйнак кына аккан Бөйдә елгасы, тау астындагы берсеннән-берсе татлы чишмәләре шикелле ук, бүтәнчә була алмый торган бик кирәк бер өлеше. Әгәр Бикә тути булмаса, Яңа Салага нидер җитенкерәмәс, ансыз күңелсезрәк булып калыр иде.

Кайчакны урамда кемнеңдер мыдыр-мыдыр сөйләшкәне ишетелә. Тыңлабрак карасаң, Бикә тути, имеш, үз-үзенә сөйләнеп бара икән.

Менә күрше Габдулла абзыйларның Дүрткүзләре ярсып өрергә тотына. Шундук Бикә тутинең зарлануын да ишетәсең. Тамагы бераз карлыккан, һәрвакыттагыча тавышы бераз тыңкышланып чыга.

— Кодайларым, тәңреләрем! — ди ул. — Менәтерәк! Ник шул катьләләр абалыйсың, ник тешләреңне ыржайтып мине ашарга келисең? Әллә җөз тапкыр борын төбеңнән узам, җөз тапкырында да өреп каласың! Бәбәкләрең кая, танаукайларың кая? Миңа өрергә оятларың кая? Тфү, тфү, ташкулчим! Минем белән бергә картаеп, җөнтәс башларына бер дә генә акыллар кермәс икән, кодайларым!

Бикә тути яшел чирәмнән ысылдап күтәрелгән ата каз белән дә, анасыннан адашып калган, кая барасын белмичә, арлы-бирле сугылып елап йөргән яшь бәти белән дә сөйләшеп уза. Ул аягын сөртендергән ташка да, койма буендагы балтырын чагып калган кычытканга да үпкәли бела:

— И җүнсез! Шул тикле көйдереп алмасаң! Бигрәк тә зәгарьләнәсең. Карт көнемдә ачуымны алыем, чагып калыем дисеңдер инде.

Аныңча, һәммә нәрсәнең дә җаны бар, тик әйтергә телләре генә юк.

Һәр йорт турысыннан узганда аның нинди дә булса әйтәсе сүзе булмыйча калмый. Безнең койма буена килеп җитәрәк, ул җәй көнс сүзне бакчага соклаиудан башлый:

— Ай исләре лә, исләре, рәкъмәтләр генә төшкере! Бәшир абзыйның хәнәфер[1] чәчәкләре бөтен дөнҗаларны җәннәтләр иткән ләбаса. Ул сулуларга иркен, менәтерәк, ул күкрәкләргә рәкать!.. Иии... Кодайларның рәкъмәте генә яусын инде аңа...

Бусагадан атлаганда, мөселман хатыннарына охшатып, ирен араларыннан «бисмил...» дигән кебегрәк бер аваз чыгара. Ул аны сәкегә килеп утыргач та әйтә, чәй эчәргә дәшсәләр, чынаягын авызына китергәндә дә, ризык капканда да. Әмма чәй эчеп, я сөйләшеп утырганда аргы якта чиркәү кага башладылармы, Бикә тути кинәт үзгәреп китә. Бисмилласын әйтеп, аннан-моннан битен сыпыра да, яулыгын почмаклап бәйли-бәйли, чиркәүгә йөгерә иде.

[1] Керәшеннәр элек къ урынына х һәм, киресенчә, h белән х урынына къ янсә гъ әйтәләр иде.

Өлкәнрәкләр моңа көлемсерәп кенә калалар. Безнең сорашуларыбызга Бикә түти һич рыясыз, ничек уйласа, шулай җавап бирә иде:

— И оланнар, сезгә уен, миңа чын. Үзем Бикә, картым Игнат, авызымда бисмилла, түшемдә тәре. Менәтерәк сезгә шул: икебезгә дә үләр багыт җиткән. Инде, кодайларым, нишләргә? Урыс алласы, минем денем чын дөрес, ди, татарныкы, минеке генә чын, дип киселеп төшә. Барып күрмиенчә торып, кайсы дөресен кайлардан белиек? Ике алланың берсенә ярап булмасмы, теге дөнҗаларда икесенең берсе рәкыймшәпкатен салындырмасмы дип сырпалану инде бу...

## II

Әмма балалар Бикә карчыкка кире карамады. Кайсы ягы белән балаларга ошады икән? Берәр сөйкемле сөяге булгандырмы, ничектер. Җәй көннәрендә Бикә карчык урмангамы, болынгамы барырга чыкса, безнең тирәнең баласы-чагасы, дәррәү кубып, аның артыннан китә иде.

Бикә түти яулыгын аркасына җәеп җибәргән, алдына эре кызыл чәчәкле алъяпкыч япкан. Аның култык астында әллә кайчангы бабаларыннан калган, озак еллар урман белән ике арада йөри торгач, көн сыман ялтырап торган кечерәк кенә карама тырыс.

Шулай дистәдән артык бала-чага, Бикә әбигә ияреп, урам уртасыннан барганда, чиркәү каршысында кем беләндер сөйләшеп торучы Микиш дьякон өстенә килеп чыктык. Микишнең чалара башлаган озын чәче иңенә ишелеп төшкән, йөзен чәче төсле үк соры сакал-мыек баскан, йонлач биттән бары тик песи борыны шикелле сәп-сәер булып борын очы гына калкып тора.

Аны күрүгә, карчыгыбыз кинәт каушады. Микишнең әле бер ягына, әле икенче ягына чыгып, еш-еш билен бөгәргә, җиргә тидерерлек итеп иелә-сыгыла башын иярга тотынды. Ләкин Микиш аны күрмәде.

Бераз киткәч, Бикә карчык куркынып кына аңа борылып карады да авыр сулап куйды.

Тик Бикә түтинең хәсрәтле чырае алай озак карангыланып тормады, кайгы-борчулары гүя чиркәү янында төшеп калгандай юк булды. Бераздан аның яңадан күңеле күтәрелде, ул яңадан шул телдәр карчыкка әверелде.

Менә ындыр артына да чыктык. Вак кына саргылт чәчәк атып, якын-тирәгә авыр бер ис аңкытып үскән куе яшел киндер җирләрен дә уздык.

Бераз баргач, карчык болын буена таба борылып туктап калды. Без караган якта, болын буена сузып салган аксыл зәңгәр билбау төсле, тар гына җитен җирләре чәчәк атып утыра.

— Иске авыл әнә шунда, болын буенда булган, — ди карчык. — «Көчек» дип йөрткәннәр.

— Нишләп эт исеме куштылар икән, Бикә әби?

— Алла белгән... Можыт, көчеккә алмаштырган авыл булгандыр.

Иске авыл урынында ул тагын нәрсәдер күрә, нәрсәдер без белмәгәнне белә. Тик аларын безгә әйтмичә, бары үзе генә белеп калдыра кебек.

Тау кырыена килеп җитәрәк, ул безгә алда сузылып яткан ямьяшел болынның ике башын күрсәтә:

— Кайсы башына төшиек? Ушара болынынамы? Әллә Сөрән таяк ташлаган инкелгәме?

Балаларның кайсы Ушарага дип кычкыра, кайсы Сөрән таяк ташлаган җиргә, ди.

Хәкимҗан белән без әле генә исемнәре чыккан шул сәер инкелләргә карап алдык. Әнә алар, каршы якта гына. Бишна урманының ике

ягыннан ике инеш килеп төшә, икесенең дә буйлары әрәмәлек, үләнлек. Шул төшләр инде ул.

«Сөрән таяк ташлаган»... «Ушара»...

— Ул ниткән сүз? Нинди сөрән? Нишләп таяк ташлаган? — дип без мәдрәсәдә хәлфә абыйдан да сорап караган идек.

Ул безгә:

— Нәрсәгә хаҗәт ул сезгә! Юк белән баш катырмагыз! — диде.

Хәкимҗан җиләк җыярга дип алып чыккан сары бадьянын бер башына киде, бер һавага чөеп уйнады. Әмма үзе һаман нәрсәдер уйлаган сыман күренә иде.

— Я, бәлкем, Сөрән атлы шундый берәр кеше булгандыр?

— Ә таягы?

— Шул кеше таягын ташлагандыр...

— Ничек ташлаган, нишләп?

— Әллә тагы... Синеңчә ничек соң?

— Минемчәме?..

Минем әнә шул яшел тугайда яшәгән борын заман кешеләрен күз алдына китерәсем килә иде. Бик кызык бит! Бәлкем, алар безнең борынгы бабаларыбыз ук булганнардыр әле. Тәгаен шулайдыр! Идел буеннан, патшалардан качып килгәннәрдер дә әнә шул урман ышыгындагы тугайга шалаш сыман нәрсә корганнардыр. Я зимләнкәдә торганнардыр. Миңа хәтта аларның урманга менеп-төшеп йөри торган тар сукмаклары да күренә. Тау куенындагы әнә теге чишмәдән су алганнар, инешендә юынганнар булыр. Бәлки, икенче авылдан килеп боларның малларын, кызларын талап киткән чаклар да булгандыр. Шул чакларда сугышмаганнардыр дисеңмени?

— Шунда берәрсе җиңелеп корал ташлаган булса?

Тик Хәкимҗанга әллә мин әйткәннәр ошамады, әллә гадәте буенча киресен әйтәсе килде:

— Таяк белән сугышырга алар сиңа малай-шалай түгел лә! Борынгы бабайлар Алып батыр тикле булганнар... Манара буе. Аларның таяк дигәне бүрәнә булгандыр әле. Чабата каккан балчыклары да тау тикле булган. Әнә, күрәсең ич!

Әйе, күреп торам. Әнә андагы бер йомры калкуны шул Алып бабай чабатасыннан калган, диләр.

Менә без Каенсар суының Бөйдәгә койган җиренә үк килеп җиттек. Камышлар өстендә күбәләкләр очып йөри, җикәннәр атына. Безгә тагын да күңеллерәк булып китте.

Шунда күгәрчен кадәрлерәк бер кош — шәүләгән[1] безнең өстебездә әйләнә-әйләнә чыелдарга тотынды. Ул шундый ачыргаланып кычкыра, шундый кырыкка бөтерелә, әйтерсең, без аның иң явыз дошманнары, әйтерсең, нәселен корытырга килгәнбез.

Хәкимҗан түзмәде. Шәүләгәнгә каты балчык тондырды. Аннан күрмәкче башкаларыбыз да төрле яктан атарга тотындык. Ләкин Бикә түти:

— Тимәгез кодайның кошларына! — дип кычкырды. Ул куркуыннан тешсез авызын капларга да онытты. — Аңа алла үзе шулай боерган!

Шунда минем тел очыма җайсызрак бер сорау килеп төшмәсенме!

— Кайсы алла, Бикә түти? Чиркәүдәгесеме?

Карчык миңа шундый рәнҗеп, шундый сызланып карады, хәтта тар гына ярыктан аның йомык күзе дә елтырап китте шикелле. Аллалар үзләре ишетә курмәсен дигәндәй, минем колагым төбендә пышылдарга тотынды:

— И олан, соң без, кара халык, каян белиек? Дөнҗаларда бер генә нәстәгә дә тамга салынмаган лабаса! Безнең өстә күк күкрәтеп кайсы

---

[1] Шәүләгән — бездә тәкәрлекне шулай атыйлар.

дөберди? Бер тамчы яңгыр яудырмыенча кайсысы иген-таруны көйдерттерә? Кайсы алла терлекләргә үләт җибәрә? Кем белсен! Әллә тегесе, әллә монысы. Кайсына келәүләр итәсе дә, кайсысына корман чаласы! Аптыраш!..

Бикә түти кулларын җәеп җибәрде.

Без аның әле уң ягына төшәбез, әле сул ягына чыгабыз. Өстә сайраган тургайга, без барып җитә башлагач пыр да пыр үлән арасыннан күтәрелгән вак кошларга карап алабыз. Карчыкның сүзен һәммәбезнең дә беренче булып ишетәсебез килә. Алла кемгә нәрсә боерган?

Ул, яулыгын чишеп, битен инеш суы белән кат-кат чылатты да «Сөрән таяк ташлаган» иңкелгә алып китте. Бераз барды да:

— Әрбер җан иясенең алла кушкан җомышы бар, — диде. — Берсе сайрый, бер ишесе кортлар чүпли. Тагын берәүләре, менә моның шикелле, узган-барган турында кабәр итеп тора.

— Кемгә хәбәр итә, Бикә түти?

Карчыгыбыз, як-ягына каранып, яңадан шыпыртка күчте:

— Кемгә икәнен үзегез дә беләсегез бит, наяннар, юрамалый гына сораган буласыз... Минем кулым түгел, Әйшә батман кулы, дигән шикелле, минем сүзем түгел, картлар сүзе. Беләсегез килсә, борынгылар бер багытта да җалган сөйләмәгән.

— Нәрсә дигәннәр соң ул борынгылар?

— Әйткәннәр алар, әйткәннәр... — Бикә түти, башын кыйшайта төшеп, әле һаман да чыелдап йөргән шәүлегәнгә карап алды. — Борынгы багытларда Арчадан поплар килеп калыкны ак патшаның үз дененә кертергә тотынганнар. Бер килгән, ди, поплар, ике дә килгән. Тик кермигенә, ди, бит калык. Каенсар тау башыннан поплар күрендеме, чыгалар да качалар, ди, кайсы кая. Аларга нәстә? Әрбересенең туып-үскән җире. Аларны чокыр-чакыр да яшереп кала, әрәмә-куак та урын бирә, карама куышлары да сыйдыра. Каян табасың! Шулай качып котылдык дигәндә генә өсләрендә әлеге шушы шәүлегән чыелдый башламасынмы! «Менәтерәк, монда алар, монда!» дигән шикелле. Казер килеп басалар, ди, тегеннән ат белән.

— Аннары? Шуннан соң нәрсә булган?

— Нәрсә булсын? Бәйләп алып кайтканнар да тондырганнар базга. Салганнар төтен. Ушы киткәннән соң, сөйрәп чыгарганнар да муеннарына тәре такканнар. Шулай иттереп шул, ак патшаның кушуы булды, ди, Мәрдәнне, чукындырып, алла колы Мәкчем иттерделәр. Миркайдәр атлысы Микайла булып китте, ди. Биатай да, янагай да сөйләрләр иде: бер дә генә дә җаратмаганнар калык бу денне. Попның күләгәсе күмелдеме, казер өзеп аталар икән тәреләрен.

Шунда мин дә тавыш биреп куйдым:

— Әти әйтә, падишаның бер кулында камчы, икенче кулында прәннек булган, ди. Прәннегенә тәмле булдымы икән аның, Бикә түти?

— Менәтерәк болай ул: үз дененә чыгучыларга патша баштарак җирнең дә җүнлерәген биргән, иманага да тулэтмәгән, солдат кызмәтенә дә алмаган. Менә шул инде прәннек дигәне. Бераздан патша күрә: кермиләр генә бит аның дененә, башларын кисәсеңмени! Тузына-тузына да әйтә ак патша: керәшенне дә алырга солдатка! Ятмасын әле мич башында чабатасын киптереп! Шуннан соң чыгарганнар, ди, теге җырны.

Бикә түти акрын гына башын чайкый-чайкый, иреннәрен кызык кына чөмәкәйләндереп, калтыранган тавышы белән көйләр-көйләмәс кенә җырлап та күрсәтте.

Кабак тауларының башында
Чирми Пауаллары бау иша,
Керәшен калкын алмасаң,
Татар беткәнмени, падиша?

### III

«Сөрән таяк ташлаган» инкелгә җиткәч, тау кырыена сибелеп, һәммәбез дә җиләк эзләргә тотындык. Бикә карчык яулыгын артка чөеп бәйләде, алъяпкычын өскә үк менгереп кыстырды да кечкенә кызавын алдына чыгарды.

Әмма әйләнәбездәге яшел болынга, камышлар арасыннан бормаланып аккан Каенсар суына, ямь-яшел киеме, эче тулы кош тавышлары белән кызыктырып, үзенә дәшеп торган Бишна урманына күтәрелеп карауга, ничектер җиләк җыясын онытты. Шулкадәр яратып карый, әйтерсең, беренче тапкыр күрүе.

— И, дөнҗаларның җомаклары шушыдыр инде димәсәң... Кошлары сайрап тора, чәчәкләре ислемайлар чыгара, бал кортларына тикле «без» дә «без» килеп үзләренчә җырлап җөриләр. Әйтәм җирле безнең әби-бабайлар монда килеп утырган, тикмәгә генә түгел икән!..

Байтак вакыт шулай сокланып торганнан соң нәрсәгәдер офтангандай:

— Их, оланнар... — диде, авыр сулады.

Шунда миңа Бикә түтинең ниндидер зур хәсрәте бардыр шикелле тоела башлады. Нигә олы кешеләр аны яратмыйлар, нигә ул килә башласа, кашларын җыералар? Әллә Анный турында әләкләүче шул микән? Әллә керәшен булган өченме? Алай дисәң, безнең якта юньле керәшенгә караңгы чырай күрсәтмиләр. Үзара кунакка йөрешүчеләр дә, дус булучылар да бик күп.

Минем Бикә түтигә нинди дә булса берәр ягымлы сүз әйтәсем, яхшылык эшлисем килде.

— Әйдә, Бикә түти, минем янга кил. Җиләкнең менә ниндиләре бар! — дидем.

Әмма озак та үтмәде, карчыкның яңадан йөзе яктырып, маңгаендагы сырлары язылып китте. Ул туктаусыз сөйләнә, әле беребезгә, әле икенчебезгә дәшә башлады. Менә ул, тавык шикелле, сыңар күзе белән кырын-кырын карангалый торгач, үлән арасына сузылды. Әмма, күрәсең, аның ярылгалап беткән кәкре бармакларына җиләк тоттырмагандыр. Ул, әйтерсең, җиләк белән кача-кача уйнагандай, кет-кет көләргә тотынды:

— Кодайларым, ник качасың япрак астына! Кара инде син моны! Җиләк булып җиләкнең тырыска керәсе килми. Килмәс тә шул, килмәс! Якты дөнҗалардан кем туйган? Иртәнге чык тамчыларын эчеп, болынның куш исләрен сулап, якты кояш җылыларында иркәләнеп пешкән шул ул, җанкаем!

Теге вакытта Миңниса алмасын тартып алып җылаткан кыз — Сәлимә дә безнең белән килгән иде. Баядан бирле безнең тирәдәрәк чуала. Менә ул җиләкләрен бармак очында бөтереп күрсәтте.

— Әләли, әләли! Куш җиләк таптым, куш җиләк!

— Ай аллам, кодаем, — ди Бикә түти. — Менә бәхетле бала! Син аны, кызым, үзең аша. Куш җиләк ашасаң, ие, ээ... матур булып үсәрсең.

Минем бу турыда Бикә карчыктан күбрәк белүемне күрсәтәсем килде:

— Юк, матур гына булып калмыйсың, игез бала табасың, — дидем.

Бикә түти кет-кет көлде. Бу сүзнең әллә кайсы гына ягы үземә дә ошамады.

— Юк, мин аны әнигә алып кайтып күрсәтәм! — диде Сәлимә. Шунда миңа карап алды. Күрәсең, теге алманы исенә төшергәндер. — Миңниса юк ич, талап алмаслар.

Сөйкемле генә икән бу Сәлимә.

Кайтырга чыккач, әрәмәлек тирәсеннән узганда, шәүлегән яңадан

безнең өстә чыелдап барды. Минем кайсыдыр китапта кошлар турында укыганым искә төште.

— Бәлкем, аның оясы шунда булгандыр әле. Ул, бәлкем, балаларыма тимәгәйләре дип шулай борчылгандыр?

Эмма Хәкимҗанның, гадәтенчә, киресен әйтәсе килде, күрәсең:

— Ие, Бикә түти белмичә әйтер инде бар! — диде. Бераз баргач, ышаныр-ышанмас кына тагын әйтеп куйды: — Аяк астына оя ясарга тинтәк дип белдеңмени син аны? Кош булса да, нибуч, аны гына белер...

## IV

Иске зират янында, шул тирәдәге пар наратка кайтып житәрәк, Бикә түти акрынрак атлый башлады. Без, аннан узып, алга йөгерергә кыймыйбыз, шауламыйбыз да. Гүя Бикә түтинең нарат белән күрешеп сөйләшүенә комачаулыйбыз кебек.

Без аның бу тирәдә бик еш булуын да беләбез. Әнә шул пар нарат төбендә бик озаклап нәрсәдер сөйләшепме, укыныпмы утыруын да, кайчакта хәтта елавын да күргәнебез бар. Без аның исән күзендәге яшь бөртеген күрмәс өчен читкә борыла идек. Тик нишләп ул зиратта укынмый, пар нарат төбендә укына икән?

Пар нарат бөтенләй корып бетә язган, алардан инде күзләрең мул булып күркә дә коелмый, баш түбәләрендә бүрек тикле генә булып эленеп торган сирәк ылысларыннан күләгә дә төшми, кабыклары да кубып, карт тәннәре шәрәләнеп калган. Бикә карчык аларга озак кына карап тора да авыр сулап куя:

— Менәтерәк, сез дәген картайдыгыз инде, — ди. — Әнә, буыннарыгыз да бирчәеп чыккан, кул-аякларыгыз да, минеке шикелле, кәкребөкре булып каткан. И дөнҗалар...

Бу ике нарат безгә чыннан да картаеп бөкрәйгән карт белән карчык сыман күренә башлыйлар. Жил-давыллы вакыт туры килгәндә, аларның башлары бер-берсенә таба бөгелеп-сыгылып шыгырдарга тотыналар. Әйтерсең, алар, менә шулай башларын иеп, яшь вакытларын болын өстенең шушы матур урынында бергә-бергә күнелле итеп уздырган өчен берсенә берсе рәхмәт әйтешәләр, шәфкатьсез давыл сындырып ташлаганчы бәхилләшеп калырга ашыгалар кебек. Соңыннан без яшенледавыллы яңгырлар вакытында бакча артына чыгып, әлеге пар наратка күз салмыйча түзә алмый торган идек.

Бикә түти безне алгарак җибәрә:

— Барыгыз, бар, кайта торыгыз, — ди.

Без читкәрәк китәбез дә, карчыкны күрмәгәнгә салынып, чәчәк өзгән, йомран оялары эзләгән булып йөрибез. Ә ул үләннәр арасына тезләнгән дә мыдыр-мыдыр нидер укый, дога кылгандай бармак очлары белән нягең сыйпап куя. Тагын нидер укый-укый да ашыгып кына «чебен куып» ала.

Шунда авыл ягыннан скрипкә моңы ишетелә башлады. Без колакларны торгызып тынып калдык. Бу нәрсә булыр икән? Әллә керәшеннәр ягында берәр бәйрәм-сәйрәм бармы икән?

Нимжан, бик белдекле кыяфәт белән, уйлап та тормастан:

— Керәшеннәрнең япрак бәйрәмнәре! — диде.

Эмма, малайлар арасында иң ялганчы малай булып танылганлыктан, аңа берәү дә ышанмады.

Гыйбаш абзый шул тирәдә генә сөзәк тау кырыеннан болынга туры юл салып маташа иде. Ул киндер алъяпкычы белән бик озаклап бакыр төсле маңгаен, муеннарын сөртергә тотынды. Скрипкә тавышы ишетелгән якка колагын салып торды да, безнең шуны да белмәвебезгә үпкәләгәндәй:

— Онытмыгызмыни? Кара көн ич бүген, карангы көн! — диде. Бала-чаганың барысының да берьюлы диярлек исенә төште:

— Әәә! — дип суздылар. — Юк, онытмадык!

Гыйбаш абзый, Бикә карчык ягына күзен сирпеп, тагын бер-ике сүз әйтеп куйды. — Әнә ул беләә. Белә ул, белә!

Гыйбаш абзый Бикәгә шундый рәнҗеп карады, мин әллә нишләп киттем. Тагын шул яратмау, тагын шул аңаниндидер явызлык эшләгән кеше төсле дошман итеп карау. Ул арада иске зиратның теге ягыннан скрипкәче Кируш үзе дә күренә башлады.

Гыйбаш абзый да, Кируш та ул вакытта егет кеше булганнар әле. Кирушның түгәрәк кенә йөзле, кара-коңгырт күзле унсигез яшәр сеңелесе Анный бар икән. Мөселман ягының Гайнулла исемле егете белән бер-берсен бик яратышканнар да ирле-хатынлы булганнар. Урыс динендәге кызга татарга чыгуны ул заманның законы бик каты тыя икән. Киткән сүз. Кемдер Микиш дьяконга барып әләкләгән, Микиш Мәнәтә побына житкергән.

Шул чагында кара көннәр якынлашуын алдан ук сизенеп, ни ялынган сеңелесе Кирушка:

— Яман күзләрдән юк булыйк! Гайнулла белән читкә чыгып качыйк. Харап булырбыз! Катыр китәрбез!..

Әмма Кируш бик тә динле, бик тә «дөрес» кеше икән, сеңелесенең качып китүен күңеле күтәрә алмаган.

— Бер-берсен яратышып өйләнгән өчен нишләп катыр җибәрсеннәр? Ак патша олы күңелле, изге кеше дип әйтә Харлампий поп. Ак патшаның үзенең дә уллары-кызлары бар, ак патша чынкый дөрес эшләр... Әләккә ышанмас.

Әмма Кирушның ак патшасы кара йөрәк, кара җанлы булып чыккан. Килгән станавай, килгән стражниклар. Станавай әйткән Анныйга:

— Бөек чарның денен хурлап нишләп магометанинга чыктын?! Я бу такыр баштан аерыласың, я катыр китәсең!..

Анный куркып тормаган, бөтен халык алдында станавайның йөзенә бәреп кычкырган:

— Асыгыз, кисегез, Себер җибәрегез! Тик мин үлсәм дә Гайнулладан аерылмыйм! — дигән.

Стражниклар алып киткәндә, Анный белән Гайнулла пар нарат янынннан узганнар. Шунда әйткәннәр:

— Шушы пар нарат шикелле без дә пар килгәниек. Туган җиребезнең яшел кочагында пар нараттай куанышып үскәниек, яшьнәгәниек. Себер суыклары башыбызга житеп, шунда череп калмасак, пар нараттка янадан кайтмый калмабыз!

Менә пар нарат инде картаеп беткән, ә Анный белән Гайнулла һаман юк та юк.

Шулай да авыл һаман көтә әле, татарлар да, керәшеннәр дә. Барысыннан да өзелебрәк Кируш көтә. Аның инде, үзен битәрли торгач, чәч-сакалына да чал кергән, битен җыерчык баскан. Теге вакытта ак патшаның яхшы күңелле булуына ышанып, сеңелесенең катыр китүенә сәбәпче булуы өчен ул үзенә ничә еллардан бирле рәнҗи. Әмма һаман да тынычлана алмый.

Моң-сагышы үзәгенә үтеп, йөрәге бик сыкрый башлаган бу кара көндә Кируш ата-бабаларыннан калган, хәзер бердәнбер юанычы булган скрипкәсен уйнарга тотына. Әмма аның йөрәкләрне кысып китерә торган ул авыр моңы бер генә тәрәзәле кечкенә өенә сыя алмый башлый да ул урамга килеп чыга. Нинди генә үзәк өзгеч моң-зар чыкмый ул борынгы скрипкәдән! Аннан елаган тавыш та килә, ыңгырашкан тавыш та, ул да түгел, ерак Себернең кышкы салкынында буран-пар улаганны да ишеткәндәй буласың.

Моны ишетүгә, бере артыннан бере капкалар ачылып, олысы-кечесе урамга чыгалар. Апа-җиңгиләр күзләрен сөртә башлый, бабайлар, таякларына таянып, башларын аска иеләр. Күңелнең әллә кай төшләреннән газаплы дулкыннар кузгала. Кешеләр бер-берсенә сүз катмыйча, Кирушка күтәрелеп карамыйча, татары-керәшене бу газелсезлеккә үзләрен дә гаепле санагандай, аяк башларына карап калалар.

Менә бүген дә шулай уйнап урам әйләнә торгач, Кируш, сеңелесе киткән юлдан бара-бара, пар нарат янына килеп чыкты. Аның сары күлмәк өстеннән кигән елтыр кара жилеты чишелеп киткән, чалара башлаган тузгак чәче маңгаена төшкән. Ул берни дә күрми, скрипкәнең үзәкләрне өзгеч сагыш-моңыннан бүтән берни дә ишетми иде.

Кируш агайның скрипкәсе пар наратка якынайган саен тагын да зарлырак, тагын да кайгылырак уйный башлады. Бикә карчыкның башы аның саен түбәнгәрәк иелде, гәүдәсе, аны нәрсәдер рәхимсез рәвештә баскандай, һаман кечерәя, җиргә сеңә барды.

Җиләктән үзебез генә кайттык. Бикә карчык ягына әйләнеп тә карыйсы килми башлады.

## Шаң-шаң итеп ни шаңгырдый?

### I

Бер көнне җәй башында кармакларны күтәреп капкадан гына чыгып бара идем, өйалдыннан дәшеп апай туктатты:

— Гомәр, дим. Минем яныма керче!

Беләм инде, беләм, эш кушмакчы! Елның бу вакытында безнең авылның хатын-кызлары атналар буе киндер сугалар. Безнең апай тагын, аннан тыш, сөлге-тастымал да, ашъяулыклар да суга. Хәзер менә миңа я шүре ясатыр, я стан янына утыртып, кылыч тотарга кушар. Иптәшләремнән аерылып, ирекле баштан, җептер, шүредер, стандыр-фәләндер арасына, тузан эченә кереп утырыр хәлем юк әле!

Болай гына күндерә алмагач, апай мине кызыктырырга тотынды:

— Я инде, Гомәр җаным, кер инде! Мин сиңа бик матур итеп кулъяулыгы чигеп бирермен. Акбүзгә дебет беләп. Чәчәкләр төшереп.

Капка төбендә иптәшләрем күзләрен мөлдерәтеп миңа карап тора, мин әле бүген генә озын тал чыбыкка таккан өр-яңа кармакларыма карыйм. Ямь-яшел болын тугайлары, Каенсар суының тын гына аккан матур борылышлары күз алдыма килә.

— Әем, кермим! Яулыгыңның бик кирәге бар менә!

Монысы апайның ачуын китерде.

— Һи, юньсез! Соңыннан үкенерсең әле. Мин сиңа чиккән яулыкның читен дә күрсәтмәм!.. Я, нәрсә кирәк соң сиңа?

— Бер нәстә дә кирәкми, балыкка барам мин!

— Алайса, мин сине Кибәхуҗа җыенына алып барырмын. Ярыймы? Яңа кәләпүш алырбыз. Ерак әби сыйлар үзенне.

Аһ, ул җыеннар, озак та калмады бит инде! Әллә...

— Юрамалый гына әйтәсең, барыбер алып бармыйсың!

— Вәгъдә бит инде! Вәгъдә, вәгъдә!

— Валлаһи диген!

Апай, йөгереп килеп, минем аркамнан сөяргә тотынды:

— Билләһи менә, валлаһи!

Тик апай теләгенә ирешә алмый калды. Без шулай килешә генә башлаганда, капкадан Кибәхуҗаның Ерак әби килеп керде. Ул килгәч, кая инде...

Әбинең өстендә ала-кола бикасәп камзул, башында тар гына кама тоткан сай бүрек, баш түбәсендә кызыл ашъяулыкка төргән зур гына

төенчеге бар. Ул төенчектә һәрвакыт чиккән ашъяулыклар, кызыл башлы сөлгеләр, тастымаллар, чиккән намазлыклар, тагын шундый һәртөрле хатын-кыз кирәк-ярагы була.

Әбинең кечерәк кенә түгәрәк ипи хәтле булып бөкресе дә чыккан инде, авызы да бераз чалышая төшкән, тешләре дә берән-сәрән генә калган. Шунлыктан сөйләшкәндә сүзләрен аңлавы да кыенлашып бара. Шулай да аның кодрәте белән дәрәҗәсе искитмәле иде. Уллары-кызлары аның белән киңәшмичә бер генә зур эш тә кузгатмый диярлек. Чәчүгә чыгу буламы ул, уракка төшүме, балаларны укырга бирүме, тегүгә чыгумы, парлап кунакка барумы — һәммәсенә карчыкның рөхсәтен сорап, фатихасын алалар иде.

Әби кеше тәсбихен тарткан көйгә башын ия-ия тыңлый да:

— Шулаймы? Алай икән... — дип куя. Байтак уйланганнан соң иң соңгы сүзне ул әйтә: — Соң, ярар, мәслихәт. Хәерле белән!..

Бик озаклап чәй эчкәннән соң Ерак әби сәке түрендә иркенләбрәк аякларын сузып утырды да, тәсбихен тарта-тарта, күзләре белән апайга ишарә итте.

— Утыр әле, кызым, — диде.

Апай сискәнеп киткән сыман күренде, әбигә яны белән борылып, яулык почмагын сыпырырга тотынды. Аның озын керфекләре ара-тирә дерелдәп киткәли иде.

Әби сөякләч куллары белән мине этебрәк җибәрде.

— Син бар, уеныңда бул!

Кая инде ул уен! Мина шундук эш таптылар. Югары очтан көтү кайтып килә икән. Бөтен авыл хәрәкәткә килде. Өйдә калган бозаулар кычкырырга тотынды. Капка төпләренә көтүне каршы алырга дип апайлар, җингиләр, карт-карчык белән бала-чага чыгып басты.

Көтүгә каршы барышлый минем яннан иптәш малай Нимҗан кычкырып узды:

— Сакалы бар, акылы юк. Ул нәрсә?

Мин әйтә алмый торгач, сикерә-сикерә куанды.

— Әһә! Белмисең, белмисең! Оныттыңмыни? Китапта шулай язган бит!

Көтү башына карасам, озын сакалларын сәлпәйтеп, мөгезләрен тырпайткан хәлдә, сарык һәм сыер халкы белән янәшә йөреп ваксынасылары килмичә, кәҗәләр кайтып килә иде. Әйтерсең аларны акылсыз дип!

Урамга тозлы сыманрак бер җылы ис, сөт исе, җылы йон исе аңкып, вак кына соргылт-кызыл тузан күтәрелде. Төрле яктан кулына бер сынык ипи тотып чыккан апай-җиңгиләрнең сарыкларын дәшеп көйләүләре ишетелә башлады:

— Бәрәч, бәрәч, бәрәч!

— Тәч, тәч, тәч!

— Бәти, бәти!

— Җибәрмә, Мәликә, тыкрыкка җибәрмә! Каршыларына чык!

— Ипиеңне суз, иснәт ипиеңне!

— Һа-һа-һа! Шуны да тота алмый!

Таныш тавышка борылып карасам, Миңниса, имеш. Менә бит әй! Әле бая гына ялан аяк иде, ни арада аягын киенеп, өстен алмаштырып өлгергән? Алдында күкрәкләре чиккән ак алъяпкыч, өстендә бала итәкле зәңгәр күлмәк, башында колак артына җибәреп бәйләгән ал яулык, колак яфракларыннан тамчылы гөлнең чәчәге төсле алсу алкалары тамып тора.

Кара син, теге вакыттан бирле Миңниса ярыйсы ук үскән. Аяк башларын эчкәрәк каратып, боргалана төшеп атлый. Янәсе, җиткән кызларга охшарга тырыша иде.

Ул, якында гына булса да мина күз дә салмастан, көтүнең каршысына кулларын-аякларын җәеп килеп басты да әле бер якка, әле икенче якка сикерә-сикерә сарыкларын аерырга тотынды. Ул терекөмеш шикелле тере, тиен кебек житез иде. Алай итте, болай итте, боргаланды-сыргаланды да, борынын чөя төшеп, чыбыгын болгый-болгый, җилжил атлап китеп тә барды.

Һи, чытлык! Бик исем китә...

Үзем терлек-туар тирәсендә чуалам, әмма күңелдә гел апай. Өйдә нәрсәләр бар? Әби нинди уйлар белән йөри икән? Апай нигә сискәнде икән?

Бераздан, чиләк-көянтәсен күтәреп, апай суга барырга чыкты. Мин, әллә кайчаннан күрмәгән кеше шикелле, аның каршысына барып бастым.

— Апай!

Аның борчулы чырае бераз яктыра төште. Тик ул бер сүз дә әйтмәде. Күзен тутырып мина бераз карап торды да иңбашыма кулын тидереп алды. Нишләптер мина бик рәхәт тә, моңсу да булып китте. Яратам бит шушы апайны, усалрак булса да яратам! Мин инде моннан соң апай стан янына чакырганда, бүгенгә кебек карышып сатулашмаска булдым.

## II

Менә бервакыт түбән очтан кызларның, дәртле бер уенчак көйгә салып, шыңгыр-шаңгыр киндер тукмаклаган тавышлары ишетелә башлады. Кичке тынлыкта ул бер акрыная, аннары тагын көчәеп китә иде. Эшемне аннан-моннан бетердем дә шунда киттем. Кем тирәсенә барасын шәйләп тә торасы юк, аяклар үзләреннән-үзләре шул тавышка таба гына атлый.

Кояш баеган инде баюын, шулай да энгер-меңгер төшеп күз бәйләнер чак җиткәнче әле тагын бераз вакыт бар. Әле ярканатлар уйный башларга да, бакалар сайрарга да иртә. Бу вакытта шундый тын була, хәтта этләр дә өрергә кыймый, казлар да каңгылдамый, кешеләр дә кычкырып сөйләшми.

Кояш баешы авыл өстенә күзне чагылдырмый торган тоныкк кына, ягымлы гына алсу нур җәйгән. Бишна урманы өстендәге шул алсу чаршауны кемдер акрын-акрын гына һаман кыса барадыр кебек тоела. Чаршау тарайган саен, сизелер-сизелмәс кенә, гүя җир йөзен ташлап китәргә теләмәгәндәй, шәфәкъ нуры да сүрелә, сүнә бара...

Җыр түгел, гармун тавышы да түгел, шулай да тансык иде ул аваз. Ул, шаң-шаң итеп, авыл өстенә саф тавышлы яшь егет җырыдай шатланып күтәрелә. Бу яңгыравыклы көй урам буенда башларын иеп йокымсырап утырган өянкеләргә, шомырт белән милләшкә, сәрби агачларына, өй түбәләренә орына-орына бөтен авылны әйләнә. Тәрәзә төбендәге исле гөлләр, кыналар, тамчылы гөлләр арасыннан өй эченә кереп, кичке чәен эчеп утыручы әбиләр колагын да рәхәтләндереп уза. Аны капка төбендә әңгәмә корып утыручы агайлар белән бабайлар да, сыер савып керүче апайлар, җиңгиләр дә — һәммәсе дә сүзләрен бүлеп, эшләреннән туктап тыңлыйлар. Бу яңгыравыклы шат көй һәммәсен дә искәртеп уза кебек:

— Тәрәзәңне ябып бетермә әле син! Шундый ягымлы кичтә гамьсезләнеп йокларга да ашыкма. Беләсең бит, мондый кичләр гел генә булып тормый, кызлар да киндер йомшартырга көн саен чыкмый. Тыңлап карале син, яшь йөрәкләр ни әйтә, кызлар күңеле ниләр дип сайрый икән?

Әсәрләнеп тыңлый-тыңлый да:

— Һай! — дип куя бабай, таягын тукылдатып. — Бар иде бит асыл чаклар, арслангай гайрәтле, аттан таза ир чаклар! Һай, дөнья!

Яшьрәк апайлар, киленнәр эңгер төшеп килгән тын өендә, миләш сиртмәсен сыгылдырып, көйли-көйли баласын тирбәтеп утыра. Күзләрендә җинелчә генә моң, ирен кырыйларында ачылып җитмәгән чәчәк таҗчыгыдай, эленеп кенә торган елмаю нурлары:

Әллиһу, бәллиһу,
Кәҗәләрне тауга ку.
Кәҗә үлән ашасын,
Улым йоклый башласын.

Һай, гомерләр! Әле кайчан гына ул да бит менә шулай бирнә маллары әзерләгән иде. Әле кайчан гына кулында киндер тукмагы уйный, инендә чиләкләр сайрый иде. Менә хәзер инде бишектә сайрый башладылар...

Шаңгырдап чыккан шул агач көе ничек шулай бөтен авылны дулкынландыра ала икән? Әллә югыйсә яшь кызларның кичке моңнары, тыелгысыз яшьлек дәртләре, ни икәнлеген үзләре дә аңлап җиткермәгән ниндидер куанычлы һәм тынгысыз хыяллары шундый яңгыравыклы авазга әверелеп көй булып чыга да бүтәннәрнең дә яшьлеген уятып йөрим икән?..

Киндер йомшартучылар парлы-парлы дүрт кыз булып чыкты. Берсе күршенең Мәликә апай, аның пары — Сарник кызы Сәхипҗамал икән. Бүтәннәре түбән оч кызлары. Өсләрендә яңа, бәйрәм күлмәкләре, башларында зәңгәрле-яшелле, сарылы-кызыллы шәлъяулык, кулларында көмеш беләзекләр, балдаклар ялтырый. Шушы сәгатьләрне көтеп күп еллар печәнлектә кибеп яткан нечкәрәк сөян бүрәнәне ике башыннан бауга элгәннәр дә киндерләрен шуңа асканнар. Кечерәк кенә икешәр тукмак белән, ике яктан торып, шул киндерне алмаш-тилмәш кыйный бирәләр.

Мәликә күрше безнең апайга кул алмашка чыккан. Ул, көйне бозудан сагайган сыман, тукмакларыннан күзен дә алмый, бер җайга бәрепме бәрә. Сәхипҗамалы тererәк, шаянрак. Аның ут төсле кызгылтсары чәче яулык читеннән тузгып чыккан, шәлъяулыгы иңбашына төшеп бара, күзләре ялт та йолт егетләр ягына карана. Аның көй ритмына куллары гына түгел, иңбашларына хәтле уйнаклый, үзе әле бер җыр, әле икенче җыр такмаклый:

Тук-тук тукран,
Тукылдатып утырам.
Тизрәк яучы җибәрмәсәң,
Ябышып чыгам, чукынган...

Егетләр ягында дәррәү килеп көлешеп алдылар.

Киндернең тукмакланган өлешен җайга гына аска тартып торучы яшүсмер кызларның берсе әлеге дә баягы Миннниса икән. Мине күргә, ул, күзләрен уйнатып, иптәш кызына ым какты:

— Күрдеңме, янәсе!.. Кил дидем, килде!

Ул гына кирәк иде, бик исем китте менә! Мин, аларга күз дә салмаска тырышып, иптәш малайларым янына барып утырдым.

Мине бүтән нәрсә борчый иде. Монда чыгар алдыннан әни миңа бик сәер нәрсәләр әйтте:

— Улым, нисәнә, — дип башлады да ык-мык итте, сүз таба алмыйча, беравык тотлыгып торды. — Ниең, апаең тирәсендәрәк йөрсәнә, яме?!

— Әем! Ул итәгенә тагылып йөргәнне яратмый!..

Әни уңайсызланды. Аптырагач, минем аркамнан сыйпагандай итте.

— Юк ла инде, тагылып йөр димим бит мин. Син, нимә! Иркенләп уйнасын, көлсен, тик кызлар арасында булсын, берүк, читкә тайпылмасын да күздән югалмасын!

— Әгәренки тайпылса?

Эни куркып китте:

— Алла сакласын! Юк, тайпылмас, боерган булса, андый бала түгел. Бар, улым, бар...

Мин килгәндә, апайның нәкъ әнә шул «тайпылган» чагы иде.

Ул, бераз читкәрәк китеп, Әхәт абый белән сөйләшеп тора. Тегесе киртәгә ике куллап чытырдатып ябышкан да, терелэй йотардай булып, апайга текәлгән. Апай башын түбән иеп, яулыгының почмагын авыз кырыена элэктергэн килеш, гаепле кеше сыман, аска караган. Аның болай коелып төшүе миңа ошамый да, аңлашылмый да иде. Әллә югыйсә, чыннан да берәр хәл булганмы?..

Ул арада авыл өстенә эңгер-меңгер иңә башлады. Якындагы эвеннән бер чыгып, бер кереп, баш очында арлы да бирле атылып, яркапатлар уйнарга, тырылдап коңгызлар очарга, инештә бакалар сайрарга тотынды. Арпа елгасы ягыннан тартай белән бытбылдык тавышы ишетелде.

Кызлар белән егетләр дә күбәйде. Берсе гармун да тартып җибәрде. Килгән берсе апай белән Әхәткә күз салалар да, мәгънәле генә итеп, бер-берсенә ым кагалар.

Ул да түгел, Сәхипҗамал кинәт туктап калды.

— Сабыр, Мәликә апай! — диде. Киндернең йомшартып узган башын кире кайтарып алды да капшап күрсәтте. — Менэтерәк, бу төше гүпчи дә шомармыйча калган. Өммикамал апайның бирнәсен болай кытыршы калдырсак, кияве шадра булыр бит! Һа-һа-һа!

Шунда миңа күзе төште дә уены-чыны белән төкеренергә тотынды:

— Тфү-тфү! Әйттем исә кайттым, әйтеп кенә бактым. Шайтан телемнән тартып кына әйттерде, Гомәр җаным! Бер дә исең китмәсен, шадра йөрәк яндыра, ди ул. Билләһи!

Ул миңа карап каш-күзләрен шундый матур иттереп ясады, ачуланыр җиреңнән дәшми калырсың.

Мәликә апай киндерне кулы белән сыйпап, битенә куеп карады да икеләнә калды. Калын тавышы белән матур гына көйли төшеп:

— И күрше генәм, — диде. — Бер дә генә дә кытыршы шикелле түгел дә соң болай югыйсә. Өммикамалның кыңгыраулы бирнә сандыгында әллә моның ише генә батармы?

Сәхипҗамал тагын каршы төште:

— Юк, юк! Күңелдә нокта калмасын! Өммикамал апай — авылның беренче остасы. Килен булып төшкәч, кодагыйлар бирнә малы карагандa берәр гаебе чыкса, оятын кая куярсың?

— Болай да ефәк шикелле шома, мамык шикелле йомшак та бит инде югыйсә. Тагын да шомара төшсен дисеңмени?

— Дим, дим! Кияү тәненә май булып кына тисен, дим.

Мәликә апай каш астыннан гына апайлар ягына күз атты.

— Боларны кигән саен мәхәббәтләре арта торган булсын дисеңме?

— Дим, дим.

— Гыйшыклары кайнар булсын, гомерләре матур узсын дип тә әйтәсеңме?

— Әйтәм, әйтәм! Киндере ак булса, күңеле дә саф, йөзе дә ак була диләр түгелме соң олылар?..

— Диләр бугай шул...

Шунда әлеге сары мыеклы карт егет Сәлимнең бер калынаеп, бер нечкәргән елак тавышы ишетелде.

— Һи, мәнсезләр! Теләнегез, теләп! Менә күрерсез, алай дигәнегез болай булып чыгар! Козгыннар йөри Өммикамаллар өстендә, козгыннар!..

Кызлар төрле яктан Сәлимне шелтәләргә тотындылар:

— Ни эшкә шулай карга булып каркылдарга инде!

— Сәлим абыйның гомергә шул инде аның. Аннан бер юньле сүз ишетмәссең.

— Нәрсә? Әллә дөрес булмас дисезме? Минә күрегез дә торыгыз! Кайберәүләрнең борын астыннан елт!

Сәлим көлеп бетерергә дә өлгермәде, Әхәт, очынып барып, аның якасыннан эләктереп тә алды.

— Нәрсә син, карт алаша, һаман шул бер нәрсәне чәйнисең? Нигә шултикле телең кычытып тора? Ә?! Нинди үчең бар? Әйт!

Сәлимнең төсләре китте, болай да чыелдык тавышы тагын да елаграк ишетелә башлады. Тотынды карганырга, кызгандырырга:

— Билләһи газим, шаяртып кына! Җир йотсын, юрамалый гына!

Тик Әхәт аны тыңлап тормады. Җан-фәрманга кизәнеп сугуы булды, ауды да китте теге. Кәләпүше бер якка тәгәрәде, үзе икенче якка. Китте шуннан чыр-чу, китте көлешү. Сәлим, иркә малайлар шикелле:

— Әтигә әйтим әле мин сине! — ди-ди кырын-кырын бөтенләй үк китеп барды. Уенның рәте чуалды. Егетләр тагын беразга калырга димләп карасалар да, кызлар, киндерләрен култык астына кыстырып, өйләренә йөгерделәр.

## III

Лапастагы йомшак печән өстенә кайтып сузылуыма төрле-төрле хуш-ис эчендә калдым. Рәхәт! Шул чәчәк исләренә исереп, йоклап кына китәсе югыйсә. Әмма күңелем тыныч түгел. Күреп, сизеп торам: Ерак әби килгәннән бирле апай үзен кая куярга белми. Бәлки, ул Әхәтне ярата торгандыр? Ә минә әби, икенче кешегә димли, ди.

Нишләптер әни дә бик борчулы. Йөри-йөри дә берәр җирдә туктап уйга кала. Чырае да караңгы. Бая, кайтып кергәч, миннән дә бик төпченеп сорашты:

— Бик күңелле булдымы соң?

— Ярый инде, күңелле... — дидем.

Ул минем иңбашыма кулын салды, башымнан сыйпады.

— Кемнәр бар иде?

Мин берән-берән андагы кызларны, егетләрне санап бирдем.

— Тагын, тагын?

Әнинең кемне әйттерәсе килүен сизеп торам. Ләкин минем аны әйтәсем килми:

— Күп инде, күп, — дидем. — Түбән очлар, югары очлар...

— Бәргәләшеп тә алганнар түгелме соң?

— И, егетләр арасында андый гына була инде ул...

Шулай да бүген кич нидер булыр шикелле.

Мин күземне йоммаска булдым.

Лапас түбәсе белән койма арасыннан янәшә өч йолдыз күренде. Алар күк йөзендә төрлесе төрле якта, бик еракларда әйләнеп йөргәннән соң, бик сагынышып очрашканнар булса кирәк. Хәзер минә, бик якын дус кызлар шикелле, күзләрен җемелдәтеп кыса-кыса, үзара бертуктаусыз сөйләшәләр, сөйләшеп сүзләре бетми, елмаешып шатлыклары кимеми. Мөгаен, алар күк йөзенең без белмәгән искиткеч серләре турында хәбәрләшәләрдер.

Ята торгач, араннан ап-ачык булып атның кетердәтеп башак ашавы колакка чалынды. Ул шулкадәр яратып, шундый тәмле иттереп ашый, әйтерсең лә, аның алдында башак кына түгел, берсеннән-берсе тәмлерәк әллә нинди ризыклар.

— Мөкерт-мөкерт, мөкерт-мөкерт...

Бирелеп тыңлый торгач, атның күзе өстендәге эчтерхән чикләвеге сыярлык кына йомры чокырының бер күмелеп, бер ачылуы, уртлары-

ның бармак юанлыгы булып ике якка калкып чыгуы, башагын борыны белән чөеп-чөеп җибәрүе күз алдына килде.

Шунда төн саен, кеше аягы сил булгач, ләтчә ана ял итәргә ирек бирмичә, озын кара ялын чуалтып бетерүе искә төште дә мин атны кызганып куйдым. Аңа күңелле булсын өчен «әһем, әһем...» дип тамак кырдым.

Бия ашавыннан туктады. Янына килә дип белде, ахрысы, алдан ук рәхмәт әйткәндәй, авыз эченнән генә кешнәп куйды: — «Әәһе-һе-һе...»

Киләме, юкмы дип байтак вакыт шыпырт кына тыңлап торды. Аннары авыр сулап алды.

Тау астындагы инештә төрле тавыш белән бакалар сайрарга тотынды. Болын ягыннан тартар белән бытбылдыкның үзләре генә белгән телләрендә бер-берсенә бик тәмле итеп нидер әйтүләре ишетелә; ара-тирә зират астындагы тегермән арыгында су шаулавы килеп җитә.

Ишек алды торган саен караңгылана барды. Төн тәрәзәләргә кунган шәфәкъ яктысын соры канатлары белән сөртеп үк алды. Лапас эчләренә, арба асларына, почмак һәм аралыкларга мул булып, һаман куера барып, соргылт караңгы тулды.

Апай һаман чыкмый иде әле. Бөтен өйдә йоклаганнар, бары югары өйнең кечкенә ягында гына ут бар. Күрәсең, Ерак әбидер, димлидер, үгетлидер...

Йокы, мине үзенең йомшак кочагында тирбәтә-тирбәтә, бөтен тәнемә татлы рәхәтен иңдерә. Кош мамыгыдай йомшак канаты белән сыйпап, үземә сиздермичә генә, күзләремне йомдыра. Бөтен тәнемне ләззәтле бер талгынлык биләп ала да мин, ничектер, бик тын гына, җайга гына әйтеп бетермәстәй татлы рәхәт эченә күмелә башлыйм.

Тик шунда апайның һаман да чыкмавы исемә төште. Мин, авыз суларымны китереп каба гына башлаган тәмле ризыкны кире куйган кебек, йокымны читкә этәреп, күземне ачтым.

Баягы йолдызларның икесе, иптәшләренең берсен ялгыз калдырып, каядыр китеп барганнар. Ялгыз калганы, күрәсең, үзенә генә күңелсез булгангадыр, елыйсы килгән сыман нурын мөлдерәтеп еш-еш күзен кыскалый иде.

Тагын бер күтәрелеп карасам, югары очтан арба тәгәрмәче тикле дәү, чия төсле алсу-кызыл булып ай калыккан да бөтен авыл өстенә аның кызгылт шәүләсе җәелгән.

Ул да түгел, югары очта егетләр гармун уйнап җибәрде. Шундук чүлпыларын чылтыратып, апай да чыгып җитте. Егетләр якынайган саен, апай тынычсызлана башлады. Ул әле авыр сулап куя, әле башын ия дә уйга кала, әле койма ярыгына каплана. Аның муенсасы ай яктысында ялт итеп бер кабына, бер сүнә.

Безнең турыга җитәрәк, егетләрнең берсе (мөгаен, Әхәттер!) гармун көенә сәер генә җыру да әйтте:

Йөгереп төштем су буена,
Кереп киттем таллыкка;
Егеттән егет ким түгел,
Кимсетәләр мал юкка.

Апай «аһ!» итте, чүлпыларын тота төшеп, житез генә бакча ишегенә таба атлады. Мин сикереп тордым:

— Апай! Туктале! Әллә син... нимә?.. Ябышып чыгасыңмы?

Апай кинәт туктады. Миңа аның өзек-өзек сулыш алуы ишетелде. Бераздан мин апайның акрын гына кире килүен абайладым. Койма буеннан шыпырт тавышы ишетелде:

— Юк ла! Син тагын!

Миңа, әгәр Әхәт абый тагын шундый берәр кызганыч җыру җырласа, апай яңадан бакча ишегенә ташланыр да, ул вакытта инде аны

берничек тә тыеп булмас шикелле тоела башлады. Китеп барса, харап бит! Нишләргә?

Нәкъ шул вакыт Әхәт абый, безнең бакча артына төшеп җиткәч, тагын җырлап җибәрде:

Эчем яна, эчем яна,
Беләмен ник янганын;
Сөйгәнемне ятка бирмим,
Күрмим ятка калганын...

Апай, еларга җитешеп, нидер пышылдый башлады. Аның ни әйткәне ачык ук ишетелми, шулай да ул «Нишлим соң?!.» дип өзгәләнде шикелле.

Егетләр ерагая төшкәч, мин апайга тагын сүз салып карадым:

— Әхәт абыйга чыксаң, килен булып кайда төшәрсең икән соң? Сандыкларыңны кая куярсың? Ул байларга ялланган саен, үз авылыңда килмешәк булып, йорттан йортка йөрерсеңмени?

Әмма апай мине, әйтеп бетермәс борын ук, битәрләп ташлады:

— Авырттырма юк белән башыңны! Тик кенә ят! Әнә ярканат! Борын астыңны сыйпап китсә, гомергә сакал-мыексыз калырсың!

Чыннан да хәтәр нәрсә бит ул! Әнә бит, ярканат сыйпап киткәннән соң, Хәми абзыйга бөтенләй сакал-мыек чыкмаган, карчыклар бите төсле шәп-шәрә калган...

Авыл күптән йоклаган иде инде. Инештәге бакалар әллә кайчан тынды. Болындагы тартар белән бытбылдыкның да әңгәмәләре өзелде. Шушы караңгы тынлыкка түзә алмагандай зарланган тавыш белән кайсыныңдыр иске әвенендә мәче башлы ябалак иңрәп алды:

— Уһу-һу! Уһу-һу!

Бераздан кечкенә капка чыелдаган тавышка уянып китсәм, апай бакча капкасыннан чыгып бара. Мин йокыдан арынмаган иләс-миләс килеш куркуымнан кычкырып җибәрдем:

— Апай, апай! Кая киттең?

Бакча ягында кемдер агачлар арасында кыштырдады. Апай, җилтерәп килеп, мине кире яткырды.

— Ни пычагыма акырасың? Кара аны! Тының чыкмасын!

Әмма соң иде инде. Күрәсең, өйдә йокламаган булганнардыр, кинәт безнең янга ап-ак күлмәктән әти килеп чыкты. Аның сүзе кыска булды. Ул апайга:

— Өйгә кер! — диде дә, аны ишектән кертеп җибәреп, үзе баскыч төбенә килеп утырды.

## IV

Бер заман киңәш-уңашлар, белешү, сорашулар туктады, икеләнүләр бетте, апайны ярәштеләр. Кем ул Кибәхуҗа егете Нәбиулла? Апай аны күргәнме, аңа барырга үзе риза булганмы? Әллә ата-ана кушуына каршы тора алмыйча гына буйсынганмы? Бу турыда йортта сүз кузгалмады шикелле.

Ярәшүен ярәштеләр, әмма булачак туй йортка куаныч белән килергә җыенмый, берсенең дә күңеле тыныч түгел. Аның бик җитди сәбәбе дә бар иде.

Бер көнне төнлә йоклар алдыннан әти ниндидер кыштырдаган тавыш ишетеп бакчага кергән икән, апай йоклый торган бүлмәнең тәрәзәсенә үрелгән бер карамчык күргән. Караса, Әхәт, ди. Әти, кул астына туры килгән күсәкне эләктереп, тегенең өстенә ташланган.

— Моңарчы утка салуың җитмәгән, әле тагын йөрисең икән, оятсыз! — дигән.

Әхәт чуен багана шикелле этинең алдына килеп баскан килеш:

— Ник килмим? Менә монда ул минем! — дип дөп-дөп күкрәгенә суккан.

— Юк шул, зимагур! — дигән эти. — Андагысы җил генә аның, бер атнадан фи-ит, оча да китә! Өйләнүем дисең икән, иң элек менә монда булырга кирәк! — Эти шап-шап иттереп кесәсенә сугып күрсәткән. — Кая алып кайтырмын дип уйладың? Нәрсә ашатырмын дип? Коры гыйшык тамак туйдырамыни?

— Соң анысына барып җиткәч әле...

— Барып җитеп узып киткән инде, узып. Белмисеңмени, яшьлек кәтми яшьлек сабырсыз!

Әмма Әхәт этине этеп кенә җибәргән.

— Белеп торыгыз! Мин алай гына үз сүземнән кайтучы егет түгел. Аны карагыз! Үкенерсез дә, соң булыр! — дигән.

Шуннан соң апай югары өйнең кечкенә ягына кереп йомылды да шуннан чыкмас булды. Этинең эшкә кулы бармый башлады. Верстагы янында әле теге эшенә, әле монысына тотынып караган була да, берни дә барып чыкмагач, бөтенесен атып бәрә.

— Менә сиңа тамаша! Менә аяк астыннан чыккан бәла! Каян шуның белән башын бәйләгән бу йөзе кара кызый? Шул йортсыз-җирсез сөрхәнтәйгә ничек күзе төшкән?!

Әни бөтенләй авыруга сабышты. Иләс-миләс килеп ары сугыла, бире сугыла да, хәле беткән сыман, сәке кырыена килеп утыра. Уйлана-уйлана да уфылдап куя.

— Ярабби, мәрхәмәтеңнән ташлама, сиңа тапшырдык инде, — ди.

Шулай сызланып-инәлеп утыра да тагын торып китә.

Кичен, әни белән эти икәү генә калганнан соң, бу борчуның икенче бер ягы калкып чыга иде. Апайның Әхәт белән күптән ук яратышып йөрүләрен бөтен авыл белә. Аның атналар буе ләм-мим бер сүз дәшмәве, берәү белән дә сөйләшмичә, уйнап-көлмичә берүзе бикләнеп утыруы эти белән әнине шомлы уйларга төшерде.

— Ай-һай, эшләр зурга киткән булмагае! — ди эти. — Алай булмаса, ничек шултикле аяк терәп сөйләшер иде икән ул зимагур? Нишләрбез? Халыкка ни йөзебез белән күренербез, хурлыгын ничек күтәрербез?

Әни алай ук булачагына ышанмавын әйтеп, этине ничек тә юатырга, тынычландырырга тырыша иде:

— Өммикамал ул тикле башсыз бала түгел. Юк, юк! Алай дип уйлама! Исән-сау, хәвеф-хәтәрсез генә иясенә тапшырырбыз әле, боерган булса!

— Ай-һай! Ышанма яшьләргә, ышанма! Алдын-артын уйламас, тәки хур итәр, тәки гүргә кертер!

Борчуларның шундый кайнап торган бер мәлендә туй хәстәре башланды. Туйдан соң абзарда ничә генә сарык калгандыр, туй күпме тавыкның, ничә баш каз-үрдәкнең башына житкәндер, келәттә күпме генә он калгандыр, мондый чакта анысы белән исәпләшмиләр.

— «Сыртым сынса да бирмәм!» — ди агайлар. Чөнки туй дигәннәре кеше гомерендә бер генә килә. Туган-тумача, кардәш-ыру, якын-тирә алдында берәүнең дә сынатасы килми. Туй нихәтле шәп булса, никах та шултикле нык булырга тиеш. Үен эш түгел ул туй, түгел!

— Кыз баланың ата-ана йортында иң соңгы бәйрәме инде бу. Әйдә, бездән калмасын! Соңыннан ай-һай лабаса дип үкенерлек булмасын, — диде эти.

Сарыклар да суелды, бал белән сыра да мул куелды. Арчадан поты бер тәңкәлек ак капчыклы, кызыл пичәтле ак он да алынды, «кызыл

башлы» чиреклэр дә, тегермән ташы тикле базар күмәче дә, куй мае, йөзем җимеше дә, бүтәннәре дә мул кайтты.

Башланды чистарыну, төзәтенү, мичләр, морҗалар, мунча мичләре агарту, чаршау, чыбылдык, күлмәкләр тегү, китте тазарыну-юыну, киенү-ясану. Хатын-кыз иртәдән кичкә кадәр, тыз да быз, өй белән келәт, баз белән өй арасында кайнаша. Ир-ат ком белән ышкып, эшлия-камытларның тәнкәләрен ялтырата, дугалар буйый, каеш йөгәннәрне дегетли, ишек алларын, капка төбендәге яшел чирәмнәрне себереп куя.

Безнең ише малай-шалайны иртәдән кичкә кадәр йомышка куалар. Әле кибеткә йөгер, әле берәрсеннән әйбер алып кайт.

Менә туй көне дә килеп җитте.

Көтә торгач, югары очтан кыңгырау тавышлары ишетелә башлады. Китте каушау, йөгереш, кабаланыш. Җыелды капка төбенә халык.

Менә кодалар, урам буенча тузан туздырып, кош-кортны куркытып, килеп тә төштеләр. Капка төбенә җыелган яшь-җилбәзәк санап тора:

— Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты... сигез пар! Ай-ай-ай! Зур да туй буласы икән бу! Кибәхуҗадан гына сигез пар!

Иң алдагы атта — баш кода. Башында камалы бүрек, өстендә кызыл төймәле кара бишмәт. Аның эчендә җилән, аның да эчендә камзул. Эссе кояш астында яңакларыннан шыбырдап тир ага.

Тарантастан төшүләренә, каршыларына кулын сузып, башта әти, аның артына посыбрак, шәлъяулык почмагын ирен кырые белән тешләбрәк, әни бара. Аннары бөтен өере белән абыйлар, җиңгиләр, җизниләр кузгала.

Иң беренче сүз этинеке:

— Исәнме, саумы, кода, таза-сау гына килеп җиттегезме? Уллар-кызлар исәнме? Йорт-җир, мал-туар иминме? Хәвеф-хәтәр юкмы?

Аңа кода бабай да шулай ук ягымлы сүзләрне бере артыннан берен тезеп кенә, бормалы-сырмалы итеп җавап бирә:

— Ходайның биргәненә шөкер әле, кода. Үзегездә исәнлек-иминлекме? Бик ару гына торып ятасызмы? Бала-чага үсәме, авыру-сырхау юкмы? Мал-туар аллага шөкерме?

— Бик-бик шөкер, кода, бик шөкер!

Башлана кара-каршы елмаешып кул кысышу, шул уңайдан бер-берсенә матур-матур сүзләр әйтешү.

Ишек алды тулы кода, кодагый, кодача. Кодалар гел актан да карадан гына киенгән. Кодагый белән кодачаларның өс-башы нәкъ чәчәк атып яткан болын төсле: яшел дә зәңгәр, алсу да бишни, кызыл да сары.

Шунда минем әллә ничек кенә этигә күзем төште. Сакалын бик пөхтәләп, түгәрәкләп кенә кырып җибәргән. Яңа кәләпүшен сизелер-сизелмәслек кенә итеп, нәни генә кыңгыр салган. Чыбык юллы ак күлмәгенең камзул өстенә төшеп торган кайтарма якасы, яңа гына теккән кара камзулы, яшел үкчәле яңа читеге аны бераз яшәртеп, бәйрәмчә кыяфәткә керткән. Күзләре шундый сөйкемле, йөзендә шундый куаныч балкый, әйтерсең, гомер буе шулай туйдан-туйга күңел ачып, кодалап кына яшәгән. Ул баскыч төбендә әледән-әле баш иеп, кулларын киң җәеп кодаларны өйгә дәшә.

— Әйдәгезче, рәхим итегезче әле!

Бераз кыстатып, нәки генә назландырып, яшьрәк кодачалар күршекүләннән җыеп кигән яңа матур күлмәкләрен борыла-сырыла бөтен Яңа Салага күрсәткәннән соң, өйгә керү башланды. Иң алдан баскычка, бисмилласын әйтеп, баш кода аяк басты, аның янында авызын каплап кодагый, аннары — бүтәннәре.

Кодалар югары өйгә, кодагый белән кодачалар үзуңача утырышып кына бетүгә, капка төбеннән сәлам биргән тавыш ишетелде. Мулла белән мәзин килеп җитте. Гөрләп торган өй эче шундук тын калды.

Шунда туйның бисмилласы, ике яшьне бер-берсенә гомерлеккә беркетеп куя торган никах уку башланды. Билгеле, безнең ише ялан аяклы юеш борыннарны ул тирәгә үк җибәрмиләр. Әмма безгә хәзрәтнең әле бер кодага, әле икенчесенә китапчалатып зерә дә мәзәк сүзләр әйтүе ишектән дә, ачык тәрәзәләрдән дә гел ишетелеп торды.

— Сез, Мостафа угылы Бәшир, — диде мулла абзый, — кызыгыз Өммикамалны Кибәхуҗаның Нәгыймулла угылы Нәбиуллага хәләл җефетлеккә разый булып бирдегезме?

Эти, гүя, әйтмичә калмагаем дигәндәй, ашыга-ашыга, берничә тапкыр сакалын селкетте:

— Әйе, әйе, бирдек, хәзрәт, алла боерса, бик риза булып бирдек.

Шуннан соң мулла абзый Кибәхуҗага борылды:

— Сез, кем, Нәгыймулла... эһем, эһем, — мулла абзый безнең җизни буласының исемен онытып җибәрде, күрәсең, әйтә алмый торды. Аңа мәзин булышты:

— Нәбиуллага, хәзрәт!

— Әйе, кем, угылыгыз Нәбиуллага Мостафа угылы Бәширнең кызы Өммикамалны хәләл җефетлеккә разый булып кабул иттегезме?

Мулла янында түрдә үк, кулларын тезләренә куеп, юаш кына, посып кына утырган коңгырт сакаллы кода бабай, үз исеме чыккач, селкенгәли башлады:

— Иттек, хәзрәт! Разый, разый...

Мулла белән мәзинне ашы, бәлеше, калҗа һәм җимеш суы белән сыйладылар да тизрәк озату ягын кайгырттылар. Ник дисәң, туйның уены да, дуены да алар чыгып киткәннән соң гына башлана бит. Мулла-мәзиннең куләгәсе күмелүгә, шундук табынга берничә чирек бал, сап-сары агач тустаганнар килеп чыкты. Без, малайлар, келәт алдына утырып, апайлар, җиңгиләр сузган төрле ит, бәлеш кисәкләрен капкалап алганчы, кодалар чибәр генә кызып та өлгерделәр. Эти кодаларны аягүрә басып сыйлый, әле бер кунак, әле икенче кунак янына барып, кулларына тустаганнарын алып бирә:

— Әйдә, тотыйк әле, кода! Яле, якын итеп, тәмле итеп кенә берне әйләндерик әле!

Шул арада үзе Гайнулла җизнинең терсәгенә төртеп, күз кысып алды. Җизни тамагын кырды. Әле дә урынындамы икән, дигәндәй, бөкрәеп килгән озын борынының очын капшады, аның кечкенә генә түгәрәк күзләре шаян елтырап арлы-бирле сугылды да кода бабайга текәлде. Әй китте шуннан калын тавышы өйгә сыймастай җәелеп, табын өстеннән дулкынланып:

Ничекләр генә килдегез ай сез безгәй,
Батмыенча гына лай диңгезгәй.
Газиз кодалар бит ай сез безгәй,
Нинди сыйлар гына куйыйк соң сезгәй...

Кибәхуҗалар, берсен берсе бүлдерә-бүлдерә:

— Һай, матур әйттең, һай, шәп әйттең, рәхмәт, рәхмәт! — диештеләр.

Яшь кодаларның берсе, сары тустаганын этинең сакалы тирәсендә айкый-айкый, көчәнүдән кызарынып-бүртенеп, тамак төбе ертылырлык дәрәҗәдә яман да ачы тавыш белән үз җырын сузып җибәрде:

Таң иртәләр генәй тышка чыксам,
Йолдызлар сөйләшәй ай белән;
Әйтер сүзләребез хәттин ашкан, Бәшир кода,
Әйтербез ләй әле җай белән...

Хәзер инде кода бабай да кулларын тезләреннән алган. Ул да шактый кызарган. Шушы рәхәткә ереп китәрдәй мәлҗерәп елмайган хәлдә, күзләрен йомар-йоммас җыр көенә арлы да бирле атына башлаган.

Ул көнне мәҗлес караңгы төшкәч кенә тынды. Иртәгесен иртүк кодалар мунча керде. Аннан чыгуга коймак, аннан соң тагын мәҗлес, тагын бөтен авылны яңгыратып кара-каршы җырлашу башланды.

## V

Бу араларда мин апай янына гел менгәләп йөрдем. Ул тәбәнәк кенә урындык белән тәрәзә каршысына утырган да, кечкенә киергесен тезенә куеп, кулъяулык чигә. Үзе бик тыныч күренә. Шулай да әллә нишләп китте ул. Көлми, елмаймый, берсенә бер сүз кушмый. Әйтерсең, аңа ни булса да барыбер. Ул кияүне түгел, әҗәлен көтә шикелле.

Апай миңа күтәрелеп карамыйча гына:

— Ник менден? — дип сорый.

— Болай гына. Синең янына...

Шуның белән беразга тынып торабыз. Миңа апайның чигүен карап торуы бик рәхәт. Аның кыска гына көрән бармаклары тамбур энәсен шундый килешле итеп, шундый җитез боргалыйлар, әйтерсең, энә үзеннән-үзе йөри.

Апай киергесе өстенә иелгән дә шундый тын утыра, хәтта сулыш та алмыйдыр шикелле. Кулъяулыкның почмакларына ул бишни дебет белән берсе янына икенчесен канәфер чәчәкләре чигеп бара. Бер чәчәкне чигеп бетергәнче тын алмыйча утыра да, аннары башын күтәреп, бер авыр сулап куя.

Тәрәзә янагына сөялдем дә карап торам. Монда эшем дә юк, шулай да һич китәсем килми. Апай китәр вакыты якынлашкан саен якыная гына бара шикелле.

Карап тора торгач, бик моңсу булып китте. Башыма елыйсыны китерә торган төрле уйлар килеп китте.

— Син киткәч, безгә бик тә күңелсез булып калыр инде, — дим.

— Нишләп?

— Кем өйне курчак өе төсле матур итеп тотар? Кем самоварга атна саен яңа йолдызлар төшерер?..

Апай бераз уйланып утырды. Аннары:

— И, кайгырма! — диде. — Солдаттан гына кайтсын. Кечтеки абыеңны өйләндерерсез дә өйне яшь җиңгәң матурлар. Йолдызларны да шул ясар.

— Син киткәч, өмәләр дә булмас инде, утырмага кунак кызлар да килмәс. Аллы-гөлле матур күлмәкләр киеп, кәшәмир яулыклар ябынып кем сулар китерер?

— И, борчылма, энем. Кыш айларында утырмага менә үзем килермен. Кәшәмир яулыклар ябып, чулпыларымны чылтыратып, бии-бии генә үзем су китерермен.

— Юк, син киткәч бик күңелсез кала инде. Безнең өйдән киенеп-ясанып кызлар уенына төшүче дә булмас. Кичләрен безнең турыдан егетләр дә җырлап узмас...

Апай минем колак яфрагымнан өскә таба тарткан булды. (Аның бармаклары бик җылы, бик кытыршы иде.)

— Үс, энем, үзең тизрәк үс! Яңа камзуллар киеп, кәләпүшеңне кыңгыр салып, озакламый яшьләр уенына үзең төшәрсең. Күп тә үтмәс, Миңнисалар турында үзең җырлап уза башларсың. Әә бит!

Мин юри генә аның иңбашына сугып алдым.

— Әй, син тагын! Чуртыма кирәк!

Шунда беренче мәртәбә мин аның моңсу гына итеп елмаюын күрдем. Әмма күзләре мөлдерәп кенә тора, керфекләре еш-еш йомылгалый иде.

Минем үземнең дә күз төпләрем кымырҗый башлады. Нишләтәсең

бит, әгәренки апай Әхәткә чыкса, болай аерылышасы булмас, мин аны көн саен күргән булыр идем. Мин апай янына чүгәләп утырдым:

— Апай, син миңа үпкәләмисенме?

— Менә тагын! Анысын каян уйлап чыгардың?

— Теге кичне мин кычкырганга эти чыкмаса, син... ниме... Ябышып чыгар идеңме?

Апай башын чайкады.

— Белмим. Әллә тагы... Бәлки...

Кайсыдыр койма буеннан сызгыргалап үтте, тыкрыкта буш чиләкләр сайраганы ишетелде. Апай тагын авыр сулап куйды.

— Бәлкем, китмәгән дә булыр идем. Утка төшәм дигәндә, суга сикердем.

— Этидән курыктыңмы?

— Юк, үзеннән түгел, каргышыннан. Гомер буе баш түбәндә кара болыттай асылынып торасы булса, дөньяларда ничек яшәрсең?

— Бәлки, тора-бара онытыр иде әле.

— Ай-һай. Безнең маңгайларга шулай язылган инде...

Ул арада яулыкның дүртенче почмагы да чәчәк ата башлаган иде инде. Никадәр тыелырга тырышсам да, яулыкның кемгә бүләк буласын сорамыйча түзә алмадым.

— Җизнигә инде бу, имә?

Апай бераз дәшми утырды.

— Юк, түгел. Икенче егеткә... Яшьрәгенә.

— Һе...

Миндә ризасызлык сыман бернәрсә туа башлады. Никах укылганнан соң әллә нинди чит бер егеткә яулык чигеп утыру... Белмим инде. Китапча гөнаһтыр инде ул. Әнә бит эти ничә тапкыр әйтте инде: «Өммикамал хәзер никахлы инде. Кеше кешесе. Өйдә генә утырсын!» — диде. Болай да яхшы түгел. Бигрәк тә безнең апайга килешми.

Белсәң иде, кемгә икән? Шул Әхәткәдер инде. Алай дисәң, ул Нәбиулла җизнидән бер дә яшь түгел, картрак булмаса әле.

Апай яулыкны чигеп бетереп тә килә. Миңа һаман шул бернәрсә тынычлык бирми. Шул ук вакытта каты бәреләсе дә килми. Кактырып-суктырып дигәндәй, тагын белешергә керештем.

— Сагынганда бер карар дип, бүләк итеп калдырасың инде, имә?

Апайның ирен кырыйларын нәни генә көлемсерәү шәүләсе яктыртып узды.

— Шулай дим шул.

— Яраткан егетең тагын да бар идемени?

— Булмыйча...

— Һе. Монысын бигрәк тә матур итеп чиктең инде. Кадерен белсәләр ярый да бит!

— Матур итмичә... Аның егете дә чибәр бит. — Апай чигүеннән туктады. Бик ягымлы һәм үз итеп, зәңгәрсу-яшькелт күзләрен мөлдерәтеп, миңа карап тора башлады. — Кадерен дә бик белер шикелле күренеп тора. Аннары мин киткәч, ул егетнең яулык чигеп бирерлек бүтән апае да калмый.

Минем, тагын да кечкенәрәк чагымдагы шикелле, апайның муенына асылынасым, култык астына сыенасым, үзен дә иркәлисем килеп китте. Ләкин — булмады, оялдым. Берни әйтә алмыйча, як-ягыма бәреләсугыла, ишек алдына чыгып йөгердем.

## VI

Туйдан соң да өйгә барыбер тынычлык кайтмады.

Һаман да эти белән әнинең йоклаганнары йокы, ашаганнары аш түгел. Төннәр буе уфылдыйлар, пошыналар, утлар йотып яталар. Телләрендә һаман шул:

— Теге юньсез нинди явызлыклар уйлап йөри икән? Кияү керер алдыннан кызны урлап китмәс микән? Я булмаса, берәр әшәкелек эшләмәс микән? Азмыни төрле этлек! Я йортыңа ут төртер, капканы деготь белән буяр, бәет чыгарыр...

Иртән торгач ук Гайнулла җизни белән Вәли абыйны чакыртып, колакларына тукыйлар:

— Кич-иртә күз-колак була күрегез. Берүк, адәм көлкесе итмәсен...

Пәнҗешәмбе көн иртәдән үк кияү бүлмәсен хәстәрләү башланды. Апайның дуслары, күрше кызлары, шау-гөр килеп, җиңнәрен сызганып, юарга, бизәргә, җиһазларга тотынганнар иде, бераздан ак келәт курчак өенә әйләнде. Әйтерсең, бүлмә эченә кызларның чыңгырдатып көлгән матур тавышлары да, көләч йөзләренең якты нуры да эленеп калды.

Әмма моның иң четерекле ягы — кияү белән кызга урын-җир хәстәрләү икән. Эш шуңа барып җиткәч, Зифа тәтәй үзе кереп, бу эшләрнең бөтенесен үзе өйрәтеп торды. Шунда җыелган кызларга берәнберән күз салып чыкты да телен чартлатып куйды:

— Урын җәяргә дүрт кенә кыз кирәк. Әмма шунысы бар, дүртесенең дә ата-анасы тигез булуы кирәк. Гаеп итештән була күрмәсен, кызлар,— диде.

— Юк, юк, Зифа тәтәй! Нинди гаеп тә нинди кыек? Менә тагын, йоласы шундый булгач! Язган булса, яз көне, көзәйгән булса, көз көне безгә кияү килгәндә дә шулай җәйдерерсен!

— Алайса менә болай инде: Мәүлиха, Сәхипҗамал, Мәрьямбикә, Бәдерниса, әйдә, шулар җәйсеннәр.

Ястыкны да, мендәр белән җәймәләрне дә дүрт кыз дүрт почмагыннан тотып сак кына урынга китереп салдылар. Нигәдер бу вакытта берсе дә көлми, бөтенесенең чырае изге бер эш башкаргандагы төсле бик җитди иде. Урын өстенә күп итеп ислемайлар сиптеләр.

Кичкә таба апайны да алып керделәр. Ул, әле генә йокысыннан уянган кеше шикелле, беравык як-ягына сәерсенеп карап торды. Апай шактый ук ябыккан иде. Аны урталарына утырттылар да ике кыз ике толымын үрделәр. Шуннан соң Зифа тәтәй, аның янына утырып, гүя үз башыннан кичергәннәрне яңадан күз алдыннан уздыргандай, бик төпчеп, тәмләп, күзләрен бер йома, бер ача, кияү кергәннән соң аның белән ничек булырга икәнен төшендерергә тотынды:

— Хәзерге кияүләр ничектер инде, бик кансыз кыланалардырмы, юктырмы, безнең заманда бик тә матавыклы булыр иде. Читеге тыгыз булса, үкчәсе белән башына сабын да тиергән булса, маңгай тирләрең чыгасы бар әле, сеңелкәем! Әүвәл башта үкчәсен эләктерергә тырыш, үкчәсен! Чыкмый икән, бер дә куркып торма, дөбердәттереп сөйрә дә төшер! Хәзер казаки өстеннән билбау бәйләү бетеп бара шикелле, аннысыннан котылдык, аллага шөкер. Югыйсә, билбауның очын эзләп кара тиргә батасың булыр иде.

Чишенгәннән соң кулын юдырасы да чәйгә утырасы икән.

— Берүк онытма, беренче чәйне икешәр чынаяк кына эчәсе, ул да, син дә! Ян, көй, тик артыгы ярамый! Ярамый булгач, ярамый! Бабайлардан калган йола. Бөтенесе пар булсын!

Кайсыдыр җилтерәтеп өйдән көзге алып керде дә аңа стенада җайлы урын эзли башлады.

— Менә монда куйсак, кияүне чаршау ярыгыннан рәхәтләнеп күреп торабыз. Әйе бит, Сәхибҗамал?

Аның үз мәшәкате бар иде.

Ул кияү утырасы кечкенә мендәр астына аш тәлинкәсе кыстырды. Тагын бераздан монда нинди кәмитләр килеп чыгуы мөмкинлеген күз алдына китерде, күрәсең, алдан ук көлә башлады.

— Һа-һа-һа! Менә шуннан беләбез инде: үткенме синең киявең, Өммикамал апай, әллә пешкән шалкан, төшкән-калганмы? Үткен булса, тәлинкәне алып куяр. Аңгыра булса, карга баласыдай авызын ачып, килер дә утырыр. Шунда тәлинкә — шатырт! Һа-һа-һа!

Апай шунда гына бераз көлемсерәп куйды.

— Шуңар гына да башы эшләмәсә, харап инде аннары эшләр!

Тик аны шундук юатырга керештеләр.

— И, төкерсәнә! Сәхипҗамалның яман телениләр тәтелдәмәс?!

Аннан соң инде апайны киендерәселәр булып чыкты. Шуңа җиткәч, малай гына булсам да, мин дә сыймый башладым.

— Бар, бар, үкчәң күтәр! Ир-затка монда булырга ярамый!..

## VII

Кияүне ничек кертергә? Шул явыздан кызны да, кияүне дә ничек мыскыл иттермичә калырга? Ул турыда тагын сүз күп булды.

— Ул, зимагур, тәгаен берәр этлек эшләр,— ди әти.— Я кияү килгәндә урамга аркылы аркан сузар, я бүрәнә салыр. Атларының аягы сынып, трантасың авып, урам уртасында хур булып ятсаң, бөтен нәселеңә китә инде...

Әни алай ук булырына ышанып җитми шикелле. Әмма кемнәрдер аны да искәртеп куйганнар. Кияүне алып кайткандә койма буена бик якын узсалар, ул дошманның кияү битенә дегет тутырылган йомырка атуы да мөмкин икән. Шунлыктан күз бәйләнер чакларга ук калдырмаска, шулай да бик үк иртә дә кертмәскә булдылар. Курыктылар диярлек тә булмасын, чамасыз гамьсезләнеп, бик үк авызыңны ачып та йөрергә ярамый. Алла сакласын!

Гадәттә кияүне кияү егетләре алып килә. Безнекеләр мондый хәтәр эшне җыен кызыл авыз, яшь-җилбәзәккә ышанып тапшырмаска булдылар. Кияүне әнинең олы энесе, чиертсәң, битеннән кан чыгарга торган, таза гәүдәле, ир урталары кеше — Сафа абый алып киләсе булды. Яхшы тарантаска пар ат җигәргә, кыңгырауларның шәбен тагарга! Авылның аргы башыннан ук зур урамга төшеп, урамның нәкъ уртасыннан җан-фәрманга чаптырып алып кайтырга! Теге сөрхәнтәй курыкттым димәсен!

Хәкимҗан белән мине яңа җизнине каршы алырга җибәрделәр. Әни өйдән үк колакларга тукып чыгарды:

— Урам буенча караштырып барыгыз. Ул-бу сиздегезме, йөгереп кенә кайтып әйтерсез. Улым, мин моны бигрәк тә сиңа әйтәм! Ишетсен колагың! Ул-бу булып күрми калсаң, үтерер атаң!

Әллә истә торган әни әйткән «ул-бу», әллә юк. Безне иң кызыктырганы икенче нәрсә иде: без кыңгыраулар чыңлатып пар атта килүче яшь җизнине каршы алырга барабыз. Беренче күрү бит! Ни килбәттәрәк икән? Мыеклымы ул, әллә түгелме? Минем моңа кадәрге җизниләрем һәммәсе дә мыеклы булганлыктан, монысы да зур гәүдәле, мыеклы булыр кебек тоела иде.

Йөгерә-йөгерә басу капкасыннан чыгып, урман ягына күз салсак, күрәбез: бөтен юлны иңләп, ургылып-ургылып, зур өй кадәр тузан кибәне тәгәри. Бераз якынлаша төшкәч, шул соры кибәннең бирге ягыннан, ыргытып бәргән шикелле иттереп, ат аяклары атылып-атылып чыга башлады. Мин, торган урынымда сикергәләп:

— Килә, килә! — дип кычкырып җибәрдем.

Хәкимҗан әлек, кечерәк чагында, сөйләшмичә теңкәгә тия торган иде. Хәзер, сөйләшкәләсә дә, ана гел кирегә таба сукалый торган бер чир йокты. Ул җиңе белән борынын сөртеп, башын селкеп куйды:

— Юк, алар түгел!

— Шулар булгач, шулар! Пар ат җигеп кичкырын бүтән кем йөрсен!

— Түгел булгач, түгел! Кыңгыраулары юк! Нинди кияү кыңгыраусыз килсен?!

Тыңласам, кыңгырау тавышы чыннан да ишетелми. Хәкимҗан, тынкыш борынын мышкылдатып, көлеп алырга да өлгерде.

— Әйттем ич мин сиңа, әйттем ич кияү түгел дип!

Әмма без бәхәсләшкән арада пар ат җиккән тарантас тузан эченнән бәреп тә чыкты, килеп тә туктады. Иң элек ат башыннан Сафа абый сикереп төште.

— Әйдә, Нәбиулла! Әнә каенең каршы алырга чыккан! Тузаннарны да басуда калдырып керик.

Җизни кеше, минем абый кебек үк, мыексыз-нисез, яшьрәк кенә бер егет икән. Керфекләренә кадәр тузан баскангамы, ничекме, күзләре сөрмәле булып күренә.

— Әһә, минем кайнеш шушы егет буламыни инде? Әйдә, күрешик алайсам!

Кулны сузуын суздым, ләкин авызны әллә ничә тапкыр ачып-йомып карасам да, нигәдер бер генә сүз дә чыкмады. Җизни кеше үзе өстенбашын кага, үзе ялт-йолт каранып, гел авызын ерып тора. Ул да минем шикелле каушаган, ахры. Шуңа авызын җыя алмый торгандыр. Кияү булып керүләре уен түгел икән шул!

Әһә! Әнә нигә кыңгыраулар чыңламаган икән! Сафа абый аларны моңарчы бәйләп килгән бит. Хәзер генә ычкындырып җибәрде.

— Менә хәзер чыңгырдатсак та ярый инде. Яңа Сала да тәпи бассын, атларга да дәрт керсен! Я әле!

Кузгалып китүгә, атлар утка баскандай булды. Сафа абыйның төпкә җиккән кара турысы, авызлыгын тешләп, муенын аккошныкыдай бөгеп китерде дә, әй китте бер мәлне бөтен гәүдәсен туптай сикертеп! Безнең кара байтал нинди авыр тәнле инде. Юлга чыксаң, юырттыра алмый кара тиргә батасың. Хәзер ул булып ул әллә нишләде. Ял-койрык күпергән, үзе сөлектәй сузылган, кая басарын белми, оча гына!

Басу капкасына җитәрәк, Сафа абый җизнигә борылып ым какты. Җизни түрдәге ястыкның өстенәрәк менеп, җәелебрәк, бер кулы белән биленә таянып, башын калкытыбрак утырды. Сафа абый үзе кузла баскычына аягын терәп, кәләпүшен басыбрак киде. Минем кабыргага төртеп алды:

— Нык ябыш! Кәләпүшеңне кулыңа ал! Төшеп калмагыз! Я, аллага тапшырдык!

Һи, моңарчы уены гына булган, менә кайчан икән әле аның дуены!

Сафа абый ун колач озынлыктагы сумалалы чыбыркысы белән, еракган ук әйләндереп торып, чажылдатып китереп сугуга: «һәәйт!» — дип кычкырып җибәргән иде, атлар бөтенләй шаштылар. Суырып та алдылар, очыртып та киттеләр. Менә кайда икән әле ул тамаша! «Выжт» иттереп кенә басу капкасын уздык, ике сикерүдә урамга да килеп кердек. Арба эзен дә күргән юк, исән каласын да белгән юк. Тәгәрмәчләр тигән җиргә тия, тимәгән җиргә юк. Кыңгырауларның ярсыган чыңы, урамга сыя алмыйча, шашынып, пыяла ватыкларыдай чыңлап, коймаларга, өй кыекларына, өянкеләргә барып бәрелә. Урамның як-ягында җелт-җелт итеп йортлар, капкалар сөрлегеп кала. Апайлар, җиңгиләр, малай-шалай капка төпләренә йөгерешә. Атларның аяк астыннан тавыклар, казлар атылып чыга. Очабыз! Авыз белән күзләргә балчык тулды, чүп тулды.

Менә югары очны да уздык, урамга ярып кергән тирән чокыр башын да уздык. Атылып мәчет янына да килеп чыктык. Ул да түгел, тарантасыбыз «дырр» иттереп тузан эченнән зырылдап борылды да капкадан да кереп китте.

Капка төбе тулы малайлар, егетләр, баскыч төбе тулы кыз-кыркын. Барысы да яулык читеннән күзләрен елтыратып, кияүне күзлиләр.

Әле мин кузладан төшеп кенә маташам, ә жизни булган кеше (ни арада шәйләп алган диген син!) келәт ишеге төбенә якынлашып та килә. Мин бит хәзер йортта бердәнбер малай, ишек бавының бүләге бүтән берәүнеке дә түгел, минеке булырга тиеш!

Әллә ике сикердем, әллә өч булды. Ничек тә ишек тоткасына жизнидән алданрак барып ябыштым. Нәрсә әйтәсен әллә кайчан ук ятлап куйган инде югыйсә: «Ишек бавы — бер алтын, безнең апай — мең алтын!» — дип такмакларга, апайның бәясен күтәрә төшәргә кирәк. Әмма тарантас башында дырылдап кайта торгач, ул көйле сүзләр, күрәсең, коелып калганнардыр, искә генә төшмиләр бит! Шулай да ишек тоткасын әләктердем дә батыраеп тотындым:

— Ишек бавы... безнең апай, ишек бавы... безнең апай...

Әмма жизни кеше бик ашыга иде. Күрәсең, аңа күз алдыннан тизрәк юк булырга, үзенә төбәлгән йөзләрчә очлы күзләрдән тизрәк кереп качарга кирәк булгандыр.

— Ә, ярар, энем, бик шәп! Мәле, тот әле менә шушыны! — диде дә миңа пәке сузып, апай янына кереп тә китте.

Ишек ябылып кына өлгерде, Хәкимҗаннар, Нимҗаннар мине сырып та алдылар.

— Кая, күрсәт, нинди пәке эләкте?

— Балыклымы? Түгелме?

Кызыл саплы, балыклы пәке алып килгән икән жизни! Кияү бүләге шундук кулдан кулга китте. Аның ике пычагын да бер-бер артлы язып, бөгеп, күзгә төсле ялтырап торган җирләренә сулыш өреп тә, йөзенә бармак тидереп тә, тырнакка, чәчкә каптырып та карадылар. Нимҗан хәтта шундук, җиргә утырып, пәке кадаш та уйнап алды. Ахырдан һәммәсе бердәй бер сүзне әйттеләр:

— Шәп пәке, балыклы пәке бу! Җилле кеше икән синең жизнәң!

Халык таралды, урам белән ишек алдында шәфәкъ яктысы гына эленеп калды, туганнар өй эченә тулды.

Шулай да безнең өйдә хәл-әхвәл бик киеренке иде әле. Әти белән әни югары өйдә абыйлар, жизниләр белән бик озак киңәш кордылар. Ниләр турында пышылдауларын колак очым белән генә мин дә ишеттем: «ул-бу» булмасын дип, дәү абый келәт янындагы бакчада төн чыгарга тиеш.

— Янына кистән сал! — диде әти.

Гайнулла жизни, капкага дегет сыламасыннар өчен, урам якка күз-колак буласы. Ул шундук җиңнәрен сызганып калын тавышы белән гадәтенчә үкереп куйды:

— Һе, килеп кенә карасыннар! Муеннарын сындырып ыргытмасам, Гайнулла булып йөрмим дә!..

Тик боларның берсе дә кирәк булмады.

Караңгы төшәр-төшмәстән Гыйльми түти килеп керде:

— Илчегә үлем юк! — диде.

— Нинди илче, кемнән?

— Хәзер әйтәм... Әхәт китә!

Безнекеләр шаккатып Гыйльми түтинең авызына текәлделәр.

— Кая китә, ничек?

— Җәһәннәмнең теге ягына! Кая китсә дә барыбер түгелмени? Сиңа әйтергә кушып калдырды. Бәшир: «Аның шикелле таш бәгырьле кансыз кешене кызганып тормаган булыр идем, аны кара җәяү калдырырга бер шырпы житкән. Тик Өммикамалны елатасым килмәде, аның хакына гына түздем»,— диде. Актык сүзен дә әйтим: «Үземчә иттем дип бик масаймасын! Безнең дә үз көнебез килер әле»,— дип тә әйтте.

Кинәт бик күңелсез булып китте. Әни битен каплап читкә борылды. Әти, берни дә ишетәсе килмичә, кискен генә кулын селтәп, чыгып китте.

## Өйдән-өйгә

### I

Мин күкеле сәгать сукканга уянып киттем. Ничәне сукты икән? Бишнеме, алтынымы?.. Зиһенем чуалып сәерсенеп ятам. Бу ниткән сәгать? Кайда соң әле мин?..

Өй эче тып-тын. Караңгы да. Тик күтәрелебрәк караганда азрак мич агы гына төсмерләнә. Борыныма әллә нинди әчкелтем авыр ис килеп бәрелде. Шундук исемә дә төште. Кулымны сузып янымдагы тула төргәген стена буена ук этәреп куйдым.

Миңа бик моңсу булып китте. Ник уяндым икән? Нигә бер дә уянмыйча, шул бер очтан бик озак, әллә нихәтле йокламаганмын икән?..

Әнә шул туладан кичә без чикмән тегә башладык. Сафа абый, сәке өстенә менеп, тезен чәнчеп утырды да чикмәннең өлгеләрен кисте. Ул кайчысын бер кыскан саен тешләрен дә кысып, уртларын уйнатып куя, калын, коңгырт кашлары бер күтәрелә, тагын җимерелеп төшә. Тула бик калын иде.

Менә чикмәннең ал тактасы булды, арт тактасы, аннары җиңнәре белән зур кайтарма якасы киселде. Шушы кырыкмаса-кырык тула кисәгеннән зур гына чикмән оештырырга кирәк. Бөтенесен энә белән, бөтенесен кулдан. Менә хәзер озакламыйча яңадан торырга, кара төнгә кадәр шул сасы тула белән җәфа чигә башларга кирәк.

Бу без тегә башлаган беренче кием иде әле. Мин шешенкерәгән имән бармагымны стена салкынынарак сузам. Бармак сулык-сулык килә. Уймак кигән урыны кабарып чыккан. Хәзер мин әнә шул кайдадыр бик озак ятып ачыган, тычкан исләрен сеңдереп сасып беткән тула кисәкләрен күрмәс өчен әлләниләр бирер идем.

Озакламыйча торырга кирәклеге исемә төшүгә, әллә нишләп китәм. Бу эшнең очын да, кырыен да күрмим, кызыгын да тапмыйм. Тегү эше энә белән мәгънәсезгә казыну, очсыз-кырыйсыз азап булып кына күз алдыма килә. Җенем сөймәгән эш...

Ә сәгать дигәнең бертуктаусыз үзенең тикелдәвен белә. Әйтерсең, ул черт-черт, черт-черт иттереп өйнең тынлыгын вак-кисәкләргә турый-турый да шулай юкка чыгара бара.

Әмма минем алай тиз генә яктыртасым да, торасым да килми. Бераз гына булса да күземне йомып, авылымны, әниләрне күз алдыма китерәсем килә. Тик анда да әллә ни юаныч юк.

Тегүгә чыгып китәр алдыннан, әти белән Сафа абый чәй янында минем турыда сөйләштеләр.

— Укытып булмый инде малайны, булмый, чама юк,— диде әти.— Ниятем бик зурдан иде. Икесен дә кеше итәргә иде исәп. Булмады. Безнең нише кешенең мулла иткәнче укытырга хәле җитми. Болай гына укып чыккан шәкертләр бер эшкә ярамый. Әнә бит, абыйсын укытып ничә ел чиләндек! Барыбер солдатка алдылар. Ичмасам, монысы һөнәргә өйрәнсен.

Сафа абый елларның авырлыгыннан зарланырга тотынды. Иген булмаган, Ямаширмәдә тегәргә эш юк, ди. Әлеге шул сүз тыңлап кына, якын кеше итеп кенә алып чыкса инде. Үзенә кыен булса да...

— Хакын үзең белеп салырсың инде. Кеше бәясе булыр.

«Кеше бәясе» дигәннәрен мин соңыннан гына белдем. Өйрәнчек ма-

лайга кыш буе эшләгән өчен я бер ситсы күлмәк, я бер ыштан бирәләр икән...

Хәер, ул ягына бик үк исем китмәде, мине башка ягы борчыды. Әтинең агара башлаган чәче, тыны бетүе, кул-аяклары туңуга чыдый алмыйча, җәй көне дә бияләй киеп йөрүе, аякларын кайнап торган самоварга терәп торуы күз алдыма килде. Күрәсең, безнең өйдәге хәлләр яхшыдан түгелдер.

Мин ул вакытта китапның тәмен белеп укый башлаган идем инде. Китапларымнан аерылу аеруча кыен булды. Мәдрәсәнең китап киштәсендәге күн тышлы калын-калын борынгы китаплар миндә нинди генә хыяллар тудырмады! Ниләр генә бар икән ул китапларда? Киләчәктә мин аларның да серенә төшенермен, теләсә кайсы китапны, теләсә кайсы урыныннан ачып укый алырмын дип хыяллана идем.

Менә хәзер минем ул хыялларымның бөтенесе җимерелеп төште.

## II

Чаршауның теге ягында сиртмә шыгырдый башлады. Шундук, мазасызланып, яшь бала еламсырарга тотынды. Ул да түгел, баланың анасы булса кирәк, кыштырдап барып кучкардагы сукыр лампага ут кабызды. Шуның артыннан ук баланың, ашыгып-ашыгып, бик тәмле итеп, авызын чәпелдәткәне ишетелде. Мин хәтта баланың кечкенә юеш иреннәренең матур булып бүлтәеп чыгуына хәтле күз алдына китердем. Менә ул, анасының беләкләрендә яткан килеш, моңарчы бер генә кайгы сөреме дә керләндермәгән, бер генә ачы күз яше дә төсен уңдырмаган, чык тамчысыдай ачык-саф күзләрен елтыратып, сөйкемле итеп, анасына карап ятадыр. Хәтта миңа бүлмә тактасы аша яшь баланың үзенә генә хас ягымлы исе дә аз гына борынга керә шикелле тоелды.

Менә анасы баласын шап-шап итеп сөяргә, бик ягымлы һәм балаларча сакау сүзләр әйтеп, аның белән пышылдашырга кереште:

— Һи, чекери күз! Һи, төн сандугачы! Торуың шушымени инде, ә?! Сулаймени?! Таң иртәдән торып әниемә булышыйм диденме, сулаймени?!. Һи, сине, тфү, тфү, күзләрең!..

Хуҗа хатын миңа үз анамны хәтерләтте. Безнең әни дә кечкенә сеңелне, шулай сөйләшә-сөйләшә, зурлар торганчы туйдыра торган иде бит.

Торганнан соң һавага чыгыйм дисәм, өй бусагасыннан атлауга, туптуры шәрә буш урында булып чыктым. Бу кешенең өйалды да, каралты-кура, койма дигәннәрнең дә берсе дә юк икән.

Хуҗа хатын түр сәкегә шакмаклы ашъяулык җәйде. Ачың уртасына ватыла башлаган иске икмәк турап өйде, дүрт-биш шакмак шикәр куйды. Шуннан соң, иске генә самоварның артына утырып, икебезгә дә чәй ясагач, бик тырышып, ихлас күңелдән кыстарга кереште:

— Яле, бары белән ашап кына утырыгыз әле. Бигрәк тә бетәшкән чакка туры килдегез, ходаем. Ичмасам, чәйгә сөтебез генә дә юк. Кәҗәбезне көзен сатып җибәрдек. Үзенә чикмән тектермичә булмый лабаса. Өсте-башы бик бетте.

Мин, үземнең болар кебек үк ярлы булмавыма уңайсызланган сыман (минем дә бишмәтем белән бүрегемнән, киез итегемнән башка бер нәрсәм дә булмаса да), кыенсынып кына өй эченә күз салдым. Бөтен өйдә агач сиртмәле бала бишегеннән, бадьян белән агач табактан һәм идәндәге бер бүкәннән башка күз төшерерлек берни дә юк иде.

Сафа абый, түр башында бөкресен чыгарып, алдына гына карап утырган килеш, бик тырышып, коры ипи мүкелдәтә. Ул минем дә ботыма төртеп ипигә ишарә итеп алды. Янәсе: «Ныграк аша! Гаеп итәләр дип уйламасын», дигәне инде.

Шулай сөйләшмичә генә чәй шупырдатып утырганда, мич башында

кемдер кыштырдаганы ишетелде. Озак та үтмәде, аралыктан күзен уа-уа, күлмәкчән, ертык ыштанлы бер малай килеп чыкты. Анасы аны шундук, житез генә үзенең артына яшерде.

— Монысы олы улыбыз була инде. Абыстайга йөри башларга иде дә кана, чалбар да юк, бишмәт тә. Менә Сафа абыйлары атасының иске бишмәтеннән чалбар сыман берәр нәрсә әтмәлли алмасмы икән соң?

Оста, бераз көттереп кенә:

— Карарбыз,— диде.

— Аталары бишмәт тышлыгына акча юнәтә алса, әчлегенә иске күлмәгемне тотарбыз дип торам да... Сафа абыйлары бик иске-москы димәсә.

— Бик муртаймаган булса...

Хужа жиңги үзе ишеккә таба карап утыра, табынга борылганда, яулык почмагын авыз чите белән эләктереп, битен капларга тырыша иде. Аның тавышы йомшак кына, кыюсыз гына. Ул хатын-кыз башы белән ир-ат алдында шулай сөйләнеп утыруына да кыенсына иде шикелле. Тик тегүчеләрдән бер сүз дә чыкмый бит. Әллә табын бик такыр булганга шулай кашларын жимереп утырамы бу тегүче? Бу тынлыкка жаны өшеп утыра торгач, жиңги бик яман кыстарга керешә, я берәр сүз табып тагын үзе сөйләнә башлый.

Алар күптән түгел генә башка чыкканнар икән. Әтиләре бик яхшы кеше булган да бит, үги ана зобаныйның да зобание икән. Шул тәмуг кисәвеннән узып әткәйләре иске келәт белән шушы күкеле сәгатьтән башка бернәрсә дә бирә алмаган. Иске келәт өй булган, күкеле сәгать әнә утыра түрдә күкелдәп.

Сафа абый анда да сүзне куертып жибәрмәде. .

— Һе, кара син, ә! — дип кенә куйды.

Үкереп торган төп йорттан шулай кимсетеп чыгарсалар да, аллага шөкер, ачка да үлмәделәр, капчык асып соранырга да чыкмадылар. Торырга куышлары, ашарга ипиләре бар, менә, исән-сау булсалар, алмадай ике бала үстерәләр...

Моннан ерак түгел, Корткачык авылы яныннан Себергә таба тимер юл узасы икән дә, аның ире шунда балчык эшенә ялланган. Кичә кич ул өйдә иде. Сафа абый чикмәнгә үлчәү алгач, ул утырган жирендә үк йоклый башлады да почмакка барып ауды.

Бу апа минем әнидән күп яшь иде әле. Аннары безнең әнинең бите озынча, моның түгәрәк. Шулай да ул үзенең оялчан әдәплелеге беләнме, әллә балалы аналарның күбесенә хас булган ягымлы йомшак күңеллелеге беләнме, ничектер минем әнигә дә охшаган сыман тоелды.

Тагын шулай бераз тавышсыз-тынсыз утырганнан соң, ул янә сүз тапты:

— Бу оланны ятим диикме соң?

Сафа абый, чәен шупырдата биреп, авыз эченнән:

— Юк, түгел, — дигән сыман ботка пешереп алды.

Хужа хатын хәзер инде бик тырышып, мине кыстарга тотынды:

— Мәле, олан, аша менә шуны бик тәмле иттереп. Монда анаң юк, оялып утырсаң, гүпчи дә ач калырсың.

Өстенә бер шакмак шикәр куйган иске ипи телемен ул миңа шундый чын күңелдән, шундый кадерләп сузды, бал белән май яккан ипи телеме сыман, мин аны чыннан да бик тәмле итеп, рәхәтләнеп ашадым.

*(Дәвамы бар.)*

*Гәрәй Рәхим*

## Сагыш һәм шатлык

Сары төс төяп көз килгән мәлдә,
Күңелне сагыш биләргә тиеш.
Ләкин яз төяп кошлар кайтыр дип,
Сагышны шатлык җиңәргә тиеш.

Картаю төяп бабайлар үлгәч,
Ирләр хөрмәтләп җирләргә тиеш.
Тик яшьлек төяп балалар тугач,
Сагышны шатлык җиңәргә тиеш.

Хәсрәтләр төяп илгә яу килсә,
Ил өчен меңнәр үләргә тиеш.
Ләкин дан төяп җиңү килгәндә,
Сагышны шатлык җиңәргә тиеш.

Яктылык төяп кояш чыкканда,
Һәр җан иясе көләргә тиеш.
Тормыш төялгән бу җир шарында
Сагышны шатлык җиңәргә тиеш.

## Сугышта югалган солдатлар

(Җыр)

Дан җырлары иҗат итегез
Сугышта югалган туганнар хакына.
Дошманнарга нәфрәт булып барсын бу җыр, нәфрәт булып.
Туганнарга рәхмәт булып калсын бу җыр, рәхмәт булып.
Дан җырлары иҗат итегез
Сугышта югалган солдатлар хакына.

Онытылмасыннар арабыздан китсәләр дә,
Кайсы илнең кайсы якларыннан,
Кайсы юлның кайсы чатларыннан
Үтсәләр дә.

Дан җырлары иҗат итегез
Билгесез югалган туганнар хакына.
Илбасарга зур кисәтү булсын бу җыр, зур кисәтү,
Чын дусларга юл күрсәтеп тусын бу җыр, юл күрсәтеп.
Дан җырлары иҗат итегез
Билгесез югалган солдатлар хакына.

Һәйкәл куегыз җирдәге бар бакчаларга,
Кайсы илнең кайсы диңгезендә,
Кайсы якның кайсы нигезендә
Ятсалар да.

Дан җырлары иҗат итегез
Мәңгегә югалган туганнар хакына.
Сугышларны җирдән мәңге кусын бу җыр, мәңге кусын.
Тынычлыкны җирдә раслау булсын бу җыр, раслау булсын.
Дан җырлары иҗат итегез
Мәңгегә югалган солдатлар хакына.

Алар үлеме безгә тормыш китергәнен
Бөтен илнең бөтен батырлары,
Бөтен чорның бөтен гасырлары
Хәтерләсен.

## Вәгъдә

Йөрәкләр турында язасы бар әле —
Атылган йөрәкләр,
Ватылган йөрәкләр,
Сатылган йөрәкләр турында.

(Атылган йөрәкләр күптәннән кабердә,
Сатылган йөрәкләр исәннәр хәзер дә.)

Йөрәкләр турында язасы бар әле —
Сафланган йөрәкләр,
Тапланган йөрәкләр,
Тапталган йөрәкләр турында.

(Бит әле кайдадыр
Сафланган йөрәкләр таптала,
Тапланган йөрәкләр аклана.)

Йөрәкләр турында язасы бар әле —
Арыган йөрәкләр,
Ярсыган йөрәкләр,
Арслан йөрәкләр турында.

(Вакыт ул рәхимсез —
Арслан йөрәкләр арыйлар;
Арыган йөрәкләр ярсымый.)

Йөрәкләр турында язасы бар әле —
һәм исән йөрәкләр,
һәм үлгән йөрәкләр,
һәм сүнгән йөрәкләр турында.

(Мин беләм:
Бер исән йөрәкнең күптәннән сүнгәнен,
Бер үлгән йөрәкнең һаман да сүнмәвен.)

Йөрәкләр турында язасы бар әле...
Йөрәкләр турында...
Йөрәкләр турында...

## Сабырларга

Яратам мин сабыр кешеләрне.
Зур кораблар кебек алар һаман
Тормыш давылларын ерып бара
Максатлары кушкан якка табан.

Зур максатлар өчен җаннарына
Алсалар да күпме авыр яра —
Шырпы кебек чәчрәп кабынмыйлар,
Алар домна кебек салмак яна.

Шуңа бераз гамьсезләр дә кебек
һәм усал да кебек бераз алар.
Тик битараф түгел, мәҗлесләрдә
Бәйрәм итсә күпшы фразалар.

Мондый чакта алар ашыгалар
Бу мөхиттән тизрәк югалырга.
һәм кораблар кебек китә алар
Зур максатлар кушкан юлларына.

*Рөстәм Мингалимов*

## Сөенечем

О-о, иске дус!
Ун ел үткәч
килеп чыктың син каян!
Үзгәргәнсең ничек, дисең:
картаям, дус,
картаям.
Күптәннән
камыл таптарга
күнекте минем табан,
сөрәмен,
кәсләр астыннан
җырларга илһам табам.
Кайгым да бар,
Шатлык кына
тумаган минем өчен.
Мин картайсам,
җир яшәрә,
Шул бөтен сөенечем.

## Очрашу

Күктә бөдрә болытлар.
Синең чәч бөдрә.
Кайтасың,
Янәшәңнән
гөрләвек йөгерә.
Шулай ук,
Бәлки, беркем дә
Сагына белмәс,
«Сагындым» сүзен оныттым,
Үзеңне күргәч.
Телсез калып,
Колач җәеп
каршыңа киләм;
Йөрәк тибешең
Тәнемә
кагылу белән,
Агып яткан гөрләвек
Тукталыр төсле:
— Ник мин су!
Мәхәббәт уты
Булмадым икән нигә! — дип
Уфтаныр төсле.

## Әрсезләр

Никтер әле җирдә әрсезләргә
җиңелрәк ачыла ишекләр.
Әрсезләрне күзләр күбрәк күрә,
колаклар да тизрәк ишетә.
Җыелышларда күккә әрсезләрнең
исемнәре ешрак чөелә.
Начальниклар — яңа эшкә кергән
әрсез замын күреп сөенә.
Егетләрне әле кай җирдә дә
әрсез кызлар тизрәк карата.
Яшь кызлар да, никтер, тол хатын да
әрсез егетләрне ярата.
Хәтта аталар да, аналар да
кызларына егет димлиләр,
имеш: «Әрсез егет, дөнья күтәр,
үзе ярты бәхет ул!» — диләр...
Яратыгыз, кешеләр, димләгез дә —
каршы килү түгел теләгем.
Әмма була микән әрсез бәхет!
Әрсез кайгы барын беләмен.

*Рифгать Закиров*

## Яшьлек эзләре

Яшьлек кире кайтмый, диләр,
Кайта.
Урманнарга барып кер генә:
Һәр ешлыктан шаян малай чагың
Аермачык булып күренә.

Әйтерсең лә,
Юри уртәп йөри,
Поса-поса яшел имәнгә,
Искәрмәстән искән җилләр булып
Кулын сала синең иңнәргә.

Я булмаса,
Ул күбәләк булып
Җилбер-җилбер очып үтә дә,
Көтмәгәндә үлән арасыннан
Чәчәк булып башын күтәрә!

Көмеш чыклар ярып үткән эзең
Монда һәрбер алан саен бар.
Шул эзләрне саклап аланнарда
Басып тора кебек каеннар!..

●

Юл буенда факел сыман балкып
Ымлавыңны ачык шәйләдем.
Ә син, ахры, шуны сизеп алып,
Аның саен алга әйдәдең.

Мин йөгердем сиңа таба ашыгып...
Инде барып җитәм дигәндә,
Әллә каян кинәт давыл чыгып,
Бөтерелде синең тирәңдә. —

Һәм син сүндең,
Сүндең шәм шикелле —
Җилгә каршы тора алмадың.
Ә мин төнне ярып,
Таңга каршы
Ялгыз киттем, —
Туктап калмадым!

Караңгыда юлны яктыртмагач,
Маяк булып алга ник бастың?
Ялтыравың синең нәрсәгә соң,
Җил чыккач та сүнәр булгачтың?!

Хәй Вахит

# Соңгы хат

*Драматик поэма, сигез картинада*[1]

**БИШЕНЧЕ КАРТИНА**

Шәһәр. Яз. Зөһрә бүлмәсе. Зөһрә ялгызы. Борчулы, бер эшкә дә кулы бармый, йөренә. Кулындагы хатны бер кесәсенә сала, бер ала. Авыз эченнән генә җырлый.

З ө һ р ә.

Трал-ля-ля-ля-лям-пам,
Трал-ля-ля-ля-лям-пам...

Ишектә звонок шалтырый, Зөһрә ишек ачарга чыга, бераздан Зөфәр белән әйләнеп керә.

З ө ф ә р. Сәлам, Зөһрә. *(Плащын сала башлый. Зөһрә башын иеп кенә җавап бирә.)* Мин сиңа шатлыгымны уртаклашырга килдем. Минем бу министерстводагы эшем җайлы булып чыкты бит. Тагын бер баскычка күтәрделәр. Болай барса... Бүген министрда булдым. Квартир мәсьәләсен яздан да калдырмыйча хәл итәргә вәгъдә бирде.

З ө һ р ә. Бәхетең баса да тора, йөзлек белән тугансыңдыр син.

З ө ф ә р. Зөһрә, мине аспирантурага чакыралар. Әмма конкурс зур булачак. Урыны бер, теләүчеләр җиде-сигез.

З ө һ р ә. Аспирантурага Нияз тели иде.

З ө ф ә р. Теләгәч, авылга китмәскә иде, шәһәрдә калдырабыз дип торганда.

З ө һ р ә. Ә син ничек уйлыйсың, аспирантурага Нияз лаеклырак түгелме?

З ө ф ә р. Кем бәхетлерәк — шул лаек!

З ө һ р ә *(бик борчылып)*. Зөфәр, Нияз фәнни эшенә баш-аягы белән kerеп чумган. Ул инде җәнлекләрдә шактый сынау үткәргән. Хәзер аны төп мәсьәлә — препаратның кеше организмына тәэсире ничек булыр — шул кызыксындыра. Зөфәр, ул үз өстендә сынау үткәрмәкче була. Куркам мин аның өчен. Күп уйлап тормас, тәвәккәлләр. Шундый бит ул.

З ө ф ә р. Тәвәккәлләргә дисәң, аңа бир инде.

З ө һ р ә. Нишләргә, әллә аның хатларын әгигә укытыргамы? Турысын әйткәндә, мин аларны күптән күрсәтмәкче идем инде. Уңайсызланам. Ни әйтсәң дә, мәхәббәт хатлары бит. Нишләргә соң? Болай кул кушырып утырырга ярамый бит инде. Нишләргә: киңәш бир.

З ө ф ә р. Ничек киңәш бирә алыйм, мин бит аның хатлары белән таныш түгел. Үзең укытмыйсың, үзең киңәш сорыйсың.

З ө һ р ә. Аптырадым инде, нишләргә дә белмим.

З ө ф ә р. Зөһрә, мин ул хатларны укырга тиеш.

З ө һ р ә. Мин аларны сиңа бирә алмыйм.

---

[1] Ахыры. Башы 6 санда.

З ө ф ә р. Аңла, без Нияз белән якын дуслар!

З ө һ р ә. Юк, юк, ярамый, хакым юк.

З ө ф ә р. Бәлки, аңа берәр ярдәм кирәктер. Мин бит министерствода эшлим, мөмкинлегем бар дигән сүз. Ә бәлки аны куркынычлы адымнан коткарып калырга кирәктер?! Зөһрә! *(Зөһрә Зөфәргә текәлеп карап тора да хатларны суза.)* О, болар шактый. Егермеләп бардыр. *(Берәм-берәм хатларга күз йөгертеп чыга. Ашыга. Ә Зөһрә һаман да борчулы, авыз эченнән генә җырын кабатлый.)*

З ө һ р ә.

Трал-ля-ля-ля-лям-пам,
Трал-ля-ля-ля-лям-пам...

З ө ф ә р *(кәефе китеп)*. Шайтан алгыры, болардан берни дә аңлап булмый. Ул бит эше турында хәбәр итеп кенә барган. Нәтиҗәләрне генә язган. Кайда сынау процессы, кайда эзләнү процессы? Берсе дә юк.

З ө һ р ә. Ни телисең, ул бит диссертация язмаган. Хатлар гына.

З ө ф ә р. Мәхәббәт хатлары. *(Берничә хатка тагын күз йөртеп чыга.)* Берни аңлап булмый. *(Кулына эләккән хаттан тагын бер өзек укый.)* «Взятка тәкъдим иттеләр. Һәм, ничек дип уйлыйсың, Нияз Салихович баш тарткандыр дипме? Тартмады шул, алды...» Бу ни, җинаять юлына басканмы? Менә сиңа кирәк булса. Бу бит судка китә торган эш.

З ө һ р ә. Ул берни белән дә исәпләшми. Аның тормышта үз максаты, үз идеалы бар. Уңга-сулга карамыйча, ул шуңа омтыла. Безнең бергә башлаган темабызны ул берүзе дәвам иттерә. Эш шарты булмаса да. Ялгышлыкны да ачты, дөрес решениесен дә эзли. Ә без?.. Тукталып калдык. Бөтен хыялларым чәлпәрәмә килде. Безнең, синең белән, ялгышлыкны икърар итәргә дә көчебез җитми.

З ө ф ә р. Моңарчы дәшмәгәнне, хәзер күтәреп чыгаргамы? Булмый. Элегрәк булса, бер хәл иде.

З ө һ р ә. Мин көткән идем, батырлыгың җитәр, мәкаләңдә ул мәсьәләгә кагылырсың дип. Әмма, һаман шул ялгыш юлны дәвам иттерәсең, дөреслекне ачып салырга теләмисең.

З ө ф ә р. Син ни сөйлисең, мәкаләне укымаган килеш.

З ө һ р ә. Укыдым.

З ө ф ә р. Юк, син аны берничек тә укый алмадың!

З ө һ р ә. Укыдым шул менә.

З ө ф ә р. Укымадың!

З ө һ р ә. Укыдым!

З ө ф ә р. Кайдан алып?

З ө һ р ә. Әти өстәленнән.

З ө ф ә р. Мөмкин түгел. Мин бит аны калдырмадым.

З ө һ р ә. Әйе, теге чакта, профессор сиңа аерым бер симпатия белән карый, аннан файдалану гадел эш булмас дип, син аны кире алып киткән идең. Ә шулай да биргәнсең.

З ө ф ә р. Бирмәдем. Биргәнем юк. *(Кисәк аңлап алып.)* Ах, шайтан алгыры, әллә аның эшеме?

З ө һ р ә. Кем эше?

З ө ф ә р. Мин аны журналның секретарена калдырган идем. Чыннан да мәкалә профессор кулына эләккәнме? Шайтан икән, димәк, ул биргән. Секретарь. Минем рөхсәтемнән башка. Кирәк бит.

З ө һ р ә. Син юкка борчыласың.

З ө ф ә р. Ничек борчылмассың, күңелсезлек килеп чыкты бит. Мине нинди уңайсыз хәлгә куйды. Мальчишка!

З ө һ р ә. Я, тынычлан. Әле эш узмаган. Әле мәкалә әти кулына барып кермәгән.

З ө ф ә р *(тынып калды)*. Ничек?

З ө һ р ә. Мәкалә миндә.

З ө ф ә р *(көтмәгән иде)*. Синдә?

З ө һ р ә. Менә ул. *(Өстәл тартмасыннан мәкаләне чыгара.)* Беренче булып аны мин күреп алдым. Күрдем дә, Зөфәр Хәлиловичны уңайсыз хәлдә калдырмаска теләп, яшереп куйдым. Әтигә күрсәтмәдем.

З ө ф ә р. Димәк, профессор аны укырга өлгермәде? Фикерен дә әйтмәде?

З ө һ р ә. Бәхеткә каршы. Я, нигә сөенмисең? Күңелсез хәл булмыйча калды ич.

З ө ф ә р. Зөһрә!..

З ө һ р ә *(кискен)*. Җитте! Кирәкми! Оят түгелме, нигә син минем алда икейөзләләнәсең?! Ышандырам дип уйлыйсыңмы?!

З ө ф ә р *(тагын да тартышып маташуның юньлегә китермәячәген аңлап)*. Ай, син беркатлы кеше дә соң, Зөһрә. Син тормышны, аның бормалы юлларын белмисең. *(Тәрәзә янына китә.)*

З ө һ р ә. Ә син артыграк беләсең түгелме? *(Зөфәр дәшми.)*

З ө һ р ә *(җитди һәм шул ук вакытта өзгәләнеп)*. Зөфәр, мин сиңа күптәннән аңлатырга җыенып йөрим. Синең... *(уңайсызлануын җиңеп.)* Үзеңнең тормыш юлың турында уйланганың бармы?

З ө ф ә р *(борылмыйча гына)*. Моның белән ни әйтергә телисең?

З ө һ р ә. Зөфәр, син каядыр түбәнгә, караңгыга, сазлыкка тәгәри башладың шикелле.

З ө ф ә р. Я, я, дәвам ит!

З ө һ р ә. Син барысын да оештырасың. Фән юлында оештыру осталыгы белән генә уңыш казанып булмый, Зөфәр. Ул иҗат юлы!

З ө ф ә р. Фактлар!

З ө һ р ә. Әнә мәкаләң! Кызыклы гына язылган, талантсыз түгел. Әмма, үзең дә беләсеңдер, аның өстендә утырырга, сынаулар белән беркетергә кирәк иде әле. Ә син, лабораториядә казынасы, төпченәсе урынга, нишлисең, тизрәк профессорның рецензиясен оештырып, журналга бирергә ашыгасың. Тизрәк җимешен өзеп алырга.

З ө ф ә р. Әле оештыручы иде, хәзер җимешен өзүче?

З ө һ р ә. Әйе, әйе, сине бигрәк тә эшнең нәтиҗәсе кызыксындыра. Җимеше!

З ө ф ә р *(һаман да борылмыйча)*. Өзәрлек җимеше булганда, ә нишләп өзмәскә?!

З ө һ р ә. Ә бит аның җимешен өзгәнче агачын утыртырга, төбен йомшартырга, су сибәргә, тәрбияләп үстерергә кирәк. Фән юлына кергән кеше шуннан тәм табарга, ләззәт алырга тиеш. Әгәр дә шулай булмаса... Зөфәр, бәлки синнән фән кешесе чыкмастыр?

Зөфәр кисәк борыла, агарынган, сүз әйтә алмый. Ул бу кадәресен үк көтмәгән иде.

З ө һ р ә *(аның саен өзгәләнеп)*. Зөфәр, бәлки, сиңа аспирантурага керүнең бөтенләй кирәге юктыр? Ә нигә, бөтен кешегә дә галим булырга димәгән. Бәлки, синең сәләтең башка эшкәдер?

З ө ф ә р *(көчкә сүзләрен чыгарып)*. Мин галим булам. Булырга тиеш.

З ө һ р ә. Неудачник булып кала күрмә. Неудачник көнче була, башкаларның уңышын күралмаучыга, үч алучыга әверелә. Интриганга әйләнә. Сак бул, Зөфәр. Үзеңне кулга ал. Ихлас күңелемнән әйтәм. Без яшь бит әле, тотынсак, кулыбыздан әллә ниләр килер.

З ө ф ә р *(иреннәре кипкән, күзе белән графин эзли)*. Кая, кайнаган суың юкмыни? Зөфәр турында менә син нинди фикердә икәнсең. Аңа җимешен өзәргә генә булсын, ә? Аңа дан кирәк, исем, акча кирәк, машина, дача, матур хатын, ә?

З ө һ р ә. Минемчә, син үз көчеңә, үз сәләтеңә ышанмыйсың. Шуңа күрә икенче юл сайлыйсың. Ә ул юл — кешенең үз талантына хыянәт итүе... Монда су беткән икән. *(Икенче бүлмәгә чыга.)*

Зөфәр. Һе... Хыянәт... *(Зөһрә чәй алып керә.)*

Зөфәр. Хатларыңны җыеп куй. Әйе... Ә бит син үзеңә булган ачуыңны миннән алдың. Мине түгел, син үзеңне үзең камчыладың. *(Зөһрә тын кала, китә.)* Начармы, яхшымы, мин хәрәкәт итәм, нәрсәгәдер омтылам. Ә син? Кул кушырып утырудан башка, кем өчендер борчылып, сөйләнеп йөрүдән башка нәрсә эшләгәнең бар?! Нияздан егермеләп хат алдың. Җавап яздыңмы? Юк. Язмаячаксың да. Горурлык рөхсәт итми. Менә бүген дә син миннән киңәш сорыйсың. Үзеңнең карарың юк, дигән сүз. Ә берәү булса, Нияздан шундый шөбһәле хат килүгә, икеләнеп торыр идемени? Кош булып очып янына китәр иде. Куркынычлы адымнан аны коткарып калыр иде, ирек бирмәс иде, кирәк икән, үзе, әйе-әйе, үзе сынауны кабул итәр иде.

Зөһрә. Син нәрсә?!

Зөфәр. Шул шул!

Зөһрә. Мин аның янына бара алмадым. Эштән — клиникадан җибәрмиләр... эти авырый.

Зөфәр. Сәбәп эзләмә. Горурлык җибәрми. Синең арттан үзләре килергә тиешләр. Менә минем кебек. Ә мин киләм. Гаепләсәң дә, кусаң да киләм. Килмичә булдыра алмыйм. *(Мәкаләне өстәлгә куя.)* Каян алсаң, шунда сал.

Зөһрә. Әти өстәлөнә?

Зөфәр. Мин үз профессорымның фикерен ишетергә тиешме, юкмы?

Зөһрә. Бирәсеңме?

Зөфәр. Киресенчә, этиеңә син аны үзең бирәчәксең. Укып чыксын һәм якласын. Аңа безнең уңышыбыз бәйләнгән. Мәкалә журналда басылырга тиеш. Мин аспирантурага эләгергә тиеш. Үзем өчен генә түгел, синең өчен дә. Икебезнең дә киләчәге өчен!

Зөһрә. Менә ничек? Яхшы, бирермен. Әмма кереш сүз белән.

Зөфәр. Анысы ни тагын?

Зөһрә. Әти, диярмен, менә бер егет сиңа мәкаләсен укытырга тели, диярмен. Ул егет башта кызыңа провокация ясады, диярмен...

Зөфәр. Нәрсә?!

Зөһрә. Су коенганда ике иптәшен җибәреп кызыңа һөҗүм иттерде дә, шунда үзе ташланып, кызыңны батудан коткарган булып маташты, диярмен. Шуннан соң инде менә мәкалә китергән...

Зөфәр. Ялган, гайбәт, яла ягу. Нәрсә сөйлисең син. Үзең дә ышанмаган сүзләрне...

Зөһрә. Башта, сине алар белән бергә күргәнен кайтып әйткәч, Рафаэльгә ышанмаган идем, ышанырга теләмәгән идем.

Зөфәр. Кайда?

Зөһрә. Ресторанда. Ә хәзер... *(Йөзенә туры карый.)*

Зөфәр *(чигенергә мөмкин түгеллеген, үзе һөҗүм иткәндә генә отачагын аңлап).* Әгәр мин әйтсәм: әйе, дисәм, утырдык, хәтта мин аларны үзем сыйладым, дисәм? Чөнки мин аларга бурычлы. Алар сиңа һөҗүм итмәгән булсалар, мин үземнең кемлегемне, синең өчен җанымны да кызганмыйча үлемгә керергә әзер икәнлегемне күрсәтә алмаган булыр идем. Алар аркасында мин сиңа үземнең бирелгәнлегемне исбат иттем. Шуның өчен мин аларга сый куйдым, дисәм?

Зөһрә. Әгәр дә мин сиңа әйтсәм: бу маневрыңны фаш иткәч, ник алайса югалып калдың, агарындың, иреннәрең үк калтырый башлады, дисәм?

Зөфәр. Ул чагында мин әйтәм: әйе, барысын да үзем оештырдым. Бернинди дә хулиган түгел алар. Икесе дә бер ишек алдында, бергә уйнап үскән иптәшем. Син эчкәрәк йөзеп кереп киткәч, әйттем мин аларга: барыгыз, әнә теге кызны куркытып, батыра башлаган булып кыланыгыз, ә мин сезне айкап ташлармын да, аны үлемнән коткарыр-

мын, дидем. Әйе, бөтенесен алдан сөйләшеп эшләдем. Ни өчен дисеңме? Синең өчен! Сине үземә ныграк бәйләү өчен, гомергә үземнеке итү өчен.

Зөһрә. Фән дөньясында гына түгел, мәхәббәттә дә оештырган.

Зөфәр. Мин бит гел куркып яшим, Зөһрә. Сине югалтудан куркам. Һәр көнем шик астында үтә. Сине югалту миңа үлем белән бер. Сине бирәүгә дә бирмәс өчен әллә ниләр эшләргә дә әзермен. Берни алдында да тукталып калмыйм: хурлык алдында да, җинаять алдында да, корбан бирү алдында да. Кирәк икән, галим булырмын, профессор булырмын, кирәк икән, министр булырмын, әмма сине үземнеке итәрмен. Я син, я берни дә түгел! Синнән башка миңа тормыш юк. Яратам мин сине! Минем синең алда бер генә гаебем бар, Зөһрә: сине шашып яратуым!

Зөһрә. Юк, Зөфәр, мин синең мәхәббәтеңә ышанмыйм.

Зөфәр. Ышанмаска синең хакың юк.

Зөһрә. Ышанмыйм!

Зөфәр. Зөһрә!

Зөһрә. Юк! *(Зөфәр көчләп үпмәкче була. Зөһрә ирек бирми. Пауза.)*

Зөфәр. Аңладым мин сине. Миңа карата синдә бер генә тамчы да якынлык тойгысы юк икән. *(Хатларга күрсәтеп.)* Йөрәгеңдә ул гына. *(Зөһрә кискен хәрәкәт белән барып Зөфәрнең плащын ала да кулына тоттыра. Зөфәр ишек буенда туктала.)*

Зөфәр. Ха, шуны да аңламаска. *(Әйтергә карар бирде.)* Әгәр дә Нияз шундый хатлар язарга карар биргән икән...

Зөһрә *(шаяруга борып)*. Димәк, ул мине ярата, димәк, ул минем кулда. Чылбыр белән бәйләнеп куелган кебек.

Зөфәр. Анысы дөрес, ярата.

Зөһрә. Димәк, миңа булган мәхәббәте аңа көч бирә.

Зөфәр. Анысы да дөрес. Ләкин...

Зөһрә *(җитди)*. Син мине куркытасың.

Зөфәр. Җүләр син. Әгәр дә Нияз шундый хатлар язарга булган икән, димәк, ул инде синнән ваз кичкән.

Зөһрә. Ничек?!

Зөфәр. Гомергә очрашмаска карар биргән. Шулай булмаса, ул мондый хатларны язар идемени? Хатлар белән синең йөрәгеңне яуларга теләсә, ул пустяк булыр иде, ул чагында ул Нияз да булмас иде. Аның характерын белмисеңмени?! *(Чыгып китә. Зөһрә үйга кала.)*

Эчке пәрдә төшә

## АЛТЫНЧЫ КАРТИНА

Авыл. Яңгырлы кич. Нияз квартирасы. Квартираның бер читен бүлеп алганнар, анда, күрәсең, Ниязның сынау үткәрү өчен кирәк булган җиһазлары яшиндер. Шунда ук төрле приборлар белән тулган шкаф, китаплар өелгән өстәл.
Розалия ялгызы, мич томалап йөри. Аннан бүлмә янына килә, куян белән сөйләшә.

Розалия. Әй син, озын колак, хәлең ничек? Йокың киләме? Йокла, йокла. *(Нәрсәсендер рәтли, бишек җыры җырлый.)* Әлли-бәү, бәлли-бәү... Әй куян, куркак куян, йомшак куян... Үзең берни дә аңламыйсыңдыр әле. Син бит дөньяда иң мәшһүр куян булачаксың. Тарихта калачаксың, син шуны беләсеңме, юкмы, ә? Белмисең, колагың озын, акылың кыска.

Нияз кайта. Арыган.

Нияз. Розалия? Син тагын монда?

Розалия. Ә бүлмәне сез авырулар карап йөргәндә кем җылытып куя? Кичке ашны кем әзерли?

Нияз *(чишенә)*. Үзем әзерләр идем.

Р о з а л и я. Шул гына житмәгән, сезнең эшегез болай да...

Н и я з. Розалия, кирәкми минем турыда шулай борчылырга. Син яшь кеше, клубка барасы урынга вакытыңны биредә уздырасың. Кирәкми.

Р о з а л и я *(өстәлдән алып китап суза)*. Менә, Ибраһим абый калдырды.

Н и я з. Ох, менә монысына рәхмәт. Шатландырды. Каян тапкан, күпме эзләгән идем. *(Ачып укый ук башлый.)*

Р о з а л и я *(бераздан, саклык белән генә)*. Нияз абый, бу сынауны дим... Кешедә дә ясарга кирәк булыр инде аны, әйеме?

Н и я з *(укуыннан аерылып)*. Ә?

Р о з а л и я. Бик зур тәвәккәллек буламы инде ул?

Н и я з. Фәндә тәвәккәлләмичә булмый. *(Тагын укырга ябыша.)*

Р о з а л и я. Шул шул, куркыныч булмаса аны... Башта ашар идегез.

Н и я з *(китабын ябып куя)*. Әйдә бергә.

Р о з а л и я. Рәхмәт, мин тук.

Н и я з. Үзең әзерләдең, үзең баш тартасың. Тәмсездер әле. Әйдә алайса, озатып куям.

Р о з а л и я. Кирәкми, Нияз абый.

Н и я з. Тышта караңгы, вакыт та соң.

Р о з а л и я. Ә мин... кайтмыйм.

Н и я з. ?..

Р о з а л и я. Биредә калам.

Н и я з. Нәрсә?!

Р о з а л и я. Минем сезнең янда буласым килә.

Н и я з. Нәрсә дидең?! Беләсеңме син нәрсә сөйләгәнеңне?

Р о з а л и я. Мин уйладым инде, шулай карар бирдем.

Н и я з. Житте диләр сиңа, акылсыз кыз. Үз язмышың белән уйнарга менә мин сиңа ирек бирермен! Кире ал сүзләреңне. Ялгышлык белән генә ычкындырдым диген.

Р о з а л и я. Мин сезне яратам, Нияз абый. Бик яратам. Инде күптәннән. Баштан ук.

Н и я з. Ахмак, тиле бәрән орлыгы ашаган нәмәрсә. *(Розалиянең күз яшьләре бите буйлап тәгәрәп-тәгәрәп төшә, ә ул аларны сөртми дә.)* Нәрсә уйлап чыгардың син?!

Р о з а л и я. Минем бервакытта да болай яратканым юк иде әле. Бу — беренче мәртәбә. Газаплы да, шатлыклы да икән. Сезне ярату ул, Нияз абый, үзе зур бәхет. Менә мин һәр көн йокыдан уянганда күземне ачып жибәрүгә сөенеп куям: хәзер, дим, эшкә барам, аны күрәм, дим. Мин сезгә кечкенә генә булышлык күрсәтә алсам да, бер стакан кайнар чәй китерсәм дә — минем өчен ул зур шатлык. Минем өчен гомеремнең иң кадерле минутлары шул...

Н и я з. Ах, жүләр кыз, жүләр кыз. Ах, тиле...

Р о з а л и я. Беләм, мин сезгә тиң түгел. Шуңа күрә онытырга тырышып та карадым. Булмый. Йөрәкне буйсындырып буламыни?! Менә сез хирург, ә мәхәббәткә операция ясый алмыйсыз ич. Аннан соң мин онытырга теләмим дә. Әйттем ич, үзе бер бәхет дип. Мин сезнең кемне яратканыгызны да беләм. Исемен дә беләм: Зөһрә.

Н и я з. Кайдан, тагын почтаданмы?

Р о з а л и я. Хәтерлисезме, бер апа кыз бала тапкач, исем эзләгәндә сез аңа «Зөһрә» дип кушарга тәкъдим иттегез. Яратмагыз. Ә мин барыбер сезне онытырга теләмим. Теләмим, менә шул.

Н и я з. Син алай бик...

Р о з а л и я *(бүлдереп, тиз-тиз)*. Кирәкми, мине юатырга кирәкми.

Шул чакта ишек шакылдаталар. Нияз ачарга чыга, бераздан Зөфәр белән керә. Зөфәр юлдан килә, киемнәре юешләнеп беткән.

Нияз. Бу ничек болай, көтмәгәндә, уйламаганда?

Зөфәр. Чакырмаганда.

Нияз *(Зөфәргә чишенергә булыша).* Менә рәхмәт, дуслардан беренче булып бусагама син аяк басасың.

Зөфәр. Гадәтемне беләсең ич, беренчелекне бирергә яратмыйм.

Нияз. Саулыкмы?

Зөфәр. Бүре кебек. Ничек, өстерисеңме?

Нияз. Ат кебек.

Зөфәр *(чишенеп бетерә).* Ну! *(Кочаклашалар, үбешәләр. Кочаклашкан килеш үзләренең таныш җырларын суызалар. Башта «тралля-ляя-ля» дип кенә, ахырына җиткәч сүзгә күчәләр.)*

Кайда гына йөрсәң дә син,
Ниләр генә күрсәң дә син,
Җиңел юллар эзләмә,
Җиңел юл эзләмә...

Зөфәр. Ха-ха-ха... Син чыннан да эзләгәнеңне тапкансың. Юлларыгыз — о-о-о! Батып беттек. Юл газабы — гүр газабы дип, мөгаен, сезнең юлларга карата әйтелгәндер. *(Розалияне күреп ала.)* Исәнмесез.

Розалия. Исәнмесез. Розалия.

Зөфәр. Я, мактана башла. Ниләр җимерәсең? О, син бүлмәңдә лаборатория ачкансың түгелме соң? Таныйм мин сине, таныйм, үз дигәнеңне итми калмыйсың.

Розалия. Нияз абый, кичке аш плитәдә. Чәй дә кайнар. Мин китим инде.

Нияз. Тукта әле, Розалия. Сине озатырга кирәк.

Розалия. Мәшәкатьләнмәгез. Кунакны яхшы сыйлагыз. Безнең якларны ошатып китсен. Сау булыгыз. *(Чыга.)*

Нияз. Кара әле... *(Нишләргә дә белмичә, икеләнеп кала.)*

Зөфәр *(көлеп).* О, син монда вакытны бушка уздырмыйсың икән. Чибәр күренә.

Нияз. Юк, ул болай гына...

Зөфәр. Башта алар барысы да болай гына булалар. *(Көлә.)* Мин үзем дә карар бирдем инде. Ялгыз яшәү туйдырды. *(Шкафтан калын бер дәфтәр алып, актара башлый.)*

Нияз *(эчендәген сиздермәскә тырышып).* Шулаймыни? Бик вакыт. *(Табын әзерли.)*

Зөфәр *(дәфтәрне актара-актара).* Ник кемгә өйләнәсең дип сорамыйсың?

Нияз. Сорамыйча да чамалыйм. Аңадыр бит?

Зөфәр. Аңа. Дөресен әйткәндә, без инде аның белән... өйләнешкән дисәң дә ярый.

Нияз кызыл аракы чыгара.

Зөфәр *(дәфтәрне яба).* О, син бөтен бер диссертация язгансың.

Нияз. Юк, анда эшнең барышы, сынау нәтиҗәләре генә язылган. Көндәлек дисәң дә ярый.

Зөфәр *(дәфтәрне шкафка куя, өстәл янына килә).* Син мине нигә килгән дип уйлыйсың?

Нияз. Сагынып. *(Икесе дә көлә.)*

Зөфәр. Беләсеңме, менә бу фәнни эш миңа да тынгы бирми. Гаҗәпмени, ул бит безнең уртак темабыз. Бергә башладык, бергә эзләндек, дигәндәй. Ул чакта тапканнарыбыз ялгыш булып чыкты. Хәзер инде син аерым, үзең генә дәвам иттерәсең, мин аерым — үзем генә. Ә бит аерылганны аю ашар дигәннәр. Безгә бергә кушылырга, эшне бергәләп дәвам иттерергә кирәк түгел микән дим.

Нияз. Бик кызыклы фикер бу. Ә нигә, мин каршы түгел.



Зөфәр — артист *Әзһәр Шакиров*. Нияз — артист *Наил Дунаев.*

Зөфәр. Юкса, үзем генә уйланам, эзләнәм, баш ватам. Әйтергә кирәк, кайбер яңа фикерләрем дә бар.

Нияз. Шулаймы? Нинди фикерләр, яле?

Зөфәр. Ну, анысы соңыннан. Ә бәлки, минә ул фикерләр синдә дә тугандыр. Без, бәлки, бер-беребезне кабатлап ятабыздыр.

Нияз. Бик мөмкин.

Зөфәр. Препаратны үзеңдә сынап карамакчы буласың икән, дип ишеттем. Ул нәтиҗәгә нинди юллар белән килдең? Составы нинди?

Нияз. Юк, кешедә сынап карарга әлегә иртә. Элегрәк тәвәккәлләп карарга да исәп юк түгел иде. Әмма препаратта дефект ачылды. Әлегә өлгереп җитмәгән. Менә гел шулай: бер уңай нәтиҗә аласың, канатланып-шатланып йөрисең. Кисәк — кире нәтиҗә. Канатың каерыла. Бер табасың, бер югалтасың. Бер ышанасың, бер икеләнәсең.

Зөфәр. Миндә дә шул ук хәл.

Нияз. Менә яңа сынаулар ни күрсәтер тагын. Нәрсә, озын колак, хәлең авырмы?

Зөфәр. Үлә ич бу.

Шул чакта рөхсәт тә сорап тормыйча Дилбәр Галиевна килеп керә. Агарынган, тыны кысылган.

Дилбәр. Нияз Салихович, нишләдегез сез? Харап иттегез бит кыз баланы!

Нияз. Ни булды?

Дилбәр. Розалия... Розалия агу эчте.

Нияз. Кайда? Ничек?

Зөфәр. Агу?

Нияз. Булмас!

Дилбәр. Булган шул менә.

Нияз. Кайда ул, дежуркадамы? *(Ашыгып чыгып китә.)*

Зөфәр. Теге кызмы ул, әле генә биредә булган кыз?

Д и л б ә р. Әйе, мин аның биредән чыкканын күрдем. Ул елаган булган, күзләре кып-кызыл иде. Карасам, нәрсәдер кабул итеп маташа. Туктатмакчы булып, янына ташландым, ләкин соң иде инде. Кабул итеп өлгерде.

З ө ф ә р. Ни сәбәптән?

Д и л б ә р. Нидән агу эчәләр? Шул, мәхәббәт аркасында. Бәхетсез мәхәббәт фаҗигасе.

З ө ф ә р. Акылга сыймаслык эш. Бу бит...

Д и л б ә р. Әй, сез белмисез, ниләр эшләнә әле бездә.

З ө ф ә р *(өстенә киенеп, ашыгып)*. Әйдәгез әле, янына барыйк. *(Ишеккә юнәләләр.)*

Пәрдә

**ҖИДЕНЧЕ КАРТИНА**

Авыл. Яз. Больницаның дежур бүлмәсе. Караңгы. Менә әкренләп бүлмәгә яктылык җәелә башлый. Киң тәрәзә аша ерактан — урман артыннан сызылып таң атканы күренә. Без бүлмәдә ике кешене — Нияз белән Розалияне — төсмерли башлыйбыз. Розалия диванда урын-җир өстендә ята, Нияз аның янына — урындыкка утырган. Икенче бер урындыкта төрле дарулар, шприцлар.

Розалия күзен ача, караса: каршында Нияз абыйсы йокымсырап утыра.

Р о з а л и я *(гаҗәпләнеп)*. Нияз абый? Без кайда? *(Як-ягына карана, шунда гына барысын да аңлап ала.)* Ә... *(Үзен тәртипкә китерә. Ниязның шулай уңайсыз хәлдә йоклап утыруына борчылып, нишләргә дә белми. Аннан уятырга дигән карарга килә. Шыпырт кына.)* Нияз абый!.. *(Нияз күзен ача, механик рәвештә Розалиянең юрганын рәтләргә керешә. Бүлмәгә иртәнге саф яктылык җәелә.)*

Р о з а л и я. Хәерле иртә!

Н и я з. Сиңа да. Кәефең ничек?..

Р о з а л и я *(тантаналы)*. Нияз абый, мин сезне тәбрик итәм! Болай булгач, сынау уңышлы үтте. Сезнең эшегез җиңде.

Н и я з *(борчылып)*. Розалия, алтыным, зинһар... сиңа дулкынланырга ярамый.

Р о з а л и я. Әллә белмисез инде, мин сезнең препаратыгызны кабул иттем бит.

Н и я з. Беләм, акылсызым, беләм. Нигә алай эшләдең инде?

Р о з а л и я. Ә сез ничек уйлыйсыз, мин сезнең үзегездә сынау үткәргәнегезне күтеп ятарга тиеш идемме? Тыныч кына? Ялгышасыз. Сез фән өчен кадерле, халык өчен кирәгрәк, ә мин...

Н и я з. Ә син гәүһәр, алмаз! Кадерлем син!

Р о з а л и я. Белсәгез иде, сезгә ярдәм итә алуым белән мин нинди бәхетле! *(Тагын нәрсәнедер аңлап алып.)* Тукта, тукта... Сез төн буенча минем янда утырып чыктыгызмы? Йокламыйча, минем өчен борчылып? Хәтта мин кайбер кешене аңлый алмыйм, башыма сыймый. Ачуым килә, ничек ул сезне...

Н и я з. Әйдә, Розалия, аның турында бүтән сөйләшмибез. Ул язмышын башка белән бәйләргә булган. Күрәсең, яратадыр. Ул кияүгә чыга. Мин аның турында бүтән уйламаска тиеш.

Р о з а л и я *(бераздан)*. Нияз абый, дөресен генә әйтегез әле, сез курыктыгызмы?

Н и я з. Ә син ничек уйлыйсың?!

Р о з а л и я. Үләр дипме? Ә мин үзем уйлап та карамадым. Ышанасызмы, әгәр мин чын агу эчкән булсам да, әйтик, мышьяк, барыбер үлмәс идем. Мине үлем җиңә алмас иде. Менә, әгәр сезнең өчен шулай кирәк булса, мин хәзер шушыннан очып чыгып китә алыр идем. Кош шикелле. Билләһи, булдырыр идем төсле. Үземне шулай хис итәм. Сәер бит, әйеме? Көләсезме?

Нияз. Нишләп көлим, күреп торам ич, син хәзер дә күктә очып йөрисең, югарыда, каядыр йолдызлар арасында...

Розалия. Мин укыган китапта мондый сүзләр бар: *(эмоция белән)* «Килер шундый көн, кешеләр бер-берсенә карап сокланып туймаслар, һәркем башкалар алдында йолдыз булып балкыр!» Минемчә, ул көн килде бит инде.

Музыка.

Нияз. Килде шул. Менә син минем тормыш юлымны яктыртып җибәрдең бит әле. Һәр кеше үзе бер ачылмаган дөнья!..

Розалия. Ой, Нияз абый, сезгә ял итеп алырга кирәк. Бүген операция көне.

Нияз. Салкын су белән юынып алам да...

Музыка, кешегә мәдхия җырлый торган музыка үскәннән-үсә бара. Ут сүнә, музыка кульминациягә житә, туктала. Ут кабына. Кояш күтәрелгән. Күптән инде эш көне башланган. Бүлмәдә берәү дә юк. Дивандагы урын-җир җыелган, урындыклар үз урыннарына куелган. Ишектән сөйләшә-сөйләшә Нияз белән Зөфәр керә. Икесе дә ак халаттан. Нияз операциягә әзерләнә. Зөфәрнең кулында кечкенә калын дәфтәр. Нияз язмалары. Зөфәр нык дулкынланган, Ниязга нидер исбат итәргә тырыша.

Зөфәр. Теләсәң нәрсә диген, мин сине аңлый алмыйм. Юк, син дөрес яшәмисең. Тормыш юлыңны дөрес сайламадың. Синең алда нинди киң офык ачылган иде. Шәһәрдә, зур клиникада, фән дөньясының үзәгендә. Ә син — галим булырга омтылган кеше, яшь хирург, талантлы кеше — син кайда хәзер? Җәһәннәм чигендә, сахрада. Киңәшәм дисәң — белгече юк, өйрәнәм дисәң — остазы.

Нияз. Әгәр дә минем биредәге эшем кешеләр өчен кирәкле икән?

Зөфәр. Ох, кара син аны — безнең Нияз Салиховичны — ул нинди олы җанлы изге бәндә икән. Ишеттем, сөйләделәр: авылда үз кешегә әверелеп беткәнсең. Һәркемнең моң-зарын тыңлыйсың, һәркемнең гозерен үтисең. Әйтерең бармы, народникның үзе инде. Әмма син шуның хисабына беләсеңме нәрсә югалттың?! Монда бит, эшлим дисәң, җүнле шарты да юк.

Нияз. Романтика!

Зөфәр. Хәзер кибернетика заманасы, дустым. Һәр адымың төгәл исәпләнгән булсын. Ярый, эшлә дә, чәнчелеп китсен, бер ел әллә ни зур югалту түгел. Әмма шул югалту бәрабәренә син нинди дә булса отыш алырга тиеш идең ләбаса. Бу сиңа югарырак сикерү өчен трамплин булырга тиеш иде. Менә шул чакта мин сине аңлар идем. Ә болай...

Нияз. Отыш эзләмим.

Зөфәр. Юк, Нияз, дөрес яшәмисең. Дилбәр белән конфликтка кереп беткәнсең. Нигә кирәк иде сиңа катнашырга. Сугышсыннар иде шунда үзара.

Нияз. Гаделсезлеккә читтән генә карап тора алмыйм. Каным кыза, җилкә төкләрем тырпая башлый.

Зөфәр. Бу Розалия мәсьәләсе тагын. Я, кемнәр белән аралаштың?! Теләсә кемне үзеңә якынайтырга ярыймы?! Хәзер инде менә скандал. Фәнни эшебезне дә юкка чыгармагайлары әле. Ә аспирантурага эләгүне башыңнан ук чыгарып ыргыт. Ишеген үзең яптың. Суд алдына бастырмасалар, шөкрана ит инде. Ярый әле үзем килеп төштем. Бу баткаклыктан, бәлки, колагыңнан тартып булса да, чыгарып булыр. Министерствода ничек тә җайларга тырышырмын. Эшне зурга җибәртмәм. Менә телефонга заказ бирдем. Министрны әзерләп куярга кирәк.

Нияз. Кара әле, мин операциягә әзерләнәм. Тынычланырга иде.

Зөфәр. Әйе, әйе...

Нияз диванга утыра, башын артка ташлап күзләрен йома, онытылырга тырыша.

З ө ф ә р *(Ниязның хезмәтен актара).* Әйткән идем ич, безнең берберебезне кабатлавыбыз ихтимал дип. Менә, бер үк фикерләр. Кара әле, синең бу диссертацияңне...

Н и я з. Көлмә.

З ө ф ә р. Язмаларыңны дим... Мин үзем белән аламмы инде?

Н и я з *(һаман да «йокы» аралаш).* Ал.

З ө ф ә р. Бәлки, кайбер урында күрсәтергә кирәк булыр. Аңарчы, әлбәттә, машинкада бастырырмын. Кайбер корректуралар кертеп.

Н и я з. Туры килер.

З ө ф ә р. Ә авторлар? Кызык килеп чыга бит әле. Тема уртак, фикерләр уртак, ә...

Н и я з. Икебезнең исемне дә куй.

З ө ф ә р. Миңа бераз уңайсызрак, әлбәттә. Әмма шулай эшләргә туры килмәгәе. Хезмәтнең киләчәк язмышы турында уйлаганда, бу, ихтимал, дөрес булыр. Бездә хәзер күмәк эш почетта. Ләкин ахырдан чигенүләр булмастыр бит? Мин күбрәк эшләдем, син азрак дип...

Н и я з. Кем исемен куюдамыни хикмәт. Эш булсын, синекеме, минекеме — нәтиҗәсе күренсен.

З ө ф ә р. Ярар, килештек. *(Канәгать.)* Без бу хезмәт белән кайберәүләрнең күзен акайтмагаек әле. Профессор үзе...

Н и я з. Соң инде. Профессор белә.

З ө ф ә р *(үзгәреп китә).* Белә?!

Н и я з. Күптән түгел профессордан хат алдым.

З ө ф ә р. Ничек?

Н и я з. Мин берәүгә хатлар язып торган идем. Шул хатларны...

З ө ф ә р *(онытылып).* Зөһрә аларны әтисенә биргәнме?

Нияз моны көтмәгән иде. Зөһрә исемен ишетүгә ул сискәнеп-«уянып» китә, әмма шунда ук үзен кулга ала, тынычланырга-онытылырга тели. Ә Зөфәр кызганнан-кыза бара.

Ах, менә ничек?! Ул хатлар бит синеке, анда минем исем юк. Димәк, хезмәтнең авторы да син генә? Тема уртак, безнеке, бергә башладык. Анысын табарга, монысын алырга — мин күпме йөгердем, күпме оештырдым. Хәзер читтә каламмыни?! Менә, дус дип ышан сиңа. *(Тәмам тугарылып.)* Хатлар, хатлар профессорда. Аларда бит барысы да язылган. Шулай булгач... *(Нияз диванга сөялгән килеш, бер дә селкенмичә тыңлаган иде, әйтерсең, йоклап утырды. Менә ул аягына баса һәм без аның үзгәргәнен, эченнән бик нык кабынганын күрәбез.)*

Н и я з. Димәк, син аларны укыдың?!

З ө ф ә р. Әйе, укыдым. Зөһрә белән безнең арада сер юк.

Н и я з. Укыдың да, минем фикерләрем белән коралланып, минем хезмәткә хуҗа булырга чамалыйсың? Соавторлык даулыйсың? Гаҗәпләнгән идем аны, бу нишләп нәкъ минем хатларда язылган кадәр генә белә соң әле дип. Аның хикмәте бар икән. Элегрәк шаяртырга ярата идең, фән юлына керү өчен бүре кебек усал, төлке кебек хәйләкәр булырга кирәк, дип. Күрәм, уйнап әйткәннәрең хәзер чынга әйләнгән. Ләкин фән юлына керү өчен ат кебек эшләргә кирәк, дустым.

З ө ф ә р. Белми идем.

Н и я з. Шуны бел, миңа синең министерствода яклавың кирәкми. Гомумән, беркайда да. Җәзага лаек икәнмен, бирсеннәр.

З ө ф ә р. Ә бу нәмәрсәңне төлкегә ышанмыйсыңдыр бит инде?

Н и я з. Әйе, мин аны сиңа ышана алмыйм. *(Хезмәтен Зөфәр кулыннан кире ала. Шул чагында Дилбәр килеп керә.)*

Д и л б ә р. Зөфәр Хәлилович, телефонда — Казан.

Зөфәр ашыгып чыгып китә.

Д и л б ә р. Нияз Салихович, сез операциягә әзерләнгәнсез икән, кызганычка каршы, ашыккансыз. Ул хатын өенә кайтып китте.

Нияз. Ничек?!

Ибраһим килеп керә.

Ибраһим. Дилбәр Галиевна, бу ни эш?! Нишләп сез операциягә әзерләнгән, хәзер операциягә ятарга тиешле хатынны чыгарып җибәрәсез?

Дилбәр. Ул үзе китте. Ул Нияз Салиховичка операция ясатырга теләми. Курка.

Ибраһим. Соң бит аңа операция кирәк. Сез врач, моны яхшы беләсез, аңлатырга тиеш идегез. Үзе белән яхшылап сөйләшергә иде.

Дилбәр. Мин сөйләштем. Ул миннән турыдан-туры сорады. Минем урында булсагыз, нишләр идегез, ятар идегезме, диде.

Ибраһим. Ә сез, әлбәттә...

Дилбәр. Ә мин әйттем, ятмас идем дидем. Шулай, мин алдарга өйрәнмәгәнмен.

Ибраһим. Барыбер аны кайтарып җибәрергә сезнең хакыгыз юк. Монда хирург бар, мин бар. *(Беренче мәртәбә тавышын күтәрә.)* В конце концов, кем монда баш врач: сезме, минме?

Зөфәр кире керә.

Зөфәр. Министр туры килмәде.

Дилбәр. Һе, хирургия бүлегеннән авырулар кача башлаганга мин гаепле икән. Хирургка авыру аллага ышанган кебек ышанырга тиеш. Белмим, Нияз Салиховичка кем генә ышаныр икән дә, кем генә операция ясатыр икән. Розалия белән булган хәлдән соң! Һәркемгә үз сәламәтлеге кадерле. *(Ибраһим йөрәге янында авырту сизеп, кулын күкрәгенә куя. Дилбәр аны шунда ук күреп ала.)* Менә бит үзегез дә Нияз Салихович пычагы астына ятарга теләмисез. Операция кирәген белсәгез дә. Нигә? Чөнки ышанмыйсыз. Ә ни өчен башкалар ышанырга тиеш?

Ибраһим *(газапланып)*. Сез... сез нәрсә?! Сез... бик яхшы беләсез бит. Мин, гомумән, операциягә ятарга җыенмыйм. Ниязга да, шәһәр авторитетларына да. Куркам, аңлыйсызмы, куркам. Монда Ниязның ни гаебе бар? Ә сез... Ничек телегез күтәрелә.

Зөфәр. Ну, Дилбәр Галиевна... кирәкмәс иде. Анысы аның Ибраһим аганың үз эше — шәхси эше, Нияз Салихович турында үз фикере бар икән, ышанып бетерми икән, без аңа катнашмыйк инде. Үзе ышанган хирургка ясатыр, шәһәрдә бер дигәненә. Урнаштырырга үзем булышырмын. *(Икенче темага күчә.)* Министрны туры китерә алмадым. Министерство вәкиле буларак, мин моннан, күрәсең, мәсьәләне хәл итмичә кайтып китәргә тиеш түгелмендер инде. Ибраһим ага, ә бит Дилбәр Галиевна бер нәрсәдә хаклы: сезгә дөрестән дә кичекмәстән операциягә ятарга кирәк.

Ибраһим *(кәефе китеп)*. Тагын!

Зөфәр. Беләбез, бу адымга сез үзегез җөрьәт итә алмыйсыз. Коллегаларыгыз да күндерә алмаганнар. Шунлыктан, үзем батырчылык итәм. Әйдәгез, мин сезгә булышам. *(Киңәш итеп.)* Сез иртәгәдән шәһәргә китәсез, операциягә. Мондагы хәлләр өчен борчылмагыз. Җайга салырбыз. Эшегезне алып баручы да табылыр. Тыныч булыгыз. Менә, мәсәлән, *(бераз көттереп)* больницада баш врач вазифасын, Дилбәр Галиевна, сезгә алырга туры килер. *(Пауза.)* Безгә билгеле булганча, Ибраһим ага үзе дә баш врачлыктан китәргә җыенып йөргән икән. Инде без аның теләге белән исәпләшмичә булдыра алмыйбыз. Карт белгечләргә без үз вакытында ял бирергә дә тиешбез.

Ибраһим. Гамәлдән сызып ташларга икән.

Зөфәр. Аннан, дөресен әйткәндә, Ибраһим ага, мәсьәләне хәл иткәндә сезнең өчен иң кулай вариант шушы булыр. Югыйсә, больницада

тәртипсезлек чамадан ашкан, түзеп торырлыгы калмаган. Без әле сезнең күпьеллык хезмәтегезне искә алып кына...

Ибраһим. Рәхмәт илтифатыгызга.

Зөфәр. Мин башкача эшли алмыйм, хакым юк. Сез, алла хакы өчен, Ибраһим ага, аңлый күрегез.

Ибраһим. Аңламыйммы соң, аңлыйм, бик аңлыйм.

Дилбәр. Мин нәрсә әйтәм: әгәр дә больницада шушындый хәл килеп чыккан икән, мин карышмыйм, Зөфәр Хәлилович, сезнең тәкъдимегезне кабул итәм. Әмма минем шартым бар: мин Нияз Салихович белән эшли алмаячакмын. Әгәр дә ул һаман да безнең больницада кала бирә икән, ул чагында, гафу итегез, мин баш врач була алмыйм. Киресенчә, бу больницадан кучү мәсьәләсен куячакмын.

Зөфәр. Сабырлык, туктагыз, зинһар кызмагыз әле.

Дилбәр. Ә бит дөреслектә Ибраһим ага да аның аркасында бу хәлгә дучар булды.

Ибраһим *(кызып)*. Нәрсә дип каныктыгыз әле сез Ниязга? Нинди гаеп таптыгыз?!

Дилбәр. Санап күрсәтергә кирәкме? Рәхим итегез: финанс законнарын бозган өчен приказ буенча кисәтү алдымы? Аның бүлегеннән авырулар кача башладымы? Менә, мәсәлән, бүгенге факт. Аның аркасында больница хезмәткәрләре агу эчә башладылар. Коточкыч хәл бит бу. Судка китә торган эш.

Нияз. Күпертмәгез. Розалия белмичә, сынау үткәрәм дип, өлгереп җитмәгән препаратны кабул иткән.

Дилбәр. Куаныгыз үлгән иде. Розалия аны белгән. Нәкъ менә шуның өчен дә, препаратның агу икәнен белгәнгә күрә дә, кабул иткән ул аны.

Шул чакта Розалия үзе килеп керә. Авырулар халатыннан.

Розалия. Гафу итегез. Мөмкиндер бит?

Зөфәр. Розалия? Нишләп урыныгыздан кузгалдыгыз?

Розалия. Сезне шатландырасым килде. Дилбәр Галиевна, нишләп сөенмисез? Менә ич күз алдыгызда басып торам, сау-сәламәт, җен шикелле. Димәк, Нияз абыйның препараты әйбәт булып чыкты. Белсәгез иде, шундый тыныч кына онытылганмын. Аркылыга-буйлыга турасалар да, берни сизмәс идем. Борчылмас идем дә. Уянып киттем — иртән йокыдан уянган кебек. Бер җирем авыртмый: башым да, йөрәгем дә.

Дилбәр. Авыртмас шул. Шулкадәр уколлар кадалгач.

Розалия. Менә анысы кирәкмәс иде.

Дилбәр. Сугыштан соң батыр күбәер, диләр. Рәхмәт әйт әле, коры куык. Уколлар ясалмаса, бәлки инде теге дөньяда булыр иден.

Розалия. Юк, барыбер берни булмас иде, менә күрер идегез, каршыгызда басып торыр идем, чекрәеп! Нияз абый, нигә инде уколлар ясадыгыз? Менә хәзер нәрсә килеп чыга инде: препарат яраклымы, яраксызмы — белә алмыйбыз.

Нияз. Иң әһәмиятлесе, үзеңә зыян килмәве, Розалия.

Розалия *(кәефе китеп)*. Бу сынау бер нәрсәне дә исбат итә алмадымыни инде?

Нияз. Итмәде.

Розалия *(шунда ук йөзе ачылып)*. Алайса, мин яңадан кабул итәм!

Дилбәр *(чәчрәп чыга)*. Менә! *(Зөфәргә.)* Менә күрдегезме? Фәнни эш шушындый методлар белән алып барыламыни?! Әллә инде... Ах, әйе, әйе, аңладым булса кирәк.

Нияз. Әйтеп бетерегез!

Дилбәр. Әйтәм. *(Розалиягә.)* Син чыгып тор әле. Бар, урынына

ят. *(Розалия чыгып киткәч, Ниязга.)* Сез Розалиянең мондый адымга барачагын алдан сизенгән булырга тиеш идегез. Ә бәлки, сизенгәнсез дә. Шулай да...

Нияз. Сез нәрсә?!

Дилбәр. Сез аңа юри юл куйгансыз. Белә торып. Яшь кешенең беркатлылыгыннан, үзегезне яратуыннан файдаланасыз. Мондый юл белән препаратны сынау рөхсәт ителә торган алым түгел. Бу җинаять! Розалия куян түгел, ирек бирмәбез!..

Ибраһим *(түземичә)*. Җитәр сезгә! *(Авыр пауза.)*

Дилбәр. Моңарчы тыныч кына яшәгән коллектив, Зөфәр Хәлилович, ул килгәч пыран-заран килеп бетте.

Зөфәр. Әйе, коллективны бу хәлендә калдырып булмый. Чамадан ашкансыз. Кемнедер моннан алырга туры киләчәк. *(Йөренә.)* Нияз Салиховичка коллегалары белән конфликтка кермәскә кирәк иде, әлбәттә. Моны һич аклап булмый. Дилбәр Галиевна китергән фактларны да читләтеп үтеп булмый. Нияз Салиховичның биредә эшли алуына мин үзем дә ышанмыйм. Аны эшеннән алырга туры килер. Ул үзе дә моны аңлар, дип уйлыйм.

Ибраһим. Ә приказны кем бирә?

Зөфәр. Приказны мена баш врач Дилбәр Галиевна бирер.

Дилбәр. Бирелгән дип исәплэгез.

Ибраһим *(ашыкмыйча)*. Алайса рөхсәт итегез, мин соңгы күрсәтмәмне бирим.

Дилбәр. Рәхим итегез.

Ибраһим. Нияз Салихович, әзерләнегез, сезгә тиздән операция ясарга туры киләчәк. *(Картның нәрсә әйтергә теләгәнен аңлап бары да тынып кала.)*

Нияз. Кемгә?

Ибраһим. Карт врач Ибраһим абзыена!!

Нияз. Нәрсә?! Мин ясаргамы? Юк, юк, сез шәһәргә китәсез.

Ибраһим. Шәһәргә китсәм, кешеләр ни дияр: «Әһә, үзе Ниязга ышанмады, китте, ә безгә ярый икән монысы да», — дияр. *(Дилбәргә күрсәтеп.)* Әнә ич, шуны гына көтеп торалар. Миңа шәһәр юлы ябылган, коллега.

Нияз. Юк, юк, минем өчен шундый адым атларга, сәламәтлегегез белән, тормышыгыз белән тәвәккәлләргә, минем өчен? Юк, хакыгыз юк!

Ибраһим. Тиле. Мине сәламәтлеген корбан итә дип уйлыйсыңмы? Юк, мин сиңа ышанам, Нияз. Шуңа күрә карар кылдым да. Анысы дөрес, яшермим, операция уңышлы чыкса, миңа икеләтә күңелле булыр: үзем өчен дә, синең өчен дә. Ә мин аның уңышлы чыгачагына ышанам.

Нияз. Рәхмәт сезгә, Ибраһим ага. *(Кочаклый, күзендә яшь.)*

Ибраһим. Я, карт алашаны тунарга алынасыңмы? Үзеңә ышанасыңмы соң?

Нияз *(бераздан)*. Алынам, Ибраһим абый.

Ибраһим. Димәк, менә мәсьәлә үзеннән-үзе хәл ителде. Нияз Салихович больницада эшләвен дәвам иттерә дигән сүз. Пациент соравы буенча.

Дилбәр. Вакытлы рәвештә.

Кузгалалар.

Зөфәр *(Нияз белән генә калгач)*. Нинди хәлгә куйдын.

Нияз *(юмор белән)*. Нишлим соң, берничек тә ярдәм итә алмадым шул. Артык борчылма инде.

Зөфәр. Кызык, мин юатасы урынга, син юатасың.

Нияз. Монда минем хәлгә караганда, синең хәл мөшкелрәк бит.

З ө ф ә р *(кызып)*. Нишләргә тиеш идем соң мин?! Мәсьәләне ачык калдырыргамы? Алай минем өчен җиңелрәк булыр иде. Әмма мин синең турыда кайгыртам. Уйла, әгәр приказ бирдертмәсәм, бүген үк гомуми җыелыш җыйналыр иде, эшең райкомга китәр иде, министрга җитәр иде. Һәр инстанциядә үзеңне чәйнәрләр иде, иләктән иләккә иләрләр иде. Ә нәтиҗәсе шул ук: эшеңнән алырлар иде. Ә болай тавыш-тынсыз гына. Сарык та исән, бүре дә тук. Монда кендегең беркмәгән. Бер чемоданыңны күтәрәсең дә министерствога киләсең, үземә керәсең. Җаен табармын: теләгән больницага китәрсең. Тик шәһәрдә генә булмас, аңысын ышандыра алмыйм.

Н и я з. Рәхмәт, мин моннан китмим. Гаделсезлекнең тантана кылуын теләмим.

З ө ф ә р. Идиот. Ахмак.

Н и я з. Куылган кеше булып китәргәме? Шуңа риза булып?

З ө ф ә р. Ә сиңа монда калырга ярамый. Взяткалар алып, җинаятькә батып беткәнсең.

Нияз шаркылдап көлә.

З ө ф ә р. Ярый, мин киттем, машина көтәдер.

Н и я з. Хәерле юл.

З ө ф ә р. Рәхмәт.

Н и я з. Туеңа чакырырсыңмы?

З ө ф ә р. Әлбәттә. Ә син?

Н и я з. Килерсеңме?

З ө ф ә р *(бераз уйлагач)*. Бернигә карамый. *(Кузгала. Тагын туктала.)* Сау бул.

Зөфәр чыгып китә. Нияз беркавым урыныннан кузгалмый. Аннан кискен бер карарга килеп, кәгазь-каләм алып, хат язарга утыра. Сәхнә караңгылана. Нияз прожектор уты яктысында кала. Һәм кисәк ике ут тасмасы ике кешене яктырта. Аның берсе — Зөһрә, ул хат укый. Икенчесе — Нияз. Без аны хәзер аягына баскан хәлдә, Зөһрәдән өч-дүрт адым арттарак күрәбез. Декорация алмаштыруның кирәге юк, чөнки ул бөтенләй күренми.

Н и я з. Хуш, Зөһрә! Бу минем сиңа соңгы хатым.

З ө һ р ә. Соңгы хат?

Н и я з. Кияүгә чыгасың икән, киләчәгеңне бозасым килми.

З ө һ р ә. Юк, юк, юк!

Н и я з. Тигез гомер телим. Бәхет телим. Ихлас күңелемнән.

З ө һ р ә. Дөрес түгел, түгел! Берәүгә дә тормышка чыгарга җыенганым юк минем. Гомумән, яратмыйча кияүгә чыкмаячакмын. Ә мин бары сине генә, ишетәсеңме, сине генә яратам!..

Н и я з. Хуш, минем өчен борчылма. О, күпме көч, илһам, шатлык бирдең син миңа. Гомеремнең шушы кыска гына юлында да аяк чалучылар булды, әмма ега алмадылар. Кая мине егарга, мин бит канатлы, күктә очам. Син бирдең миңа ул канатларны, Зөһрә! Әгәр дә эзләгәнемне таба алсам, мин аны синең исемең белән атар идем.

З ө һ р ә. Мактарга түгел, орышырга кирәк мине, тиргәргә кирәк. Күпме хатыңа бер җавап язмадым, йөрәгемне ачмадым. Эшеңдә ярдәм итә алмадым. Борчылган булдым, әмма шуннан узмадым.

Н и я з. Гомер юлым кая гына илтсә дә, кемнәр белән генә очраштырса да, синең исемең минем күңелемдә булыр, Зөһрә. Рәхмәт! Хуш мәңгегә!

Китә.

З ө һ р ә. Юк, юк, түгел. Түгел! Шулай ук син минем дөньямнан бөтенләй китәргә карар кылдыңмыни? Хатларың килеп тора иде, мин аларны көтеп ала идем. Сине янәшәмдә хис итү рухыма дәрт, күңелемә шатлык китерә иде, бөтен дөньям ямьгә күмелә иде. Болар барысы да вакытлы гына булдымыни? Шулай ук мин сине гомергә югал-

таммыни? Шулай ук син миннән ваз кичтеңмени? Синнән башка ничек яшәрмен мин?! Ә нишләп сиңа йөрәгемне ачмыйм әле? Язам, хәзер үк язам!..

Зөһрә хат язарга утыра. Ләкин шунда ук бер карарга килеп, язганын ертып ташлый.

**СИГЕЗЕНЧЕ КАРТИНА**

Нияз булмәсе. Кич. Ниязның дуслары җыйналган. Нияз белән Розалиянең язылышулары уңае белән үткәрелә торган кечкенә генә мәҗлес. Араларында Зөфәр дә бар. Беренче чиратта күзгә ташланганы шул — Нияз Розалияне Зөһрәгә охшатып киендергән. Җыр, музыка. Кунаклар бераз кызарга да өлгергәннәр инде, үзләрен бик иркен тоталар. Розалия аларны сыйлап йөри, ул шат.

Талдай зифа буйлары,
Бигрәк матур уйлары.
Шаулап торсын,
Гөрләп торсын,
Җырлап торсын туйлары

Якты гомер юлыгыз
Күмелсен гөл-чәчәккә,
Дуслык нурын,
Яшьлек җырын
Алыгыз киләчәккә.

Нияз янына Розалия килә, Зөфәр өстәл белән ике арада йөри. Нияз белән Розалиягә рюмкалар китерә.

Розалия. Нияз абый!.. Мин сезгә һаман да «абый» диярмен микән?

Нияз. «Сез?» Ә син башта «син» диярга өйрән.

Розалия. Анысы булыр да. *(Әйтеп карый.)* Нияз абый, син... Минә ич, була. *(Тагын әйтеп карый.)* Нияз, син! О, юк, монысы булмый, Нияз абый.

Нияз. Вакыт өйрәтер әле.

Зөфәр *(яннарына килә)*. Минем сезне аерым тәбриклисем килә. *(Рюмка күтәреп.)* Тигез гомер телим!

Розалия. }
Нияз. } Рәхмәт!

Нияз. Ә шулай да, Ибраһим абыйны алып килеп утыртыйк.

Зөфәр. Ашыкма, Нияз. Уен дип беләсеңме, карт организм, шундый катлаулы операциядән соң. Шаяра торган эш түгел.

Нияз. Белмим инде. Аннан башка мәҗлес үткәрү...

Зөфәр. Мәҗлес аңа өстәмә авырлык кына булачак. Борчыма картны, тыныч кына ятсын. Соңгы мәҗлесең булмас.

Нияз. Әллә ничек...

Зөфәр. Мин аның янына кереп чыктым, урыныннан кузгалмаска күндердем.

Розалия. Ибраһим абый анда тыныч кына ята аламы соң? Күнеле белән ул, барыбер, бирелә. Хәзер җилтерәтеп алып киләм мин аны. *(Ишектә Фәйзи Шакирович белән очраша.)* Фәйзи абый, әйдәгез, әйдә.

Розалия үзе чыгып китә.

Фәйзи. Нәрсә, мине көтмәдегез дәмени?

Нияз. Әйдә, Фәйзи абый, түрдән уз.

Фәйзи. Болай булгач, узабыз инде аны. Әстәгъфирулла, сез шактый юл алгансыз түгелме соң, никадәр шешәнең башына җиткәнсез. *(Фәйзи алдына чәнечке-кашыклар куялар.)* Монысы булды — формасы. Кормасы да булырмы?

Нияз. Нәрсә китерик?

Ф э й з и. Нәрсә сорасам оттырмам икән? Бармы кыздырылган мороженое? *(Көлеш.)*

Н и я з. Плаумы, тавыкмы, балыкмы?

Ф э й з и. Өчесен дә.

З ө ф ә р. Иптәшләр, безгә тамада сайларга кирәк булыр.

Ф ә й з и. Кирәк. Клаунсыз цирк, мәзәкчесез мәҗлес буламыни?!

З ө ф ә р. Фәйзи Шакирович, сезне!

Ф ә й з и. Уйлаган идем аны, болар тикмәгә генә түргә утыртмыйлардыр дип. Зарплатасы күпме булыр? *(Көлеш.)* Ярар, риза. Тавышка куям. Каршылар юкмы? Менә мин хәзер күрсәтим әле сезгә кемлегемне!

Н и я з. Кемнең кем икәнен беләсең килсә, кулына власть тоттыр, дигәннәр.

Ф ә й з и. Разговорчики! *(Мәҗлес шау-гөр килеп утыра. Көлеш.)*

Н и я з *(Зөфәргә кинаяләп)*. Фәйзи абый, сине бит әле анда взятка биргән, дип сөйлиләр.

Ф ә й з и. Ният юк түгел иде, әмма булдырып булмады. Акчаны кире кайтарып бирде. Мин вҗәткә дим, ә ул әҗәткә ди. Әҗәткә дә вҗәткә. Шул ике сүз арасында буталдым.

Н и я з. Ә син ул кешегә бик зур ярдәм иттең. Әҗәткә биреп торып.

Ф ә й з и. Кешесе шундый иде. Берни җәл түгел. Акча гынамы, акылымны да бирер идем әле, булса. *(Мәҗлес тагын гөр килеп ала. Фәйзи җырлап ук җибәрә.)*

> Агыйделгә сал килгән,
> Агар җире тар килгән,
> Юк Казанда, юк Мәскәүдә
> Сезнең кебек пар килгән.

Ибраһим белән Розалия керә.

И б р а һ и м. Ышан син хәзерге яшьләргә. Кара, миннән башка гына уздырмакчы булалар бит, ә. *(Ибраһим керү белән, һәркемдә күтәренкелек.)*

Ф ә й з и. Ай, рәхмәт, Ибраһим абый, шатландырдың безне.

З ө ф ә р. Урын, урын, хөрмәтле кунакка урын! Менә, түрдән.

И б р а һ и м. Каяле, башкода урынына!

Ф ә й з и. Әй-әй, монда башкодадан да өстенрәк — тамада үзе утыра!

И б р а һ и м. Нияз, хәтереңдәме, әйткән идем: ике шатлык бергә килер дип. Монда өч шатлык бергә килде бит әле.

Ф ә й з и. Аңлатып бирүегезне сорыйбыз, Ибраһим абый.

И б р а һ и м. Операция уңышлы чыкты — бер куанам, Нияз уңышы өчен — ике куанам. Өченчесе *(Нияз белән Розалиягә күрсәтеп)* — менә аларның бәхете өчен.

Ф ә й з и. Ай, рәхмәт! Бу үзе тост әйтү булып чыкты. Күтәрдек!

Н и я з. Ибраһим абый, сезгә ярамый.

И б р а һ и м. Беләм, беләм. Нишләп эчим, язмаганны. Миңа ярамый. Хәер, шушындый вакыйга хөрмәтенә генә берне күтәрмәсәм. *(Тиз генә бер рюмканы эчеп куя.)*

Н и я з. Ибраһим абый!

И б р а һ и м. Ай-яй, саран хуҗа булып чыктың син, Нияз.

Б а р ы с ы д а.

> Талдай зифа буйлары,
> Бигрәк матур уйлары.
> Шаулап торсын,
> Гөрләп торсын,
> Җырлап торсын туйлары.

Зөһрә килеп керә. Мәҗлестәгеләр, Зөһрәне күреп алгач, кисәк тынып кала.

Нияз. Зөһрә?! *(Аптырап кала. Күзләр күзгә текәлә.)*

Ибраһим. Әйдәгез, бик вакытлы килдегез. Шулай кирәк. Дуслар бер-берсен онытмаска тиешләр. *(Зөһрәне мәҗлескә тәкъдим итеп.)* Бу — Ниязның бергә укыган иптәшләреннән.

Зөһрә янына Зөфәр килеп житә, плащын салдыра.

Зөһрә. Зөфәр? Син ничек биредә? Әле кичә генә шәһәрдә идең.

Зөфәр. Бүген иртән килеп төштем. Самолет белән. Ниязның туена.

Зөһрә. Мин әле үземнең нинди мәҗлескә килеп эләккәнемне аңламый да торам икән. Киленнең исеме ничек соң?

Ибраһим. Розалия.

Зөһрә *(аягына баса)*. Розалия, Нияз! Рөхсәт итегез, мин сезне... тәбрик итәм.

Нияз. Рәхмәт.

Розалия *(тәмам югалып кала)*. Рәхмәт.

Зөһрә. Белмәдем, бу хәлләрне белгән булсам... Белгән булсам, бүләк алып килгән булыр идем. Ә мин, Ибраһим ага, шатлыклы хәбәр алып килдем бит әле. Ниязны быел аспирантурага кабул итәләр. Чакырдылар.

Фәйзи. Алып китәргә икән. Бу нинди шатлык булсын.

Ибраһим. Юк, шатлык ул, зур шатлык. Ниязга тагын да укырга кирәк. Үсәргә.

Нияз. Рәхмәт, Зөһрә. Ләкин мин моннан китмәм, ахры.

Ибраһим *(йөзе яктырып китә.)* Менә! Ул читтән торып та укый алачак!

Фәйзи. О! Моның хөрмәтенә тагын берне күтәрәбезме инде? *(Шау-гөр килеп эчәләр. Урыннан кузгалалар. Биешү башлана.)*

Фәйзи *(бии)*.

> Әй имерә, имерә,
> Имерә сөяк кимерә.
> Башкода ни карап тора?

Ибраһим. Тамада идән җимерә.

Фәйзи бер-ике әйләнә дә Розалия алдына килеп баса. Күрәсең, Розалия оста биюче булып танылганга күрәдер, аның биюен барысы да сорый. Розалия башта бик җиңел биеп китә, ләкин бу озакка бармый, аның эчке кичереше тышка бәреп чыга. Ул, моны сиздермәскә теләп, үзен кулга алырга тырышып, тагын да кызурак темпта бии башлый, әмма көче җитми, сыгылып төшә һәм кисәк тукталып кала. Үксеп җибәрә. Аны Нияз тотып кала, урындыкка утырта. Башкалар әкрен генә ишек алдына чыгалар. Биредә Розалия, Нияз, Зөһрә, Зөфәр генә кала. Зөһрә шулай да ишеккә юнәлә. Розалия аны туктата.

Розалия. Зөһрә апа, сез калыгыз әле, безгә сезнең белән сөйләшергә кирәк. Хәл итәргә кирәк. Хәзер, хәзер үк! Нишлибез?

Зөһрә. Мин күрәм, сезнең хәл ителгән инде.

Розалия. Ышаныгыз, мин гаепле түгел. Тырнак очы кадәр дә гаебем юк. Нияз абыйның да. Мин бит сезнең турыда аны яратмыйсыз дип уйлый идем. Ул үзе дә. Кияүгә чыгасыз, дип әйттеләр ич. Нияз абый сезгә күпме хатлар язды, ник бер генә җавап алсын. Шулай булгач, башкача ничек уйларга мөмкин?! Ләкин менә үзегез килеп төштегез. Йөрәгегез тартмаган булса, килер идегезмени? Димәк...

Зөһрә. Димәк!

Розалия. Ник соң алданрак килмәдегез сез?! Бер ай гына булса да элегрәк. Бер атна! Хәзер бик соң бит инде.

Зөһрә. Соң.

Розалия. Ел буе нишләдегез соң сез?

Зөһрә. Мин көттем.


Розалия ролендә артистка *Фирдәвес Әхтәмова.*

Розалия. Нәрсәне, бәхетегезнеме? Бәхет өчен көрәшергә кирәк! Белгәнсездер бит, Нияз абый бик җаваплы, бик кирәкле эш белән шөгыльләнә. Аңа һәркем булышлык күрсәтергә тиеш иде. Якын кешеләре бигрәк тә! Шундый чакта яраткан кешесе аңа ярдәм кулын сузмаса, янына килмәсә, онытса — ничек була инде?!

Зөһрә. Мин онытмадым, мин аның өчен гел борчылып яшәдем.

Розалия *(гаепләп)*. Ходаем, борчылу белән генә ярдәм итеп буламыни?! Нияз абый, сез ир кеше, нигә үз сүзегезне әйтмисез?

Нияз. Без «син» дип сөйләшергә килешкән идек түгелме соң, Розалия?

Розалия. Сез әйтмәсәгез, үзем әйтәм: мин сезнең арага керергә теләмим! Миңа кеше бәхете кирәкми. Үз өлешемне табармын әле. Мин сезне очратуым белән дә бәхетле. *(Күзендә яшь, сыгылып төшә.)*

Нияз. Розалия, син ни сөйлисең?

Розалия *(үзен кулга алып)*. Мин сезгә ирек бирәм. Үз бәхетемнән баш тартам. Менә хәзер барысын да чакырам да әйтәм. Бөтенесе алдында. Яшермичә, ачыктан-ачык!

Нияз. Розалия!

Розалия. Бу миңа җиңел дип уйлыйсызмы? Юк, авыр. Ай, авыр. Үлем белән бер. Чөнки мин сезне, Нияз абый... Кемне дә булса шулай ярата алырмынмы, белмим. *(Айнып.)* Ә туйны өзмибез. Бу сезнең туй!

Нияз. Розалия, син юкны сөйлисең!

Розалия. Мин карар бирдем инде.

Нияз. Синең миңа ышанмаска хакың юк!

Розалия. Мин сезгә ышанам, ышанам, Нияз абый.

Нияз. Шулай булгач?!

Розалия. Мин сезнең бәхетле булуыгызны телим.

Нияз. Розалия!

Розалия. Әгәр дә Зөһрә апа килмәгән булса... Юк, алай түгел, дөрес сөйләмим... Әгәр дә Зөһрә апа сезне яратмыйча, язмышын башка берәү белән бәйләгән булса, ул чакта сез аны оныта алыр идегез. Ләкин бит ул килде. Хәзер инде сез аны оныта алмыйсыз, ул һаман да сезнең күңелегездә булачак. Сез мине онытыгыз. Әйтерсең, мин булмадым. Әйтерсең, сез бервакытта да мине очратмадыгыз. Мин сезнең өчен моңлы бер җыр булып кына калырга тиеш. *(Ишеккә килә.)*

Нияз. Розалия!

Розалия *(катгый һәм кисәтеп)*. Нияз абый!

Розалия чыгып китә, Нияз кала.

Нияз. Моңлы бер җыр...

Пәрдә

совет властенең 50 еллыгына

*З. Әхмеров, Э. Касыймов*

# Н. К. КРУПСКАЯ ИДЕЛ-КАМА БУЙЛАРЫНДА

Мең тугыз йөз унтугызынчы елның язында көнчыгыштан ябырылып килгән Колчак яулары Совет республикасына үлем куркынычы тудырды. Дошман инде гаять зур территорияне, шул исәптән Кама буйларын да, басып алган һәм Вятка елгасына килеп терәлгән иде. Акларны аерата Казан каласы кызыктыра, аны тизрәк басып алу теләге яндыра, чөнки анда ул вакытта яшь Совет дәүләтенең валюта запасы (43 мең пот алтын, 30 мең пот көмеш, шактый күп күләмдә платина һәм бик күп санда әһәмиятле кредит кәгазьләре) тупланган була. Бөек юлбашчы В. И. Ленинның чакыруына кушылып, яшь Совет республикасы бердәм төстә дошманга каршы көрәшкә күтәрелде, һәм Кызыл Армия чиксез авыр хәлләрдә, тиңдәшсез батырлыклар күрсәтеп, бу дәһшәтле өермәне туздырып ташлады, Колчак гаскәрләрен 1919 елның җәенә үк Урал аръягына, Себергә таба куып алып китте.

Кара болытларны туздырып, Идел — Кама буйларына аяз көннәр килсә дә, хәлләр шәптән түгел: кая гына аяк басма, ачлык, ялангачлык һәм таркаулык хөкем сөрә иде. Кызыл Армия тарафыннан азат ителгән төбәкләрдә партия эшчеләре, совет активистлары, алдынгы укытучылар бик аз сакланып калган, аларның күбесен аклар үтергән, байтагы фронтларга киткән. Хуҗалык эшләре, транспорт, мәктәпләр һәм культура-агарту оешмалары — барысы да эштән чыгарылып таркатылган. Җирле органнарга Совет властен яңадан торгызу, тормышны яңача, Советча корып җибәрү өчен күп көч куярга, ифрат кыен хәлләр кичерергә туры килә, өстәвенә Үзәк белән дә ныклы элемтә юк. Менә шундый чиксез авыр шартларда партиянең Үзәк Комитеты җирле оешмаларга турыдан-туры һәм конкрет ярдәм күрсәтү өчен үз аппаратыннан һәм шулай ук җитәкче Совет органнарыннан аерым кешеләрне инструкторлар итеп җибәрә иде. Яшь Совет дәүләте өчен Идел һәм Кама районнары аерым әһәмияткә ия иде ул заманда. Шушы хәлне искә алып, В. И. Ленин тәкъдиме белән, Идел һәм Кама буйлап махсус пароход җибәрү турында карар кабул ителә. Агитация һәм инструктажлар үткәрү өчен оештырылган бу сәяхәткә Үзәктәге җитәкче Совет органнарыннан вәкилләр китәргә тиешле була.

Владимир Ильич бу эшкә гаять җитди карый, аңа зур әһәмият бирә, хәтта аның үзенең дә Идел — Кама буйларына сәяхәткә китәргә теләге була. Әлбәттә, ул авыр көннәрдә Совет хөкүмәте җитәкчесенә андый сәяхәттә катнашырга мөмкинлекләр булмый.

Халык Мәгарифе Комиссариаты вәкиле булып, агитпароходта Надежда Константиновна Крупская да китәргә тели. Бу фикер В. И. Ленинга да ошый, һәм ул ризалык бирә. Н. К. Крупскаяның каты авырудан соң яңа гына аякка баскан көннәре була. Шунлыктан В. И. Ленин аңа сәламәтлеген сакларга, арып хәлдән тайганчы эшләмәскә, вакытында ашап-эчеп, вакытында йокларга, гомумән, врачлар кушкан режимны бозмаска киңәшләр бирә. Шулай ук ул аңа күргән-белгәннәрен көндәлеккә теркәп барырга куша. Соңгысын Надежда Константиновна җиренә җиткереп үти. Әмма Мәскәүгә әйләнеп кайткач, аның көндәлеге төрле кәгазьләр, документлар арасында югалып кала. Тик 1932 елны гына

ул көндәлек табыла, «Красная звезда» газетасы анардан аерым өзекләрне бастырып та чыгара.

«Красная звезда» пароходы Нижний Новгород янындагы затонда тукталган була. Китүчеләр сәяхәт өчен кирәк-ярак нәрсәләрен шунда җибәрәләр, һәм озак та үтми, үзләре дә Мәскәүнең Курск вокзалыннан Нижний Новгородка чыгып китәләр. «Китәр алдыннан, — дип исенә төшерә Н. К. Крупская соңыннан, — без Ильич белән анда ни нәрсә эшләргә, ничек эшләргә, халыкка ничек ярдәм итәргә, нинди мәсьәләләргә күбрәк тукталырга, нәрсәгә күбрәк күз салырга кирәклеге турында озак кына фикер алыштык. Ильичның үзенең дә барасы килә иде, әмма аңа эшен бер генә минутка да ташларга ярамый иде. Иртәгә китәсе дигән көнне төне буе сөйләшеп чыктык. Ильич безне вокзалга кадәр озата барды, өзлексез хат язып, телефонда туры чыбыктан шалтыратып, үзе белән сөйләшкәләп торуымны үтенде...»[1]

* * *

10 июль иртәсе. «Красная звезда» пароходында баручыларның күз алдында әкренләп борынгы Казан Кремленең силуэтлары калка.

Казан... Н. К. Крупская Казан большевиклары белән әле революциягә кадәр үк нык элемтәдә торган. 1906 елда алар аны РСДРПның дүртенче съездына делегат итеп сайлыйлар. Эмиграциядән дә ул Казан партия оешмасы белән хатлар алыша.

Агитпароход килеп туктаган көнне үк Казан университетында митинг оештырыла. Надежда Константиновна митингка бик тырышып, бик дулкынланып әзерләнә: уен эш түгел, кайчандыр бу университетта аның Ильичы укыган.

Митингта булган кешеләрнең сөйләвенә караганда, университетның җиде йөз кеше сыйдырышлы Актлар залына халык ташкын булып агыла. Зал шыгрым тулы. Надежда Константиновна җыелган халыкка җылы һәм ачык итеп ялкынлы речь сөйли.

«Митинг шактый озакка сузылды, — дип яза соңыннан Н. К. Крупская. — Иң азакка йөзләп эшче, халык мәктәпләрендә укытучы ир һәм хатыннар калып, сораулар яудырырга тотындылар, аннары «Интернационал» җырладылар, иптәш Ленинга сәламнәр җибәрделәр»[2].

Надежда Константиновнага университетта уздырылган митингтан соң да Казанда тагын берничә тапкыр чыгыш ясарга туры килә. 11 июльдә Советларның бишенче губерна съездында сөйләгән речендә ул делегатларны хезмәт ияләренең теләк-үтенечләренә игътибарлы булырга, Советларның эшен халык тормышына якынайтырга, тик хезмәт халкы интересларын гына кайгыртырга чакыра. Ә 13 июльдә шәһәр бакчасында үткәрелгән эшчеләр митингысында Н. К. Крупская ялкынлы чыгыш ясап, либераль карашлы интеллигентларның Совет власте өчен никадәр куркынычлы булулары хакында аерым басым белән аңлатып китә. Аны бигрәк тә балалар язмышы борчый, һәм ул: «Без үзебезнең мәктәпләрне ачып, балаларны советчыл рухта укытырга тиешлебез»[3], — ди.

Н. К. Крупская Татарстан башкаласында үткәргән биш көнендә мондагы тормышның эченә үтеп, аның бик күп яклары белән тирәннән таныша һәм җирле оешмаларга, аерата культура-агарту, халык мәгарифе органнарына эшләрне тәртипкә салып, җанландырып җибәрү өчен шактый чаралар күрә.

1919 елның 15 июлендә «Красная звезда» пароходы Казаннан кузгалып китә һәм Идел буйлап беркадәр төшкәннән соң, Кама елгасына кереп, агымга каршы юл тота. Казан җәмәгатьчелегеннән пароходны коммунист Садыйк Әхмәтов озата бара.

* * *

«Красная звезда» пароходы Казан губернасының дүрт җирендә — Богородскоеда, Лаешта, Балык бистәсендә һәм Чистайда — тукталыш ясый.

Төнлә пароход Лаеш пристанена килеп туктый. Иртәгесен агитпароход членнары җәяүләп кенә Лаешка юнәләләр. Монда Н. К. Крупская өяз башкарма комитеты утырышында катнаша, партячейканың эшләре белән таныша. Танышып кына калмый, башкарма комитет членнарына да, партячейка секретарена да практик яктан

---

[1] В. Дридзо. Надежда Константиновна. «Детская литература» нәшрияты, Мәскәү, 1966, 103 бит.

[2] Н. К. Крупская. Әсәрләр, XI т., 739 бит.

[3] «Знамя революции» газетасы, 15 июль, 1919 ел.

бик тә кирәкле киңәшләр бирә, эшләрендә булган кайбер житди кимчелекләрне дә күрсәтә.

Нәкъ менә шул айларда Лаешта укытучылар өчен курслар ачылган була, анда өч йөзләп кеше укый. Арада байтак кына татар хатын-кызлары да була — матур һәм шатлыклы күренеш. Бу курсларга бармыйча, андагы хәл белән ныклап торып танышмыйча мөмкинме соң?

Үз вакытында бу курсларда укып йөргән һәм бүгенге көндә Чистайда яшәүче пенсионер Нина Александровна Скворцова сөйләвенә караганда, Надежда Константиновна курсларга килеп, бик күп тыңлаучылар белән сөйләшә. Һәркайсыннан диярлек укуы, тормышы, көнкүреше, хезмәт мәктәпләренә мөнәсәбәте турында сораштыра. Курсларның программасы белән танышкач, Н. К. Крупская, аның житешсез якларына күрсәтеп, курсларны яхшырту юлларын өйрәтә. Аннары ул курста укучыларга ике сәгатьлек лекция сөйли.

Лаештан соң агитпароход Балык бистәсенә туктала. Монда Надежда Константиновнаны искитмәле хәл көткән икән: мәктәп-мәгариф эшләре тәмам таркалган. Бушлык, хуҗасызлык, буталчыклык... Әмма жепнең очын тиз табалар: Хәрби эшләр комиссары, Халык мәгарифе комиссариатына хәбәр итми-нитми генә, волостьтагы мәгариф бүлеген ябып, таратып җибәргән икән. Мәктәп биналарына исә гаскәриләр һәм госпитальләр кереп урнашкан. Балык бистәсендә Надежда Константиновнага мәктәп-мәгариф эшләрен рәткә салу буенча бик житди шөгыльләнергә туры килә. Волостьта мәгариф органнарын тергезүгә шунда ук ирешә ул. Мәктәпләрне гаскәриләрдән бушату турында да күрсәтмә бирелә.

Ләкин Совет властеның халык мәгарифе өлкәсендә үткәргән чараларына Чистайдагы кебек каршылык күрсәтүне, чын-чынлап саботаж ясауны Н. К. Крупская аңарчы беркайда да күрмәгән дә, ишетмәгән дә була. Биредәге укытучылар православие һәм мөселман руханилары тәэсиреннән котыла алмаганнар, алар динчеләр тараткан сөремнән миңгерәүләнеп калгандай тоелалар.

Н. К. Крупская, шәһәрдә уку-укыту эшләренең торышын тикшереп алгач, бер нәрсәне ачык билгеләп куя: юк, монда халык мәгарифе органнарын булдырырга теләмиләр, хәтта кирәксезгә санныйлар. Укытучылар эшчеләрдән аерылганнар. Мәктәптән тыш белем тарату буенча инспектор «Мәктәпнең политикага катнашы юк», дигән сүзләр белән акыл сата.

Агитпароход члены Чистай укытучылары өчен митинг уздырырга карар кылалар. Темасы: «Интеллигенция һәм Советлар власте». Митингка меңгә якын кеше җыела.

Ул митингка катнашкан һәм хәзерге көндә пенсиягә чыккан карт укытучы Габделхәй Рәмиев истәлегенә караганда, митинг Чистайдагы икенче номерлы мәктәпнең Актлар залында үткәрелә. Н. К. Крупская җыелган халык алдында дәртле речь белән чыгып, укытучыларны халыкка турылыклы хезмәт итәргә, Советлар властеның яңача мәктәп кору эшләренә булышлык күрсәтергә чакыра.

Әйе, Чистай Казан түгел. Монда бөтенләй бүтән чолганыш. «Биредә обыватель чамадан тыш ярсыган», — дип язып куя Н. К. Крупская үзенең көндәлегенә [1].

Әнә шул «ярсыган» обывательләрнең черек карашларын чагылдырып һәм аларның «атасы» кыяфәтен алып, укытучылардан берәү (Габделхәй ага Рәмиев әйтүенчә, семинария укытучысы Красновский) Н. К. Крупскаяга каршы чыга. Дөрес, ул Крупскаяның төп фикерләренә кушылгандай кылана, әмма шундук, ЧК дан, кулга алулардан зарланырга тотына, «Советлар власте кешеләрне ата да, аса да», ди һәм укытучыларны Крупская әйткән «Социалистик мәгариф Союзы»на кермәскә, бәлки укытучыларның элеккеге Бөтенроссия союзы сафларында калырга өнди. Митингта аны яклаучылар да табыла.

«Надежда Константиновна Крупская речена каршы Красновский чыгып сөйли башлагач, — дип сөйли Габделхәй ага Рәмиев, — безнең укытучылардан Ибраһим Камалетдинов ярсулы ачу белән кычкырып, тегене бүлде: «Сез Советлар властеннан кешеләрне кулга алып, ата-нитә дип зарланасыз, ә беләсезме, аклар нихәтле эшче белән крестьянны атып үтерде? Камада үлем баржалары йөрде, ни өчен сез бу хакта бер сүз дә әйтмисез?» — диде ул. Ибраһим Камалетдиновның әйткәннәргә шундук укытучылардан А. Ф. Советкин, Н. И. Виноградов, Зәйтүнә Кәбирова-Рәмиева һәм бүтәннәр кушыла. Ахырда күпчелек укытучылар Н. К. Крупская

[1] Н. К. Крупская. Әсәрләр. XI т., 744 бит.

тәкъдимен кабул итеп, «Социалистик культура һәм мәгариф хезмәткәрләренең профсоюзын» төзүне яхшы һәм әһәмиятле эш дип таба.

«Митингтан соң, — дип исенә төшерә укытучы-пенсионер Зәйтүнә апа Рәмиева,— без Н. К. Крупскаяны пароходка хәтле озата бардык. Пароходларына да кердек. Анда «Могҗизалар дөньясында» дигән бер кинокартина күрсәттеләр. Аннары, безнең теләкне үтәп, В. И. Ленинның граммофон язмасындагы речен тыңлаттылар». Надежда Константиновна чистайлыларга да күп кенә әдәбият өләшә.

1919 елның 20 июле көнне Чистай өяз Советы белән «Красная звезда» пароходында килгән әдәби-инструкторчылык составының берләштерелгән утырышы була. Утырышта өяз Советыннан 24, ә агитпароход коллективыннан 8 кеше катнаша. Мәгариф бүлегенең эше турындагы докладтан укытучылар арасында политик-тәрбия эше бөтенләй диярлек алып барылмавы, аның тәмам торгынлык хәлдә булуы ачыклана. Утырышның беркетмәсеннән күренүенчә (бу беркетмә Чистайның крайны өйрәнү музеенда саклана), анда катнашучылар мәгарифкультура тармагындагы җитешсезлекләрне күрсәтеп, ачы тәнкыйть белән генә чикләнмиләр, эшләрне рәткә салу буенча конкрет, практик чаралар да билгелиләр. Арада Халык мәгарифе советын төзү һәм укытучылар арасында политик-тәрбия эшен җанландыру, үзәк китапханә белән эшчеләр китапханәсен берләштерү, шәһәрдә «Ана белән бала йортын» оештырып, хатын-кызлар өчен консультация ачу, ачлык җәфасына дучар булган җирләрдән килүче балаларны кабул итеп, әйбәтләп урнаштыру кебек көндәлек тормыш үзе таләп иткән мәсьәләләр карала.

Октябрь революциясеннән соң, башка бик күп җирләрдәге кебек үк, татар халкына да үз милли мәктәпләрен ачып җибәрүгә мөмкинлекләр туа. 1918 елда ук Чистайта Нариман урамындагы бер йортта (хәзер анда эшче-яшьләр мәктәбе урнашкан) икенче баскыч татар мәктәбе ачыла. Аның беренче мөдире һәм укытучысы Габделхәй ага Рәмиев була. Башта бу мәктәптә бер генә класс ачылып, аңа тик кызлар гына кабул ителә. Әмма икенче елны инде мәктәпкә башлангыч белем алырга өлгергән кырыклап малай да йөри башлый. Шул рәвешле, Чистайда яшәгән татар халкының балалары — кызлары һәм малайлары — бер түбә астында, бер һаваны иснәп, белем алу юлына басалар. Мөселман руханилары һәм аларның фанатик иярченнәре моңа, әлбәттә, аяк терәп каршы торырга азапланалар, төрле коткылар тараталар, ата-аналарны төрле янаулар белән куркыталар. Ахырда, мәктәпнең һаман да яшәвен күреп, анда дин укытылуын таләп итәләр. Инде монысы да барып чыкмагач, җирле власть органнарына протест белдерәләр, хәтта партиянең Чистай өязе секретарена: «Ислам менә инде 1300 ел яши, аны фиргавеннәр дә, патша Николай да җиңә алмады, коммунистлар да җиңә алмаячак, без җиңәчәкбез»[1], — дип язылган гариза тоттыралар.

Н. К. Крупская, Чистайга килгәч, бу мәктәпнең эшләре белән дә җентекләп таныша. Ул малайлар белән кызларны бергә укытуны хуплый, мәктәпне тагын да киңәйтеп, уку-укытуны тагын да яхшыртып, үстереп җибәрү юлларын өйрәтә. Укытучыларга ул, руханилар коткысына карамыйча, нык торырга, кыю булырга куша.

* * *

Вятка елгасы тамагында утырган Соколка пристане. Моннан ары Каманың уң як яры буйлап элеккеге Вятка губернасы территориясе башланып китә. Әле күптән түгел генә Колчак бандаларыннан азат ителгән җирләр...

Соколка пристанендә агитпароходка халык ябырыла. Якын-тирәдәге авыллардан да ишетеп килгәннәр. Арада яшь хатын Александра Петровна Булашова[2] да бар. Ул Мамадыш өязенең Омары авылыннан. Бүтәннәргә иярен, ул да пароходка барып керә. Исәбе: килүчеләргә зиһенендә кайнаган уй-теләкләрне, күңелен биләгән хисләрне әйтү.

«Кинәт мин ике хатын янына килеп чыктым. Алар утырган җирләреннән күтәрелеп, минем белән кул биреп күрешкәч, каушадым да калдым», — дип исенә төшерә Александра Петровна. Шул хатыннарның берсе, соры күлмәк кигәне, бик ягымлы карашын текәп, аңардан: «Я, ничек яшисез? Нинди нужаларыгыз бар?» — дип сорый. Александра: «Барыннан да бигрәк китаплар кирәк... авылыбызда китапханә

---

[1] Татар дәүләт архивы. 15 фонд, 9 эш, 36 бит.

[2] А. П. Булашова — 1919 елдан КПСС члены. Бүгенге көндә Алабугада яши. Еш кына яшьләр алдында үзенең истәлекләре белән чыгышлар ясый.

оештырмакчы булабыз, әмма китапларыбыз юк», — дип, тотлыгып, көч-хәл белән җавап кайтара ала. Һәм Надежда Константиновнаның елмаюын күргәч, кисәк кыюланып китеп: «Тагы кәгазебез дә юк, ни нәрсәгә язарга белмибез,ә хатыннарыбыз укырга тели», — дип өстәп куя [1].

Н. К. Крупская пароходка килгән крестьяннар белән озаклап, иркенләп сөйләшә, аларның хәл-әхвәлләрен сораша, яңа тормышны ничегрәк башлап җибәрүләрен белешә, киңәшләр әйтә. Ә А. П. Булашовага ул күп кенә әдәбият һәм бер төргәк кәгазь бүләк итә.

Александра Булашова авылына кайтса, үзенең ишек алдына халык җыелганын күреп, шакката. Ни гаҗәп дисә, кулаклар аның сыерын агулап үтергәннәр икән. Җитмәсә, кичен ире кайтып керә дә йодрыкларын йомарлап: «Сиңа грамота кирәк булдымы әле, сыер саварга, савыт-саба тирәсендә чуалырга грамотасыз да бик шәп булдырырсың!» — дип, аның өстенә ташлана.

Ләкин коммунистка Александра Булашова мондый янау-куркытулар алдында каушап, югалып калмый, үз сүзендә нык торып, авылда китапханә ачып җибәрә һәм авылдашларына Н. К. Крупскаядан алган китапларны өләшә, ә теге бер төргәк кәгазьне кискәләп, дәфтәр ясый. Кичләрен китапханәгә крестьяннар җыела. Александра Петровна, берничә укытучы белән бергәләп, аларны укырга-язарга өйрәтә. Әлбәттә, җиңел булмый аларга. «Әле дә бик яхшы хәтерлим, кулаклар, поплар безнең белем тарату, агарту эшебезгә һаман да аяк чалып торырга тырыштылар. Кайчакны эш хәтта шуңа барып җитә торган иде: поп малайлары кулларына көрәкләр, ломнар тотып, дәрескә бәреп керәләр дә укучыларны куркытып-кыйнап, таратып җибәрәләр иде. Әмма алар Бөек Октябрь идеяләренең таралуын туктата алмадылар», — дип сөйли Александра Петровна Булашова.

Моннан бик күп еллар элек А. П. Булашова башлап җибәргән ул күркәм эшне бүгенге Омарда аның кызының кызы Тамара Гурьянова дәвам итә: ул Омар авылында меңләгән китаплары булган китапханәнең мөдире булып эшли. Китапханәдәге китаплар арасында Н. К. Крупская әсәрләре дә аз түгел.

22 июльдә «Красная звезда» пароходы Алабуга пристанена килеп туктый.

Алабуга — ул заманда Вятка губернасының көньяк чигендә утырган өяз каласы.

Октябрь революциясе булып, гражданнар сугышы башлангач, бүтән бик күп өяз калалары шикелле үк, Алабуга да дәһшәтле көннәр кичерә. 1918 елда ул ак чехлар кулында булып ала, ә 1919 елның язында аңа Колчак яулары басып керә. Ак террор — кызыл кан...

1919 елның җәй башларында атаклы Азин дивизиясе бу тирәләрне Колчак явыннан тазарткач ук, алабугалылар зур тырышлык һәм көч куеп, Совет власте канаты астында тыныч тормышларын җайга салырга тотыналар.

«Красная звезда» агитпароходы килгәндә, Алабуганың үзендә һәм өязендә байтак кына эшләр эшләнгән була. Бу бигрәк тә халык мәгарифе өлкәрендә ачык күренә. Мәгариф бүлеген бик тә энергияле, бик тә җитез һәм үткен коммунистка В. П. Степанова җитәкли, ул үз бүлегенә мәгариф эшләрен чын күңелдән сөйгән, советчыл рухлы кешеләрне туплый. Шул сәбәпле өяздә халыкка белем тарату, культура-агарту эшләрендә матур җанлылык башланган: зурлар өчен 306 мәктәп, 20 китапханә, 71 культура-агарту түгәрәге, 6 халык йорты һәм 2 пролетар клуб булуы — шуның гәүдәләнеше.

Ләкин монда да бөтенесе дә ал да гөл булмый әле. Укытучылар җитми, культура-агарту челтәренең түбәнге оешмаларында аз әзерлекле, тар карашлы кешеләр эшли. Иң әйбәт кадрлар колчаклылар шәһәрдә чагында ак террордан һәлак була. Аклар бер Алабуга өязендә генә дә унбиш укытучыны атып үтерәләр, байтак кешене канга батырганчы кыйныйлар, мәсхәрәләп урамнарда йөртәләр. Алар арасында хәтта унбиш яшьлек кыз, комсомолка Анна Чувыгина да була.

Алабуганың партия оешмасы да шактый кимегән. Күп кенә коммунистлар аклар тарафыннан үтерелгән яисә фронт белән Колчак бандаларын куа киткән. Гомумән, өяз партия оешмасы чын-чынлап ныгып, аякка басарга өлгермәгән әле.

Агитпароход коллективы, мондагы хәл белән танышып алгач, шәһәрнең бөтен коммунистларын да киңәшмәгә чакыра. Киңәшмә «Красная звезда» пароходында үткәрелә. Анда эшләнгән эшләр турында отчет белән өяз партия комитеты секретаре

---

[1] М. Җәлилова. «Крестьянка» журналы, 1964, № 2, 8 бит.

Я. С. Тугаров чыгыш ясый. Каланың бүтән коммунистлары да чыгып сөйли. Сөйләшәкиңәшә торгач, өяз партия комитетының үз эшендә, аерата халыктан налог җыю кебек гаять җитди мәсьәләдә, зур гына хаталар җибәргәнлеге ачыклана. Үзәктән килгән вәкилләр өяз партия комитетыннан һәртөрле законсызлыкларга чик куюны таләп итәләр.

Надежда Константиновна Крупская, пароход Алабугага килеп туктаган көнне үк, каланың җиденче татар мәктәбендә оештырылган педагогик курсларда лекция укый. Курсларга килгән 150 татар егете һәм кызы аның сөйләгәнен онытылып тыңлый.

Бу мәктәпнең элгәреге укытучысы, хәзерге көндә пенсиядә яшәүче Зәйтүнә апа Максудова Н. К. Крупская белән очрашкан көнен сагынып искә ала. Надежда Константиновна яшь укытучыларга рус телен белүнең әһәмиятен, аны үзләштерү методларын аңлата, бу эштә күргәзмә әсбапларның гаять файдалы булачагына басым ясый, ахырда үзе алып килгән рәсемле бер җыентыкны курсантларга бүләк итә.

«Надежда Константиновна, — ди Зәйнәп апа Максудова, — лекциясен бик тә аңлаешлы итеп сөйләде. Аның үз-үзен тотышы да гаҗәеп гади, иптәшләрчә, дусларча иде. Ул безгә Петроградта Воскресенский эшчеләр мәктәбенең ничек эшләве, укучыларның белемен нинди методлар белән күтәрүгә ирешү турында да сөйләде. Мин аңа белемем аз булуга зарландым. Надежда Константиновна мине Мәскәүгә укырга чакырды. Анда вак милләтләр өчен укытучылар әзерләү курслары ачылган икән. Әмма, кызганычка каршы, мин аның киңәшен тота алмадым: озак та үтми авырып китеп, Мәскәүгә бара алмыйча калдым».

Алабугада Н. К. Крупская тагын өч мәртәбә чыгыш ясый: шул ук көнне шәһәр интеллигенциясе өчен оештырылган митингта речь сөйли, икенче көнне эшче-дружинниклар белән очраша, ә кичен шәһәр халкы җыелган митингка килеп, үзенең ялкынлы сүзләре белән кешеләрнең йөрәгендә ут кабыза.

Алабуга шәһәрендә ике көн эчендә бик күп файдалы эшләр башкарганнан соң, агитпароход Кама буйлап югарыга таба юл тота һәм, Чаллыда берәз вакытка туктап алгач, Тихие горы пристанена килә.

Бондюг химия заводы эшчеләре агитпароход турында күптән ишеткән була инде. Алар аның килүен түземсезләнеп көтәләр. Менә бервакыт шатлыклы хәбәр таралып та өлгерә, һәм халык, дәррәү кузгалышып, Тихие горы пристанена юнәлә. Барысы да бәйрәмчә киенгән, барысының да йөзләре кояштай балкыган. Кулларында: «Хуш киләсез, кадерле кунаклар!» дип язылган плакатлар... Завод эшчеләренең бәйрәм демонстрациясе диярсең...

Пароходтан шулай ук якты елмаеп Надежда Константиновна һәм бүтән пассажирлар төшә. Алар эшчеләр белән бик җылы күрешәләр. Һәм шунда ничектер үз-үзеннән митинг башланып китә. Н. К. Крупскаяның сөйләвен шунда ук татар теленә тәрҗемә итеп барырга кешесен дә табалар.

Митинг беткәч, агитпароход коллективы, эшчеләргә кушылып, Бондюг заводына юнәлә.

Н. К. Крупская, вакытының бер минутын да әрәм итмәстән, заводның гомуми хәле, производствосы һәм эшчеләр тормышы белән танышырга тотына. Завод тирәсендә утырган авыллардагы хәл һәм крестьяннар тормышы хакында да ул бик ныклап, җентекләп сораша. Аны бигрәк тә зур завод эшчеләренең авылларга йогынтысы, аң-белем күтәрүдә, культура таратуда авыл халкына ярдәме кызыксындыра. Кичен ул завод эшчеләре оештырган митингта катнашып, зур гына речь белән чыга.

Икенче көнне, 25 июльдә, аны мөселман хатын-кызлары җыелышына чакыралар. Монда да ул үзен бик иркен һәм гади тотып, татар хатыннарына һәм кызларына бик күп нәрсәләрне аңлатып бирә. Аның речен шунда ук татарчага тәрҗемә итәләр, шунлыктан кунак апаның сөйләвен барысы да аңлый, сүзләре барысының да йөрәк түренә кереп утыра. Әмма хатын-кызның күңелен борчыган, зиһенен чуалткан нәрсәләр дә аз булмый әле ул заманда. Надежда Константиновнага бик күп сораулар яудыралар. Н. К. Крупская сорауларның берсен дә игътибарсыз калдырмый, һәммәсенә төпле, аңлаешлы һәм ышандыргыч итеп җаваплар биреп бара. Бу самими һәм эчкерсез очрашу аның үзенә дә бик ошый, күңеленә матур бер истәлек булып сеңеп кала. Соңыннан да ул аны хәтеренә алып: «Эшчеләр янында үз туганнарыңа килгәндәй буласың» [1], — дип язып куя.

[1] Н. К. Крупская. Әсәрләр, XI т., 745 бит.

Ә инде эшчеләргә бу очрашуларның нинди тәэсир ясавы турында әйтеп торасы да юк. Бондюг эшчеләр поселогында яшәүче пенсионер А. С. Сорокина белән Ж. И. Исрафилов: «Ачык чырайлы, ягымлы карашлы рус хатынының кыяфәте мәңге җуелмаслык булып хәтерләребезгә кереп урнашты. Ул дөньяның бар ямен үзенә җыйган диярсең», — дип, бүген дә исләренә төшерәләр.

Мөселман хатын-кызлары белән очрашкан көнне Н. К. Крупская Бондюг заводының партячейка утырышында катнаша. Утырышта ул илнең гомуми политик хәле турында сөйли, коммунистларны бар энергияләрен һәм көчләрен халык хуҗалыгын тизрәк торгызу эшенә тупларга чакыра. Үзенә бик якын булган нәрсәгә — халыкка аң-белем тарату мәсьәләсенә дә тукталa ул. Бондюг эшчеләр поселогында бу яктан эшнең әйбәт кенә булуын билгеләп үтә, аерата азчылык милләт вәкилләрен тиешенчә укыта белүләрен, яхшы һәм матур күренеш дип, мактап куя. Заводның зур һәм бай гына китапханәсе булуы, халыкның андагы китаплардан иркен файдалануы да ошый аңа. Ләкин ул җитешсезлекләргә дә күз йомып карамый, аларны ачык итеп әйтеп бирә.

Бондюг химия заводы белән танышып йөргән чагында, Н. К. Крупская биредә политехник белем бирү өчен уңай шартлар булганлыгын күрә һәм кичекмәстән химзавод янындагы мәктәп өчен программа да төзергә тотына. Аңа бу эштә коммунист укытучылардан Сәхабетдиновлар ярдәм итешәләр. Программа төзелеп, аны тикшергәндә дә, соңыннан тормышка ашырганда да агалы-энеле Сәхабетдиновлар, Н. К. Крупская киңәшләрен үтәү йөзеннән, башлап йөрүчеләрдән булалар.

...Ниһаять, үзенең ачы тәтен-сөремнәре һәм кайнар йөрәкле эшчеләре белән Бондюг заводы да артта кала. Моннан ары «Красная звезда» агитпароходы хәзерге Татарстан җирләрендә бүтән тукталыш ясамый. Ул Кама буйларында утырган авыл һәм шәһәрләргә нур сибә-сибә елга белән югарыга таба юл тота. Атаклы сәяхәт Пермь каласында тәгалләнә.

* * *

Надежда Константиновна белән очрашканда, татар, чуваш, мари, удмурт укытучылары Ленин партиясенә бирелгәнлекләрен, Совет властен чын-чынлап яклауларын күрсәтәләр. Соңыннан 1935 елда Советларның XVI Бөтенроссия съездында ясаган чыгышында Н. К. Крупская, «Красная звезда» пароходында йөргән көннәрен исенә төшереп, болай ди: «Татар укытучылары гаять тә революцион иде, укытучы татарларның яңача әзерлеге зур дәрт белән алып барыла иде. Алар үзләренең дин йогынтысыннан котылуларын сизгәннәр иде. Элек шулай булган: авылда укытучылар хезмәт хакы алмаганнар, алар мулла ни бирсә, шуның белән генә яшәгәннәр, ягъни алар материаль яктан тулысынча муллага буйсынган булганнар. Совет власте исә бу мәсьәләне баштан ук хәл итеп куйды: укытучы хезмәт хакы ала башлады һәм шул рәвешле мулла йогынтысыннан азат ителде. Бу адым укытучыларны чиктән тыш канатландырды. Шуны да әйтергә кирәк, 1919 ел рус педагогларының кайбер юлбашчылары икеләнгән, еш кына кискен төстә Советлар властена каршы чыгышлар ясаган елы иде, ә бит аларга укытучыларның түбәнге катлавы иярә иде. Татар укытучылары исә нәкъ менә Советлар властена таба аерым бер омтылышта торалар иде» [1].

...Ул заманнан соң күп еллар үтте, Идел һәм Кама елгаларында күп сулар акты. Тормышыбыз танымаслык булып үзгәрде. Ләкин без, ирекле һәм югары культуралы тормыш шартларында яшәгән хәлдә, кайчандыр ул тормышның беренче нигез ташларын салып йөргән олы йөрәкле, ялкынлы рухлы кешеләрне бүген дә зур хөрмәт белән искә алабыз.

[1] Советларның XVI Бөтенроссия съездының стенографик отчеты. ВЦИК бюллетене, № 14, 1935 ел.

·——□——

*Абдильда Таҗибаев*

## Моң турында

Моңлы мин диеп зарланмыйм яшьләргә,
Куркам ләкин җирдә моңсыз яшәргә;
Мөмкинме соң, өзелеп сөйгәч гомерне,
Гомер моңнарыннан бүтән яшьнәргә?!

Сөям язның күбәләгеп, гөлләрен.
Сөям язның җылы, ефәк төннәрен;
Сөям язын фәрештәдәй сабыйның
Күбәләкләр белән уйнап йөргәнен.

Күз килдеме — күбәләкләр үләләр.
Күз килдеме — асыл гөлләр шиңәләр;
Сагынып гөлен,
сагынып күбәләкләрен,
Моңсулана акын язган үләңнәр...[1]

Җырда зурлап,
җырда җырлап үтәрлек
Ут холыклар, утлы күзләр җитәрлек;
Ут холыклар, утлы күзләр өчен дип,
Бокал тулы тостларны күп күтәрдек.

Газиз башлар кайчак хәсрәт чигәләр,
Ямансулап утлы күзләр сүнәләр;
Шул чак дәртле думбрага кушылып,
Моңсулана акын язган үләңнәр.

Моңлы мин диеп зарланмыйм яшьләргә.
Куркам ләкин җирдә моңсыз яшәргә;
Мөмкинме соң,
өзелеп сөйгәч гомерне,
Гомер моңнарыннан бүтән яшьнәргә?!

●

Борчылма ярлы чагыңа,
Ярлылык үтә-китә;
Кызыкма дөнья малына,
Сөйгәнең булса — җитә.

Дәрәҗәм бар дип зурланма,
Ул да югала, бетә;
Кыйнаса дошман — хурланма,
Сөйгәнең булса — җитә.

[1] Үләң — шигырь.

●

Кайнар булсын — ялкын булса.
Боздай булсын — салкын булса;
Урталыкны сөйми акын агагыз,
Урталыкны яртылаш дип санагыз.

Ярты килеш кирәк түгел бәхет тә,
Ярты килеш кирәк түгел вакыт та...
Мин яртылаш ала алмыйм айны да,
Ярты килеш кирәк түгел кайгы да.

Миңа тоташ кояш кирәк, көн кирәк,
Миңа тоташ йолдыз тулы төн кирәк;
Миңа тоташ диңгез кирәк, тау кирәк,
Миңа тоташ сугышучан яу кирәк.

Мәхәббәтне дә яртылаш алмыйм мин,
Яртылаш дус чакырса да бармыйм мин;
Ярты түгел, бөтен йөрәк бир миңа!
Сораганым шушы гына гомердән,
Теләгәнем шушы гына илемнән.

●

Сөенечемнең чиге юк
Сөелгәнгә, сөйгәнгә;
Ут булып кабынып идем
Жылысы юк өйләрдә.

Сөенечемнең чиге юк
Сөелгәнгә, сөйгәнгә;
Йолдыз булып балкыр идем
Яктысы юк өйләрдә.

Сөенечемнең чиге юк
Сөелгәнгә, сөйгәнгә;
Риза мин гыйшкым хакына
Янарга да көяргә.

Иркәм шиңдерсә тамырдан
Минем гыйшык гөлемне,
Төпсез боз дәрьясы каплар
Ялкын тулы күңелне.

Йөрәгемә сөйгән ярым
Җәя икән куләгә,
Санармын шул чак үземне
Тере килеш үлгәнгә.

## Ак нурлар

Җир кара,
кыр яшел,
гөл аксыл,
Күк зәңгәр, әйтерсең, бер диңгез...
Кояшка күмелгән дөньяны
Ак нурлар каплаган бертигез.

Ак нурлар жылытты җиремне,
Яктыртты басуны, болынны;
Кызартты ямь-яшел гөлемне,
Назлады кызымны, улымны...

— Кояш! — ди сайраучы кошлар да,
— Кояш! — ди нараси дуслар да.
Күкнең дә теле бар: — Кояш! — ди.
Чүпнең дә теле бар: — Кояш! — ди...

Ак нурлар яктысы җитмәгән,
Ак нурлар чаткысы үтмәгән
Сап-салкын кара баз диярлек
Бар микән биеклек, тирәнлек?

Кызганыч булса да бар икән!
Андагы сукмаклар тар икән...
Бар икән караңгы күңелләр,
Әйтерсең, кап-кара күмерләр...

Ак балкыш!
Учаклар көйрәттең,
Яктырттың күгемне, күлемне,
Жылытчы бозын да йөрәкнең,
Агартчы караңгы күңелне!..

1962

Казакъчадан *МӘХМУТ ХӨСӘЕН*
*тәрҗемәләре.*

*Мәхмут Хәсәнов*

# ЭШ СӨЙГӘННЕ ИЛ СӨЯ

*Очерк*

## Январь чилләсе



Бу якларда узган елгыдай салкыннарны соңгы чирек гасыр буена күргәннәре булмаган. Ай-һай өстәдә дә соң! Үзе аяз, үзе чатнама суык.

«Татбурнефть» трестының Азнакайдагы 3 нче номерлы вышка монтажлау участогында Гәрәй Баһманов житәкчелегендәге бригада шул салкыннар аркасында ике көн рәттән эшен дәвам итә алмады. Кешеләр тынгалыктан түгел, әлбәттә. Бригада членнары гадәттәгечә үз вакытында җыелдылар һәм, сәгате-минутында вахта машиналарына утырып, эш урыннарына киттеләр.

Тырышып, факеллар яндырып җылыта торгач, егермеләп авыр «С-80» маркалы тракторларны да кабыздылар. Әмма эш тукталды: 180 тоннадан артыграк авырлыктагы буровой вышкасын, лафетларга утырта башлау белән, калын диаметрлы чуен трубалар, тимер блоклар, салкынга чыдый алмыйча, пыяла кебек уалып коела башладылар.

Бригада членнары махсус чана өстенә эшләнгән җылы культбудкага җыелдылар.

— Булмый болай... — диде кайсыдыр.

— Әйе, — дип килеште Гәрәй. — Җайланмаларны эштән чыгарабыз...

— Нишлибез соң?

— Бераз сабыр итәргә туры килер.

Андый «сабыр итүнең» нәрсә икәнлеген Гәрәй бик яхшы белә: һәрбер минутны, һәрбер секундны исәпкә алып төзегән график сүтелә, айлык план үтәлүе дә куркыныч астына куела...

Әйе, январь аеның икенче яртысында, иң җаваплы көннәрдә, ике көн вакыт югалды... Әйтергә генә җиңел — ике көн!

Көне — көн, төне — төн булмады Гәрәйнең. Бөтен борчылганы — планның үтәлмичә калуы иде. Ә план зур: егерме җиде кешедән торган бригада ай саен 9—10 буровой төзергә тиеш. Шуның өстенә әле, һәр айда өстәмә бер буровой монтажлап, еллык планны Совет властеның 50 еллык юбилеена үтәргә дигән социалистик йөкләмәләре дә бар.

Бригадага ял бирсә дә, Гәрәй үзе көннәр буе яланда, урман буйларында, буровой тирәсендә булды. Күчереләсе буровойларны кабат карап чыкты, үтеләсе юлларны тикшерде һәм бик җентекләп үзенчә план төзеде. График буенча иң беренче булып 2976 номерлы буровой күчерелергә тиеш иде. Бу буровойның юлы бик озын: Тымытык кырларыннан Карамалы ягына, кимендә 27 километр ара үтәсе бар. Шуның өстенә юл катлаулы, 12 тапкыр югары вольтлы линияләрне үтәргә кирәк... Бу мәшәкатьле буровой бик күп вакытны алачак. Ә бораулау бригадаларына иртәгә, берсекөнгә үк яңа точкалар кирәк.

Нишләп карарга?..

## Чыннан да нишләргә?

Конторада әйттеләр: ике бораулау бригадасына иртәгә үк буровой кирәк!

Хәер, конторада әйтмәсәләр дә, Гәрәй барысын да үзе күреп тора. Әнә, Матвей Гринь буровоена махсус машиналар «колонна»лар ташый башлаганнар. Димәк, Матвей скважинасын бораулап бетергән, димәк, хәзер анда каратаж ясап яталар. Хәтта абыйсыннан да — Социалистик Хезмәт Герое М. П. Гриньнән дә — уздырды Матвей. Конторада беренчелекне үзендә тота. Әнә, яңадан бер скважина бораулап бетергән... «Колонна» (бер-берсенә тоташтырып ике километр тирәнлеккә төшерелгән трубалар тезмәсе) төшереп цемент измәсе белән ныгытып, перфарация ясыйсы гына кала. Димәк, бу бригадага да ике көннән яңа точка кирәк булачак...

Уйлана, баш вата торгач, Гәрәй бөтенләй икенче бер карарга килде. 2976 нчы номерлы, ерак юл үтәргә тиеш буровойны туктаган җирендә калдырып торып, Карамалы ягындагы 2951 нче һәм 2967 нче буровойларны күчерергә кирәк дигән фикер туды аңарда. Точкаларның аралары ерак түгел, берсе — өч километр, икенчесе — нибары ике километр чамасы гына. Димәк, аз гына вакыт эчендә ике бораулау бригадасы яңа точкалар белән тәэмин ителәчәк. Айлык план да үтәләчәк...

Нәкъ шул көннәрдә Гәрәйнең туган энесе килеп төште. Уңыш бәйрәменә чакыра килгән. Бәйрәм тантанасы 1 нче февральдә буласы икән.

— Эшләр җайга салынса, кайтырбыз... — диде Гәрәй.

Энесе ишетергә дә теләмәде.

— Кайтасыз булгач, кайтасыз. Барыбыз да көтәбез... — диде ул.

Авылда, Октябрьның 40 еллыгы исемендәге колхозда, дүрт энесе эшли Гәрәйнең. Дүртесе дә колхозның алдынгы механизаторы, дүртесе дә макталып телдән төшми торган егетләр...

Гәрәй энесенә үз хәлен аңлатып бирде. Эшләр чак кына җайга салыну белән, кунакка кайтырга вәгъдә итеп озатып калды.

Икенче көнне иртүк, алтынчы яртыларда ук, Гәрәй автовокзал янында иде инде. Мәхшәр көне кебек монда. Йөзләрчә һәм йөзләрчә машиналар. Тирә-як гөр килеп тора. Автовокзал кыегына беркетелгән көчле репродуктор аша, диспетчер машинаның номерларын әйтеп, кайсысының кайсы юнәлешкә барасын һәм кайчан кузгалып китәсен хәбәр итеп тора.

Кемнәр генә юк монда! Үзләрен данга күмгән атаклы бораулаучыларны да, бөтен илне хәйран иткән нефть чыгаручыларны да, алдынгы төзүчеләрне дә, тауларны ярып, сазлык-баткаклыкларны күмеп автострада салучыларны да очратырга мөмкин.



М. Гринь һәм Г. Баһманов.

Торган саен шау-шу, ыгы-зыгы арта бара. Колонна-колонна булып тезелгән вахта машиналарының кайберләре кузгала да башладылар...

Нәкъ шул вакыт Гәрәйнең дә егетләре килеп җитте.

— Хәерле иртә, Гәрәй!

— Сәлам, дуслар!

— Димәк, эшкә?

— Эшкә.

Гәрәй башында туган фикерне белән иптәшләрен таныштырды.

— Әйдәгез, бер өермә уйнатып карыйк булмаса... — диде кайсыдыр.

— Димәк, риза?..

— Риза!

— Алайса, эшкә, дуслар! — Һәм Гәрәй әмерләрен бирә башлады. — Син, Рәшит, 2951 нчегә. Монтажга. Ә син, Миргасим, 2967 нчегә. Тракторлар шунда... Өстерәтергә әзерләнә башла. Бульдозерларны үзем җибәртермен... Нурулла, ә син әйдә, минем белән.

Гәрәй бригаданы шулай, звеноларга бүлеп, һәркайсын аерым вахта машиналарына утыртып, озатып җибәрде.

Рәшит тә, Миргасим да, Нурулла да үз эшләренең осталары. Гәрәйнең Рәшит Вәлиуллин белән бергә эшли башлавына да инде ун елдан артык вакыт үтте. Шул чор эчендә бик күпне күрергә, бик күп кыенлыкларны кичерергә туры килде.

Коммунист Миргасим Мөслиев — Гәрәй бригадасында үсеп, чыныккан егет. Бригадирның беренче ярдәмчесе ул хәзер. Гәрәй аңа үзенә ышанган кебек ышана. Иң җаваплы, иң катлаулы эшләрне аңа тапшыра.

Конторада булып, кирәк-яракларны барлап, бульдозерлар мәсьәләсен ачыклагач, Гәрәй үзе дә бригадасы янына китеп барды.

Миргасим звеносы янына барып чыккач күрде Гәрәй: буровой блогы инде лафетлар өстендә. Бу хәл аны ничектер җилкендереп, күңелен

күтәреп җибәрде. Ирексездән: «Молодцы, егетләр!» — дип мактап куйды.

Гәрәй үз егетләрен яхшы белә. Алар һәр минут, һәр секундның кадерен белеп эшлиләр. Әмма бүгенге кебек ритм һәм темп әле сирәк була иде. Кара син аларны!

Уннан артык «С-80» маркалы авыр тракторлар буровойга «җигелә» башладылар.

Бар нәрсә дә әзер, «Кузгалырга!» — дигән команданы гына көтәләр.

Барысының да күзләре Гәрәйдә...

Менә аның соңгы әмере яңгырады:

— Һәрберегез үз урыннарыгызга!

Тракторлар гөрелтесеннән тирә-як тетрәп китте.

Гәрәй, билдән кар ерып, бераз алга узды. Барысының да күзләре — колонна алдына чыгып баскан бригадирда.

Менә ул, оста дирижер кебек, ике кулын да күтәрде һәм кинәт кырт кисеп аска төшерде...

«Кузгалырга!..» — дигән сигнал иде бу.

Як-якка куе төтен бөркелде һәм, тирә-юньне дер селкетеп, тракторлар колоннасы кузгалып китте...

## Кызыклы биография

Урамны тутырып атлый ул, хуҗаларча җиргә нык басып атлый. Уртачадан чак кына калкурак буйлы, киң җилкәле, түгәрәк йөзендә елмаюга охшашлы мөлаемлек балкый.

Эштән кайтып килә.

Очраган бер кеше аны зурлап, хөрмәт белән, исәнләшеп уза.

— Сәлам, Баһман туган!..

— Исәнмесез, Гәрәй абый!

Алты почмаклы йорты янында мең төрле яңалыклар хәбәр итеп, аны өч улы каршы ала. Әнә, иң төпчеге, биш яшьлек нәни кызы, Гөлсинә дә шунда. Әтисе, кочагын киң җәеп, аның йөгереп килеп җиткәнен көтеп тора һәм кинәт кенә күтәреп өскә чөя...

Шау-гөр килеп өйгә керәләр. Аларны тынгысыз Гәрәйнең турылыклы тормыш иптәше Миңсылу ханым каршы ала.

Өйдә дә эш...

Әнә ул өстәл янында утыра. Юынып, өс-башын алыштырган да яңадан эшкә керешкән.

Алдында — наряд-табельләр, китап-журналлар, карталар, схемалар... Картада — буровой нокталары. Алар Гәрәй кушуы буенча һәм аның бригадасы көче белән бер урыннан икенче урынга «сәяхәт итәргә» тиешләр.

Хезмәт җитештерүчәнлеген тагын да күтәрү өчен, буровойларны тагын да кызурак темп белән «сәяхәт иттерү» өчен тагын нәрсә эшләргә мөмкин соң?..

Шул сорауга җавап эзли ул.

Соңгы вакытта керткән тәкъдимнәре аеруча кызыклы аның. Һәр тәкъдиме буровойларны бер урыннан икенче урынга тагын да тизрәк күчерүгә юнәлдерелгән.

Гәрәй эшләп утыра...

Ул эшләгән арада без дә тик тормыйк, һич югында стенага эленгән фотоларга күз йөртеп чыгыйк. Монда аның бөтен тормыш юлы, биографиясе...

...Менә күп вакыт үтү сәбәпле, шактый саргаерга өлгергән бер яшүсмер малай рәсеме. Гәрәй бу, 8 нче класс укучысы. Шунда ук икенче

рәсем... Малай инде солдат формасында. Йөзе җитди, күзләре кырыс карый. Бу — балаларны балалыктан мәхрүм иткән, яшьләрнең яшьлеген таптаган мәрхәмәтсез сугыш башланган елда — 1941 елда төшкән рәсеме.

Сугышның беренче көннәреннән алып соңгы көннәренә кадәр фронтта була Гәрәй. Берничә тапкыр яралана, контузия ала. Мәскәүдән Берлинга кадәр барып җитә.

Өченче бер фотода күкрәген берничә орден һәм медальләр бизәгән совет офицеры басып тора. Дошманны тар-мар итеп, бик күп халыкларга азатлык китерүче совет офицерының кыяфәте горур, күз карашлары бөркетнеке кебек. Бу да Гәрәй. Монысы — 1945 елда Берлинда төшкән рәсеме.

Аннары инде тыныч хезмәт фронты... 1946 ел. Ул — Башкортстанның атаклы нефть шәһәре Октябрьскида. Монда инде бите шактый суырылган, яңак сөякләре төртеп торган хезмәт кешесе карап тора. Баштарак Гәрәй нефть вышкалары монтажлау бригадасында гади балта остасы булып эшли.

— Сиңа, егет, укырга кирәк,— диләр аңа.

Һәм ул Октябрьскидагы нефтьче кадрлар әзерли торган махсус курсларга укырга керә. Аны бетергәч, Баһмановны бригадир итеп куялар. Тиз арада ул үзен оста вышка төзүче, сизгер һәм хәстәрле җитәкче итеп таныта.

Нәкъ шул елларда партия һәм хөкүмәтебез ерак Себернең бетмәс-төкәнмәс хәзинәләрен ачарга чакыра.

Гәрәй — Себердә.

Кышларын — 50—60 градуска җиткән түзә алмаслык салкыннар. Ә җәйләрен чебен-черки, озынборынга түзәр хәл юк. Битләргә челтәрләр киеп, ә тәннәрне дегет-мазут белән буяп эшләргә туры килә. Анда да Гәрәй үзен чын новатор итеп таныта. Аның бригадасындагы егетләрнең рәсемнәре Почет тактасыннан, исемнәре телдән төшмиләр.

Себердә 4—5 ел вакыт үтеп тә китә. Нәкъ шул елларда, алар эшләгән трестка СССР нефть промышленносте министры килә.

— Курку белми торган, кыю егетләр кирәк,— ди ул.

Ерак Төньякта нефть һәм газга разведка ясау өчен бер бригада вышка монтажлаучылар кирәк икән.

— Бар андыйлар,— дип җавап бирәләр трестта. Бу юлы да Баһмановның фамилиясен атыйлар.

Министр үзе сөйләшә Гәрәй белән. Һәм Гәрәй Баһманов Ерак Төньякка китәргә ризалык бирә...

Шунда ук, министрның махсус приказы белән, бригаданың барлык членнарына да бушлай путевкалар биреп, илебезнең иң яхшы курортларында берәр ай ял иттерәләр.

Һәм, ниһаять, Гәрәй — Ерак Төньякта...

Менә кайда булган икән ул күз ачкысыз бураннар, тын алгысыз салкыннар...

Нәкъ ике ел үтте дигәндә, Гәрәй яңадан Себергә кайта.

Нәкъ шул елларда аны яңадан берничә җиргә эшкә чакырган кәгазьләр килә. «Зур нефть республикасы» дип телгә керә башлаган Татарстаннан да хәбәр бар. Җитмәсә тагын, туган ягы Азнакай да телгә алынган...

1956 елның башында Гәрәй «зур нефть» ягына — Азнакайга кайтып төшә... Шунда ук аңа вышка монтажлаучылар бригадасын бирәләр.

Азнакай!..

Таный алмаслык булып үскән, үзгәргән иде инде ул. Бу үзгәреш, Сәпәй тавына менеп карасаң, аеруча нык күзгә ташлана. Аста, тау буена ук елышып, иске Азнакай җәелеп ята. Гади бер авыл ул. Ә чит-

тәрәк — өчәр-дүртәр-бишәр катлы таш йортлар тезелеп киткәне — нефтьчеләр Азнакае.

Азнакай!

Кайчандыр бу гади бер татар авылының исеме телгә дә алынмый иде. Хәзер исә Азнакай турында ишетмәгән бер генә кеше дә юктыр. Өлкә газеталарында гына түгел, үзәк газета битләрендә дә: «Азнакай — алдынгы эш тәҗрибәсе мәктәбе», «Азнакай — бораулау эшенең академиясе»,— дигән сүзләр языла. Яңа техника белән коралланып, өр-яңа һәм иң прогрессив эш алымнарын кулланып, Азнакай бораулаучылары рекорд артыннан рекорд куйдылар, бөтенсоюз күләмендә дан казандылар.

Данның төбе — хезмәт, хезмәтнең төбе — хөрмәт,. ди мәкаль. Әйе, чын хезмәт кешесен хөрмәтли белә безнең халык...

## Съездлар Сарае кулуарларында

Әйе, чын кешене хөрмәтлиләр.

Гәрәй Баһманов бригадасындагылар арасында хөкүмәтебез орденнары һәм медальләре белән бүләкләнүчеләр шактый. Квартал саен диярлек Почет Грамоталары һәм кыйммәтле бүләкләр алулары турында әйтеп торасы да юк. Гәрәйнең, мәсәлән, үзенең генә дә 50—60 Почет Грамотасы бар.

Узган ел да бик истәлекле булды. Бригаданың берничә кешесе Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе медальләре алдылар: биш кеше бронза, дүрт кеше — көмеш, ә Гәрәй үзе алтын медаль белән бүләкләнде. Аның бригадасы Бөтенсоюз күләмендә барган социалистик ярышта җиңүче булып чыкты, Нефть промышленносте министрлыгының һәм Профсоюз Үзәк Комитетының Күчмә Кызыл Байрагын һәм акчалата бирелә торган беренче премияне яулап алуга иреште. Нибары бер ел эчендә генә дә йөз мең сум дәүләт средствосына экономия ясады.

Хәер, бу бердәм коллектив 1959 елдан бирле беренчелекне үзендә саклый. Шулай ук «Татбурнефть» трестының Күчмә Кызыл Байрагы да бөтенләйгә Гәрәй Баһманов бригадасында калдырылды.

Белгәнебезчә, бу коллектив Татарстанда иң беренчеләрдән булып, җидееллыкны срогыннан элек үтәве турында рапорт бирде. Ул үзенә бирелгән җидееллык заданиене 5 ел да 2 ай эчендә үтәп чыкты.

Тәбрикләүләр дә, бүләкләүләр дә күп булды. Әмма, фидакарь хезмәте өчен Гәрәй бүләкнең иң зурысын узган елда алды: аңа 1966 елның 27 май Указы белән Социалистик Хезмәт Герое дигән мактаулы исем бирелде.

Әйе, аның эше илебезнең барлык вышка монтажлаучылары өчен үрнәк булып тора. Илебезнең төрле почмакларыннан: Башкортстан нефтьчеләре, Баку, Себер, Грозный, хәтта Сахалин нефтьчеләре дә алдынгы эш тәҗрибәсе үзләштерергә Азнакайга, аның янына киләләр...

Өйнең түренә, иң күренә торган урынга, яна фотолар эленгән. Монда инде Гәрәй — Мәскәүдә, Кремльдә. КПССның XXIII съезды делегаты ул. Беренче фотода Татарстаннан килгән делегатлар җыелып төшкәннәр. Икенчесендә Гәрәй — партия һәм хөкүмәтебез җитәкчеләре арасында.

Бу фотоларга карау белән, Гәрәйнең күз алдына гомергә онытылмаслык дулкынландыргыч бер вакыйга килеп баса.

Съезд барганда, тәнәфес вакытында, Съездлар Сараеның кулуарларында йөргәндә була бу хәл. Гәрәй КПССның Әлмәт шәһәр комитетының беренче секретаре иптәш Ермаков белән сөйләшеп йөри. Шул

вакыт алар каршысына партия һәм хөкүмәтебезнең житәкчеләре килеп чыгалар. Л. И. Брежнев, А. Н. Косыгин, Н. В. Подгорный, М. А. Суслов, Д. С. Полянский белән очраша ул. Кул бирешеп исәнләшәләр. Менә шунда иптәш Ермаков Леонид Ильич Брежневны Гәрәй белән таныштыра.

— Безнең атаклы вышка монтажлау остасы Гәрәй Баһманов менә шушы инде.— ди ул.

Леонид Ильич үз итеп Гәрәйнең җилкәсенә кулын куя да:

— Беләбез, беләбез,—ди.— Фидакарь хезмәте турында һәрвакыт ишетеп торабыз.

Аннары алда торган планнары белән кызыксына.

Тәмам каушап калган булса да Гәрәй җавабын таба тагы:

— Безнең планнарыбыз бер, Леонид Ильич. Тагын да яхшырак эшләп, күбрәк нефть бирү.— ди ул.

Шул сөйләшүдән соң, барысы да җыелып, рәсемгә төшәләр...

## Берничә сан

**34 тәүлек ярым...**

һәм

**3 сәгать тә 40 минут.**

Гади вакыт берәмлеге генә түгел бу саннар. Гәрәй Баһманов җитәкчелек иткән вышка монтажлаучылар бригадасы куйган рекорд сроклары.

Аерма тик шунда: беренчесе 1956 нчы елда куелган. Ә икенчесе — «3 сәгать тә 40 минут» дигәне — соңгы вакыттагысы.

Менә тагын бер мисал. Шул ук Гәрәй Баһманов эшли торган «Татбурнефть» трестының Азнакайдагы 3 нче номерлы вышка монтажлау участогында моннан җиде-сигез ел гына элек кырыгар, хәтта иллешәр кешедән торган алты бригада эшли иде. Һәм ул бригадалар ел тәүлегенә нибары 12—13 нефть вышкасы монтажлый торганнар иде. Хәзер исә участокта 27 кешедән торган нибары бер комплекслы бригада калдырылды. Гәрәй Баһманов җитәкчелек итә торган бу бригада хәзер елына 130—140 вышка монтажлый.

Билгеле булганча, нефть вышкалары монтажлау гаять дәрәҗәдә авыр һәм катлаулы эш. Бораулау эшләре тәмамлану белән буровойны сүтәргә, өлешләп башка урынга күчерергә, икенче «точка»да яңадан монтажларга кирәк. Сүтеп алдың да икенче урында җыеп куйдың гына түгел. Хәзерге буровойлар һәркайсы үзе бер завод кадәрле. Буровойны электрлаштыру да, үзәк су линиясе белән тоташтыру да монтажлаучылар вазифасына керә. Никадәр көч, никадәр вакыт таләп итеЛә бу эшкә.

Моннан җиде-сигез ел гына элек бер буровойны кимендә ай ярым, ике ай буена коралар иде. Буровойлар җитмәү сәбәпле, күп кенә бораулау бригадалары эшсез торырга мәҗбүр булалар иде.

Бу эшен җиңеләйтү, вышкалар монтажлауның срокларын кыскарту өчен, баштарак мең төрле эш алымы файдаланып карадылар. Кагыйдә буларак, буровойлар детальләп җыелалар. Шулай булса да «комплекслы метод» дип атала иде үзе. Кырык-илле кеше берьюлы буровой тирәсендә эш алып бара. Уннарча кеше вышка тирәсендәге корылмаларны сала, шунда ук корылмаларга нигез салу өчен җир казыйлар... Ыгы-зыгы, шау-шу. Бер-берсенә комачаулыйлар, бер-берсенең эшен тоткарлыйлар. Бер үк эшне кат-кат эшләргә туры килгән вакытлар да еш була. Ә хезмәт җитештерүчәнлеге түбән, миллионнарча сум торган средстволар әрәм-шәрәм итеЛә, җилгә оча...

«Комплекслы» дип аталган бу эш алымы «узел методы» белән алыштырылды. Эш аңа карап әллә ни җиңеләймәде. Кичекмәстән, нинди булса да башка чара күрергә кирәк иде.

Чара күрелде. Вышка монтажлаучыларга «Гидронефтемаш» институты ярдәмгә килде. Бу фәнни-тикшеренү учреждениесенең инженерлары, Татарстан нефтьчеләре белән берлектә, буровойлар монтажлауның өр-яңа ысулын уйлап таптылар. Бораулау җайланмаларын элеккеге кебек буыннарга (узелларга) бүлгәләп түгел, ә эре блоклардан төзергә кирәк дигән тәкъдим керттеләр. Шулай иттеләр дә. Буровойларны яңа урынга эре блоклар белән күчерә башладылар. Бу метод эшне җиңеләйтеп кенә калмады, буровой төзүгә тотыла торган вакытны берничә тапкырга кыскарту мөмкинлеген дә бирде. Вышка монтажлаучы бригадалар буровойны алты-җиде көн эчендә төзеп бетерә башладылар.

Нәкъ шул көннәрдә Гәрәй Баһманов бригадасы буровойларны айлар буена түгел, ә берничә көндә, көндә генә дә түгел, берничә сәгатьтә төзеп бетерергә мөмкин икәнлекне илебездә беренче булып практикада күрсәтте.

1958 ел Азнакай вышка монтажлаучылары өчен зур җиңү елы булды. Баһманов бригадасы ел әйләнәсенә илледән артыграк нефть вышкасы корып, бөтен ил буенча рекорд куйды.

Коммунист Баһманов җитәкчелегендәге бригада тарафыннан куелган рекорд байтак вакытлар иң яхшы күрсәткеч булып кала бирде. 7 сәгать иде ул рекордның күрсәткече. Нибары 7 сәгать!

Әмма бу рекордның да гомере кыска булды. Гәрәй Баһманов бригадасының эш тәҗрибәсен җентекләп үзләштергән «Әлмәтбурнефть» трестының вышка монтажлаучылары да зур сикереш ясадылар. Алар бер буровойны нибары 5 сәгатьтә монтажлап бетереп, Гәрәйнең рекордын искерттеләр.

Күп тә үтмәде, Баһманов бригадасының яңа рекорд куюы турындагы хәбәр яшен тизлеге белән яңадан таралып өлгерде.

Яңа рекорд!

Буровой нибары 3 сәгать тә 40 минутта корылып бетте. Буровойны кабул итеп алган мастер Михайлов бораулаучылары, буровойны монтажлый башлауга нәкъ бер тәүлек тулды дигәндә, 180—200 метр җир бораулап үткәннәр иде инде.

...Тракторлар үкереп алга баралар. Буровойның 45 метр биеклектәге корыч вышкасын өстериләр алар.

Прораблар берничә бульдозер белән өч-дүрт километр алдан баралар. Бульдозерлар юлларны тигезлиләр. Электриклар да алда. Алар югары вольтлы линияләрнең чыбыкларын ычкындырып, «корыч колонна» үткәнче, җиргә күмеп торалар.

Колонна җирне тетрәтеп алга баруын дәвам итә...

Кышкы күз ачкысыз бураннар дими, җәйнең түзә алмаслык чилләсе дими, язгы-көзге пычраклар дими, Азнакай кырларында бер урыннан икенче урынга нефть вышкалары, буровойлар шулай күченеп йөриләр. Социалистик Хезмәт Герое коммунист Гәрәй Баһманов бригадасы кодрәте белән «сәяхәт итәләр» алар.

——□——

совет властенең 50 еллыгына

# ТАТАР СОВЕТ МӘДӘНИЯТЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ДӘФТӘРЕННӘН

*СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институтында «Татар совет әдәбияты хроникасы» аерым китап төсендә басарга әзерләнә. Вакытлы матбугат, төрле китаплар, җыентыклар һәм архивлардагы материаллар нигезендә төзелгән бу хроника әдәбиятыбызның Бөек Октябрь көннәреннән алып соңгы вакытларга кадәр булган үсешен конкрет фактлар аша күрсәтә.*

*Әлеге хроникадан Совет властеның беренче елларын чагылдырган өлешен филология фәннәре кандидаты Азат Әхмәдуллин журнал өчен махсус әзерләде. Аңар аерым материаллар туплашуда институт хезмәткәрләре Рифат Сверигин һәм Әдибә Исәнбаева ярдәм иткән.*

## 1917 ел

**26 октябрь** *(яңа стиль белән 8 ноябрь)*

Казанда Вакытлы революцион комитет төзелде, шәһәрдә һәм губернада Совет власте игълан ителде.

**27 октябрь** *(9 ноябрь)*

Казан Вакытлы революцион комитеты Үзәк типографияне конфискацияләү турында карар чыгарды.

**31 октябрь** *(13 ноябрь)*

Габдулла Кариев житәкчелегендәге «Сәйяр» труппасы Максим Горькийның «Мещаннар» пьесасы буенча эшләнгән спектакль күрсәтте.

**Октябрь ахырлары**

Мәҗит Гафуриның «Кызыл байрак» исемле шигырьләр җыентыгы басылып чыкты. Җыентыкка язучы Ф. Сәйфи-Казанлы рецензия язды. Анда түбәндәге юллар бар: «Кызыл байрак» революция теле белән язылган.... Шигырьләрнең бөтен рухы адәмнәрнең киләчәктәге гомуми бөек әләме булган социализмга өнди».

*«Безнең юл» газетасы. Уфа. 13 ноябрь.*

**Ноябрь**

Уфада бер төркем әдәбиятчылар һәм артистлар тарафыннан «Сәхнә сөючеләр җәмгыяте» төзелде.

*«Октябрьская революция и рождение Советской Башкирии». Уфа. 1959 ел. 127 бит.*

**Декабрь**

Мәскәүдә татар яшьләре «Ташкын» исемле музыка һәм драма түгәрәге оештырдылар.

*«Яңа вакыт» газетасы. 29 декабрь.*

## 1918 ел

**18 (31) январь**

Петроградта Үзәк Мөселман комиссариаты органы «Чулпан» газетасының беренче саны чыкты. Аның фактик редакторы — Галимҗан Ибраһимов.

«Чулпан» бераздан Мәскәүгә күчереләә һәм ел ахырына кадәр чыгып килә.



*Б. Тарханов, С. Булатов, Ф. Бурнаш, К. Сәгыйди.*

«Бу газета эчке Россия мөселманнарының Милләтләр халык комиссариаты члennары тарафыннан чыгарыла. Газета мөселман хезмәт ияләре арасында социалистик идеяләрне киң пропагандалауны һәм мөселман руханиларының реакцион йогынтысына каршы көрәшүне максат итеп куя».

*«Правда» газетасы. 23 январь.*

**21 январь** *(3 февраль)*

«Олуг Төркстан» газетасында Һади Такташның «Төркстан сахраларында» исемле беренче шигыре басылды.

**24 январь** *(6 февраль)*

Уфа революцион комитеты «Көрәш» исемендә газета чыгара башлады. Газета 1918 елның 30 июнендә, Уфа акгвардиячеләр тарафыннан басып алынгач, чыгудан туктады.

**26 февраль**

«Известия ВЦИК» газетасында Мулланур Вахитовның «Революцион мөселман халкына мөрәҗәгате» басылып чыкты. Анда революция учагы Петроградка зур куркыныч тууы турында әйтелә: «Үзегезнең азатлыгыгыз хакына, милләтегезнең чәчәк атуы хакына, киләчәк буынның шатлыгы һәм бәхете өчен героик көрәштә һәлак булган эшчеләр һәм солдатлар канынннан стеналары алланып торган революция крепостен батырларча саклаучылар сафына ашыгыгыз».

*«Социалистик Татарстан» газетасы. 1965 ел. 22 август.*

**26 февраль**

«Көрәш» газетасында Мәҗит Гафуриның «Хисап көне» исемле шигыре басылды.

**Март башлары**

Галиәсгар Камалның «Өйләнәм... ник өйләндем» дигән комедиясе «Алга» китап нәшриятында басылып чыкты.

**12 март**

Казан Советы Мөселман комиссариаты органы «Эш» газетасының I саны чыкты. 1920 елның июлендә бу газета урынына «Татарстан хәбәрләре» чыгарыла башлады. (Хәзерге көндә ул «Социалистик Татарстан» исеме белән чыгып килә.)

**Март урталары**

Уфада «Татар әдәбияты һәм музыкасы җәмгыяте» төзелде. Аның җаваплы председателе итеп Сәгыйт Сүнчәләй сайланды.

*«Көрәш» газетасы. 25 март.*

**Март**

«Шәрыкъ кызы» журналының беренче саны чыкты.

**12 апрель**

«Тормыш» газетасында М. Гафуриның «Бер төндә» исемле шигыре басылды.

**17 апрель**

«Шималь ягы» (Петроград) газетасының тугызынчы саны тулысынча Г. Тукайга багышланып чыкты.

**Апрель**

Оренбург мөселман яшьләре оешмасы «Туплан» исемле журнал чыгара башлады.

**2 майга кадәр**

Үзәк Мөселман комиссариаты члены Г. Ибраһимов Уфада булып китте. Ул татар эшчеләре Советы җыелышында һәм зур митингта «Советлар хөкүмәте», «Революциядә эшче халыкның роле» кебек берничә темага докладлар белән чыкты, урындагы оешмаларга кайбер практик чараларны эшкә ашыруда ярдәм итте.

*«Эш» газетасы. 7 май.*

**11 майга кадәр**

Сембердә (хәзерге Ульяновск) татар телендә большевистик «Көн» газетасы чыга башлады. 1920 елга кадәр аның редакторы булып Фәтхи Бурнаш эшләде. 1919 елның июленнән газетаның исеме «Таң» дип үзгәртелә, ул 1921 елга кадәр чыгып килә.

**17 май**

«Сәйяр» труппасы, төрек әсире Сабит Гали Хәйдәр бәкнең «Шаһгали хан» трагедиясен сәхнәгә куеп, кышкы сезонны япты.

**23—31 май**

Казанда Бөтенроссия мөселман укытучылары съезды эшләде.

Г. Ибраһимов съездны Үзәк Мөселман комиссариаты исеменнән тәбрик итте һәм көн тәртибендәге беренче мәсьәлә буенча доклад ясады, өч утырышта җыелыш аның җитәкчелегендә булды. Ул барлык мәсьәләләр буенча да чыгышлар ясады.

Съезд эшендә язучылардан, әдәбият һәм тел галимнәреннән Габдрахман Сәгъди, Фатих Сәйфи, Сәлах Атнагулов, Галимҗан Шәрәф, Мөхетдин Корбангалиев, Хуҗа Бәдигый, Гыйбад Алпаров, Әхмәтҗан Мостафый һәм башкалар катнашты.

**Май**

«Шәрык кызы» журналының 3 санында Ф. Бурнашның «Шәрык кызы» балладасыннан бер өзек («Диңгез кызлары — шәрык кызына») басылды.

**Июнь**

«Шәрык кызы» журналында Фатих Әмирханның «Канвалардан берсе» дип аталган озын хикәясе басыла башлады. (Ахыры журналның июль — август саннарында.)

**10... 17 июль**

Казанда Ильяс Кудашев-Ашказарский җитәкчелегендәге труппаның гастрольләре башланды. Труппаның репертуарында «Мескен Фатих», «Сөешү юлында» һ. б. спектакльләр бар.

*«Эш» газетасы. 17 июль.*

**28 июль**

«Эш» газетасында Галиәсгар Камалның («Азат» псевдонимы астында) «Изге таң» исемле шигыре басылды.

**31 июль**

Әбрар Сәгыйдинең «Язгы таңда» дип аталган шигыре «Чулпан» газетасында басылып чыкты.



*Гыйльми үзәк коллегиясе.*

**Сентябрьнең беренче яртысы**

Мәркәз мөселман хәрби һәйәте органы «Кызыл Армия» газетасы чыга башлады. 1921 елны Хәрби һәйәт бетерелгәч, газета республиканың политик идарәсе (ПУР) карамагына күчә һәм егерменче елларның урталарына кадәр чыгып килә.

**20 сентябрь**

«Кызыл Армия» газетасында Шамун Фиданның «Кызылармеецка» исемле шигыре басылды.

**27 сентябрь**

Мөселман коммунистларының Мәркәз һәм Казан комитетлары органы булган «Эшче» газетасының беренче саны чыкты. Газета соңрак Мәскәүгә күчә һәм, «Коммунист» исеме астында, 1933 елга кадәр чыгып килә.

**4 октябрь**

Зур театр бинасында татар драма артистлары Сәгыйт Рәмиевнең «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин» исемле пьесасын куйдылар.

**10 октябрь**

Гыйльми һәйәт каршында айлык журнал чыгарырга карар бирелде. Шул ук вакытта ул Казан Мөселман мәгариф бүлегенең дә органы булырга тиеш иде. «Мәгариф» дип аталган бу журналның беренче саны 7 ноябрьда чыкты.

**22 октябрь**

Гыйльми һәйәт тарафыннан «Имля комиссиясе» төзелде. Татар телен фәнни нигезләрдә эшкәртү өчен оештырылган бу комиссия үзенең беренче утырышын үткәрде.

**25 октябрь**

Акчехләр һәм буржуаз милләтчеләр җәзалап үтергән күренекле революционер Закир Сәетзадәнең «Бичара Бибиҗиһан» исемле 3 пәрдәлек драмасын татар драма театры труппасы артистлары сәхнәгә куйды. Режиссеры Камал II.

**29 октябрьга кадәр**

Астрахань татар театрында Ф. Әмирханның «Тигезсезләр» пьесасы уйналды.

**Октябрь**

Кызылармеец шагыйрь Ибраһим Йосфый (Ибраһим Кушаев) Россия Коммунистлар партиясенә керде.

*Х. Усманов. «Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорында татар поэзиясе». Казан. 1960. 120 бит.*

**3 ноябрь**

«Эш» газетасында түбәндәге мөрәҗәгать басылды:

«Драматург иптәшләргә!

Татар сәхнәсен күтәрүгә теләүче иптәшләр сәхнәгә куярлык революционный һәм башкача сәхнә өчен язган пьесалары булса, яки язарга теләгән иптәшләр һәм һәвәскәрләр язып бетергәч, түбәндәге адрес белән озакламыйча язып җибәрүләрен үтенәбез: Казань, Московская ул., д. 26, (...) Мусульманский Коммунистический комитет».

**14 ноябрь**

«Эш» газетасында Кадыйр Хәкимнең «Октябрь инкыйлабының еллык бәйрәме хөрмәтенә бөек бәйрәм» исемле зур шигыре басылды.

**21 ноябрьга кадәр**

«Гасыр» китапханәсе «Идел буе әдәбияты» сериясеннән берничә китап, шулар җөмләсеннән «Г. Газиз хикәяләре»н бастырып таратты.

**22 ноябрь**

«Эш» газетасында Г. Камалның «Вәгазь-нәсихәтләр» дигән сатирик куплетлары басылды.

**Ноябрь**

Кәрим Тинчурин Казанга килде, «Сәйяр» труппасында режиссер һәм артист сыйфатында эшкә башлады.

**3 декабрьдан соң**

В. И. Ленинның биографиясе, татарчага тәрҗемә ителеп, нәшриятка тапшырылды.

*«Эш» газетасы. 3 декабрь.*

**10—11 декабрь**

«Эш» газетасында Кәләй имзасы астында «Даһи» исемле поэма басылды.

**13 декабрь**

Рәүф Ниязбаевның «Беренче таң» исемле драмасы буенча эшләнгән спектакльнең премьерасы булды. Режиссеры К. Тинчурин.

**16 декабрь**

Татар драма артистлары труппасы тарафыннан Исхак Бәхтиевнең «Революция» исемле комедиясе сәхнәгә куелды. Спектакльнең режиссеры К. Тинчурин.

**27 декабрь**

Кызыл Армия Сараенда Ф. Шиллерның «Юлбасарлар» трагедиясе буенча эшләнгән спектакльнең премьерасы булды. Мохтар Мутин постановкасы, әсәрне татарчага Шәриф Камал тәрҗемә иткән.

*«Эш» газетасы. 29 ноябрь.*

**1918 ел**

Сәгыйт Сүнчәләйнең «Ихтилал шигырьләре» исемле җыентыгы басылып чыкты.

(Дәвамы бар.)

*Фатих Ибраһимов*

# Без түбәннән күтәрелдек

## МУЗЫКА ГЫНА ТҮГЕЛ, РӘСЕМ ЯСАУ ДА ЯЗЫК САНАЛГАН... [1]

Музыка сәнгате өлкәсендә Бөек Октябрьга кадәр кайбер уңышларыбыз булса да, милли сынлы сәнгать әсәрләреннән без бөтенләй мәхрүм ителгән идек.

Сынлы сәнгать [2], аерым алганда, аның нәкыш сәнгате төре (живопись) — безнең культурабызның революциягә кадәр профессиональ югарылыкка күтәрелә алмаган икенче бер тармагы. Нәкыш сәнгате өлкәсендә хәлебезнең тагын да мөшкелрәк булуының сәбәпләрен, беренчедән, патша хөкүмәтенең вак милләтләрнең культура үсеше турында бөтенләй кайгыртмавыннан, теге яки бу халыкка үзенең профессиональ рәссамнарын булдыру юнәлешендә экономик шартлар тудырмавыннан, икенчедән, ислам йолалары сагында зобаныйлардай торган дин әһелләренең рәсемгә «сын» дип карап, аның үсүе, тәрәккый итүе өчен ирек бирмәүләреннән эзләргә туры килә. Ислам дине җанлы нәрсәләрнең рәсемнәрен ясауны тыйганлыктан, халыкның таланты башка юнәлеш ала. Халык арасыннан чыккан осталар өйләрне, аяк, өс-баш киемнәрен бизәү, чигү буенча җитди уңышларга ирешәләр. Гаять матур итеп чигелгән сөлгеләрне һәм ашъяулыкларны, билбауларны һәм киҗе тукымаларны, укалы калфакларны һәм чәмчәле читекләрне, геометрик сызыклар ярдәмендә сырлап, бизәп ясалган беләзекләрне һәм чулпыларны күреп безнең кайсыбыз гына сокланмый икән?! Аларда халык төрле үсемлекләрне, аларның чәчәкләрен һәм яфракларын сурәтли, әнә шулай үзенең тормыш-көнкүрешен матурларга, бизәргә тырыша. Ул чигешләрнең кайберләрендә атка, боланга, кошка һәм җәнлекләргә охшаш нәрсәләр дә күзгә чагылып киткәли. Ләкин алар бик гадиләштерелгәннәр, аларны еш кына аеруы да читен. Бу — Болгар чорыннан калган традиция. Чишмә берьюлы гына кипмәгән шикелле, халыкның ерак бабалардан килгән традицияләре дә кинәт кенә туктапып калмый. Чигешләр арасында җанлы нәрсәләрнең анда-санда очравын шуның белән аңлатырга туры килә.

Әмма шул нәрсә аңлашылмый, ни өчен татарның дин башлыклары рәсемгә шул хәтле каршылык күрсәткәннәр? Ни өчен татар кешесенә рәсем ясарга, өенә шәмаил-

[1] Ахыры. Башы 6 санда.

[2] Сынлы сәнгать живопись, скульптура, графиканы берләштерә. Изобразительное искусствоны — сынлы сәнгать, живописьны — нәкыш сәнгате дип, скульптура һәм графиканы бездә дә шул ук исемнәр белән алу урынлы булыр шикелле.

дән [1] башка сурәт әләргә ярамаган да, шул бер үк мөселман динен тотучы төрекләрдә һәм фарсыларда, мәсәлән, бу һөнәр тыелмаган? Бу халыкларның моннан 100 еллар элек чыккан китап һәм газета-журналларында сурәтләр тулып ята. Ә бездә 1908 елда чыга башлаган «Шура» журналына да баштарак сурәт урнаштырылмый, тик соңга таба гына ул рәсемнәр һәм фотолар белән бизәлеп чыга һәм үзе сынлы сәнгатьне пропагандалаучы булып китә.

Ахмаклык шуңа барып җитә ки, «Дин вә мәгыйшәт» журналында «Зингер» фирмасының игълан (рекламасы) урнаштырыла. Ләкин акчага да комсыз булган, шаригатькә дә ярарга тырышкан нәширләр машинада тегеп утыручы хатын-кызны башсыз чыгаралар. Тик акча түләүчеләр моңа катгый рәвештә ризасызлык белдергәч кенә, теге рәсемгә баш куйдырып, кабат басарга мәҗбүр булалар.

Октябрь революциясенә кадәр сынлы сәнгатьнең хәле турында сүз барганда, шул чорларда басылган бер мәкаләдән өзек китерми үтә алмыйм.

Мәгълүм булганча, бик озак вакытлар башлангыч мәктәптә беренче уку китабы булып килгән «Иман шарты» XX йөз башларына таба (тәгәлрәге 1891 елдан) яңа, заманчарак төзелгән әлифбалар белән алыштырыла башлый. Әлифбалар арасында рәсемлеләре дә була. Шул уңай белән «Әлифба китапларына тәнкыйть» (1909 ел) дигән кечкенә бер брошюра дөньяга чыга. Рәсемле әлифба турында әлеге авторның түбәндәге сүзләрен укыгач, хәйран каласың: «Сурәтләрнең бәгъзеләре, — дип фикер йөртә ул, — бик муафикъ түгел һәм карья балаларына аңларлык та түгел. Әлифбаның икенче сәхифәсендә гармун сурәте куелган. Бу бик мәгълүм вә күп истигъмаль кылына торган нәрсә булса да, мәктәп вә мәдрәсәләрдә һәм мөгаллим вә шәкертләр кулында күренә торган нәрсә түгелдер. Халыкның күбесе буны исереклар кулында һәм трактирларда күбрәк күренгәнлектән, шуларга гына хас нәрсә дип санап килә.

Гәрчә музыка бик шәрәфәтле вә күп җәһәтдән файдалы нәрсә булса да, безнең халык хәзергә кадәр аның коралларын мөкатдәс урыннарга вә сурәтләрен дәрес китапларына куярга нәфрәтләнә. Шул сәбәпле бундаен нәрсәләрнең сурәтләрен дәрес китапларына куюны шуларның файдаларын халык аңлап үзләренә мәхәббәт куйганчы кетәргә кирәк була».

Күренә ки, шәригать канунарына һәм йолаларына таянып кына түгел, дөньяви әдәбиятта да әле рәсемгә караш әнә шундый булган, теге яки бу юл белән җәмәгатьчелек фикерен рәсемнең китапларда урын алуына каршы юнәлдерергә тырышылган.

Гаҗәп хәл. Европада бу вакытларда инде сынлы сәнгать искиткеч адымнар белән алга киткән, аның тарихы мең еллар белән исәпләнә иде. Европа илләрендә һәм Россиядә дисталәгән сәнгать музейлары эшләп килә. Шул музейлар Рафаэль, Микеланджело, Леонардо да Винчи, Рембрандт, А. Г. Венецианов, К. П. Брюллов, А. А. Иванов, И. Е. Репин, якташыбыз И. И. Шишкин кебек мәшһүр рәссамнарның картиналары белән бизәлгән бер вакытта, татар милләте культураның кешене сафландыра һәм пакьландыра торган шушы тирәннән махрүм хәлдә яши. Ислам ике дөнья арасына йөз еллар буе җимереп булмаслык әнә шундый кара стена кора.

Менә шушы шартларда баштарак Габдулла Тукай «Фикер» газетасында (1906 ел) «Хиссияте миллия», бераз соңрак Галимҗан Ибраһимов «Йолдыз» газетасында (1910 ел башы) «Рәссамлык» исемле мәкаләләр белән чыгалар. Г. Ибраһимов үзенең мәкаләсендә, мәсәлән, 1905—1907 елгы буржуаз-демократик революция уңае белән мәдәниятыбыз фронтында җанлану сизелүе турында санап күрсәтә дә фикерен болай дәвам иттерә:

«Татар сүзе байтак нәрсәләргә изафә кылынып, «татар әдәбияты», «татар шагыйре», «татар театры», «татар композиторы» кеби сүзләр еш-еш очрый, әмма «татар рәссамнары» дигән сүзне һичкайда ишетеп булмый. Вә татар мәгыйшәтеннән алынган рәсемнәрне һичкайда күреп булмый» [2]. Сүз арасында гына әйтеп узыйк, Ш. Бабич та шул ук фикерне кабатлый:

Сыз, Камал, рәссам, хариталар,
Шәмаилләр чыгар.

---

[1] Шәмаил — татарларда рам эченә язылып куела торган сүрәләр, дини текстлар. Шәмаил язып эленгән өйгә шайтан керми дигән ялгыш фикер таралган.

[2] Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. 1960 ел. 25 бит.

Я илаһем, бездә кайчан
Рафаэльләр чыгар.

Озак та үтми, Галимҗан Ибраһимов яңадан бу мәсьәләгә әйләнеп кайтырга мәҗбүр була. Ул югарыда искә алынган «Альбом»да, профессиональ музыка керәклеген яклап чыгу белән бергә, н ә к ы ш  с ә н г а т е  к и р ә к л е г е н дә игътибар үзәгенә куя [1]. Халкыбызның бу өлкәдә артта калуына ачына, моның сәбәпләренә тагын бер кабат анализ ясый, алга зур өметләр баглый. Әдип үзенең унике яшьлек бер иптәшенең, ике буяулы кыска карандаштан башка һичнәрсәсе булмаса да, көн-төн шелтәләп торсалар да, бөркәнчегенә тирәнә төшеп, оялчан кыяфәттә басып торган татар килененең рәсемен зур маһирлык белән ясавын исенә төшерә дә: «Андый балалар күп булгандыр. Ләкин аларны таш каплый — алар кибәләр, корыйлар иде. Инде таш ярылды. Читкә ташланды. Өмет бар ки, халык табигатенә чәчелгән орлыклардан бере, утырган туфрагының, эчкән һавасының, көяшлы күкнең тәэсире белән көннәрнең берендә җир өстенә чыгар, сабак үстерер, яфрак ярыр, чәчәк атар, вакыты белән җимеш бирер», дип нәтиҗә ясый.

Бөек әдип халык талантларына иксез-чиксез киңлекләр бирәчәк социалистик революциянең якынлашуын нык тойган булса кирәк. Ул, киләчәгебезгә пәйгамбәрләрчә карап, түбәндәге сүзләрне әйтә: «...Зарар түгел, болар туачак сәнгатьнең үсәчәк бакчасын тазарта, аңар йомшак туфрак хәзерли. Имдеки: кояш ачылыр, һава төзәлер, рәхмәт яңгыры явар — шуның соңында без дә киткәнебезне күрермез... Әдәбият туды, музыка белән рәсем туарга якын бер хәлдә. Без аның туар заманының якынлаганын төрле галәмәтләрдән күрәмез һәм аларны тудырырлык һава вә туфрак безнең хаятемызда да ясалып килгәнен хис кыламыз».

Чыннан да, татар халкының профессиональ милли сынлы сәнгате туу өчен бездә нинди алшартлар бар иде соң? Хәзер инде кыскача гына бу мәсьәләгә дә тукталыйк. Мәгълүм ки, Казан Россия дәүләтен Көнчыгыш белән тоташтыручы күпер рәвешендә һәрвакыт бай культура үзәге була. Казанда XIX йөз башларында ук инде Л. Крюков, В. Турин кебек рус художниклары эшли. Аларның беренчесе майлы буяу белән Н. И. Лобачевскийның портретын ясый, икенчесе Казанның аерым күренешләрен мәңгеләштерә. Аның «Кафедраль Благовещенский собор», «Гостиный двор күренеше», «Казан духовный семинариясе» дигән һ. б. бик күп рәсемнәре әнә шундыйлардан. XIX йөзнең урталарында Казанда А. Ракович, Б. Марков, Ф. Мелентьев, Р. Ступин, Н. Зеблов, З. Иванов, А. Иванов кебек художниклар яши. Алабугада туып-үскән И. И. Шишкинның да тормышы Казан белән бәйле. 1804 елда университет, 1895 елда художество мәктәбе ачылуның да Казанда сынлы сәнгатьнең җанлануына йогынтысы зур була. Художество мәктәбе (хәзер училище) ачылгач, ел саен диярлек Казанда җирле художникларның күргәзмәләрен оештыру традициягә диярлек әйләнә.

Галимҗан Ибраһимовның «татар мәгыйшәтеннән алынган милли рәсемнәрне һичкайда күреп булмавы» турында борчылып язуын әйтеп үзган идек инде. Әмма татар халкы тормышыннан алып ясалган рәсемнәр дә булган икән. Ул рәсемнәр һәм аның авторы республикабыз җәмәгатьчелегенә моннан берничә ел элек мәгълүм булды. Мин Мирсәй Әмирнең 1960 елның февралендә «Социалистик Татарстан» газетасында басылып чыккан «Кыйммәтле табылдык» дигән мәкаләсен күз алдында тотам.

1861 елда латыш художнигы Карл Гун белән рус художнигы В. П. Верещагин Алабуга шәһәренә чиркәү бизәргә киләләр. Шул чакта алар буш вакытларын Алабуганың үз эчендәге тормышны һәм аның тирә-ягындагы гүзәл күренешләрне рәсемгә алуга багышлыйлар. Вятка һәм Казан губерналарындагы матур табигать, анда яшәүче кешеләр белән танышып, Карл Гун чиксез зур дикъкать белән җирле халыкның типларын, аларның тормыш-көнкүреш әйберләрен, киемнәрен, авыл күренешләрен рәсемгә төшерә.

К. Гунның «Татар кешеләре» (Казан губернасы, Бирдебәк авылыннан), «Яшь татар хатыны» (художник аны соңыннан майлы буяу белән Парижда тәмамлаган),

---

[1] Бу аңлашыла да. Чөнки зур әдәбиятны романнан башка күз алдына китерү кыен булган кебек, теге яки бу милләтнең сынлы сәнгатен дә аның нәкыш сәнгате (живопись) тереннән башка күз алдына китереп булмый.





*К. Гун.* Сулда — Татар карты.
Уңда — Татар хатыны.

«Татар кызы Латыйфа», «Мулла һәм аның хатыны», «Калфак», «Чистай елгасы буенда», «Котлы Бөкәш авылы мәчете», «Татар киемнәре», «Татар теләнчесе», «Вятка губернасы татарлары» кебек рәсемнәре тарихи яктан да, сәнгать әсәрләре булу ягыннан да безнең өчен бүген дә зур әһәмияткә ия булып торалар.

Октябрь революциясе алды елларында һәм революциядән соң Казанда рус художникларыннан Н. Фешин, П. Радимов, П. Беньков (Г. Ибраһимов портретының авторы), В. Тимофеев кебек күренекле художниклар иҗат итәләр.

XX йөз башларына хәл шактый үзгәрә. Татар яшьләреннән дә, кулына каләм, карандаш һәм буягыч тотып, рәсем өлкәсендә көч сынап караучы һәвәскәрләр ешая башлый. Аларның кайберләре укышка да иреша. Шундыйлар рәтенә китап һәм газета-журнал иллюстраторлары М. Галиев белән Г. Гумеров керә. 1907 елда Оренбургта чыккан «Карчыга» журналының сатирик рәсемнәрен Шакир Мөхәммәдев белән бергә эшләүче Лотфулла Мостафин дигән контора эшчесенең ясавы билгеле. «Яшен» һәм «Ялт-Йолт» журналларын сатирик рәсемнәр белән бизәүдә Галиәсгар ага Камал катнаша.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң яшь талантларга беренче адымнарын ясауда Казанда яшәүче рус художниклары зур булышлык күрсәтәләр. Революциядән соң, элекке заманнардан аермалы буларак, рус һәм татар художниклары бердәм коллективта иҗат итәләр. Милли художникларның саны да шактый арта. Ф. Таһиров (хәзер Мәскәүдә яши. Союзда матур шрифтлар уйлап чыгаручы графикларның берсе булып танылды), И. Сөләйманов, Б. Сәитов, Җ. Булат, Ш. Мөхәммәтҗанов (соңгы икесе хәзер пенсиядә), Г. Йосыпов һәм башкаларның имзалары китап, газета-журнал битләрендә торган саен ешрак күренә бара.

Мәскәүдә «Эшче» газетасы һәм «Көчкенә иптәшләр» журналы, Казанда «Чаян», «Азат хатын» журналлары, «Кызыл яшьләр» газетасы чыга башлау, Татарстан китап нәшриятының продукциясе арту талантлар өчен киң мөмкинлекләр ача. Мәсәлән,



*К. Гун.* Кәдрәк авылы.

озак еллар «Чаян» журналында эшләгән карикатурачы Госман Арслановның таланты киң ачылуда әле генә саналган фактлар зур роль уйный.

1925—1930 елларда Татарстан художниклары графика өлкәсендә җитди уңышларга ирешәләр. Фаик Таһиров бизәгән китаплар 1925 елда Парижда ачылган халыкара күргәзмәдә күрсәтелә. Татарстан графикларыннан Ф. Таһиров, Ш. Мөхәммәтҗанов, Д. Красильников, Н. Сокольский, К. Чебатаревларның әсәрләре шулай ук Париждагы халыкара күргәзмәгә куелалар, бу күргәзмәнең (1931 ел) экспонатлары соңрак Нью-Йорк һәм Филадельфия шәһәрләрендә дә зур кызыксыну белән карала.

Инде без революциядән соңгы елларда китап, газета-журнал, спектакльләр бизәүче һәм сатирик рәсемнәр ясаучылар белән берләттән, нәкыш сәнгате өлкәсендә эшләүче профессиональ художникларны да очратабыз. Шундыйларның беренчесе Татарстанның халык художнигы Бакый ага Урманчы була. Ул, татарлардан беренче буларак, махсус югары белем ала. Аның иҗаты 1916 елда «Ямьле Агыйдел буйлары» дигән өйрәнчек рәсеме белән башлана, аннары ул пейзажлар ясау белән шөгыльләнә. «Сепарат янында» (1927), «Кадиевкада Ильич исемендәге шахта» (1935), «Ишембай нефть промыселында» (1936) исемле полотнолары татар нәкыш сәнгате әсәрләренең беренче карлыгачлары булып торалар.

Өлкән буын рәссамнарыннан Бакый ага башлангыч адымнарын әнә шулай нәкыш сәнгате өлкәсендә ясаса да, хәзер ул скульптур портретлар тудыруга күп көч куя. Соңгы елларда ул безне Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Г. Кариев, М. Җәлил бюстлары белән шатландырды. Бу хезмәтләре өчен ул быел Тукай исемендәге премиягә лаек булды.

Н. Вәлиуллинның (1911—1943) «Татар авылында Октябрь көннәре», Җәгъфәр Булатның беренче картиналары шулай ук Бөек Ватан сугышы алды елларында иҗат ителделәр.

Утызынчы еллар башында Садри Ахун татарлар арасыннан беренче скульптор буларак чыгыш ясады. Моңа чаклы безнең рәсем культурабызда скульптура әсәрләре бөтенләй диярлек юк иде әле. Б. Әлминевнең утызынчы елларның икенче яртысында эшләгән график рәсемнәре үзләренең профессиональ яктан шактый җитлеккән булулары белән аерылып торалар. Ул — Г. Тукай әсәрләренә иң күп иллюстрация ясаучы графикларның берсе. Байназар соңгы елларда уңышлы гына портретлар да бирде. Шундыйлардан һәркайсыбызга мәгълүм булган К. Насыйри һәм Г. Тукай портретларын күрсәтергә мөмкин.

Татарстанда нәкыш сәнгате бигрәк тә Бөек Ватан сугышыннан соңгы елларда чәчәк атты.

Октябрь революциясе алдыннан һәм аннан соңгы елларда да, Бөек Ватан сугышы еллары алдыннан да татар милли художникларының таланты, күреп үтелгәнчә, беръяклырак, графика (китап-журналларга иллюстрация, сатирик рәсем һ. б.) һәм декорация өлкәсендә тәрәккый итеп килде. Нәкыш сәнгате өлкәсендә кайбер адымнар гына ясалып калынды. Әмма Бөек Ватан сугышыннан соңгы еллар безгә профессиональ нәкыш сәнгате әсәрләре тудыру юнәлешендә яңа уңышлар китерде. Бу үсеш РСФСРның халык художнигы Харис Якупов һәм РСФСРның атказанган художнигы Лотфулла Фәттахов исемнәре белән бәйле.

Казан художество училищесын тәмамлауга фронтка киткән яшь белгечләр Л. Фәттахов һәм Х. Якупов кыен шартларда да иҗат эшләрен дәвам иттерәләр. Әле урта мәктәптә укыган елларда ук алар арасында башланган дуслык, сугыштан кайткач, иҗади хезмәттәшлеккә әверелде. 1950 елда алар «В. И. Ленин Татарстан АССР төзелү турындагы декретка кул куя» дигән уртак картина тәмамладылар. Полотно Дәүләт премиясенә лаек булды. Х. Якуповның «Хөкем алдыннан», «Герой ананы хөрмәтләү», «Иделдә яз», «Әнием рәсеме», «Ш. Камал» дигән һәм башка бик күп әсәрләре зур осталык белән ясалганнар.

Жанрлы рәсемнәр остасы Л. Фәттахов та коммунизм төзүче совет кешесенең рухын, милли горурлыгын үзенә генә хас буяулар белән матур итеп күрсәтеп бирә. «Икмәкләр өлгерде», «Яңа бура», «Басу лабораториясендә», «Райком секретаре иртәсе» кебек киң танылган полотнолары аның тирән психолог, алган теманы ачып бирү өчен төрле алымнардан оста файдалана белүче, хыялга бай художник булып җитешүен күрсәтәләр.

Татарстан художниклары союзы тирәсенә хәзер талантлы рәссамнарның зур гвардиясе тупланды. Алар арасында, Б. Урманчы, Х. Якупов, Л. Фәттахов, К. Кузнецов кебек киң танылган рәссамнар белән бергә, М. Усманов, С. Лывин, И. Халиуллов, В. Кудельхин, Р. Нигъмәтуллина, И. Әхмәдиев, З. Гельмс, Б. Әлминев, Ә. Нагаев, А. Радионов, К. Максимов, В. Маликов, Г. Рахманкулова, И. Колмогорцева, Ә. Тумашева, М. Сутюшев, И. Язынин, И. Рафиков, В. Карамышев, М. Семенов, Т. Хаҗиәхмәтов кебек бик күп художниклар бар. Татарстан рәссамнары РСФСР художниклары союзының иң көчле отрядларыннан берсенә әйләнде.

Хәзер инде җыр җырлауны, тегеяки бу музыка коралында уйнауны, рәсем ясауны, өйдә рәсем тотуны язык дип, хәрам дип әйтүчеләрне көндез чыра яндырып эзләсәң дә табуы читен. Музыкасыз, рәсемсез тормышны хәзер без күз алдыбызга да китерә алмыйбыз. Музыканың, рәсемнең кешене сафландыруын, аңа яңа көч һәм дәрт бирүен тирәнтен аңлыйбыз, сәнгать алдында баш иябез.

Болар күп нәрсә турында сөйлиләр. Барыннан да элек, бу — милли политика өлкәсендә Ленин идеяләренең бөек тантанасы, формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик культураның чәчәк атуы, илебездә барган культура революциясе биргән гүзәл җимешләрнең берсе.

## Ә ХӘЗЕР ҺӘММӘСЕ ДӘ ҖИТЕШМЕ СОҢ?

Укучылар гафу итәрләр, музыка һәм сәнгать өлкәсендә үткәннәребезне һәм ирешкәннәребезне күзәтү характерында бер ноктага туплап күрсәтү нияте белән язылган бу мәкаләдә барлык композиторларыбызның һәм художникларыбызның әсәрләренә дә киң тукталу, аларга тәпле анализ ясау һич мөмкин түгел. Аларның иҗаты махсус өйрәнүгә һәм һәркайсысы мәкалә генә түгел, китаплар язуга лаек.

Бу өлкәдә әлегәчә киң гомумиләштерү максаты куеп язылган хезмәтләрнең булмавы сәнгатебезнең аерым жанрлары һәм төрләре буенча үсеш тенденцияләрен билгеләргә комачаулый, аның кайбер тармакларының акрын үсешенә яки бөтенләй «онытылып» кала баруына китерә.

Моңа сынлы сәнгатьнең бүгенге торышы ачык мисал була ала. Сүз дә юк, татар нәкыш сәнгате хәзер ныклы аякка басу, формалашып җитү чорын кичерә. Художникларыбыз карамагында бөтен дөньяга танылган рәссамнарның гаять бай мирасы бар. Ел саен диярлек иҗат күргәзмәләре оештырыла. Күп кенә рәссамнар, төрле күргәзмәләрдә катнашып, үзләренең әсәрләренә карата зур осталарның, белгечләрнең тәнкыйть сүзләрен һәм акыллы киңәшләрен ишетәләр. Димәк, уңай якларыбызны һәм

кимчелекләребезне күрергә, аларга анализ ясарга һәм, иң әһәмиятлесе, үсеш тенденцияләребезгә юнәлеш бирергә иксез-чиксез мөмкинлекләр бар.

Шулай да «юнәлеш бирү» дигәнебез хәзергә һич тә җитәрлек түгел. Яшьләрнең профессиональ осталыгын күтәрү өстендә Татарстан художниклар союзында эшнең йомшак куелуын әйтеп тә тормастан, кайбер жанрларның бүгенге художникларыбыз игътибарыннан бөтенләй төшеп кала баруын күрсәтеп үтәргә туры килә. Шундыйларның берсе — тарихи жанр. Әлегә кадәр чал тарихыбызны бүгенге бурычлар югарылыгыннан, бүгенге иҗат позициясеннән күрсәтү юнәлешендә бөтенләй омтылыш ясап каралганы юк. Һәр халык үзенең тарихын ярата, аңа зур хөрмәт белән карый. Үзенең тарихын белмәгән, аны яратмаган кешенең гомумән үз иленең ялкынлы патриоты булуына исәп тоту бик кыен. Ата-бабага, аларның хезмәтенә, үзләрен гасырлар буе изеп килгән сыйнфый дошманнарына каршы көрәшенә ихтирамыбыз, билгеле, сынлы сәнгать әсәрләре яки тарихи романнар аша чагылса (монысы инде язучыларыбызга кагыла), ата-бабаларыбыз хөрмәтенә нинди гүзәл һәйкәл булыр иде! Шунсыз «тарихыбызны яратабыз» дип әйтү буш сүз генә булып калачак.

Алда күренгәнчә, республикабызда сынлы сәнгать үсешенең билгеле бер тарихы бар. Шушы тарихны өйрәнгән тәкъдирдә аны тагын да киңәйтергә һәм тирәнәйтергә мөмкин булуын да онытмыйк. Кызганычка каршы, без бу юнәлештә дә бернәрсә дә эшләмибез икән әле. Рәсем ясыйбыз дип кулларына беренче каләм алучы Г. Гумеров, М. Галиев, Л. Мостафин кебек графикларыбызның кемлеген белмәү, уңае туры килгәндә аларның исемнәрен санап китү белән генә чикләнү, бу инде — йөзгә кызыллык китерә торган игътибарсызлыкның бер күренеше. Ә андый кешеләрнең XIX гасырда да, хәтта аннан элгәрәк тә булуы бик ихтимал.

XIX йөз урталарындагы татар халкының тормыш-көнкүрешен үзенең рәсемнәрендә күрсәткән Карл Гунның тик 1960 елда гына безгә мәгълүм булуы да әнә шул хакта сөйли. К. Гун рәсемнәренең билгеле булуына да инде 6 елдан артык вакыт узды. Танылган әдибебез Мирсәй Әмир шул вакытта ук эшлекле тәкъдимнәр әйткән иде. «Казан музее, художниклар союзы, Татарстан китап нәшрияты кебек оешмаларыбыз, — дип язды ул, — аның белән чынлабрак кызыксынсалар, Казанда Карл Гун рәсемнәренең күргәзмәсе оештырылса (аның төп нөсхәләренең күбесе Рига Дәүләт музеенда саклана) һәм, алар арасыннан аеруча әһәмиятлеләрен сайлап, альбом бастырып чыгарылса, республикабызның кырык еллыгына бик матур бүләк булыр иде». Күрәсез, гаҗәп конкрет тәкъдим, тик нәтиҗәсе генә булмаган. Халык, соң булса да уң булсын, ди. Татарстан республикасының 40 еллыгына бу күргәзмәне оештыра алмаганбыз икән, Совет дәүләтенең 50 еллыгына хәзерлек көннәрендә оештыру турында уйлыйсы иде.

Соңгы елларда милли архитектураның үсмәве һәркемгә билгеле. Мәгълүм ки, ул аерым кешеләрнең талантына яки тырышлыгына гына бәйләнмәгән. Архитекторның фикерен тормышка ашыру зур акча чыгымнары белән бәйле. Халыкның торакка ихтыяҗын тизрәк тәэмин итү теләге белән кертелгән типовой проектлар милли архитектураның үсүенә, билгеле, уңай шартлар тудырмый. Ләкин бу милли архитектура турында, милли орнамент турында бөтенләй онытырга дигән сүз түгел. Татар халкының милли архитектурасы, милли орнаменты гаҗәп бай. Ул ерактан, Болгар дәүләтеннән үк килә. Аның гүзәл үрнәкләре СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институтында тупланган. Шул мирасны гомумиләштерү һәм халыкка җиткерү өчен бик күп эшлисе бар. Беренчедән, милли архитектурага мөнәсәбәтне үзгәртергә кирәк. Бүгенгә кадәр азмы-күпме сакланып калган архитектура үрнәкләреннән берсе — мәчет биналарына без, ни өчендер, дини йолаларны үтәүче урын дип кенә карыйбыз. Аларның архитектурасына мөнәсәбәт тә моңа чаклы әнә шуннан чыгып билгеләнеп килендә. Шушы ук мәчет биналарын салган алтын куллы осталар, әгәр бүгенге шартларда яшәсәләр, берсеннән-берсе матуррак, берсеннән-берсе мәһабәтрәк таш пулатлар сала алмаслар идемени?

Аннары безнең яктагы мәчетләрнең биналары нигездә татар халкына гына хас. Ул безнең үз шартларыбызга яраклаштырылган, шул чордагы экономик мөмкинлекләрдән чыгып барлыкка килгән архитектура, тәгәлрәге, милли архитектураның бер чагылышы.

Тагын бер нәрсә бар. Шул ук мәчет биналарына (мәчетләргә түгел) Урта Азиядә, әйтик, Бохарада, Самаркандта тарихи истәлекләр итеп карала. Бездә дә милли архитектура үрнәге, тарихи истәлек итеп каралырлык мәчет биналары бар. Шулай да аларның Насыйри урамындагы Мәрҗани һәм Апанай мәчете дип йөртелгәннәреннән башкаларын саклауга бөтенләй игътибар ителми. Сабанчы урамындагы Әҗем мәчете бинасы, Әхтәмов һәм Тукташ урамнарындагы мәчетләрнең биналары, Әтнә ягындагы Кышкар авылындагы мәчет бинасы (ул 1768 елда, Мәрҗани мәчете белән бер чорда салынган. Хәзер манарасы юк) шул ук архитектура үрнәге буларак әһәмиятләрен югалтмаганнар. Болары — таш мәчетләр. Агач мәчетләр арасында да әлекке осталарның алтын куллы кешеләр булуларына сокланырлыклары шактый очрый.

Эш хәтта мәчет биналарында гына да түгел. Татарның XVIII гасыр урталарына кадәрге архитектура үрнәкләре бөтенләй сакланмаган. Хәзер аларны казылмалар вакытында табыла торган аерым детальләрдән, элеккеге язмалардан, кайбер рәсемнәрдән файдаланып кына торгызырга, элгәреге хәлләренә кайтарырга туры килә.

Борынгы истәлекләргә саксыз карау, тарихыбызны белмәү кайчакларда гаҗәеп күңелсезлекләргә китерә. Моннан ике-өч ел элек чит илдән килгән туристларга Каюм Насыйри урамындагы мәчет бинасын бер экскурсовод:

— Моны XVIII йөздә Мәрҗани исемле г а р ә п г а л и м е салдырган, — дип аңлаткач, бик нык кызарырга туры килгән иде. Бу бердәнбер факт түгел. Татарстанның башкаласына аның милли байлыкларын һәм ул байлыкларның милли үзенчәлекләрен күрү өмете белән килгән туристларга иярәп йөрсәң, тарихыбызны искиткеч начар белүебезгә һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, кунакларга бик күп нәрсәләрне ялгыш, ә кайбер очракларда тарихи фактларны бозып аңлатып җибәрүебезгә хәйран каласың. Менә ни өчен милли архитектура турында, милли декоратив орнамент турында, гомумән, электән килгән сынлы сәнгатебез һәм аның үзенчәлекләре турында безгә монографияләр бик кирәк. Андый хезмәтләр болай да шактый буталчык тарихыбызны, культурабыз тарихын бүгенге бурычлар күзлегеннән чыгып, марксизм-ленинизм идеяләре яктылыгында төшенергә һәм аңларга булышлык итәрләр иде.

Шушы ук теләкне Болгар дәүләтеннән безнең көннәргә кадәр килеп җиткән «Кара сарай», «Кече манара», кабер ташлары (соңгыларында борынгы язулар гына түгел, төрле орнаментлар да саклана), төрле эзләнүләр һәм археологик казулар вакытында табылган табылдыкларга карата да әйтергә кирәк.

Борынгы декоратив орнаментларны һәм архитектура элементларын хәзерге төзелештә, бигрәк тә җәмәгать биналарын бизәүдә куллану республика художниклары һәм архитекторлары игътибарыннан төшеп калуда дәвам итү белән дә килешеп булмый. Дәүләтебезнең архитектурадагы артыклыкларны бетерү турындагы күрсәтмәсен безнең иҗат хезмәткәрләребез артык берьяклы аңладылар һәм Казанның киләчәк йөзен билгеләүче үзәк урамнарга, күңелләргә рәхәтлек бирсәләр дә, күз карашын һич тә иркәләмәүче, берсе икенчесенә игезәкләрдәй охшаган, шифер түбәле тартма сыман соры йортлар бер-бер артлы төзелә генә торалар. Теләгәндә шул ук йортларны бернадәр матурларга, билгеле бер милли колорит бирергә мөмкин булмас идемени?

Казанда махсус сәнгать әйберләре фабрикасы, халыкның тормыш-көнкүрешен матурларга, аңа ямь бирергә чакырылган көнкүреш хезмәте күрсәтү идарәләре бар. Алар эшләп чыгара торган товарларга, бигрәк тә хатын-кыз киемнәренә татар милли орнаментын кертү кирәклеге турында уйларга да вакыт җитте бугай. Сәнгать белеме галимнәре, тәнкыйтьчеләр хәзерләү мәсьәләсе дә Татарстан художниклары Союзы идарәсенең игътибар үзәгенә куелырга тиеш.

Хәзер генә әйтелгән фикерләрнең күбесе җыр музыка сәнгатенә дә кагыла. Мәсәлән, җырларыбыз тарихын өйрәнү, борынгы музыка коралларына мөнәсәбәт турындагы мәсьәләләр дә игътибар үзәгеннән төшәргә тиеш түгел. Мәрхүм Габдулла Тукай безгә бу өлкәдә беренче үрнәкне күрсәткән. 1910 елда ук «Тәфтиләү», «Ашказар», «Сак-сок», «Касимский Ибрай», «Җизнәкәй», «Башмак» көйләренең килеп чыгу тарихын язып, халык җырларының шулай җәүһәр вә якутлардан да кыйммәтле бер нәрсә булганы өчен дә аларга әһәмият бирергә кирәк, аларны югалтмаска, иҗтиһат итәргә кирәк, дигән фикер әйткән. Бездә татар халык җырларын туплаган 35 кә якын җыентык булуы билгеле. Бу — беренче карәштә аз түгел. Басарга әзерләнгән хезмәтләр дә бар. Әмма Габдулла Тукайның кечкенә бер омтылышыннан соң, җыр-

ларыбызның һәм көйләребезнең килеп чыгу тарихын өйрәнү юнәлешендә бер нәрсә дә эшләнмәгән дисәк, һич ялгыш булмас. Бөек шагыйребез төртеп күрсәтеп калдырган васыятькә битараф калу килешмәстер.

Онытылып бара торган музыка коралларыбыз турында да бер-ике сүз әйтми ярамас. Иң элек кубыз. Кубыз турында сүз чыкканда без аны татарның иң борынгы милли музыка коралы дибез. Бәлкем менә иң борынгы булганга ул хәзер онытылып бара торгандыр да. Юк, борынгы булганы өчен генә дә түгел. Кубызны бик гади, тавышы бик нечкә, ерактан ишетелми диләр. Бу сүзләрдә хаклык бар. Кайчандыр, бездә музыка коралында уйнау язык булган заманнарда кубыз халык арасында чыннан да иң кулай корал булган. Кечкенә дә, тавышы да еракка ишетелми. Алай-болай мулла-мөнтагай килеп чыкса, кесәгә яшерергә дә, качып-посып уйнарга да уңай. Әмма ул әнә шулай бәләкәй булып туган, шулай бәләкәй булып калган да. Аны үстерү, камилләштерү юнәлешендә уйлап табылган көненнән башлап берәр нәрсә эшләндеме икән? Ай-һай, юктыр! Немецларның авыз гармунын беләсез инде сез. Алар, аккордеон, баян кебек музыка кораллары булса да, әнә шул авыз гармуныннан бүген дә аерылмыйлар. Беренче уйлап тапканда авыз гармуны да хәзерге хәлендә булмагандыр, безнең чорда да аны матурлаганнан-матурлый, камилләштергәннән-камилләштерә баралар. Теләгән вакытта кубызны шулай ук яхшыртырга да, матурларга да, тавышын көчәйтергә дә мөмкин булыр иде. Транзистрлар заманында моңа ышанмый мөмкин түгел. Моңа безнең кубызга вак нәрсә итеп, бик югартын кимсетеп каравыбыз комачаулый. Ә менә башка халыклар алай түгел. Мин Кавказ арты халыкларының җырга һәм биюгә бик хирес булуларына сокланам. Сугыш вакытында зур хезмәтләрдән, авыр юллардан соң да алар, аз гына буш ара калдымы, мәйдан оештырып, җырлап-биеп алырга яраталар иде. Аларның бердәнбер музыка коралы, әгәр шулай әйтергә яраса... солдат котелогы иде. Котелок төбенә бәрүдән чыккан тавышка биилэр дә, җырлыйлар да иде алар. Котелок белән чагыштырганда, кубыз алай ук бик начар шәй дә түгел.

Кубызны сәхнәдән бөтенләй куу белән һич тә килешергә ярамый. Иң шәп музыка коралы булып китүенә өмет итмәсәк тә, концертларда, радио һәм телевидение тапшыруларында кубызга урын бирү, үзешчән кыллы оркестр составына булса да кубызны да кертү аның бөтенләй үк онытылып китүен кисәтер, кем белә, тора-бара, охшап куйса, аның үзенең һәвәскәрләре, маһирлары да табылыр иде.

Курайның онытылып баруын нәрсә белән аңлатырга? Моңсысының, югыйсә, тавышы кубызныкы кебек алай көчсез дә түгел. Башка халыклардагы кебек, татарларда да курай зур юл узган. Сыбызгыдан бүгенге хәленә килгән. Ата-бабаларыбызның яшьлек елларында да әле курай тавышы яңгырый иде. Күп булса моңа 30—40 ел үткән. Ләкин без, аларның уллары һәм кызлары, кепшәдән курай ясауны гына түгел, хәтта ясалган курайда уйнауны да онытып барабыз. Ә киракме икән?!

Скрипка да халык арасында почеттан төшеп, сәхнә әһелләре коралына гына әйләнеп бара. Егерменче-утызынчы елларда скрипка бездә, тальян, Саратов гармуннары кебек үк, иң күп таралган музыка коралларының берсе иде. Әле дә хәтерлим, Шөгер якларында, безнең Шушма буе авылларында скрипканы тал агачын кисеп, киптереп, кайнатып осталар үзләре ясый иде. Шулай да, кулдан ясалган шушы скрипка белән дә, авыл егетләре матур-матур көйләр уйный, яшь җилкенчәкләр кушылып җырлый, дәртләнеп бии торганнар иде. Хәзер скрипка уйнаган һәвәскәрне авыл клубларында да бик сирәк очратасың.

Әнә шулай кубызны санламасак, онытсак, курай уйнауны ташласак, скрипкадан бизсәк, тальян һәм кыңгыраулы Саратов гармуннарын санга сукмасак, халык музыка коралларыннан нәрсәбез генә калыр соң безнең?! Болай бергә җыеп караганда бай гына төсле булсак та, игътибарсызлыгыбыз, элеккеге уңай традицияләребезне онытуыбыз аркасында ярлыланганнан-ярлылана барабыз түгелме соң?

Мондый эшләрдә аерым инициаторларның гына тырышлыгы җитми. Татарстан композиторлар союзы идарәсенең моңа оешкан төс бирүе, ниһаять, музыка сәнгатебезне баету юнәлешендә барыбызның да армый-талмый эзләнүе, иҗади эшләве кирәк.

...Тормыш алга бара, халыкның культурасы туктаусыз үсә. Культуралы кеше бүгенге көн белән генә канәгатьләнеп калмый, ул үзенең узганы белән дә, киләчәге

белән дә мавыга. Халкыбызның тарихы, уңай традицияләре белән соңгы елларда кызыксынуның көчәюе дә нәкъ шуның белән аңлатыла.

Шуны да онытмыйк, тарихыбызны өйрәнү, культурабызга бәйләнешле истәлекләрне җыю, бергә туплау өчен хәзер бик уңай вакыт. Чөнки хәзерге урта буын яшь буын белән өлкән буын арасындагы ике ярны тоташтыручы күпер кебегрәк бер чорда яши. Тагын берничә елдан халкыбыз кичергәннәрне ата-бабадан үз колаклары белән ишетеп яки үз күзләре белән күреп белгән бүгенге картларның бик теләгәндә дә ярдәм итә алмаулары, шушы җанлы чыганакның җәмгыятькә хезмәт итүдән туктавы мөмкин. Мондый игътибарсызлык өчен киләчәк буыннар безне һич тә гафу итмәс.

* * *

Бөек Октябрь социалистик революциясенең 50 еллыгын каршылауга хәзерлек уңае белән туган кайбер уй-фикерләр әнә шулар. Алар безнең халкыбызның үткәненә, аның тарихына, бүгенгесенә бәйле рәвештә тудылар. Ә тарих безне күп нәрсәгә, узганнарны күз алдына дөрес китерү аша бүгенге көннең бөеклеген билгеле, аңа бәя бирә белергә өйрәтә. Тарих, ниһаять, кайчандыр кычкырып җырлау гына түгел, рәсем ясау да язык булган, үзенең композиторлары һәм рәссамнары турында хыяллана гына алган татар халкының түбәннән күтәрелүе, якты коммунизм биеклекләренә ышанычлы адымнар белән атлавы турында сөйли.

Һәм безнең тагын бер нәрсәне онытырга хакыбыз юк, әгәр бүген без илебездәге барлык милләт халыклары белән тигез сафларда олуг юбилейга бертуганнардай барабыз икән, Советларның изге туфрагында яшәүче барлык халыклар алдында безнең дә горурланырлык үз композиторларыбыз, үз җырчыларыбыз, үз хор коллективларыбыз, үз рәссамнарыбыз, аларның танылган әсәрләре бар икән, алар барысы да безнеке, безнең уртак рухи байлыгыбыз икән, без моның белән Бөек Октябрьга, Совет дәүләтенә, Маркс-Ленин партиясенә бурычлы.

——□——

*Солтан Габәши*

# ТАТАР ҺӘМ БАШКОРТ КӨЙЛӘРЕ ТУРЫНДА

*Татар һәм башкорт халыкларының профессиональ музыка сәнгатен башлап җибәрүчеләрнең берсе Солтан Хәсәнгата улы Габәшинең тууына күптән түгел 75 ел тулды. Ул 1891 елда Казан өязенең Алат волосте Сулабаш авылында туган. 1901—07 елларда Казанда «Галия» мәдрәсәсендә укып, соңыннан Уфага күчеп китә.*

*1909—10 елларда ук С. Габәши Уфада татар әдәбияты кичәләрендә актив катнаша. Соңрак, үзенең «Кәккүк», «Оркыя», «Пикник» һ. б. әсәрләре белән, ул композитор булып та танылa.*

*Совет властеның беренче елларында Габәши катнашыннан башка бер генә татар концерты да үтмәгәндер, дисәк зур хата булмас. Ул беренче татар хорын оештыручы һәм аның дирижеры. Казан музыка училищесында татарлардан беренче музыка теориясе педагогы, С. Габәши беренче татар операларының («Сания», 1925; «Эшче», 1930) соавторы була.*

*Шул ук вакытта С. Габәши татар һәм башкорт халык музыкасын фәнни өйрәнүчеләрнең дә беренчесе һәм күренеклесе иде. Кызганычка каршы, аның күп кенә материаллары вакытында матбугатта басылып чыкмаган. С. Габәши архивында күп кенә документлар, татар музыкасына багышланган кулъязмалар бар. Арада «Татар музыкасы тарихы буенча конспект», «Татар һәм башкорт музыкасы турында», «Татар музыкасының тавыш нигезләре» исемле һәм башка мәкаләләрне күрсәтергә була.*

*Журналның бу санында укучыларга композиторның моңарчы матбугатта чыкмаган мәкаләсен тәкъдим итәбез. Билгеле, 20 елларда язылган бу мәкаләдәге кайбер фикерләр, бүгенге фән күзлегеннән чыгып карaганда, бераз искерә төшкәндер. Ләкин бу хезмәт зур иҗади тәҗрибәгә һәм бай фактик материалга таянып язылган. Мәкаләдә күрсәтелгән проблемаларның байтагы әле бүген дә актуальлеген югалтмаган.*

**М. НИГЪМӘТҖАНОВ,**
**музыка белгече.**

Татар музыкасы турында сөйли башласаң, башкорт музыкасы турында да сүз ачмый мөмкин түгел. Чөнки бу ике халыкның музыкасы бер-берсенә шулкадәр нык бәйләнгәннәр ки, кайда татар музыкасы бетеп, башкорт музыкасы башланганын, яки киресенчә, кайда башкорт музыкасы бетеп, татар музыкасы башланганын ачык кына итеп әйтү мөмкин түгел. Чөнки бу халыкларның музыкалары шулкадәр бер-берсе белән буталган һәм аралашкан ки, бу халыкларның берсендә туган көйләр икенчесе тарафыннан сөеп үтәлә, сөеп тыңлана гына түгел, хәтта ул аны үз көе итеп хисаплап һәм шуңа ышанып йөри. Үрнәк өчен мәшһүр Ашказар, Тәфтиләү, Сакмар, Зиләйлүк көйләрен алсак, ул көйләр кайсы гына татар авылларында җырланмыйлар да, Татарстанның кайсы гына почмакларында сөелеп тыңланмыйлар икән?!

Татарстанның иң түрендә (Башкортстаннан иң ерак торган почмагында) яшәүче һәм үз авылыннан башка бер генә дә ил күрмәгән һәм әлифне таяк дип белмәгән бер надан карчык алдына барып, ул көйләрне үтәргә-җырларга, я уйнарга тотынсаң, ул аннан тәэсирләнеп, моңланып еларга тотына. Чөнки ул көй аңа үзенеке булып тоела — ул аннан үзенең моң-зарларын ишетә, үткәннәрен, авыр көннәрен, хәлләрен исенә төшерә дә ихтыярсыз еларга тотына. Инде шул әбидән «Бу кайсы халык көе» дип сорап карагыз. Һичшиксез, ул «татар көе» дип җавап бирәчәк. Дөньяда тагын әле башкорт дигән бер халыкның барлыгы һәм бу көйләрнең шул халыкның көе булу ихтималы аның башына да кереп чыкмаячак.

Ул гына да түгел әле, шул ук көйләрне үтәп йөрүче йөзләп, меңләп уенчы, җырчыларның үзләренә шул ук сорауны бирсәң дә, белмим ничәсе генә «бу башкорт көе» дип җавап бирә белер икән? Хәлбуки, ул көйләр, исемнәреннән үк күренеп торганча, һичшиксез, башкорт җирендә чыккан саф башкорт көйләре[1].

---

[1] Авторның бу фикере шактый бәхәсле. Чөнки хәзерге Башкортстан территориясенең шактый өлешендә элек-электән татарлар яшәгән; шул ук «Тәфтиләү», «Зиләйлүк» көйләре үзләренең интонация-ритмик үзенчәлекләре белән турыдан-туры татар халык музыкасы стиленә керәләр. Аларда башкорт халык көйләренә хас төп элементлар (аларның берсе С. Габәши түбәндә әйткән «сикертелгән» интонацияләр) сизелми диярлек. Болай кисәтеп нәтиҗә ясау, күрәсең, аңа мәкаләнең төп идеясен күпертеп күрсәтер өчен кирәк булгандыр.

Менә бу хәл башкорт көйләренең татарлар тарафыннан бөтенләй үзләштерелүен күрсәтә, түбәндә сөйләячәк вакыйгам моның киресен, ягъни башкортларның да саф татар көйләрен шулай ук бөтенләй үзләштерүләрен күрсәтә:

1914 елның язында миңа Башкортстанның Златоуст өязе тирәсендәге берничә авылларында булырга туры килде. Шул вакытта мин, башкорт көйләрен бик яратканга күрә, кичләрен-төннәрен урамга чыгып утырып егетләрнең җырлаган-уйнаганнарын тыңлап карадым. Ләкин теге озын, бормалы башкорт көйләре урынына мин чеп-чи Казан көйләрен ишеттем. Әлбәттә, мин, аның белән канәгать итми, башкорт көйләрен эзләргә тотындым. Яшьләр белән таныштым. Җырчылар, уенчылары хакында сораштым. Ләкин эзләгәнемне таба алмадым. Мин әүвәл мәртәбә дә курайчы эзләгән идем. Ләкин «Бездә курайчылар юк», диделәр. Аларда бары гармоньчылар белән скрипкачылар һәм җырчылар гына бар икән. Шуннан соң инде мин бу үзләренчә атаклы уенчы-җырчылары белән күрештерүне сорагач, аулак өймедер шунда, нидер — үзләренең бер җыелышып җырлашып утыра торган йортларына алып киттеләр. Ләкин утырышларында хатын-кыз да, эчемлек тә юк иде. Уенчыларыннан мин башкорт көйләрен уйнауларын (бар да гармоньда уйныйлар) үтенгәч, уйнаган әйберләре бар да «Баламишкин», «Порховой Фатих», «Берсе алма, берсе хөрмә» кебек татар көйләре булгач, мин озынрак көйләр уйнауларын сорадым, алары да «Мәкәрҗә гаете», «Шакир солдат» төсле нәрсәләр булып чыкты. Ахырында: юк, сез башкорт көйләрен уйнагыз, диюемә каршы, «башкорт көйләре инде шулар» дип җавап бирделәр. Аптырагач мин, «Бурамбай», «Салават батыр» кебек башкортларның үзләре арасында да белүчеләр сирәк булган берничә көйнең исемнәрен атап, шуларны уйнауларын сорадым. «Аларны белгән кеше юк бездә»,— дип җавап бирделәр. Баксаң, күрсәң, әлеге иң мәшһүр «Ашказар», «Тәфтиләү»ләрне юньле-башлы белмиләр, имеш.

Менә бу хәл башкортларның татар көйләрен үзләштереп, аларны үз көйләре дип ышанып йөрү генә түгел, хәтта үз көйләрен онытып, алар урынына татар көйләре кулланганлыкларын бик ачык күрсәтсә кирәк.

Ләкин, әле татар-башкорт музыкаларының катышып бетүләре бу көйләрне аңлашу белән генә дә тәмам булмый, бәлки көйләрнең төзелеш җәһәтеннән дә бик чуалчык хәлгә килеп беткәннәр. Татар-башкорт көйләре арасында күп көйләр бар ки, аларның төзелеше җәһәтеннән карап кына түгел, хәтта исеменә һәм чыккан җиренә карап та татар көе дип тә, башкорт көе дип тә әйтер хәл булмый. Андый көйләргә мисал итеп «Оренбург бөтие» көен күрсәтергә мөмкин. Бу көйнең төзелешенә карасаң, татар көе булырга да мөмкин, башкорт көе булырга да мөмкин. Чөнки көй әлеге «Баламишкин»нәрчә вак-кыска көйләрдән булмыйча, озын сузып үтәлә торган көй. Шуның белән бергә тавышларның төзелү тәртибендә башкорт көйләре өчен үзлекле булган зур сикерешләр (киң диапазонлы интонацияләр — М. Н.) дә юк. Көй бер-беренә якын гына тора торган тавышлардан төзелеп, тыныч кына, сикертмәләрсез генә үтәлә.

Ул көйнең Оренбургта бик таралган мәшһүр көй булып, Оренбургта булган уенчы-җырчылар гына белгәнлеген игътибарга алганда һәм Оренбургта дөрестән дә Бөти исемле бер кешенең яшәгәнлегенә карагандa, аның чыккан урыны Оренбург булса кирәк. Оренбург исә үзе башкорт җире[1] булганы хәлдә, анда яшәүче татарлар да бик күп. Көйнең чыгаручысы бөтенләй билгеле түгел. Ул көйне Бөти дигән кеше үзе чыгарганмы, яки башка берәр кеше аны чыгарып Бөти исеменә багышлаганмы, якынрак ихтималы, әлбәттә, соңгысы. Шуңа күрә көйне чыгаручы башкорт булганмы яки татар булганмы, анысы да билгеле түгел (Бөтинең кем булучылыгы миңа мәгълүм булмаса да, ул үзе татар булгандыр дип уйлыйм).

Димәк, көйнең татар көеме яки башкорт көеме икәнен һичбер җәһәттән өзеп әйтү мөмкин түгел[2]. Чыккан урыны, чыгаручысы да мәгълүм булмаган һәм төзелеше белән дә татар көеме, башкорт көеме икәнен белеп булмаган көйләр тагын да күбрәк. Мондый көйләргә мисал өчен «Газизә балдыз» көен алырга мөмкин. Ул көй үзенең төзелеше белән татар көе булырга ошый. Бигрәк тә кушымтасы шуны күрсәтә. Ләкин шул ук кушымтадагы «Газизәкәй балдыз, кайгырма — калдырмам ялгыз» дигән сүз нәкъ башкортта мәшһүр булганга, тол калган хатын (җиңгә яки килен) мәрхүм иренең кардәшенә хатын булырга тиеш гадәтне бик хәтерләтеп тора. Менә шул рәвешчә бу музыка, бер-берсенә бик якын торган һәм бер-берсенә бик охшаган хәлдә, алар башка халыклар музыкасыннан бик нык аерылалар. Безгә чит булган европалылар вә башкаларның гына түгел, хәтта шул ук төрек-татар кабиләләренең күбесенең музыкасы бөтенләй башка булып, бөтенләй бер урын тоталар һәм аларга һич ошамыйлар. Мәсәлән: кыргыз-казакъ, үзбәк — аерым кыргыз-кавказ татарларының музыкалары белән чагыштырып караганда, алар белән татар-башкорт музыкасы арасында бөтенләй охшашы юк. Болар бөтенләй бер-беренә ят-чит музыкалар булып торалар...

Шул югарыда әйтелгән сәбәпләргә бинаән, татар музыкасын үзен генә, аерым гына алып карарга мөмкин булмаган шикелле үк, башкорт музыкасын да татар музыкасыннан аерып алып тикшерергә мөмкин түгел дип уйлыйм[3].

---

[1] Автор монда тарихи-этнографик башкорт территориясен күз алдында тотмый.

[2] Бу җөмләдә каршылык сизелә. Автор үзе өстә башкорт һәм татар көйләренең стиль аермаларының берсен күрсәтеп үткән иде. Дөрес, әле ул чорда бу халыкларның музыкасы бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән, конкретрак рәвештә фикер йөртү читен булган.

[3] XX йөзнең башында башкорт һәм татар халкының көйләрен еш кына «Татар-башкорт» көйләре дип йөрттәләр. Моңарга мисаллар итеп «Татарские и башкирские песни» (Лейпциг, 1901 ел), «8 татарско-башкирских песен» исемле 1923 елны чыккан җыентыкларны, Гайса Еникеев тарафыннан төзелгән «Татар һәм башкорт көйләре» исемендәге җыр җыентыкларын һ. б. күрсәтергә була. Бу табигый хәл, чөнки әле ул дәвердә безнең халыкларның музыкасы туплана һәм өйрәнелә башланган гына, халык музыкаль иҗатының күп жанрлары әле бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән булуын истә тотарга кирәк.

— — □ — —

*Ибраһим Нуруллин*

# КИҢ КАРАШЛЫ ГАЛИМ



Әдәбиятыбызның нигез ташларын салуда, аның кирпечләрен өеп мендерүдә зур өлеш керткән талантлы каләм осталары арасында Галимҗан Нигъмәтинең исеме дә мактаулы урын тота. Түбәннән күтәрелеп, күренекле тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме булып җитешкән бу талант иясе нибары унбиш елга сузылган иҗат гомерендә бай әдәби мирас калдырды. Аның китап булып чыккан дистәгә якын хезмәте һәм төрле газета-журналларда басылган йөздән артык мәкалә һәм рецензияләре бар. Болар арасында бик күбесе, бүген дә әле кыйммәтен югалтмаган булып, татар әдәбияты тарихын өйрәнүдә зур роль уйныйлар.

Галимҗан Нигъмәтинең тәнкыйть эшчәнлеге егерменче елларның беренче яртысында башланып китте. 1922 елда ул «Октябрь һәм әдәбият» исемле мәкаләсе белән чыга. Күзәтү характерында язылган бу беренче зур мәкаләсендә яшь тәнкыйтьче Октябрь давыллары вакытында баррикаданың ике ягында калып көрәш алып баручы ике әдәбият турында сүз йөртә, революциягә хезмәт итүче яшь совет әдәбиятының беренче адымнарына күзәтү ясый, аерым алганда Г. Ибраһимов иҗатына туктала.

1923 елда Г. Нигъмәти, Г. Тукайның үлүенә ун ел тулу уңае белән зур мәкалә язып, халык шагыйренең иҗат юлын марксистик күзлектән карап бәяләргә омтылыш ясый. Ләкин бу елларда әдәбият белемендә, тәнкыйтьтә пролеткультчылык тамыр җәйгән иде. Әдәби мирасны инкарь итү, язучының идея-политик позициясен билгеләгәндә аның социаль чыгышын төп үлчәү итеп алу, язучыга социологик ярлыкларябыштыру шул заманның характерлы күренешләреннән иде. Кайбер тәнкыйтьчеләр хәтта Тукайны да буржуа шагыйре итеп күрсәтергә тырыштылар. Г. Нигъмәти, Тукай иҗатын бәяләгәндә, әлбәттә, бу кадәргә үк барып җитмәде, ләкин шулай да аның мәкаләсендә пролеткультчылык йогынтысы үзен нык сиздерә иде.

Г. Нигъмәти гаять тырыш, хезмәт сөючән һәм үзенә таләпчән тәнкыйтьче иде. Ул күп өйрәнде, эзләнде, үз өстендә нык эшләде һәм нәтиҗәдә баштагы хаталарыннан бик тиз арына барды. Моңа Г. Нигъмәтинең тормыш эчендә кайнавы һәм, зур иҗтимагый эшчәнлегеннән тыш, марксизм-ленинизм тәгълиматын, әдәбият теориясен һәм гомумән эстетика фәнен җентекләп һәм тирәнтен өйрәнүе ярдәм итте. Марксизм-ленинизм методологиясен үзләштерүгә ул аеруча көч куйды. Бөек фикер ияләренең китапларын кат-кат уку белән генә чикләнмичә, ул үзе дә иҗтимагый фәннәргә караган күп кенә мәкаләләр һәм хезмәтләр язды. Аның төрле газета-жур-

галларда басылган мәкаләләренең тулы булмаган исемлеген китерү дә моңа ышаныр өчен җитсә кирәк: «Карл Маркс безгә нәрсәләр калдырды?» (1922), «Адәмнәр ничек яратылган?» (1924), «Ленин һәм пролетариат революциясе» (1924), «Февраль ничек әзерләнде?» (1928), «Партиянең уникенче съезды һәм милләтләр мәсьәләсе» (1928). Моңа тагын фәнни социализм нигезләрен популяр тестә аңлатып биргән «Коммунизм турында» (1924) исемле китабын һәм «Көнбатышта сыйнфый көрәшләр тарихы» (1928) дигән хезмәтне (авторларыннан берсе — Г. Нигъмәти) өстәргә кирәк. Бу юнәлештәге хезмәтләрә, һичшиксез, танкыйтьчегә, марксизм-ленинизм нигезләрен иҗади үзләштереп, әдәбият күренешләренә фәнни дөрес анализ ясар өчен ачкыч биргәннәр.

Г. Нигъмәти шулай ук рус һәм көнбатыш әдәбиятлары тарихын, төрле эстетик теорияләрне, бигрәк тә марксизм-ленинизм эстетикасын өйрәнүгә күп көч куйды. 1925 елда, мәсәлән, аның «Әдәбият мәйданында» исемле китабы чыга. Ул анда әдәбиятның асылы һәм бурычлары, реализм, романтизм, символизм, футуризм, имажинизм кебек иҗат методлары һәм юнәлешләренә киң аңлатма бирә. 1931 елда чыккан «Әдәбият һәм тормыш» исемле китабында исә әдәбият фәненең асылы, бурычлары һәм тикшерү методлары турында кызыклы фикерләр әйтә. 20 елларның беренче яртысында ук теория өлкәсендә әнә шулай актив эшләве Г. Нигъмәтинең әдәби-эстетик яктан үсүе, танкыйть хезмәтләрендә, эмпиризмнан арынып, теоретик тирәнлеккә һәм фәнни тотнаклылыкка ирешүе өчен гаять файдалы булды.

Егерменче елларның икенче яртысында Г. Нигъмәти вакытлы матбугат һәм нәшрият өлкәсендә җаваплы эшләр башкара. Әдәби-танкыйть эшчәнлегенең тагын да киңрәк колач белән җәелеп китүе дә шушы елларга карый. Биш ел эчендә генә дә (1927—32) ул дүрт китап, эреле-ваклы иллегә якын мәкалә яза. Аның бу хезмәтләрендә рус классикларыннан Н. Г. Чернышевский, Л. Н. Толстой, А. П. Чехов, А. М. Горький (берничә мәкалә), татар язучыларыннан М. Гафури, Г. Коләхметов, Дәрдмәнд, Г. Ибраһимов, Ш. Бабич, К. Нәҗми, һ. Такташ, Х. Туфан, А. Шамов, И. Гази һәм башкаларның иҗатлары тикшерелә.

Г. Нигъмәти аеруча Г. Ибраһимов иҗатын яратып өйрәнде. Бу аңлаешлы да: Г. Ибрагимов, революциягә кадәр үк татар прозасының зур вәкиле булудан тыш, һәм художник, һәм танкыйтьче, галим буларак, татар совет әдәбиятына нигез салучыларның иң күренеклесе иде. Г. Нигъмәти 1922 елда ук «Октябрь һәм әдәбият» исемле мәкаләсендә Г. Ибраһимовка зур урын биргән иде. Моннан соң да ул әдипне үтә сулланучы танкыйтьчеләрнең һөҗүменнән саклап килде. «Иске әдәби мирастан файдаланырга кирәкме?» (1928), «Матбугат һәм әдәбиятка юлбашчылыкта авыру яклар» (1928) кебек мәкаләләре әнә шуны күрсәтә.

1932 елда язылган «Г. Ибраһимов һәм аның әдәби иҗат юлы» исемле мәкалә аерым игътибарга лаек. Танкыйтьченең зәк карашын, эрудициясен, эстетик зәвыгын һәм нечкә сиземләвен күрсәткән бу мәкаләдә бүгенге көн өчен дә актуаль һәм гаять әһәмиятле күп кенә мәсьәләләр күтәрелгән. Алыйк Г. Ибраһимов иҗат методының үсеш мәсьәләсен.

Ул елларда иҗат методларын, аерым алганда реализм һәм романтизмны өйрәнүдә вульгар социологизм шаукымыннан арына алмау күзгә ташлана иде. Шуның бер күренеше — романтизмны реализмга каршы кую, романтизмда бернинди прогрессивлык күрмәү тенденциясе иде. Ә инде мондый концепциягә нигезләнү Г. Ибраһимовның катлаулы иҗат юлына бәя биргәндә ялгышуга китерергә мөмкин. Чөнки бу язучының революциягә кадәрге иҗаты реализм белән генә түгел, романтизм белән дә характерлы. Икенең берсе: яки аның романтизм стилендә язылган әсәрләрен бөтенләй читкә атарга, яки ул әсәрләрне реализм рамкасына кертергә тырышып көчәнергә кирәк. Г. Нигъмәти алдында исә мондый проблема тормаган. Ул Г. Ибраһимовның реализмы турында гына түгел, бәлки романтизмы турында да авыз тутырып сөйли: «Галимҗан Ибраһимовның бу ун ел эчендә (1907—17 елларда — И. Н.) чыккан әсәрләре, я азмы-күпме романтизм буявына сугарылып, яки бөтенләй шул юнәлештә («Яшь йөрәкләр») язылган. Һәрхалдә бу заман Галимҗан Ибраһимов әдәби стилендә романтизм элементлары характерлы урын тота» [1]. Шунысы әһәмиятле: бу мәсьәләдә

---

[1] Галимҗан Нигъмәти. Сайланма әсәрләр. Таткнигоиздат. 1958 ел. 74 бит.

ул, коры сүз белән генә чикләнмичә, «Яшь йөрәкләр»дәге романтизмның конкрет гәүдәләнешен ышандырырлык итеп күрсәтә алган.

Мәкаләнең «Безнең көннәр» романына [1] багышланган өлеше дә үзенең кыйммәтен бүгенге көнгә кадәр югалтмаган. Тәнкыйтьче «Безнең көннәр» романын «Яшь йөрәкләр» белән бәйләнештә тикшерә һәм бу әсәрләр мисалында язучының иҗат методы үсешен күзәтә. «Биредә («Безнең көннәр»дә — И. Н.) каһарманнар сыйныфтан тышта, нинди дә булса көчле бер хирес колы итеп бирелмәстән, бер сыйныф вәкиле, нинди дә булса бер сәяси, иҗтимагый идеягә хезмәт итүче итеп бирелә», — дип яза ул. Шул ук вакытта Г. Нигъмәти бу ике роман арасындагы эзлеклелекне дә күрсәтә: «... әсәрдә әле «Яшь йөрәкләр»дәгечә итеп бирелгән сурәтләр дә бар. Андыйларны без революция хәрәкәтеннән читтә торганрак каһарманнар арасында очратабыз» [2]. Моннан бүтән персонажлар исә «иҗтимагый тәрбиянең җимешләре, тормыш үзгәрү белән үзгәрүчеләр». Ә бит «Яшь йөрәкләр»дә, бу яктан карагайда, тәнкыйтьче бөтенләй башка нәрсәне күргән иде: анда персонажны яшәтүче «хирес», үзәк сыйфат тумыштан килә, иҗтимагый шартлар тәэсирендә бирелмичә, үзгәрешсез кала. Димәк, тәнкыйтьче фикеренчә, «Безнең көннәр»дәге күпчелек персонажлар җәмгыять продукты итеп күрсәтеләләр, аларда җәмгыятьнең теге яки бу закончалыклары гәүдәләнә, кыскасы, алар инде чын мәгънәсендә реалистик тип дәрәҗәсенә күтәрелгәннәр.

Г. Нигъмәти, «Безнең көннәр» романының реалистик характерын күрсәткәндә, язучының гомумиләштерү һәм индивидуальләштерү алымнарына да киң туктала. «Г. Ибраһимов,—диелә мәкаләдә,—бу әсәрдә нинди генә революционерны алмасын, ул аны кешедә табыла торган бөтен сыйфатлары белән гәүдәләндерергә тырыша» [3]. Шул ук вакытта ул Г. Ибраһимовның гомумиләштерү һәм индивидуальләштерүдәге кайбер кимчелекләрен дә күрсәтеп китә. Анычча, язучы, бер яктан, иҗтимагый күренешләрне урыны-урыны белән «җитәрлек гомумиләштерү, типлаштыру ясамыйча», «натуральлек дәрәҗәсендә төчлык (төгәллек — И. Н.) саклап» сурәтләсә, икенче яктан, вакыт-вакыт образны сыйнфый рамкалар белән чикләүдә артык мавыгып китә, ягъни шәхеснең социаль чыгышы һәр конкрет очракта да аның иҗтимагый эшчәнлеген билгеләмәскә мөмкин икәнлекне искә алып җиткерми. «Әдип әле кеше башка бер сыйнфый мөхит эченә кергәндә, — ди тәнкыйтьче,— шуның сәяси тәрбиясе астында аның карашы үзгәрә дә ала икәнен күрсәтеп җиткерә алмаган» [1]. Татар совет әдәбияты тарихын өйрәнүчеләргә Г. Нигъмәтинең бу фикерләрен искә төшерү зарар итмәс иде. Әдәбиятыбызның (безнең әдәбиятның гына да түгел) башлангыч елларында әнә шул тенденция, ягъни кеше образларын иҗат иткәндә «сыйнфый сыйфат»ны гына нигезгә алу тенденциясе үзен сиздерә иде әле. А. М. Горькийның утызынчы еллар башында да әле әнә шул схематизмга, ягъни «кешеләрне сыйнфый сыйфат» буенча гына характерлауга каршы чыгуы очраклы хәл түгел иде. «Тасвирлана торган һәр шәхеснең,— дип язды ул,— гомуми тышкы сыйфаттан тыш, аңа аеруча характерлы булган һәм ахыр чиктә аның **социаль эшчәнлеген билгели** торган (курсив безнеке — И. Н.) индивидуаль үзен табарга кирәк» [2].

Г. Нигъмәти, тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме буларак, әсәрнең теле, композициясе һәм сурәтләү чараларына да зур игътибар бирә иде. Композицияне ул, мәсәлән, нинди дер механик чара итеп кенә карамый. Композиция, аныңча, идея белән тыгыз бәйләнгән күренеш, ул гына да түгел, композиция — идеянең гәүдәләнеше. «Безнең көннәр» романының композициясендә ул пролетариатны үзәккә куеп тасвирлый алмаудан килеп чыга торган бер нәрсәне — «вакыйгаларның революцион үзәк тотканын тотып алып, күренешләр, хәрәкәтләрне бишенче ел революциясенә карата үстереп, бер җепкә ныклап бәйләү» җитмәгәнлекне ачып сала. «Тирән тамырлар» романының композициясен исә «мәркәзләү рәвешендә эшләнгән» дип бәяли һәм аны түбәндәгечә аңлата: романның сюжеты җинаятькә, җинаятьчеләрне эзләүгә, аларны хөкем итүгә бәйле. Язучы әсәрнең әнә шул үзенчәлегенә ярашлы композиция сайлаган. «Ул (Г. Ибраһимов — И. Н.) башта серле вакый-

---

[1] Романның 1920 елда чыккан беренче басмасы турында сүз бара.
[2] Г. Нигъмәти. Сайланма әсәрләр, 108 бит.
[3] Шунда ук. 112 бит.

[1] Г. Нигъмәти. Сайланма әсәрләр. 112 бит.
[2] А. М. Горький. Собрание сочинений. Рус телендә. 26 том. 415 бит.

ганы күрсәтеп, шуның сәбәбен әзләрлек сорау куйган (ягъни «Фәхрине кем үтергән?» — И. Н.). Вакыйга артыннан вакыйга, күренеш артыннан күренеш тезеп, шул сорауга җавап эзләтә барган»[1].

Язучының иҗат манерасын ачу һәм әдәбият фактларын теоретик планда анализлау ягыннан «Кави Нәҗми һәм хикәяләре» исемле мәкалә кызыклы. Тәнкыйтьче иң элек К. Нәҗминең шәхесе һәм эстетик принциплары турында сөйли, аннары, шуңа бәйләп, хикәяләренең үзенчәлеген, уңай һәм тискәре якларын ача. Революция һәм сугыш чынбарлыгын чагылдырган хикәяләрендә, ди ул, «күренешләр калейдоскоп төрлелеге белән тиз-тиз утәләр», һәм бу рәвешле сурәтләү «сугыш заманы, революция давылы картиналарын язуда урынлы да, матур да...» Ә инде шушы ук алым, тыныч тормыш күренешләрен тасвирлаганда, уңышсызлыкка китергән. «Башланды...» хикәясендә, мәсәлән, мещанлык торгынлыгы һәм аның кешене вакландыруы, үзенә суыруы турында сүз бара. Биредә инде «вермәле һәм бераз бизгәнле» тасвир һич тә ятышмый.

Тәнкыйтьче К. Нәҗминең кайбер соңгы хикәяләрендә пессимизм, ягъни «тормышта якты буяулардан бигрәк, караңгы, ямьсезләрен генә» күрсәтеп тә, шуның сәбәпләрен ачу җитәрлек булмаганлыгын әйтә. Тормышны ялтыратып, лаклап күрсәтүгә реакция рәвешендә, икенче чиккә ташланып, социалистик чынбарлыктагы авырлыкларга, аерым кимчелекләргә, тискәре якларга басым ясап язу очраклары әле бүген дә булып торуын искә алсак, Г. Нигъмәти әйткән бу фикерләрнең дә актуаль булганлыгын чамаларбыз.

Г. Нигъмәти, билгеле, бу елларда да әле вульгар социологизм йогынтысыннан тәмам азат түгел иде. Моны без тегә яки бу дәрәҗәдә М. Гафуриның «Эшче» поэмасында эшче сурәте», «Гафур Колахметов һәм аның иҗаты» кебек мәкаләләрендә дә, хәтта аз булса да, Г. Ибраһимов турындагы мәкаләләрдә дә очратабыз. Заманасына бәйле хаталарының асылын һәм сәбәпләрен аңлау өчен, Г. Нигъмәтинең «Туфан шигырьләре» һәм «Һади Такташ» исемле мәкаләләрен карап китик.

Туфан һәм Такташ. Ике зур шагыйрь, татар совет поэзиясендә ике зур фигура. Әмма Г. Нигъмәтинең Х. Туфанга багышланган мәкаләсе мактаудан, ә Такташ турындагы мәкаләсе шагыйрьнең хаталарын санаудан гына тора. Әш нәрсәдә? Эш шунда: тәнкыйтьче һәр ике мәкаләдә шагыйрьләрнең иҗатына башлыча социологик анализ ясый.

Туфан «әйбер эшләп чыгару» темасына яза, ди ул, пролетариатның эш-хәрәкәтләрен тасвирлый, аның шигырьләрендә металл, чүкеч тавышлары яңгырый, ә Такташ үзенең «ата казлар кыйнап үскән» бала чагын сагына, авылның «бозылмаган стихиясен» җырлый, аның әсәрләрендә «шахтада, завод-фабрикада, станок янында чыныгып үскән кешеләрне» күреп булмый. Әнә шул рәвешчә, Г. Нигъмәти «әйбер эшләп чыгару» темасына язуны төп критерий итеп ала һәм, шушы критерийдан чыгып, шагыйрьләргә бәя бирә. Әлбәттә, язучыларны эшчеләр сыйныфы тормышын сурәтләүгә чакыру, производство темасына яза торган каләмнәрне хуплап каршы алу кирәкле һәм файдалы иде. Ләкин эшчеләр тормышыннан алып язу-язмауны бердәнбер критерийга әйләндерү әдәбият һәм сәнгатьнең спецификасын инкарь итүгә, вульгар социологизмга этәрә иде. «Туфан шигырьләре» мәкаләсендә вульгарлаштыру артык сизелми, чөнки Х. Туфан, производство тематикасына язган шагыйрь булудан тыш, көчле талант та. Шуңа күрә тәнкыйтьче язучыны темасы өчен генә мактау кебек күңелсез эштән котылган.

Ә Такташта «әйбер эшләп чыгару», ягъни производство тематикасы юк дәрәҗәсендә. Өстәвенә ул поэзиягә бормалы юллар белән килгән гаять үзенчәлекле шагыйрь. Аның иҗаты тәнкыйтьченең теория кысаларына сыеп бетә алмый. Шуңа күрә Г. Нигъмәти шагыйрьнең шул кысаларга сыярдай әсәрләрен сайларга, яки, үзе дә сизмәстән, күп кенә шигырьләрен бозып аңлатырга мәҗбүр булган.

Партия Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать оешмаларын яңа баштан кору турында»гы 1932 елгы карары һәм совет язучыларының I Бөтенсоюз съезды Г. Нигъмәтинең әдәби-эстетик карашлары тирәнәюенә һәм киңәюенә этәргеч булды[1]. Бу чорда тәнкыйтьче татар совет әдәбиятының егерме елга якын вакыт эчендә тупланган тәҗрибәсен, социалистик реализмның бу әдәбиятта үсеш процессын тикшерү

[1] Г. Нигъмәти. Сайланма әсәрләр. 141 бит.

[1] Ул бу съездда делегат булып катнашкан иде.

эшенә кереша. «Татар совет әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре» (1933), «Социалистик реконструкция чорында совет татар матур әдәбияты» (1934), «Татар совет драматургиясенең үсеше» (1935) кебек күләмле мәкаләләреннән тыш, ул 1934 елда, күзәтү рәвешендә язылып, татар совет әдәбиятының барлык чорларын эченә алган «Татар совет әдәбияты күтәрелештә» исемле китабын чыгарды. Бу елларда аның Такташ иҗатына карашы да үзгәрде. «Һади Такташ» («Кызыл «Татарстан», 1936, 8/XII) исемле мәкаләсендә ул, мәсәлән, еллар Такташ поэзиясенең «яңадан-яңа якларын» ача баруын белдергәч, шагыйрьнең катлаулы иҗат эволюциясен бөтенләй яңача, әйтергә мөмкин, дөрес аңлатып бирә. Әгәр тәнкыйтьче элекке мәкаләсендә Такташның 1924—28 еллар иҗатында да әле индивидуализм һәм бунтарьлык белән характерлы хаталарны гына санаса, хәзер инде ул «шәхес интересы белән җәмгыять интереслары мөнәсәбәте мәсьәләсен... иҗтимагый интереслар өстенлеген яклау формасында» куючы шагыйрь турында сүз алып бара. Хәтта «Нәни шаярулар» циклында да ул «революциянең зур җиңүләргә алып барган көрәшенең ничек итеп тормышның вак, кечкенә күренешләрендә»[1] чагылышын күрә.

Бу еллар шулай ук Г. Нигъмәтинең драматургия һәм театр тәнкыйте өлкәсендә дә актив эшләве белән характерлы. Драматургия һәм театр турында ул докладлар белән чыга, театр сезоны йомгакларына карата мәкаләләр яза, аерым драматургларның иҗатын тикшерә. Артык сулланып китү очраклары булуга карамастан, аның бу хезмәтләре заман таләпләренә җавап бирерлек репертуар булдыруда, репертуарның идея тотнаклылыгын тәэмин итүдә әһәмиятле роль уйнадылар.

Г. Нигъмәтинең «Шәриф Камал — драматург» (1934) исемле мәкаләсе, атаклы язучының иҗатына йөгерек күзәтү рәвешендә генә язылган булса да, күп кенә кызыклы фикерләрне эченә ала. «Хаҗи әфәнде өйләнә» пьесасының комедиячел асылы, «Ут»тагы драматик ситуациянең мәгънәсе, «Козгыннар оясында» драмасында язучының иҗади үсеше матур ачылган. «Таулар» пьесасы уңае белән әйтелгән фикерләр дә игътибарга лаек.

Ш. Камалның «Таулар» пьесасы, аның башка драмалары белән чагыштырганда, йомшаграк язылган әсәр иде. Аның кимчелеген заманында кайбер тәнкыйтьчеләр «РАПП методын тулысынча дөрес куллана белмәүдә»[1] күрделәр. Г. Нигъмәти исә пьесаның йомшаклыгын нәкъ менә «РАПП методын» кулланырга тырышу белән аңлатты.

Г. Нигъмәтинең соңгы чор иҗатында зур урын тоткан хезмәте Тукай иҗатына багышланган монографиясе булды. «Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы» (1936) исемле бу хезмәт галимнең күпьеллык эзләнү һәм тикшеренүләренең җимеше иде.

30 елларның урталарына таба да әле «Тукай кем шагыйре?» дигән сорау көн тәртибеннән алынмаган була. Берәүләр, шагыйрьнең йомшак якларына күз йомып, аны пролетариат шагыйре дәрәҗәсенә күтәрергә азапланалар, икенчеләре, үтә сулланып, Тукайның мирасын инкарь итәләр, аның әсәрләрен тарихи әһәмияткә ия булган документлар итеп кенә күрсәтәләр. Г. Нигъмәти исә, В. И. Ленин өйрәтмәләренә таянып, Тукай иҗатына ачык күз белән карый алды. Менә нәрсә ди тәнкыйтьче: «Ул үзенең гаеп ачучылык, ачы көлү аша тәнкыйть итүчәнлек сыйфатлары ярдәменнән, ике катлы эксплуатация астында изелгән татар хезмәт ияләренең зур протестларын да иҗатында чагылдырды. Шул яклап ул үзен изелүчеләр ялчысы итеп куйды һәм болай куюы белән хаклы иде». Моннан инде Тукай иҗтимагый-политик карашлары белән революцион-демократ, ә иҗат методы белән критик реалист иде, дигән дөрес нәтиҗәгә дә ерак калмый.

Тәнкыйтьче, Тукай иҗатын шул заманның катлаулы иҗтимагый-политик һәм әдәби хәрәкәте эченә куеп, шагыйрьнең дөньяга карашындагы каршылыкларга да киң туктала. Хәзер инде ул, социологик концепцияләр белән генә чикләнмичә, әдәби иҗатның спецификасын күздә тотып, Тукайның көчле ягын аның художниклык таланты, эстетик сиземләве белән дә бәйләп карый башлый. «Тукай, — ди ул, — вакыты белән вакыйгаларга гаҗәп аек карап, тапкыр бәя бирә алды», күп кенә әсәрләрендә «...капитализм тормышы вакытындагы эксплуатация күренешләрен» гәүдәләндереп бирә белде. Ләкин шул ук вакытта шагыйрьнең «... алга — пролета-

[1] Шул ук китап. 188 бит.

[1] «Атака» журналы. 1931 ел. 11—12 саннар. 35 бит.

риатка таба тарткан агылы белән, артка — хосусый милекчелеккә, динчелеккә өстерәгән «предрассудкасы» бар, һәм шулар арасында Тукай өзгәләнеп яшәде». Шулай итеп, халык белән тыгыз бәйләнгән булу, көчле талант һәм художниклык күзе Тукайга үз заманының реалистик картиналарын тудырырга мөмкинлек бирсә, дөньяга карашындагы йомшак яклар аның шигъри авазында кайбер ялгыш ноталарның яңгырап китүенә сәбәп була. Г. Нигъмәтинең монографиясендә үткәрелгән төп фикер әнә шуңа кайтып кала, һәм моның белән килешми булмый.

Тагын шунысы әһәмиятле: Г. Нигъмәти Тукайның иҗат методындагы үзгәрешне дә күрсәтергә омтыла. Мәсәлән, ул шагыйрьнең башлангыч чор шигырьләренең художество үзенчәлекләренә мондый бәя биреп китә: «Жанрлары буенча боларны дидактик лирика әсәрләре дип атарга мөмкин булыр иде», — ди ул. Дөрес, тәнкыйтьче Тукайдагы «дидактик лирика»ның асылы, үзенчәлекләре һәм аны китереп чыгарган сәбәпләргә киң тукталмый, мәсьәләнә кую белән генә чикләнә. Ләкин бу һәм моңа охшаш фикерләр татар әдәбиятында критик реализмның үсеш этапларын өйрәнүдә әһәмиятле роль уйныйлар.

Ниһаять, Г. Нигъмәти үзенең монографик хезмәтендә Тукай әсәрләренең художество үзенчәлегенә, аның поэтик осталыгына да игътибар итә. «Тукай һәм художество фольклоры» дигән бүлекчәдә ул, мәсәлән, Тукай поэзиясенең эчтәлек һәм форма ягыннан халыкчанлаша бару процессын ышандырырлык мисалларда күрсәтеп бирә алган.

Тукай шигырьләренең төзелешенә ул шулай ук зур бер бүлек багышлый. Тукайда үлчәү һәм ритмика мәсьәләсе гаять кыен һәм катлаулы мәсьәлә. Эш шунда: халык шагыйре иҗатының башлангыч чорында гарәп гарузы бәхерләренә һәм халыкта популяр булган дини-әхлакый әсәрләрнең үлчәүләренә яраштырып язды. Моннан соң да аның иҗатында үзенә кадәрге поэзиядә булмаган шигырь формалары сирәк очрый. Ләкин Тукай, татар поэзиясендә яңа дәверне башлап җибәрүче буларак, яңа чор, яңа эчтәлек таләбе белән борынгы шигырь кануннарын эчтән җимерә, элекке шигырь формаларын яңача яңгырата иде. Тукай поэзиясенең әнә шул ягы соңгы елларда гына чынлап торып өйрәнелә башлады. Г. Нигъмәти исә моннан 20 ел элек үк инде шул юнәлештә уңышлы омтылыш ясаган иде. Ул Тукайның халык иҗаты һәм рус поэзиясенә нигезләнеп язылган яңа форма, яңа үлчәүләрен күздән кичергәч, элекке поэтик формалар кысасында язылган шигырьләрен җентекле башлый. Биредә ул ябык һәм ачык иҗекләрнең чиратлашуына, пауза һәм цезураларга, рифма һәм рифмалаштыру тәртибенә һ. б. моментларга туктала. Шушы килеш, тәнкыйтьче әнә шул поэтик чаралар ярдәмендә бер үк үлчәүдәге шигырьләрнең төрлечә яңгырашын, бик борынгы шигъри формаларның яңача тәэсир итеп, яңа эчтәлекне тулы җиткерүен ышандырырлык итеп күрсәтә алган.

Г. Нигъмәтинең бу зур мәкаләсендә, билгеле, заманасының чире булган кайбер тегәлсезлекләр һәм ялгыш фикерләр дә юк түгел. «Буржуа тәнкыйтьчесе», «вак буржуа язучысы» кебек атамаларны бик юмарт куллану, иҗат техникасын турыдан-туры экономикага бәйләп караучы теоретиклар йогынтысына бирелеп китү кебек очраклар әнә шуны күрсәтә. Моңа тагын Тукай поэзиясенең чыганаклары турында сөйләгәндә, көнчыгыш классик һәм борынгы татар поэзиясе традицияләренә җитәрлек игътибар итмәвен дә өстәргә кирәк. Шулай булса да, Бөек Ватан сугышына кадәр Тукай иҗатына багышлап язылган хезмәтләр арасында Г. Нигъмәтинең монографиясе иң күренекле урын тота.

Г. Нигъмәтинең иҗат юлын күздән кичергәннән соң, йомгак итеп түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин:

Г. Нигъмәти киң карашлы, эрудицияле, принципиаль тәнкыйтьче һәм галим иде.

Г. Нигъмәти беркайчан да әдәбият фактларын механик теркәп бармый, аларның асылына үтеп керә, теоретик яктан нигезле иде. Ул, язучының иҗатына бәя биргәндә, иҗтимагый шартларны күздән кичерә, әдәбиятның, шул исәптән рус һәм дөнья әдәбиятының бөтен тәҗрибәсенә таяна иде.

Г. Нигъмәти әсәргә социологик анализ ясау белән генә калмый, аның тукымасын, барлык элементларын да тикшерә, язучының язу рәвешен һәм иҗат үзенчәлеген дә ачарга омтыла иде.

Ниһаять, тагын бер сыйфаты: Г. Нигъмәти, үз заманының әдәбияты эчендә кайнап, оператив эшли иде. Бер-бер артлы туып торган әсәрләрне ул эзлекле күзәтеп

**бара, әдәби процесска караган гомумиләштерүләр ясый, үсеш перспективасын күрсәтә иде. Бу турыда басым ясап әйтәсе килә. Чөнки бүгенге тәнкыйтьчеләребезгә нәкъ менә шушы сыйфат җитеп бетми.**

**Бүген, атаклы тәнкыйтьченең тууына 70 ел тулган көнне, ачынып әйтергә мәҗбүрбез: иҗат көченең чәчәк аткан бер вакытында Г. Нигъмәти шәхес культы корбаны булды. Тик шунысы гына юата: аның нибарысы унбиш ел чамасы дәвам иткән иҗат эшчәнлеге татар совет әдәбиятының үсешенә уңай йогынты ясаганы кебек, бүгенге әдәбиятның үсеш процессы тудырган күп кенә проблемаларны хәл итүдә дә ул калдырган мирас файдалы эш башкара. Бу мирас шулай ук татар әдәбияты тәнкыйте тарихын өйрәнүдә, яшь әдәбиятчы кадрларны үстерүдә дә зур роль уйный.**

# ТӘНКЫЙТЬЧЕ, ПЕДАГОГ ҺӘМ ФӘН ЭШЛЕКЛЕСЕ

Галимҗан Нигъмәти 20—30 еллар татар совет әдәбияты үсешенә зур өлеш керткән күренекле галимнәрнең берсе иде. Шул елларда әдәбият мәйданына аяк баскан кайсы гына шагыйрьне, язучыны алма, аларның һәрберсе Нигъмәтинең игътибарын, конкрет ярдәмен күреп үсте, дияргә була. Ул талантлы яшьләрне үстерүгә, алар иҗатындагы уңышларны һәм җитешсезлекләрне вакытында күрсәтеп барырга, яшь талантларга һәрвакыт ярдәм итәргә тырыша иде. Ул елларда, мәсәлән, Туфанны формализмда гаепләүчеләр булды. Нигъмәти исә Туфан иҗатының уңай, көчле якларын күрә алды һәм аны хаксыз гаепләрдән саклап калды.

Мин Нигъмәтине 24 еллардан, ул Мәскәүдә Коммунистлар университетының тулай торагында яшәгән чактан, ук беләм. Ул күче яшьтән китап яраткан. «Галия»дә укыган елларда Тургенев томнарын алырга бик кызыкканын, һәр көнне китап магазины алдында озак вакыт шул томнарны карап торуын, соңыннан, акча җыеп, аларны сатып алгач, ничек шатланганын сөйли торган иде. Нигъмәти кайда очратса да китап сатып алды. Аның библиотекасында, мәсәлән, Шекспирның 1914 елда басылган томнары саклана иде. Соңыннан ул бөек язучының совет чорында чыккан томнарын сатып алды. һәм ике басманы чагыштырып, тикшереп утырганын әле бүген дә хәтерлим.

Студент буларак та, аспирант буларак та, миңа Г. Нигъмәтинең бик күп лекция һәм беседаларын тыңларга туры килде. Ул тапкыр сүзле, аңлаешлы итеп сөйли белә торган, оста педагог иде. Лекцияләрен ул рус һәм чит ил язучыларыннан алынган мисаллар белән баета, шул сәбәпле, аларны тыңлау мавыктыргыч та, кызыклы да була.

1932 елда, аспирантурада укыганда, мин аның ассистенты идем. Шуңа күрә җитәкчемнең бер генә лекциясен дә калдырмадым. Берничә елдан миңа ул кайбер курсларда лекцияләр укуны тапшырды, бу эштә зур ярдәм күрсәтте. Лекция планнарын тикшерә һәм, дәресемә кереп, конкрет күрсәтмәләр бирә иде.

Нигъмәти татар әдәбияты буенча аспирантлар әзерләүче беренче профессор иде. Үзенә тапшырылган аспирантларның ничек үсүләрен ул җентекләп тикшереп торды. Әйтик, аспирант Искужинга беренче курсларда әдәбият теориясен укытуны тапшырды, аңа зур өметләр баглый иде. Ләкин көтелмәгәндә, очраклы бер авырудан, Искужин вакытсыз үлде. Аның аспирантларыннан Мамин Һади Такташ иҗаты буенча беренче мәртәбә монография язып чыкты, Байков Шакир Мөхәммәтов иҗаты турында диссертация әзерләде, ләкин диссертациясен якларга өлгермәде. Ватан сугышында Мамин да, Байков та һәлак булдылар.

Нигъмәти үз шәкертләренең иҗтимагый эшләрдә катнашуларын, халык алдында чыгыш ясауларын, газета-журналларга язышуларын таләп итә иде. 1933 елда Татарстан Мәгариф министрлыгы урта мәктәпләр өчен дәреслекләр әзерләүдә пединститут укытучыларының катнашуын сорады. Мин III класс өчен, Нигъмәти V класс өчен дәреслек әзерләдек. Дәреслекләр басылгач, Нигъмәти үз дәреслеген миңа бүләк итте. Анда: «Маһинурга, дәреслек язучылыкның хатирәсе итеп Г. Нигъмәти. 2 ноябрь, 1933 ел», дип язылган иде. Ул дәреслек хәзер дә миндә саклана.

1937 елның кыш һәм җәен Нигъмәти урта мәктәпләр өчен әдәбият теориясеннән зур бер китап язуга багышлады. Кайбер бүлекләрен бергә укып тикшергән дә идек. Ләкин 1937 елгы бәхетсезлек ул дәреслекнең мәйданга чыгуына комачаулык итте. Дәреслекнең кайда, ничек югалуы билгесез.

Ул заманнар артта калды. Нигъмәти мәктәбе, аның акыллы киңәшләре миңа укыту практикамда зур ярдәм итте. Һәм мин институтта укыту дәрәҗәсенә күтәрелергә юл ачкан күренекле укытучымны һәрвакыт зур хөрмәт белән искә алам.

**М. ФӘЙЗУЛЛИНА,**
**доцент.**

# БЕЗНЕҢ САФТА

Мин Галимҗан ага Нигъмәтине 1930—1936 еллардан бирле беләм. Миңа башта өч ел Казан дәүләт педагогия институтының тел-әдәбият факультетында укырга, соңыннан шул ук институт каршындагы аспирантурада белем алырга туры килде. Студентлар һәм аспирантлар Г. Нигъмәтинең лекция һәм практик эшләрен ашкынып көтеп алалар, укытучы буларак, аны бик ихтирам итәләр иде. Аның тел һәм әдәбият өлкәсендәге тирән теоретик мәсьәләләрне гади итеп аңлатып бирүенә без сокланып карый идек. Ул бездән фәнгә, фәннең үзебез сайлаган өлкәсенә бик җитди карауны, көч һәм энергияне кызганмыйча, фән өстендә эшләүне таләп итте: Г. Нигъмәти үзенә һәм укучыларына карата бик таләпчән галим-педагог иде.

Әдәбият белгече буларак, фән өлкәсендәге көндәлек эше белән ул безгә үрнәк булып торды. Без-аспирантлар белән әңгәмәләшкәндә ул һәр көнне бик күп китап укып баруы турында сөйли иде. Чыннан да, Г. Нигъмәти Маркс, Энгельс, Ленин әсәрләрен, борынгы грек әдәбиятын, русның бөек фикер ияләре Белинский, Чернышевский, Добролюбов, Герцен әсәрләрен тирәнтен белә иде. Шулкадәресен дә әйтергә кирәк, әдәбият дәресләрендә татар язучыларын аерым, изоляцияләнгән хәлдә тикшерү Нигъмәти өчен ят нәрсә иде. Мәсәлән, ул Ш. Камалны рус классикларыннан Чеховка яки көнбатыш Европа әдәбияты вәкиле Мопассанга охшату, Г. Тукай иҗатын Гейне белән янәшә куеп карау кебек алымнарны киң куллана иде. Нигъмәтинең мондый алымнарын формаль мавыгу дип кенә карарга ярамый, әлбәттә.

Укытучымның тагын бер характерлы сыйфаты: ул пролетариат идеологиясе булган марксизм-ленинизм тәгълиматын үсеш хәлендә аңлады, студентларга һәм аспирантларга да аны шулай аңларга кирәклекне белдерде. Фикер аңлашыла төшсен өчен, бер факт китерәм. 1933 елның көзендә институт каршында татар әдәбияты буенча аспирантлар группасы оешты. Я. Агишев, А. Кудашев, Х. Ярми, Җ. Локманов, М. Мамин иптәшләрдән торган бу группада мин дә бар идем. Укулар башланды, аспирантлар үзләренә тапшырылган темалар өстендә эшләргә керештеләр. Миңа «Г. Тукай иҗаты» дигән тема буенча реферат язарга туры килде. Тема өстендә бер айдан артык эшләгәннән соң, аспирантларның практик дәресләрендә әлеге рефератымны укыдым. Җитәкчебез Г. Нигъмәти, минем эшкә йомгак ясап, болай диде: «Исхаковның докладын бик игътибар белән тыңладым, ләкин аның докладны, үзенең эчтәлеге буенча, ошамады һәм мине канәгатьләндермәде».

Ул минем рефератымда күп проблемалар куелуын, ләкин аларның тирән яктыртылмаганлыгын, Тукай иҗатында очраган каршылыкларның сәбәпләре тулы чишелмәвен, шулай ук беренче рус революциясе чорындагы вакыйгаларның шагыйрь иҗатына булган тәэсирләре тулы чагылдырылмавын һәм рефератның башка җитешсезлекләрен күрсәтеп үтте... Шуннан соң Г. Нигъмәти безгә аерым язучыларның тормыш һәм иҗат юлларына багышланган доклад һәм рефератларның нинди таләпләргә җавап бирергә тиешлекләре турында методологик күрсәтмәләр бирде.

Г. Нигъмәти татар әдәбияты тарихы һәм әдәбият теориясен марксизм ноктасыннан чыгып тирән аңлаучы һәм киң катлау укучыларга аңлатып бирүчеләрнең беренче сафында торган коммунист галим иде. Аның әсәрләре әле дә үзләренең актуальлекләрен югалтмаганнар. Шунлыктан, аның тормыш һәм иҗат юлын киңрәк, тирәнрәк өйрәнү татар әдәбияты тарихы өлкәсендә эшләүче иптәшләрнең мөһим бурычы булып тора.

**Мөнзир ИСХАКОВ,**
**пенсионер.**

*Нияз Хәкимуллин*

# ФОТООБЪЕКТИВТА—НЕПАЛ

Непал!

Бу сүзнең кечерәк кенә бер дәүләт исеме икәнлеге журнал укучыларына мәгълүм, әлбәттә. Әмма аның нинди дәүләт икәнлеген, ул дәүләтнең халкы нәрсә белән шөгыльләнүен, аның тормышын, көнкүрешен, гореф-гадәтләрен яхшы белүчеләр, ихтимал, бик аздыр. Һәм бу гаҗәп тә түгел. Хикмәт шунда, Непал үзе бик борынгы дәүләт булса да, дөнья әдәбиятында аның хакында бик аз язылган. Икенче бөтендөнья сугышына кадәр европалылардан берәү дә ул илгә аяк басмаган. Башка дәүләтләрдән тулысынча изоляцияләнеп яшәгән бу ил турында күп кенә легендалар туган. Ул легендаларда Непал «җиде йозак белән бикләнгән ил», «дәрвишләр дәүләте», «аллалар иле» дип атала.

Непалның шулай, башка илләр белән аралашмыйча, күп заманнар буена табышмак булып яшәвенә, бердән, аның менеп булмаслык Һималай таулары арасындагы джунглида урнашуы сәбәп булса, икенчедән, һәм барыннан да бигрәк, бу илдә чит халыкларны кертүгә каршы гамәлдә йөргән закон киртә булган.

Ләкин соңгы елларда европалылар өчен Непал ишекләре шактый киң ачылды һәм хәзер анда ел саен бик күп туристлар булып кайта.

Күптән түгел генә, совет туристлары составында, миңа да Непалда булып, андагы халыкның эше, тормышы, көнкүреше, культурасы белән якыннан танышып кайтырга туры килде.

Непал — таулы ил. Ул Һималай тауларында, ике бик зур дәүләт — Кытай белән Һиндстан арасында урнашкан. Шунлыктан картадан караганда бик кечкенә булып тоела ул. Әмма чынлыкта Непал алай бик бәләкәй ил түгел, җире Татарстанныкыннан ике мәртәбә артыграк аның. Халкы бик тыгыз утырган. Бер квадрат километрга уртача 70, ә кайбер үзәнлекләрдә 700 кеше туры килә. Хәзер аның халкы 10 миллион чамасы.

Непал — җылы климатлы ил. Иң салкын саналган январь аенда да уртача температура 15° җылы була. Муссон җилләре алып килгән еллык явым-төшем 3 метрга җитә. Җылылык, кояш һәм мул дым лианалар белән уралып беткән, үтеп булмаслык джунглидагы үсемлекләрнең котырып үсүенә сәбәп булып тора.

Непал формаль яктан беркайчан да нинди дә булса капиталистик илнең колониясе булып тормаган, әмма соңгы йөз елдан артык вакыт эчендә Англия контрольлегә астында яшәгән. Анда Ран дигән феодаллар семьясы хакимлек иткән. Раннар барлыгы сигез агай-эне булып, шуларның берсе Непалда премьер министр, икенчесе чит ил эшләре министры вазифасын башкарган, калганнары да җаваплы постлар биләп торган. Бу мөһим дәүләт постлары аларның туганнарына мирас булып күчә килгән. Непалдагы эшкәртелә торган барлык җирнең 80 проценты шул семья кулында булган.

1924 елга тикле Непалда официаль рәвештә коллык яшәп килгән. Анда тимер юллар төзелә башлауга, почта ачылуга һәм газета-журналлар чыга башлауга да берничә генә ел әле.

Икенче бөтендөнья сугышыннан соң, көньяк һәм көньяк-көнчыгыш Азия халыклары актив рәвештә милли азатлык көрәше башлап җибәрделәр. Непал да ул көрәштән читтә калмады. Илнең прогрессив көчләре белән берлектә, Непал халкы 1951 елның 18 февралендә Раннар семьясы хакимлеген җимереп ташлады. Ул көн непаллыларның милли азатлык бәйрәме булып исәпләнә һәм ел саен бик зурлап, тантаналы шартларда билгеләнеп үтелә.

Күп гасырлар буена дәвам иткән феодаль изелү Непал халкының культура ягыннан артта калуына китергән. Әле хәзерге көндә дә непаллыларның бары тик 7 проценты гына укый-яза белә. Алары да фәнни түгел, дини белем генә алган кешеләр. Халкы ун миллион булган Непалда нибары 200 врач бар. Шуның нәтиҗәсендә, илдә төрле авырулар киң таралган, үлүчеләр бик күп. Непал халкының уртача гомере 32—35 елдан артмый.

Дәүләт башлыгы — король. Бөтен власть аның кулында. Барлык политик партияләр таратылган. Бары король каршында «бурычлылык һәм җаваплылык» уятырга тиеш булган «Яшьләр оешмасы» гына яшәп килә.

Непал — артта калган аграр ил. Илдәге халыкның 97 проценты авыл хуҗалыгы өлкәсендә эшли: дөге, шикәр камышы, джут, мамык үстерә. Әмма, шулай булуга да карамастан, Непал үзен-үзе азык-төлек белән тәэмин итә алмый. Чөнки техника юк, һәркайда кул көче белән эшлиләр, шунлыктан уңыш бик аз була. Халыкның фәкыйрьлеге ягыннан Непал дөньяда беренче урыннарның берсен алып тора. Халыкның төп өлеше күп дигәндә көненә бер тапкыр ашау белән канәгатьләнергә мәҗбүр. Феодаль мөнәсәбәтләр әле хәзер дә яши: эшкәртелә торган җирләрнең 80 проценты феодаллар, алпавытлар кулында.

Илдә промышленность һәм транспорт әле яңа туып кына килә. Бу эштә Советлар Союзы Непалга шактый зур ярдәм күрсәтә. Шикәр заводы, сигарет фабрикасы, госпиталь, гидроэлектростанция төзүдә Непалга безнең ил ярдәм итте. Төзелеп ята торган авыл хуҗалыгы кораллары заводына да безнең ил булышлык күрсәтә.

Непалның төп аралашу юлы — тау сукмаклары. Транспортның төп төре — профессиональ носильщиклар һәм өсләренә йөк куеп ташырга яраклы хайваннар. Хәзер Непалда «Көнчыгыш — Көнбатыш» исемле автострада төзелә. Меңнән артык километрга сузылачак ул юлның бер өлешен безнең ил белгечләре төзи. Непаллылар ул юлны «Бәхет юлы» дип йөртәләр. Менә шул якын киләчәктә тормышка ашачак прогрессив үзгәрешләр Непалның экономик яктан үсүенә, әлбәттә, уңай йогынты ясар һәм аның халкына гасырлар буена килгән артталыктан, фәкыйрьлектән котылырга ярдәм итәр дип уйларга кирәк.


...Самолетыбыз Һималай таулары өстеннән оча. Алда ап-ак кар сөнгеләре — Һималай тауларының болытлардан ашып торган түбәләре. Без һаман аларга якыная барабыз. Ә аста, тау итәкләрендә, шырпы тартмасы кебек кенә булып, йортлар күренеп кала. Болынлыкларда утлап йөрүче сарык көтүләре чагылып үтә. Аннары тау аралыкларындагы иңкүлекләргә урнашкан авыллар, шәһәрләр очрый башлый. Бу — Непал җире. Тау һавасы шундый чиста, шундый саф — бөтен җир ап-ачык булып күренә. Без сигез мең метр биеклегендәге гигантлар өстеннән түгел, бәлки өй түбәләре өстеннән генә очабыз төсле тоела...


Менә самолетыбыз кискен генә сулга борыла да, аэродром өстеннән бер тапкыр әйләнеш ясап, җиргә куна. Бу — Непал башкаласы Катманду аэродромы.

Аннары без шәһәр белән таныша башлыйбыз. Иң элек күзгә ташланган нәрсә шул — велосипедлар бик күп. Ике көпчәклеләре дә, өч көпчәклеләре, ягъни велорикшалар да мыж килеп тора. Автомашиналар сирәк очрый, алары да Америка яки Англия машиналары.

Башкала йортларының күбесе таштан салынган, ике-өч катлы. Тәрәзәләрендә пыяла юк, агач рәшәткәләр генә куелган. Урамнарда җиздән, агачтан һәм бакырдан ясалган төрле зурлыктагы дракон, хатын-кыз һәм ир алла сурәтләренең исәбе-хисабы юк. Аннары храмнар бик күп. Будда храмнары. Алар шәһәргә шундый үзенчәлекле фон биреп торалар, әйтерсең, Катмандуда торак йортларга караганда храмнар күбрәк.







Храмнарның күбесе агачтан салынган. Сирәк-мирәк кызыл кирпечтән төзелгәннәре дә очрый. Барысының да стеналарына гаҗәеп оста эшләнгән бизәкләр, төрле хайван сурәтләре төшерелгән. Күп кенә храмнарның түбәсе алтын белән йөгертелгән.

Непалдагы иң зур, иң борынгы храм — Сваяму-Натх храмы. Будда диненең үзәге булган ул храм Катмандудан биш километрдагы тау башына салынган. Шунлыктан аның алтын гөмбәзе бик ерактан күренеп тора. Безнең эрага кадәр үк салынган ул храм хәзер дә бик мәһабәт әле. Гөмбәзе өстенә дүрт кырлы манара куелган һәм шул кырларның һәркайсына икешәр күз сурәте ясалган. Имеш, барысын да күреп-белеп торучы Будда күзләре ул.

Храм тирәсендәге тау буйларында һәрвакыт дини халык күп була. Төркем-төркем бүленеп, үзләренә изге ашамлык әзерли алар. Шуның өчен биргә махсус килгәннәр. Һәр төркем янында дистәләрчә маймыл, алар үзләренә кучтәнәч биргәнне көтеп утыра. Ә дини халык алардан бернәрсәсен дә кызганмый, чөнки, будда дине буенча, маймыл — изге җан, алла. Күрәсең, маймыллар үзләре дә бу хәлне аңлыйлар булса кирәк — бик иркен кыланалар, бер дә алай әдәп саклап тормыйлар.



Без тау башында. Зур храмга карап торабыз. Әнә аның стенасы буенда, түгәрәк ясап, аллага ышанучы бер төркем кеше утыра. Уртада — йөзен төрле буяулар белән чуарлап буяп бетергән рухани. Аның алдында дөге, савыт белән су һәм тагын нindидер үләннәр куелган. Ач, ялангач һәм күбесе авыру ул кешеләр гыйбадәт җырлары җырлыйлар, кыңгыраулар чылтыраталар, ә рухани аларга изге ашамлык әзерли.

Болай ялварып, алладан нәрсә сорый икән ул мескеннәр? Кием-салыммы, икмәкме, әллә сәламәтлекме? Без анысын аңламыйбыз. Тик шунысы ачык: ерак юлларны якын итеп, монда юкка җыелган алар, чөнки алла аларга барыбер берни бирмәячәк лөбаса!

Непал халкы бик дини. Кешенең һәр хәрәкәте, һәр адымы нинди дә булса бер дини йоланы үтәүгә кайтып кала. Непал — буддизмның үзәге, мөселманнар Мәккәгә барган кебек, дөньяның төрле почмакларыннан бирегә буддистлар гыйбадәт кыларга килә. Бу илдә дини бәйрәмнәр бик күп, аларның кайберләре егермешәр көнгә сузыла. Май аенда, мәсәлән, непаллылар Будданың туган көнен бик зурлап үткәрәләр. Ә сентябрьдә «сыер» бәйрәме була. Ул көннәрдә алар сыерлары койрыгына сары җепләр бәйләп куялар һәм шул җеп үзләрен һәртөрле бәлаләрдән һәм фәкыйрьлектән саклый дип уйлыйлар. Сыер бәйрәменнән соң күп тә үтми, эт бәйрәме башлана: изге җәнлек исәпләнгәнлектән, бөтен этләргә чәчәк букетлары тагалар һәм шәһәр, авыл урамнарында бизәлгән этләр бик күп була.

Непал халкының аллалары искиткеч күп, утыз миллионга якын. Тычканга да, комакка да, агулы еланга да, котырган әткә дә, кыргый маймылларга да гыйбадәт кылалар, чөнки ул җәнлекләр барысы да изге исәпләнә.

Хәтта аларның тере аллалары да бар. Гап-гади кеше үзе, әмма ул — алла! Ә аны болай билгелиләр. Дүрт-биш яшьлек кызларны җыялар да бер караңгы җиргә ябып куялар. һәм сыный башлыйлар: төрле куркыныч нәрсәләр күрсәтәләр, яман авазлар белән кычкыралар. Әгәр шунда бала куркуыннан елый башлый икән, аны чыгарып җибәрәләр, янәсе, ул изге җан түгел, тере алла булырга ярамый. Әгәр балалар арасында берсе, бөтен куркытуларга һич тә игътибар итмичә, тыныч кына утыра бирсә, ул алла итеп билгеләнә. Андый кешеләрне Непалда Кумари дип атыйлар. Ул изге җан санала. Аңа ата-аналары янында яшәргә рөхсәт ителми. Ул махсус әзерләнгән храмга күчерелә һәм берүзе яши. Аңа бернинди белем дә, тәрбия дә бирелми, хәтта урамга чыгарга һәм храмда берәрсе белән сөйләшергә дә рөхсәт ителми. Ата-анасыз, туган-тумачасыз һәм дусларсыз яшәү, әлбәттә, читен аңа, әмма, нихәл итсен, ул изге җан бит.

Тере алла яши торган храм шәһәр уртасына салынган. Ул шактый зур һәм ике катлы. Храмның ишек алды дүрт почмаклы. Аның чисталык ягы бик чамалы. Уртада су краны куелган. Храмның һәр дүрт стенасы да агачтан эшләнгән бизәкләр белән бизәлгән. Тәрәзәләре күп, әмма берсенә дә пыяла куелмаган. Алар урынына агач рәшәткәләр генә ясалган.

Храмда безне ап-ак чәчле бер карчык каршылады. Ул Кумарины карап, аны «явыз рух»лардан һәм кемнең дә булса урлап китүеннән саклап торучы икән.

— Без, Кумарины күрергә дип, бик ерактан килдек, күрсәтегез әле, зинһар, — дигәч, карчык үз телендә нидер мыгырданып алды. һәм, күп тә үтмәде, каршы яктан, икенче кат тәрәзәсеннән бер кыз бала башы күренде. Җирдәге тере алла — Кумари менә шул икән инде. Ул кызга унике-унөч яшьләр булса кирәк. Димәк, ул монда җиде-сигез ел утыра инде. Аның йөзе бик нык буялган: кашлары дуга сыман итеп тартылган, битләре кызартылган һәм маңгаена да нинди-дер таплар ясалган. Чәчләре озын, әмма таралмаган. Өстенә өйдә тукылган кызыл күлмәк кигән.

Кумарины без яхшылап карарга да өлгерә алмый калдык, чөнки ул безгә бернichә секунд кына карап торды да юкка чыкты. Шунлыктан рәсемгә төшерергә дә өлгереп булмады.



Күпме генә үтенсәк тә, фото һәм кинокамераларыбызны яшереп торабыз, рәсемгә төшермибез дип вәгъдәләр бирсәк тә, тере алланы яңадан күрә алмадык: өлеге ак чәчле карчык рөхсәт итмәде.

Аптырагач, «майлап» карарга булдык без аны: үз арабыздан төрле значоклар, агач кашыклар, борынгы акчалар җыйдык та, карчыктан шуларны аллага илтеп бирүне үтендек. Күрәсең, безнең бүләкләр тәэсир иткәндер, карчык йомшап китте дә аллага нидер әйтте. Алла тагын тәрәзәдән башын тыгып, елмаеп безгә карады. Ихтимал, ялгызлыкта байтак еллар яшәү дәверендә бу беренче мәртәбә елмаюы булгандыр аның.

Кумари храмнан елына бер тапкыр гына, үз бәйрәме көнендә генә чыга. Ул көнне храм янына дингә ышанучылар бик күп җыела. Храм янына алла өчен махсус әзерләнгән һәм яхшылап бизәлгән арба китереп куялар. Тере алла шул арбага чыгып утыра да шәһәр урамнары буйлап сәяхәт кыла башлый. Менә шул чакта фанатик динчеләрнең кайберләре, өлеге зур арба көпчәкләре астына ташланып, үзләрен үзләре һәлак итәләр. Моны алар изге үлемгә саныйлар.





Тере аллалар храмда гомере буена түгел, бәлки уналты-унҗиде яшенә кадәр генә торалар. Аннары аларны монастырьга озаталар. Монастырьда да аларның гади халык белән аралашырга һәм кияүгә чыгарга хаклары юк, чөнки алар изге җан санала.

Ул кыз-аллаларның гомере шулай үтә. Бәхетле дип әйтеп буламы соң аларны?

Непалда ирләр, гадәттә, өсләренә якасыз ак күлмәк, кара жилет, тар балаклы ак чалбар һәм башларына түбәтәй сыманрак итеп тегелгән бүрек киеп йөриләр. Күбесе муенына йон шарф та урый. Ә хатын-кызлар үзләре тукыган материядән аяк йөзләренә тиеп торырлык итеп тегелгән озын күлмәк кияләр. Барысының да чәчләре озын толымлы. Беләзек, йөзек, алка — Непал хатын-кызларының иң яраткан бизәнү әйберләре. Кайбер хатын-кызлар борын кимерчәкләренә боҗра кидерәләр. Ул боҗра иреннәренә төшеп торганлыктан, авызларын йозаклап куйган сыман тоела.



Непал балалары бик ягымлы, бик җитез һәм барысы шомырт кара күзле. Табигый каралык өстенә пычракка да буялып беткән булганга, аяк-куллары, битләре, муеннары тагын да карарак булып күренә. Күрү белән үк, аларның гомерләрендә бер мәртәбә дә мунча кермәгәнлекләрен, туганнан бирле юынмаганлыкларын абайлап алу һич тә читен түгел. Непал балаларын очраткан саен, безнең күңелгә, эх, бер рәхәтләндереп сабынлап, мунчалалап юындырасы иде шушы сабыйларны, дигән уй килә иде.

Непал халкы, гадәттә, ялан аяк йөри. Аяк киемен бары тик баерак, алдынгырак кешеләрдә генә күрергә мөмкин. Непаллылар төрле әйберне һәрвакыт бамбук көянтәгә асылган корзинкаларга тутырып, иңенә күтәреп ташый. Азык-төлек һәм башка бик күп тормыш-көнкүреш әйберләре турында сөйләп тә торасы юк, хәтта балаларын да шул корзинкаларга салып йөриләр.

Күп кенә Азия илләрендәге кебек үк, Непалда да халыкның яртым тормышы урамда үтә. Ризыкны да урамда пешерәләр, ашау да урамда, шунда ук йоклыйлар да. Кайбер урамнар буеннан буена сәүдә-



гөрләр белән тулган. Җиләк-җимеш дисеңме, төрле үсемлек орлыклары дисеңме, кызыл, сары, ак һәм башка төстәге йон дисеңме — барысын да шул бер урамда, таш тротуарда сатып утыралар.


Ә икенче урамга карасаң — бөтенләй башка күренеш. Урам буйлап утыртылган бамбук таякларны туку станогына «әверелдергәннәр» дә, хатын-кызлар йоннан тукыма эшлиләр. Непалда туку фабрикалары юк. Ә киенергә кирәк. Кыскасы, бөтен кирәк-яракны халык үз кулы белән җитештерә.

Непал шәһәрләрендә дә, авылларында да йортлар, гадәттә, ике катлы. Кагыйдә буларак, ул йортларның беренче катында кухня, эш урыны яки кибет була. Хайваннар абзары да шунда ук. Бу катта тәрәзәләр, морҗалар юк. Аның урта бер җирендә ут яныл тора, ә төтене ишектән чыга. Непаллыларга җәен эсседән, кышын салкыннан сакланырга (унбиш градус җылылыкны салкынга саный алар) кирәк. Беренче катта шуңа тәрәзә уймыйлар.




Икенче катта торак һәм азык-төлек саклау бүлмәләре урнашкан. Торак бүлмәләрдә өстәл-урындык кебек әйберләр юк; идәндә утыралар, идәндә ашыйлар һәм, бамбук маты җәеп, шунда ук йоклыйлар да.

Непал җире — мул уңыш бирә торган җир. Анда уңышны елына ике-өч тапкыр җыялар. Әмма ул җирнең һәр мыскалын бик ныклап эшкәртергә кирәк. Непал крестьяннары — бик тырыш халык. Иртәдән алып кичкә кадәр туктаусыз эштә алар: тау итәкләренә террасалар ясап, аны дөге, бодай, кукуруза һәм яшелчә үстерү өчен җайлаштыралар.




Халык эшчән, әмма ул халыкка бик кыенга туры килә. Авыл хуҗалыгы эшләренең бары тик кул көченә генә нигезләнүе, ашламалар булмау аркасында, никадәр зур хезмәт куйсалар да, крестьяннар җирдән уңышны бик аз алалар. Авыл хуҗалыгы үсешен тоткарлаучы төп сәбәпләрнең берсе илдә феодаль мөнәсәбәтләр хөкем сөрүгә, крестьяннарның җире аз булуга бәйләнгән.




Ә менә бу ике хатын-кыз дөге җыя. Әллә каян күренеп тора: алар әле яшьләр, нибары ундүрт-унбиштә генә. Әмма алар инде күптән кияүдә. Хикмәт шунда, Непалда кызларны бик иртә — 12—13 яшендә үк кияүгә бирәләр. Ә иренең ничәдә булуына беркем дә игътибар итми. Яшь-яшь егетме ул, чәче агарып беткән картмы — барыбер. Шунлыктан урамнарда үзләренә оныклар булырлык яшь хатыннарын ияртеп йөрүче ирләрне бик еш очратырга мөмкин. Һәм бу хәл беркемне дә гаҗәпләндерми.

Аерылышу мәсьәләсе дә үзенчәлекле бу халыкта. Хатын аерылышу турында беркемгә берни дә әйтергә тиеш түгел. Барысын да ир хәл итә. Әгәр иренең аерыласы килә икән, ул хатынының баш астындагы мендәренә кокос чикләвеге кыстырып куя да — вәссәләм! Бөтен мәсьәлә инде хәл ителгән: бүгеннән башлап ул инде ир хатыны түгел. Әмма, шул ук вакытта, хатынның ир йортыннан китәргә дә хакы юк. Ир йортында хезмәтче булып калырга тиеш ул.

Менә шулай итеп, кокос чикләвеге кичтән ир хатыны булып йокларга яткан хатын-кызны иртәнгә тол итеп, бернинди хокукы булмаган хезмәтче ясый да куя. Әмма, аның урынына, чикләвек иргә бик зур хокуклар бирә: ул тота да теләгән кешесенә яңадан өйләнә. Инде икенче хатыны да туйдыра икән, ир өченчесенә дә, дүртенчесенә дә өйләнергә хаклы. Чикләвекне озак эзләп йөрисе юк, базар тулы ул! Кыскасы, иренең берничә хатын алырга хокукы бар.

Шул ук Непалның төньяк районнарында исә ир түгел, бәлки хатын семья башлыгы булып тора һәм аның да берничә ир тотарга хокукы бар.

Үзебез торган кунак өе тәрәзәсе турысыннан һәр көн иртән аркаларына зур-зур утын бәйләмнәре күтәреп үтеп китүчеләрне күреп кала идек без. Бу хәлгә гаҗәпләнеп:

— Кемнәр алар, кая алып баралар ул утынны? — дип сорадым мин тәрҗемәчебездән.


— Базарга! — диде ул.

— Сездә болай да кызуга чыдый торган түгел бит, мичкә ягуның нигә кирәге бар?

— Юк, ул утын мичкә ягарга түгел. Туган-тумачалары үлгән кешеләргә мәет яндырырга кирәк ул, алар ала аны...







Без «изге» елга буенда. Бездән ерак та түгел, берничә кеше яр буена утын алып килделәр. Башта бик ипләп кенә утын агачларын дүрт рәт итеп өеп куйдылар, аннары шул утын өстенә кәфенлеккә төрелгән кеше мәетен урнаштырдылар да аның өстенә тагын утын өйделәр. Алар мәет яндырырга әзерләнүчеләр. Непаллылар мәетне бездәге кебек кабергә күммиләр, бәлки яндыралар да көлен елгага сибереп төшерәләр икән. Һәм бу хәл алар өчен шундый гадәти нәрсә — аңа беркем дә гаҗәпләнми. Теләсә, туктап карап тора, теләге юк икән — юлын дәвам итә.

Элегрәк Непалда мондый гадәт тә яшәп килгән: әгәр ир үлә икән, аның мәете белән янәшә куеп, хатынын да тереләй яндыра торган булганнар. Хәзер мондый кыргыйлык беткән инде. Әмма әле дә ире үлгән хатынның яңадан кияүгә чыгарга хакы юк.

Без кичерәк кенә бер тимер юл станциясендә идек. Ак күлмәк кигән бер яшь кенә ир кеше кинәт коточкыч аваз белән кычкыра башлады. Халыкның игътибары шундук аңа юнәлде. Күрәсең, ул шуны гына көткән булса кирәк — бик кәефе килеп, күлмәк изүен чишә-чишә су үткәргеч кран янына килде. Кранны ачып, авызын куйды да су эчәргә тотынды. Су аның авызына, чиләккә аккандай, тоташ агым булып коелып тора. Әйе, су ага тора, ә теге бәндәнең корсагы күзгә күренеп үсә, зурая бара. Ә аның әле һич тә туктар чамасы күренми.

Безнең арадагы хатын-кызлар, бу хәлдән куркышып:

— Ой, ярыла бит бу хәзер! — дип вагонга ук кереп киттеләр.

Ә теге кеше әле тагын эченә байтак су коеп торды. Әмма шартламады. Ярылырга җиткән корсагын көчкә күтәреп, ашыкмыйча гына мәйдан уртасына чыкты да, аякларын як-якка җәеп басып, эчкән суын, тоташ агым итеп, кире коярга тотынды. Әллә бу күз буамы икән дип, башта бераз шикләнеп торсак та, соңыннан ышанырга туры килде: су чыккан саен, тегенең корсагы шиңә барды һәм, ниһаять, элекке хәленә кайтты.


Бик озак күнегүләр ясау нәтиҗәсендә организмын шушы эшне башкарырга күнектергән кеше — иог икән ул.

Менә хәзер шушы рәсемгә карагыз. Йөзенә карап кына аның ничә яшьтә икәнен әйтүе дә кыен. Гомерендә бер тапкыр да тарак күрмәгән озын чәчле, сирәк сакаллы-мыеклы бу кешенең картмы яки яшьме икәнен, чыннан да, ничек аермак кирәк. Урам читендәге бер почмакта утыра ул. Күзләрен билгесез бер ноктага текәп, селкенмичә һәм керфек тә какмыйча утырганлыктан, аның тереме-үлеме икәнен дә аерып булмый. Янына ук килеп, текәлеп караганнан соң гына аның сулыш алуын тоясың.

Безгә ул кеше янынан берничә мәртәбә үтеп китәргә туры килде. Ул һаман шулай җансыз карачкыдай бер кыяфәттә утыруын дәвам итә иде әле.

Менә шулай аягын бөкләп, кулларын тезләренә куеп көннәр буе утыруның аңа берниндидә кыенлыгы юк, аның организмы моңа инде күптән күнеккән, чөнки ул да — иог.

Непалның төп байлыгы — аның эш сөючән халкы. Уртача буйлы, җыйнак кына гәүдәле, кара тут йөзле, коңгырт кара чәчле бу халыкка хас сыйфатлар шул, алар бик батыр, тәвәккәл һәм гаҗәеп дәрәҗәдә түзем. Һималай тауларын тикшерергә барган җитди альпинистик экспедицияләрнең берсе дә непаллылар ярдәменнән башка эш




итми. Хикмәт шунда, непаллылар, бердән, ул таудагы бөтен сукмакларны бик әйбәт беләләр, икенчедән, алар күп әйбер күтәреп бара алучы иң чыдам халык.

1954 елда кешелек тарихында беренче мәртәбә җир шарының иң биек ноктасы — Джомолунгма тавына күтәрелделәр. Җирнең «өченче полюсы» дип аталган бу тауны штурмлауда бик күп кеше катнашты. Әмма аның иң югары ноктасына менеп, җиңү байрагы кадау бәхетенә бары тик ике генә кеше ирешә алды. Шул икенең берсе — Непал кешесе, әйбер ташучы Тенсинг иде...

Без яшәгән кунак өенә һәр көн Непал яшьләре — Совет-Непал дуслыгы җәмгыяте членнары килә иде. Совет халкының Непал халкына күрсәткән эчкерсез ярдәме турында бик теләп, үзенә бер рәхәтлек тоеп сөйли иде алар.

Непал яшьләре үз илләренең матур киләчәгенә ышаналар, шуңа омтылалар. Ачык йөзле һәм безгә, совет кешеләренә, зур хөрмәт белән караучы менә бу яшүсмер малай — Непалның киләчәге. Ул ялгыз түгел, аның иптәшләре бик күп.

— — ◻ — —

## Әдәби тәнкыйть

*М. Госманов, М. Мәһдиев*

# XX ЙӨЗ БАШЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ һӘМ МАТБУГАТ ТАРИХЫНЫҢ КАЙБЕР МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Әдәбиятыбыз тарихына караган хезмәтләрнең саны ишәя килә һәм, әйтергә кирәк, сан белән бергә, аларның сыйфатлары да күзгә күренеп яхшыра бара. Бер урында таптанулар, күптән мәгълүм фактларны үзгәртмичә генә тәкрарлап чыгулар дәвере, ниһаять, сизелерлек артта калды. Моңа дәлил итеп Г. Халитның «Тукай һәм аның замандашлары», И. Нуруллинның «XX йөз башында татар әдәбияты» һәм М. Гайнуллинның «XX йөз башында татар әдәбияты һәм публицистикасы» исемле зур күләмле китапларын күрсәтеп була. Шулардан без Мөхәммәт ага Гайнуллинның рус телендә чыккан хезмәтенә[1] махсус тукталырга уйлыйбыз. Чөнки бу китапка, соңгы елларда чыккан башка хезмәтләрдәге кебек үк, мәсьәләгә киң планда килеп, материалларны мөмкин кадәр күбрәк җыеп, аларны яктыртуда иҗади эзләнү һәм яңа фикер әйтергә омтылу хас. Анда без кайбер мәсьәләләрдә авторның элекке ялгыш, яисә берьяклы позицияләреннән ваз кичүен дә күрәбез. Бу — иҗади үсүнең бәхәссез бер билгесе.

Китап «Журналистика һәм публицистика», «Әдәби тәнкыйть», «Поэзия», «Драматургия» һәм «Әдәби проза» дигән зур-зур биш бүлектән тора.

«Журналистика һәм публицистика» исемле бүлекне М. Гайнуллин хезмәтендә генә түгел, бәлки бөтен татар әдәбияты белемендә, бу өлкәгә багышланган беренче зур хезмәт, дип бәяләргә мөмкин. Биредә монарчы өйрәнелмәгән бик күп өстәмә фактлар туплау белән бергә, ул фактларны яңа позициядән карап, яңача тикшерү омтылышы да көчле. Димәк, бу бүлекнең әдәби тикшеренү методологиябез һәм шул чор иҗтимагый фикер тарихын өйрәнү өчен дә әһәмияте зур. Шуңа күрә бу бүлектәге кайбер катлаулы һәм ачылып җитмәгән мәсьәләләргә киңрәк тукталу урынлы булыр дип уйлыйбыз.

[1] М. Гайнуллин. Татарская литература и публицистика начала XX века. Казань, Рус телендә. 1966 ел. 433 бит.

## I

Беренче карашка революциягә кадәрге татар матбугаты турында шактый фикерләр әйтелде кебек инде. Ләкин алар (И. Рәминең кызыклы альбомын исәпкә алмаганда), кызганычка каршы, төпченеп эзләнүләрдән соң ясалган фәнни фикер булудан бигрәк, мәгълүм калыпларга туры китерергә тырышып әйтелгән нигезсез хөкемне хәтерләтәләр. Татар вакытлы матбугаты турында сүз йөрткәндә, ул авторлар үз хөкемнәрен В. И. Ленинның 1905 елгы революция дәверенә карата әйткән «Өч төп сыйныф, өч төп политик агым» турындагы фикеренә яраклаштырырга тырышып килделәр. Ләкин, үкенечкә каршы, юлбашчының: «Бу төп өч юнәлеш арасында исә, билгеле, ике арада торган, күчмә, ярым-йорты ясалгылар теләсәң никадәр»[1], — дигән иҗади һәм принципиаль искәрмәсе онытылыбрак калды. Нәтиҗәдә, «Йолдыз», «Вакыт», «Казан мөхбире» кебек газеталардагы, «Аң», «Шура» шикелле бай эчтәлекле журнал-

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. 31 том. 11 бит.

лардагы прогрессив характерлы материаллар файдаланылмый яттылар.

М. Гайнуллин исә, менә шундый берьяклылыктан баш тартып, мәсьәләгә киң караш белән килергә тырыша һәм бик әһәмиятле казанышларга ирешә. Мәсәлән, моңарчы гел «либераллыкта» гаепләнеп, читкә тибәрелгән «Йолдыз» газетасын алыйк. Автор «Йолдыз»ның нилектән озын гомерле һәм популяр булуын, мөхәррире Һади Максудиның газетаны яшәтүдә дипломатларча эш йөртүен күрсәтү белән генә чикләнми, революцион карашлы прогрессив әһелләрнең, күренекле язучыларның газета трибунасыннан системалы рәвештә файдаланып килүләрен дә матур-матур мисаллар белән дәлилли.

Гел «миллионерлар органы», «милләтчеләр трибунасы» сыйфатында тәкъдим ителеп килгән «Вакыт» газетасына (анда ул характердагы материалларның күп булуы бик табигый) багышланган эзләнүләр дә буржуаз җәмгыяте дәвере матбугатын аңлау өчен гаять характерлы нәтиҗә биргән: наширның кем булу-булмавына карамастан, газетадан демократ язучылар, революцион яшьләр, хәтта Х. Ямашев кебек большевиклар да нык файдаланганнар. Бу — игътибарга лаек момент. Менә шулардан чыгып, М. Гайнуллинның «Вакыт» газетасы баш редакторы Фатих Кәрими эшчәнлегенә озаграк тукталуы урынлы. Татар журналистикасы формалашу дәверендә күп хезмәт күрсәткән аксакал газетчының эшчәнлеге, һичшиксез, өйрәнелергә тиеш. Шул ук вакытта иске интеллигент Ф. Кәриминең бик катлаулы чорларда абынмалы юллардан гражданлык хисенә тап төшермичә уза алуы да ихтирамга лаек. «Социалист»лыкта лаф орып, җаваплы моментларда илен саткан һәм диңгез аша һава бозып яткан иске интеллигенциянең башка вәкилләре белән чагыштырганда, Ф. Кәриминең мораль йөзе уңай яктан ачыла. Ләкин безнең алда ике Ф. Кәрими бар. Беренчесе — практик журналист, редактор, педагог, гыйльми популяризатор, әдип Фатих Кәрими, һәм ул ихтирамга лаек. Шунда ук байтак вакытлар буржуаз милләтчелек белән мавыккан идеолог Ф. Кәрими дә бар, моныссы инде кискен тәнкыйть ителергә тиеш. Китапта исә соңгы момент йомшаграк чагылган.

«Шура» журналына һәм аның редакторы Риза Фәхретдинов эшчәнлегенә карата бирелгән бәя белән дә нигездә килешерлек. «Шура» журналы үзенең бай эчтәлеге һәм гаҗәп каршылыклы позициясе белән татар дөньясында бердәнбер орган дип әйтерлек. Бу хәл М. Гайнуллин китабында, күләм биргән мөмкинлекләрдән чыгып, шактый тулы тасвирланган. Әйе, XX гасыр башы татар әдәбияты һәм культурасына, татар халкының төрле дәвердәге катлаулы тарихына кагылганда, «Шура»дагы материалларны һәм Р. Фәхретдиновның бихисап әдәби-публицистик әсәрләрен, гаять нигезле гыйльми-тарихи хезмәтләрен читләтеп уза алмыйбыз. Әдәбият һәм тарихыбыз белән әзме-күпме шөгыльләнгән кеше моны яхшы аңлый. Р. Фәхретдинов, күп еллар актив эшләп, бай гыйльми мирас калдырган галим. Ул яшәгән чорларга күз салсак, без матур әдәбият өлкәсе белән әдәби тәнкыйть мәйданында да, журналист трибунасы белән редактор кабинетында да, тарихчы лабораториясе белән археограф китапханәсендә дә, философ креслосы белән педагог кафедрасында да Р. Фәхретдиновны очратабыз. Ләкин теләсә кайда тыгылып йөрүче, күпкә дәгъва иткән җилкуар дилетантны түгел, бәлки сүз-фикернең бәясен белеп, авторлыкның җаваплылыгын аңлаган төпле галимне, наданлыктан сыкранган, ахмаклыктан җирәнгән акыл иясе гуманистны күрәбез. Без сөйли торган китапта менә шул катлаулы һәм бай иҗатның бер-ике ягы гына карала, матур гына нәтиҗәләргә ирешелә. Әмма Р. Фәхретдинов эшчәнлегендәге каршылыклы, хәтта тискәре моментларны читләтеп узу белән килешәсе килми. Фәнни гадел булырга теләсәк, безгә аның объективизмы белән идеализмын да ярып күрсәтергә иде, шуңа күрә, вәгазьче мөнбәрендә дә, мулла михрабында да, пишкадәм хөҗрәсендә дә аһ-ваһ орып, бакырын алтынга тәкъдим итеп йөргән «Риза хәзрәт» белән дә очрашырга, принципиаль рәвештә «моназара» кылып алырга кирәк иде. Нигәдер, автор нәкъ бу моментларны читләтебрәк узган. Тик юкка. Р. Фәхретдинов эшчәнлеге бездә беренче мәртәбә шулай киңрәк планда яктыртыла. Һәм тәкъдир итү белән тәнкыйть янәшә йөрсә, хезмәтнең кыйммәте бермәбер артыр иде.

Ләкин бездә тәнкыйть итүне берьяклырак аңлау өстенлек итә кебек. Мәсәлән, зур яки хезмәтләре игътибарга лаек кешене тәнкыйтьләүне аның иҗатын өйрәнүдән баш тарту кебек кабул итәбез. Ачыграк әйткәндә, безгә тәнкыйтьне Ленинча аңлау җитеп бетми әле (мисалга, татар әдәбияты белемендә киң таралган «тәнкыйть»

методы белән В. И. Ленинның Л. Н. Толстой иҗатына ясаган фәнни нигезле тәнкыйтен чагыштырып карагыз). Күрәсең, субъективизм хөкем сөргән чорда гел аяк астына салып таптарга янсә бертавыштан мактарга күнегеп калганбыз. Бу хәл исә метафизиканың корбаны булу дигән сүз. «Метафизик тәмамланган капма-каршы положениеләр белән уй йөртә, — ди Энгельс «Анти-Дюринг» дигән мәшһүр хезмәтендә, — аның өчен әйбер яки бар, яки юк; аның сүзе «әйе-әйе, юк-юк» сүзләреннән гыйбарәт». Чын тәнкыйть — инкарь белән икърарның диалектик кушылмасы. Р. Фәхретдинов эшчәнлеге дә шундый гыйльми тәнкыйтькә мохтаҗ.

Мәгълүм булганча, Р. Фәхретдиновка бер үк вакытта панисламист та һәм пантюркист та дигән мөһерләр сугылып килде. Бу ике төшенчәнең (ике политик юнәлешнең) нормаль бер кеше башында бер үк вакытта була алмавы — бәхәссез нәрсә. Шуңа күрә без Фәхретдиновны пантюркист кына дип кабул итик, ди. Тик нинди дәлилләр китерербез? Тел ярышы оештыруымы? Алайса, бер «гомумтөрки» телнең барлык төрки халыклар өчен яраксыз булуын Р. Фәхретдинов мөхәррирлек иткән «Шура» журналы исбатлады. Галимнең үз теле дә, гомум татар әдәби теле белән бергә, елдан-ел сафлануга таба барды. Инде этногенез проблемасын алыйк. Чын пантюркист, авантюрист З. Вәлиди белән Р. Фәхретдинов арасында бу мәсьәләдә бармы берәр уртаклык? Беренчесе тарихта илбасар ханнарны идеаллаштырган «төрек-татарчы», «туранчы» булса, икенчесе, мәсьәләгә берьяклырак килсә дә, М. Гайнуллин күрсәткәнчә, шактый дөрес юлда торган «болгарчы». Икесенең язмышы да ике төрле.

Пантюркистлык, гадәттә, Төркия дәүләте йөрткән агрессив политикага мөнәсәбәттә бик ачык чагыла. Р. Фәхретдинов та үз мөнәсәбәтен ачык әйткән. Төркиянең гарәп илләрен, шул исәптән Ямәнне яулап алуын ул бөтенләй тискәре хәл сыйфатында квалификацияли. Галим пантюркизмның төп сыйфаты булган расачылыктан бик ерак тора, бер үк вакытта яулап алу политикасында халыкның гаебе булмавын да күрсәтә. Кыскасы (мисалларны тагы да китереп булыр иде), Р. Фәхретдиновка карата «пантюркист» дип әйтерлек тиешле дәлилләр таба алмыйбыз.

Әмма Р. Фәхретдиновның вакыт-вакыт милли чикләнгәнлек шаукымына бирелеп алуына килсәк, монда мәсьәлә шактый катлаулы. Без проблемага Ленинча килеп, изелүче милләтләрнең милләтчелеге белән изүче милләтләрнең агрессив шовинизмын бер-берсеннән аера белергә тиешбез. Шулай итмәгәндә XX гасыр башында «халыклар төрмәсе» булган Россиядә киң җәелгән катлаулы милли хәрәкәтне дә, бүгенге көндә колониализмга каршы купкан дөньякүләм милли азатлык давылын да тарихи дөрес аңлата алмабыз. Бу сүзләрне без Р. Фәхретдинов эшчәнлегендә чагылып киткән кайбер чикләнгәнлек сөремнәрен аклар өчен түгел, бәлки шул ялгышларның татарга гына хас милли чир булмыйча, кешелек җәмгыяте үсешендәге котылгысыз бер этап җимеше икәнлеген искәртер өчен язабыз.

Риза Фәхретдиновның панисламизмына килсәк, биредә «гаепләү» өчен бөтен дәлилләр дә бар сыман. Нечкәртелгән идеализм һәм ислам динен идеаллаштыру, югары рухани дәрәҗә, теологик хезмәтләр — барысы да бар. Ләкин ныклабрак тикшерсәң, бу дәлилләр дә көчләрен югалталар. Һәрбер «хак мөселман»ның панисламист булуы зарури түгел. Казый-мөфтилек тә критерий була алмый. Дини әсәрләргә килсәк, алар панисламизм идеясе туганчы тагы да күбрәк язылганнар. Шуңа күрә без тышкы сыйфатларны читкә куеп, ул идеяне аның үз хезмәтләреннән эзлик. һәм эзләнү әҗерен бирәчәк: панисламизм хакында аның үз сүзләрен, ул идеологиягә карата ачык мөнәсәбәтен табабыз.

1912 елда язган бер хезмәтендә Фәхретдинов, шәрык илләрендәге антиколониаль хәрәкәтләргә карата Европа колонизаторларының мөнәсәбәтләре турында сөйләп, панисламизм (иттихады ислам) проблемасына туктала һәм аны бер карачкы күсәк итеп түгел, бәлки тарихи принцип белән өч төшенчәгә бүлеп тикшерә: 1) политик союз, 2) дини (мәзһәби) берләшмә һәм 3) политик максатлардан ерак торган иҗтимагый союз. Европа политиклары, ди автор, панисламизм дип беренче төр, ягъни политик союзны күздә тоталар. Ләкин мондый союз мөмкин булмаган бер хәл, чөнки «һәрберенең махсус бер мәнфәгате, гадәт вә максуды, лисан вә шивәсе» булган мөселман илләренең «бер хөкүмәт идарәсенә җыелмаклары мөмкин улмаса кирәк». Мәкалә дәвамында Р. Фәхретдинов, панисламизмның реальлектән ерак булуын күрсәтү белән генә чикләнмичә, аның за-

рарлы икәнлеген дә ачык әйтә[1]. Шул ук вакытта галим панисламизмны «мәкерле кешеләр тарафыннан мал һәм карьера өчен уйланып чыгарылган хыял» дип исәпли. Шулай ук аның бу күрсәтүе Россиядәге мөселман халыкларының иҗтимагый узганын тикшерү өчен дә әһәмиятле. Ул фикер тарих фәннәре докторы Р. И. Нәфыйговның: татарлар арасында панисламизм эзләү — патша самодержавиесенең провокацион уйдырмасы ул, дигән ачышына яңа дәлил өсти[2].

Фәхретдиновны панисламизмга нисбәт итүчеләр, гадәттә, аның мөселман илләре турында күп язган булуын игътибарга алып, галимне шәрык илләрен идеаллаштыра дип уйлыйлар. Тик бу — нигезсез шөбһә. Ул шәрык илләрендә хөкем сөргән гомум регрессны, торгынлыкны яхшы күргән, фаҗигане төбе-тамыры белән аңлаган, аның сәбәпләрен шактый дөрес сиземләгән; гарәп илләренең «искелек ноктасыннан каралдыгында... гомуми бер музейханә хөкемендә» булуын да яхшы белгән. Бу мәсьәләдә ул күп кенә замандаш Европа галимнәреннән югарырак торган.

Дөрес, Фәхретдиновның диннән бөтенләй баш тартуын көтү урынсыз булыр иде. Алай гына түгел, динне нечкәртү, сыгылмалырак итү юлында актив эшләгән рухани галим дә ул. Әгәр узганны бәяләүдә, панисламизм кебек зарарлы тәгълиматларны тәнкыйтьләүдә Фәхретдинов интернациональ карашлы прогрессив җәмәгать эшлеклесе дәрәҗәсенә күтәрелә алса, диннең тормыштагы урынын билгеләүдә ул гадәти мулла түбәнлегенә төшеп кала.

Р. Фәхретдинов фәлсәфәсенә без бирдә очраклы рәвештә генә болай озак тукталмадык. Капитализм чоры иҗтимагый фикеребез һәм культура тарихыбызда ул иң катлаулы, кызыклы шәхесләрнең берсе. Ләкин комик түгел, бәлки трагик шәхес. Шул ук вакытта иҗтимагый тормыштан читтә калган Дон-Кихот түгел, ә бик күп мәсьәләләрнең очын үзендә төенләгән Вольтер кебек үзәк фигураларның берсе ул. М. Гайнуллин үз хезмәтендә аның эшчәнлегенә махсус бүлекчә багышлап дөрес эшләгән. Ә безнең бирдә төпченүдән теләк исә, китаптагы тәгълсезлекләрне тулыландыру белән бергә, катлаулы мәсьәләләргә карата комплекслырак анализ тәҗрибәсе ясап караудан гыйбарәт.

Мондый анализ алымы, фикеребезчә, аерым шәхесләр иҗатларын гына түгел, матбугат органнары эшчәнлеген тикшерер өчен дә зарури. Киресенчә булганда, синтезлап гомумиләштерә башлаган чакта, схемалар тирәсендә калачакбыз. Күзәтелә торган китапта моның да мисаллары юк түгел. Мәсәлән, югарыда татар матбугат органнарын формаль рәвештә өчкә бүлүгә каршы фикер әйтелгән иде. М. Гайнуллин газета-журналларның эчтәлегенә һәм аерым материалларга ясаган күзәтүләрендә дөрес юлдан барса да, нәтиҗәләр чыгара башлагач, иске традицияләрдән котылып бетә алмый. Алай гына түгел, бер органга карата да төрле урында төрлечә, бер-берсенә каршы билгеләмәләр бирә. Мәсәлән, «Казан мөхбире» газетасы бер җирдә «радикаль буржуаз юнәлештә» булса (7 бит), икенче төштә «либерал»га әверелә (23 бит), өченче урында исә ул «либерально-умеренный» дигән бүрек астына алына (119 бит). «Вакыт», «Йолдыз», «Шура» һ. б. белән дә шундыйрак хәл килеп чыккан. Киләчәктә, андый буталчыклыклардан азат булыр өчен, татар вакытлы матбугатына карата сыгылмалырак классификация принциплары эзләмәскәме икән, дигән фикер туа. (Рус буржуаз матбугаты белән татар газета-журналлары арасына бөтен мәсьәләләрдә тигезлек билгесе куеп булмавы бүген һәрбер кеше өчен аңлаешлыдыр.) Наширның кем булуыннан чыгып кына түгел, бәлки редактор позициясен дә, редколлегия составын да һәм киң катлам корреспондентларны да хокуктан мәхрүм итмичә хөкем йөртергә кирәктер. Шулай ук укучыларның таләп һәм тәэсирләре дә онытылмаска тиеш. Киресенчә булганда, буржуаз җәмгыятьтәге **матбугат спецификасын** аңлатуда буталып, чыганаклар хәзинәсенә юлны кисеп куюыбыз бар. Моңа хәтле, кызганычка каршы, шулайрак эшләнде дә.

Революциягә кадәр чыккан татар газеталары арасында иң хөрмәтле урында торганы, һичшиксез, большевиклар органы — «Урал» газетасы иде. Ул, кыска гомерле булуына карамастан, безнең матбугат тарихында бер эпоханы тәшкил итә алды. Китапта бу газетага тагы да киңрәк тукталырга мөмкин иде. «Урал» материалларын җыеп, бер аерым китап итеп чыгарырга

[1] «Шура» журналы. 1912 ел. 12 сан.

[2] Р. И. Нафигов. Формирование и развитие передовой татарской общественно-политической мысли. Казань. Рус телендә. 1964 ел. 40—53 битләр.

да, ниһаять, вакыт җитмәде микән? Бер «Урал» гына түгел, башка демократик органнарның сайланма материалларыннан төзелгән хрестоматияләр турында да уйланыр чак җитте сыман. М. Гайнуллин китабы шикелле хезмәтләр янында шундый хрестоматияләр дә булса, студентларыбыз һәм киң җәмәгатьчелек өчен мөмкинлекләр арта төшәр иде. Һәм мондый мактаулы эшне башкаручылар коллективына җитәкчелек итүдә М. Гайнуллинның тәҗрибәсе бик файдалы булыр иде.

Яңа китапның уңай ягы итеп тагы шуны күрсәтергә кирәк: автор реакцион матбугат органнарын да дежур сүзләр белән генә шелтәләп узмый, бәлки аларның эчләренә кереп, фактик материаллар ярдәмендә тәнкыйть итә. Ә без моңарчы, күңелсез булса да әйтик, реакцион органнарны эчләренә кереп тәнкыйтьләүдән бигрәк, аларның капка төпләрендә тузан бөркетеп алу белән канәгатьләнеп яшәдек...

Җыеп әйткәндә, М. Гайнуллин китабының беренче бүлеге, материалга гаҗәп бай булуы белән бергә, күп кенә мәсьәләләрне яңачарак — дөресрәк яктыртуы белән дә характерлы.

II

Китапның икенче бүлеге XX йөз башындагы әдәби тәнкыйть тарихына багышланган. Күрсәтелгән дәвердәге әдәби-эстетик фикернең формалашуы, әдәби тәнкыйть принциплары Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов иҗатларына багышланган хезмәтләрдә шактый тикшерелде. М. Гайнуллин әсәрендә исә менә шул хезмәтләргә беркадәре йомгак ясала, һәм автор, бик хаклы рәвештә, XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте үзенең язмышын азатлык өчен көрәшкә бәйләде, һәм ул реализм, халыкчанлык, югары сәнгатьчәнлек принципларының җиңү казанышына ирешә диган нәтиҗәгә килә.

Бүлек башында татар иҗтимагый тормышындагы әдәби-гыйльми тәнкыйтьнең ярлыгы дәверләренә — узган гасырдагы тәнкыйди фикер тарихына тукталып автор бик дөрес эшләгән. Чыннан да бу өлкәдә Г. Курсави, И. Хәлфин, Ш. Мәрҗани, Х. Фәезхан һәм К. Насыйриларның рольләре бик зур.

Бездәге чын мәгънәсендәге әдәби тәнкыйтьне Г. Тукай исеме белән баглау бик дөрес: махсус трактатлар язмаса да, бу өлкәдә бөек шагыйрь гаять тирән эз калдыра алган. Тик шагыйрьнең тормыш тискәрелекләрен чыбыркылауга багышлаган саф сатирик әсәрләрен дә «әдәби тәнкыйть» категориясенә кертү (130—132 битләр) аңлашылып җитми. Юмор һәм сатирадагы тәнкыйть белән әдәби тәнкыйтьтәге объектлар бер-беренә бөтенләй башка нәрсәләр бит. Ә менә алдарак, 132—153 битләрдәге анализлардан исә, без чын Тукайәдәбиятчыны күрәбез. Китапта Ф. Әмирхан эшчәнлеге тагы да күпкырлырак, тирәнрәк ачыла. Бер хакыйкать көннән-көн калкурак булып күренә: бишенче-унынчы еллардагы әдәби-эстетик фикернең формалашуында Ф. Әмирхан иң зур фигураларның берсе һәм, профессор Г. Сәгъдичә образлы итеп әйтсәк, татар әдәбиятының «карчыга күзле үткен тәнкыйтьчесе» булган. Ф. Әмирхан эшчәнлегендәге гомумкешелек, интернациональ моментларны ассызымлап күрсәтүе белән автор бик хаклы. Ф. Бурнаш әйтүенчә, шәкертләр хәрәкәтендә аларның «сәхнәдән торып командалык итүче җитәкчеләре» сыйфатында танылган, социал-демократлар һәм большевик С. Н. Гассар белән якын мөнәсәбәттә торган Ф. Әмирхан саф язучы, саф тәнкыйтьче, саф журналист кына түгел, бәлки зур җәмәгать эшлеклесе дә иде. Олы әдипнең бу сыйфатлары анық әдәбият белеме өлкәсендәге урынын да билгеләгән, әлбәттә.

Г. Ибраһимовка багышланган бүлекчә дә материалга бай булуы белән игътибарга лаек. Ләкин авторның «Татар шагыйрьләре» тирәсеннән йөгереп кенә узуы аңлашылып бетми. «Татар шагыйрьләре»нең барлыкка килүен бер «кызу канлылык» белән генә аңлату канәгатьләндерми, һәм ул алай а-лап кына узарлык иләмсез әйбер дә түгел. Авторга ул әсәрнең барлыкка килүендәге объектив сәбәпләрне эзләү белән бергә, бу өлкәдә М. Хәсәнов ирешкән дөрес һәм әһәмиятле нәтиҗәләрдән[1] файдаланырга кирәк иде. Безнең уебызча, автор Г. Ибраһимовның «Әдәбият кануннары» исемле зур хезмәтенә дә күз сирпеп кенә узу белән чикләнгән. Күп кенә проблемалар белән бергә, анда Г. Ибраһимов, татар филологларыннан беренче буларак, фольклор теориясе буенча да нигез ташларын сала башлаган иде бит.

М. Гайнуллинның бу хезмәтендә күренекле тәнкыйтьче Җ. Вәлиди эшчәнлеге дә өлешчә яктыртылган. Тарихи аңлаешлы

[1] Мансур Хәсәнов. Г. Ибраһимов. Казан. 1964 ел. 55—71 битләр.

мәгълүм хаталары булуга карамастан, үзенең эрудициясе, төпленлеге белән Җ. Вәлиди — тәнкыйть тарихында үз урынын тәэмин иткән галим. Г. Ибраһимовның Октябрь революциясеннән соң Җ. Вәлиди әсәрләренә игътибар итүе һәм аның белән полемика алып баруы очраклы түгел иде. Ләкин М. Гайнуллин әдипнең 1923 елда чыккан китабына анализ ясаудан элек, аның «Вакыт» газетасында бастырган әдәби-тәнкыйть мәкаләләре циклына тукталып, галим кичергән эволюцияне күзәтеп, аның ялгышларын тәнкыйть итү белән бергә, Җ. Вәлидинең нинди юллар аша Совет строена хезмәт итүгә хәтле үсеп җитүен дә күрсәтергә тиеш иде.

Күренекле әдип М. Гали сүзләре белән әйткәндә, «татар дөньясының күгендә метеор кебек сызылып узган» шагыйрь С. Рәмиев эшчәнлеге М. Гайнуллин китабында бөтенләй яңа сыйфаты белән ачыла. Сүз С. Рәмиевнең тәнкыйть хезмәтләре хакында бара. Автор бик дөрес әйтә: Рәмиев-тәнкыйтьчә бер дә өйрәнелмәгән әле. Шуның өчен дә М. Гайнуллин китабының бу өлеше игътибарны җәлеп итүе бик табигый. Шулай ук С. Рәмиевнең Х. Ямашев истәлегенә багышланган мәкаләсе аерата характерлы. Анда без шагыйрьнең авыр елларда да демократик идеалларга турылыклы булып калуын күрәбез. Җыеп әйткәндә, С. Рәмиевнең тәнкыйть һәм публицистик эшчәнлеге киләчәктә монографик тикшеренүне көтсә, М. Гайнуллин тарафыннан ясалган бу кечкенә обзор ул монография өчен кирәкле бер кереш сүз ролен үти. Китапта Г. Сәгъди, Г. Кәрам, М. Акчурина һ. б. әдипләрнең дә эшчәнлеге яктыртыла. Урын тар булудан, билгеле, аларның иҗатлары, алдагы каләмдәшләрнекенә караганда таррак яктыртылган. Шулай да моңарчы гел онытылып яткан авторлар белән очрашу уңай тәэсир калдыра. Тик бу бүлекнең азагына җитүгә шундыйрак фикер туа: әгәр дә автор аны биографизм ысулы белән түгел, ә теоретик планда язган булса, әзләнү тагы да отышлырак чыгар кебек иде. Бер үк вакытта автор гел фактлар теркәп барулардан һәм кайбер кабатлаулардан да котылган булыр иде.

### III

Поэзия бүлегенә бирелгән кереш беразкиңрәк тукталуны сорый. Мәсәлән, XIX гасыр татар әдәбиятында үзенә аерым бер урын билгәләгән Мифтахетдин Акмулла иҗатына ике генә җөмлә багышлау бик сәер. Мәгърифәтчелек идеясе байрагын биек күтәргән бу гаҗәеп шагыйрь әдәбиятыбыз тарихында бер бөтен этапка вәкаләтлек итә. Әгәр Г. Кандалый, әдәбиятта фанатизм чылбырларын өзеп, гади кеше мәхәббәтен суфиларның мәгънәсез «күкләр»еннән алып төшеп, җир кызына китереп кавыштырса, Акмулла да борынгы тарих томаннарында күмелеп калган «мәгърифәтчелек» идеясен реаль татар дөньясына, аның да конкрет шәхесләренә китереп бәйләде. Икенчерәк әйткәндә, борынгырак дәвер шагыйрьләребез өчен аң-белем, мәгърифәт идеалы — реальлеге шөбһәле изгеләр, тарихилыгы бәхәсле падишаһлар булса, Акмулла өчен — гадәти кеше, конкрет шәхес, акыл һәм фикер иясе якты идеал иде. Бу инде — фани дип гел түбәнсетелеп килгән кешенең олылыгын җырлаган гуманизм поэзиясе. Шуңа күрә Акмулла иҗаты турында киңрәк язып, борынгы дәвер татар поэзиясе белән М. Гафури һәм Г. Тукайлар иҗаты арасында Кандалый белән янәшә Акмулланың да зарури күпер хезмәтен үтәүләрен ачыграк күрсәтү киләчәктәге бурычларның берсе.

Г. Тукай һәм М. Гафури иҗатлары татар әдәбияты белемендә шактый өйрәнелгән инде. Шуңа карамастан, автор алар иҗатына багышланган бүлекчәләрдә дә яңа фикерләр әйтә алган. Моңа бер мисал итеп авторның «Китмибез!» исемле шигырьгә карата дөрес аңлатманы торгызуын күрсәтергә кирәк. Чыннан да: «Если лучше вам, туда сами пожалте, господа!» — дип тәмамланган бу әсәрне русча ипи дә сорый алмаган әфәнделәргә адресланган дип аңлатылу — иң кимендә укучыларны хөрмәтләмәү иде [1]. Әмма шигырь, чыннан да, пантюркистлар өчен дә естәмә бер мичкә бозлы су булды. Тик шагыйрьнең бу әсәрне язган чагында турыдан-туры алар хакында уйлавыннан түгел, ә патриотлык, чын гражданлык идеясенең пантюркистлар өчен дә ярага сибелгән тоз булуыннан иде. Башкачарак әйтсәк, монда Тукай бер таяк белән ике куянны үтерә. Әйе, ихлас патриотизм, олы гражданлык!.. Бу инде шул һәм башка дәвердәге ватанчылык хисен пассив рәвештә кабул итеп, актив рәвештә исем һәм акча эшләгән дежур патриотларның «дан җырлаулары» һәм сыкрануны мода иткән икенче төр шагыйрьләрнең

[1] Мондый кимчелек Г. Халит һәм Ш. Байчура хезмәтләрендә дә мөстәкыйль рәвештә төзәтелде.

«моңы» да түгел. Олы патриотизм кимчелекне рәхимсез фаш итеп, искелекне себереп ташлап, яңаны төзүне үзенә изге бурыч итеп куя.

> **Иң беек максат безем: хөр мәмләкәт, хөр Русия!** [1]

«Олуг юбилей мөнәсәбәте белән...» дигән шигырьгә бирелгән яңачарак аңлатма белән дә килешергә кирәк. Чыннан да, 1908 елда Россияне шпионнар, камчылы казаклар, хәзинә талаучылар, кара йөзләр оясы һәм утлы җир итеп таныган Тукай ни өчен соңрак шулай бик тиз әллә нинди «иллюзияләргә» бирелде икән? М. Гайнуллинның биредә (беренче һәм соңгы строфаларда) нечкәртелгән ирония күрүе бик нигезле. Монда да Тукай үзенең олы патриотизм идеяләренә турылыклы булып калган һәм юбилей уңаенда яңа көч белән кабынган шовинизм сөременә каршы уртак ватан таләпләрен куя:

> **Шул халыкныңмы хокукка хакы юк!**
> **Хаклыбыз уртак ватанда шактый ук.**

Әйе, Тукай, үз халкының улы буларак, ак намусы, пакь вөҗданына бернинди тап төшермичә дөньядан китте, әллә кайдан килгән фатирчы кебек түгел, бәлки тиң хокуклы туганнарча кер елмаеп, ихлас күңел, горур саубуллашып китте...

Рус әдәбияты һәм Тукай дигән катлаулы тема, кечкенә күләмдә булса да, отышлы гына яктыртылган. Тик ул сәхифәләрне укыгач, бер фикергә киләсең: гомум татар әдәбиятында XX йөз башында эшләнгән тәрҗемәләрне, икътибас һәм тәкълидләрне күзәтеп, рус әдәбиятындагы алдынгы фикернең ничек һәм нинди призмалар аша татар әдәбияты тарафыннан үзләштерелүен күзәткәндә, уебызча, бу китапның кыйммәте тагы да арта төшәр иде. Чөнки алдынгы рус әдәбияты дәрьясыннан су эчеп, татар әдәбияты елгасына өлеш кушкан әдипләр бер Г. Тукай гына түгел бит. XX гасыр башында прогрессив рус әдәбиятына карата булган якын мөнәсәбәт алдынгы татар язучыларының барысы өчен дә хас. Ләкин бу мәсьәләгә кагылганда, Лермонтов һәм Пушкинны белү: «помогло поэту (Дәрдмәндкә — авторлар) создавать поэтические произведения на татарском языке», дигән кебек нигездән ялгыш фикерләр җибәрү ярамас (260 бит). Дәрдмәнд турында сүз чыккач, шуны да әйтик, аның «поэзиясе татар телендә дә әдәби матур шигырьләр тудырырга мөмкин икәнлеген дәлилләде», кебек сәер фикер белән дә килешеп булмый (259 бит). Чөнки, беренчедән, нормаль кеше тарафыннан татарча нәфис шигырь язылу мөмкин түгел дигән караш белдерелмәде кебек; икенчедән, татар поэзиясендәге бөтен нәфасәткә бер Дәрдмәнд кенә вәкаләтлек итми әле. Дәрдмәнднең зур шигырь остасы булуын танып, аның таланты алдында баш игән хәлдә дә, ул шагыйрьнең берүзен бай традицияле бөтен бер әдәбиятка алай каршы кую дөреслектән бик ерак.

Шагыйрь С. Рәмиев иҗаты да рус телендә беренче мәртәбә буларак М. Гайнуллин китабында шулай киң планда тик шерелә. Автор, шагыйрьнең катлаулы иҗат лабораториясенә керүе белән бергә, аның тормыш юлындагы буталчык мәсьәләләрне дә дөрес хәл итүгә ирешә алган. Мәсәлән, ясалма рәвештә куертылган Тукай — Рәмиев мөнәсәбәтләрен автор, принципиаль гыйльми позициядән торып, кешечә гадел яктырта алган. Шулай ук Рәмиевне провокаторлыкта гаепләүләрнең нахак булуы да ышанычлы дәлилләнгән.

Поэзиягә багышланган бүлек азагында кыскача гына булса да Н. Думави, М. Укмаси, З. Бәшири, З. Ярмәки шикелле заманында актив эшләгән шагыйрьләр, Маһруй һәм Мәхмүдә Мозаффарияләр, Рокыя Ибраһимова, Фатыйма Фәридә, З. Сәгыйдә, Гыйффәт Туташ кебек шагыйрәләрнең иҗатлары да күзәтелеп, аларга тиешле гадел бәя бирелә. Ләкин С. Сүнчәләй, К. Әмири, Г. Мостакаев (Г. Биги), Ф. Туйкин һ. б. күп кенә шагыйрьләр, нигәдер, онытылып калган. Ә Ш. Бабич иҗатының бик кыска һәм өстен-өстен генә яктыртылуы белән автор үзе дә канәгать түгелдер дип уйлыйсы килә.

XX гасыр башы — революцияләр чоры бер поэзиядә түгел, бәлки драматургия белән әдәби прозабыз өчен дә әлек күрелмәгән биеклекләргә менү дәвере булды. Китапның аларга багышланган бүлекләре дә шактый кызыклы эшләнгән. Ләкин бу өлкәләр укучылар өчен ул хәтле яңа түгелләр; аларда сизелерлек яңа проблемалар да куелмый кебек. Шулай да галимнең аерым авторларны гына түгел, бәлки бер

---

[1] Кызганычка каршы, русча тәрҗемәдә бу һәм башка юлларның мәгънәләре бик зәгыйфьләнгән, мәсәлән, әлеге юл болай бирелгән: «К единой цели мы идем, свободной мы хотим России», — нихәтле сүлпән, никадәр җансыз яңгырый! «Хөр мәмләкәт», — дип гомумиләштерү, «хөр Русия» дип конкретлаштырудан туган поэтик экспрессивлык, мәгънәви тирәнлектән тәрҗемәдә бернәрсә дә калмаган бит!

бөтен чорны күзәтергә теләве сизелеп тора һәм ул уңай тәэсир калдыра.

Дөрес, бу бүлекләрдә, алдагыларында да сизелеп киткәндәй, фактография алымы үзен ныграк күрсәтә. Моны бөтен китап күләменә күчереп карaганда да аңларга мөмкин: XX йөз башындагы татар әдәбияты һәм язма культура дөньясы егерме табаклык китапка баш-аягы, форма-эчтәлеге белән сыеп китәрлек хосусый бер хәрәкәт түгел. Бу чор әдәбияты һәм матбугатыбыз ике-өч йөз ел дәвамында «түл җыю»ның нәтиҗәсе булды. Алай гына да түгел, ул татарларның феодализмнан капитализмга, һәм соңгысыннан, бөтен Россиянең зур семьясында, социализмга сикерер өчен әзерләнгән катлаулы, кызу темплы дәверенең җимеше иде. Ул эпоханы чын-чынлап, күп яклап тикшерер өчен бер түгел, ике түгел, биш-алты зур-зур том да җитмәс иде. Менә шуңа күрә дә М. Гайнуллин китабы вакыт-вакыт факто-библиографик белешмәне хәтерләтеп куя. Ярар, бу типтагы хезмәт тә файдалы, андыйлар булмаганда әле генә хыял иткән күп томлы эзләнүләргә ирешеп булмаячак. Ләкин шул ук вакытта, югарыда әйтелгәннәрдән дә сизеләдер, яңа хезмәт уйланырга, эзләнергә, бәхәсләшергә мәҗбүр итә. Ә бу һәрбер авторны горурландыра алырлык мактаулы казаныш.

* * *

Мәкаләбезне югарыдагы җөмлә белән тәмамларга мөмкин иде. Ләкин безне борчыган тагы бер нәрсә бар. Ул — русча басылган китаплардагы кайбер гомуми техник кимчелекләр. Кызганычка каршы, андыйлар без тикшерә торган китапта да үзләрен нык сиздерәләр.

Җитешсезлекләрнең беренчесе итеп татарча сүзләрнең русча транслитерациясен күрсәтергә кирәк. Китапның Казанда, татар шрифтына мохтаҗлыгы булмаган комбинатта басылуын игътибарга алганда, «күзе аның», «мәхәббәт», «хөрмәт» кебек татарча сүзләрдән «кузе анын», «мэхэббэт», «хэрмэт» дип тел сындыргычлар ясау акланган микән? Безнеңчә, юк. Чөнки татарча бер дә аңламаган рус укучысы өчен әсәр исемнәрен һәм аерым өзекләрнең оригиналда тәкъдим ителүе бернәрсә дә бирми, ә татарчадан азмы-күпме хәбәре бар кеше өчен мондый «транслитерация» мәгънә буталчыгы һәм эстетик ризасызлык кына тудыра. Шуңа күрә, уебызча, беренчедән, татарча сүзләрне урынлы-урынсыз транслитерацияләү белән мавыкмаска; икенчедән, биргән тәкъдирдә, фәнни транскрипция нигезендә эшләү таләп ителә. Бу очракта бер Гайнуллинны гына гаепләү гаделсезлек булыр иде, биредә шушы көнгә хәтле татарча-русча транслитерация кагыйдәләрен эшләп бирмәгән телчеләребез гаепләрәк шикелле.

Икенче төр төгәлсезлек итеп гарәпчә «аль-әл» артикленең гел «эль-эл» формасында бирелүен күрсәтергә мөмкин. Дөрес, XVIII—XIX гасырларда руслар шулай язганнар иде, әмма хәзер һәрбер азмы-күпме грамоталы хезмәттә гел «ал» яисә «аль» рәвешендә бирелә. Шуңа күрә безгә дә хәзерге рус грамматикасы кагыйдәләреннән чыкмаска кирәк.

Кимчелекләрнең өченчесе итеп фәнни аппарат булмавын күрсәтәсе килә. Мәсәлән, китап азагында библиография бирелеп, бу китапта телгә алынган шәхесләр, газета-журнал һәм әдәби әсәрләрнең исемнәренә төзелгән махсус күрсәткечләр тәкъдим ителсә, китапның гыйльми культурасы бик күтәрелеп, аннан файдалану мөмкинлекләре киңәер иде. Гыйльми аппарат исрафчылык яисә коры педантлык түгел, бәлки югары эш культурасының мөһим бер чарасы.

Хезмәттә очраган кайбер хосусый җитешсезлекләргә, мәсәлән, «Асар»ны «Сочинение» дип ялгыш тәрҗемәләүгә, «Сәмруг кош»ын «Орел» (55 бит), «Сарыф»ны «Этимология» дип (190 бит) уңышсыз аңлату кебек аерым төгәлсезлекләргә тукталып тормыйбыз. Чөнки безнең максат ул китаптагы хәреф хатасын чүпләү түгел, бәлки китап чыгу мөнәсәбәте белән кайбер гомуми методологик һәм әһәмиятле фактик мәсьәләләр турында фикер уртаклашудан гыйбарәт иде. Хезмәтнең икенче басмасын матбугатка әзерләгәндә, автор югарыда әйтелгәннәргә игътибар итәр дигән өмет белән китапны ябабыз.

— — □ — —

Равил Фәхретдинов

# Болгар тарихына яңа истәлекләр

Дөньяда болгарларның бар икәнлегенә
ышансыннар,
Якты бәхетебезгә башкалар да көнләшсен-
нәр һәм омтылсыннар.

*Г. Тукай.*

*Татар халкының ерак гасырлардан килә торган бөек тарихы бар. Бу озын юлның кайбер өлешләре әле тулысынча ачыкланмаган, кайбер өлешләре яңача карауны, яңача бәяләүне таләп итә. Монысы, әлбәттә, киләчәк эше.*

*Туган халкыбызның борынгы заманнары турында татарча махсус китапларның юклыгын искә алып һәм журнал укучыларның күп санлы үтенечләрен канәгатьләндерү йөзеннән, «Казан утлары»ның икенче санында без Фуат Вәлиевнең «Борынгы бабаларыбыз кемнәр?» дип аталган мәкаләсен, 6 нчы санда «Археология докторы Альфред Халиков белән әңгәмә» дигән язманы бастырдык. Журналның бу санында без хөрмәтле укучыларыбызга яшь галим Равил Фәхретдиновның шушы хезмәтен тәкъдим итәбез.*

Журнал редакциясе

### ТАРИХНЫ ӨЙРӘНҮГӘ КЕЧКЕНӘ СӘЯХӘТ

...921 нче елның май урталары. Багдад шәһәренә еракта, кайдадыр Идел буена урнашкан Болгар дәүләтеннән илче килеп төшә. Илче Багдад хәлифенә Болгар ханы Алмыш ханнан ике хат тапшыра. Габбаслар династиясе хәлифе Җәгъфәр әл-Мөкътәдиргә язган хатында Алмыш хан Болгар илендә ислам дине тарату һәм мәчет салдыру өчен белгеч сорый, шулай ук үз дошманнарыннан саклану өчен ныгытма корырга акча белән ярдәм итүне үтенә.

Бу вакытта инде Багдадта Идел буе болгарлары турында, Болгар ханының ислам дине кабул итүе хакында ишеткән булалар. Алмыш ханның хаты хәлиф сараенда зур кызыксыну тудыра һәм гарәпләр өчен киң политик мөмкинлекләр ача.

X йөз башына таба Багдад хәлифәлеге үзенең элекке көчен югалта башлый. Азербәйҗан, Саманилар дәүләте һәм Харәзем, хәлифне рәсми рәвештә тануларын дәвам итсәләр дә, чынында инде мөстәкыйль дәүләтләр булып әверелә баралар. Хазар (Кас-

пий) диңгезе буйларында, Тәбарстанда тынычсызлык башлана: ерак Төньяк белән сәүдә юлларын Хазар дәүләте каплап тора. Әмма шул ук Хазарда һәм аларның көнчыгыш күршеләре булган угызларда исламга якынаю көчәйгәннән-көчәя. Шуңа күрә сарай әһелләре Европа белән Азия арасындагы әһәмиятле сәүдә юлларын үз кулларында тотып торучы хазарлар, угызлар һәм болгарлар арасында ислам дине тарату Багдад хәлифәлегенең халыкара хәлен һәм политик нигезен ныгытачак, әлеге төрки халыкларны гарәпләр империясенә буйсындырачак дип өметләнәләр.

Менә шуларны истә тотып, Багдадта болгарларга илчелек җибәрергә карар бирәләр. Илчелекнең башлыгы итеп Сусан әр-Расси, киңәшче һәм секретарь итеп Әхмәт Ибн-Фадлан билгеләнә. Оста дипломат Ибн-Фадлан чынында илчелекнең иң ышанычлы житәкчесенә әверелә. 5000 кешедән һәм, дөяләрне санамыйча, 3000 аттан торган кәрван 921 нче елның июль аенда Багдадтан чыгып китә һәм Бохара, угыз, бәҗәнәк, башкорт җирләре аша үтеп, гомердә күрмәгән авырлыклар кичереп, бер ел дигәндә, ягъни 922 нче елның 12 нче маенда Болгар ханының җәйге торак урынына[1] килеп житә.

Гарәп илчеләре Болгарда рәсми рәвештә ислам дине кабул итүдә катнашалар. Илчелек 923 нче елда кире Багдадка әйләнеп кайта. Ләкин Багдад илчеләренең вакыт уздырып, акча туздырып йөрүләре хәлиф хөкүмәте өчен нәтиҗәсез кала: угызлар ислам дине кабул итмиләр; Хазарда мөселманнар партиясе таркатыла; ныгытма кору өчен соралган акча килеп житмәү аркасында, Алмыш хан хәлифкә булган ышанычын югалта һәм Урта Азия белән элекке элемтәсендә кала.

Әйе, гарәпләр империясе өчен бу илчелекнең әллә ни нәтиҗәсе булмый. Әмма тарих өчен, бигрәк тә татар халкының борынгы тарихы өчен бу илчелекнең әһәмиятен берни белән дә бәяләү мөмкин түгел. Ибн-Фадлан үзенең күргәннәрен җентекләп язып чыга. Үзенең язмаларында ул төрки халыкларның (угыз, бәҗәнәк, башкорт, болгарларның) һәм русларның көнкүрешләрен, гореф-гадәтләрен, йолаларын һ. б. бәйнә-бәйнә тасвирлап бирә. Ибн-Фадлан язмалары ул безнең борынгы бабаларыбызның берсе булган болгарлар турында иң кызыклы һәм иң ышанычлы язма документ булып исәпләнә. Болгар дәүләтенең язма тарихы Ибн-Фадланнан башлана дисәк, һич тә ялгыш булмас. Билгеле, Ибн-Фадланнан башка, X йөздә һәм аннан соңрак яшәгән гарәп, иран, төрки географлары, тарихчылар һәм тел галимнәре дә Идел — Чулман буе болгарлары турында азмы-күпме мәгълүматлар калдырганнар. Җөмләдән: Ибн-Рүстә, әл-Мәсхүди, әл-Истахри, Ибн-Хәүкаль, әл-Бәлхи, Мөкатдәси, әл-Бәкри, Ибн-ән-Нәдим, Мәхмүт Кашгари, бөек географ Идриси, әл-Гарнати, Әбү-әл-Фида, Ибн-әл-Әсир, Җүәйни, әл-Гомәри, Ибн-Батута, мөселман урта гасырының бөек тарихчысы Рәшидетдин һ. б.

Атаклы гарәп сәяхәтчесе һәм дипломаты Ибн-Фадланның язмалары белән бер без генә түгел, бөтен дөнья галимнәре кызыксына. Әйтергә кирәк, Ибн-Фадлан белән кызыксыну бик иртә башлана. Болгарларга булган сәяхәттән соң 300 ел чамасы үткәч (1215 нче елда) әлеге язмалар гарәп энциклопедисты Якут әл-Хәмави кулына төшә. Ул аны көнчыгыш илләрдә сәяхәт кылып йөргәндә, Урта Азиянең Мәрв шәһәрендәге бай китапханәләрнең берсендә таба. 1224 нче елны тәмамлаган атаклы «Географик сүзлек» исемле китабында Якут, кайбер җирләрен кыскартып, кайбер җирләрендә үзеннән аңлатмалар биреп, Ибн-Фадлан язмаларын да кертә.

Якут үлеп, биш-алты гасыр үткәч, Европаның берничә китапханәсендә аның «Географик сүзлеге» табыла. 1814 нче елда Дания башкаласы Копенгагенда Я. Расмуссен, Якут сүзлеге буенча, Ибн-Фадлан язмаларын тәрҗемә итә. Расмуссен тәрҗемәсе тиз арада Европа галимнәренең игътибарын җәлеп итә һәм озакламый Ибн-Фадлан «Рисаләсе» швед, инглиз, латин телләрендә дә басылып чыга.

XIX йөздә Ибн-Фадланны өйрәнүдә Россия академигы Х. Френ аеруча зур хезмәт күрсәтә. Моңарчы рус елъязмалары һәм тарихчы В. Н. Татищев әсәрләре буенча гына билгеле булган Болгар тарихы Френның 1832 нче елда чыккан хезмәтеннән соң фән дөньясында зур кызыксыну уята. Якут сүзлегендәге язмаларга карата төрле телләрдә тагын берничә фәнни хезмәт языла. Билгеле, галимнәр арасында Ибн-Фадлан сәяхәтнамәсенең дөреслегенә шөбһәләнүчеләр дә була. Ләкин В. Г. Тизенгаузенның һәм

---

[1] Хәзерге Татарстан АССР Куйбышев районы Өч күл авылы тирәсе.

В. Р. Розенның андый шөбһәләнүчеләргә карата үтергеч тәнкыйть мәкаләләреннән соң Ибн-Фадланның даны тагын да күтәрелә[1].

Шәрык чыганаклары һәм рус елъязмаларындагы мәгълүматлар XIX гасырда әле яңа гына туып килә торган археология фәне мәгълүматлары белән исбатлана башлый. Идел буеның фәнни үзәгенә әверелгән Казан шәһәрендә рус һәм татар галимнәре, шулай ук укытучылар, офицер-топографлар, студентлар һәм башка һәвәскәрләр шәһри Болгар, Иске Казан, тагын башка шәһәрләр, кабер ташлары, хәзинәләр турында төрле мәгълүматлар җыялар, шул турыда матбугатта язып чыгалар. Фәнни экспедицияләр оештырыла, музей заллары болгар-татар материаль культура калдыклары белән баый, шәхси коллекцияләр һәм китап киштәләре тулыландырыла.

Ләкин болгар һәм татар халкының борынгы истәлекләре белән тирәнтен кызыксыну илебездә Бөек Октябрь революциясеннән соң гына башлана. Совет властеның беренче елларында Галимҗан Ибраһимов җитәкчелегендәге Гыйльми үзәк бу юнәлештә шактый эшләр башкара. Соңрак Болгар турында зур хезмәтләр күренә башлый. Мәскәү профессоры А. П. Смирнов болгар тарихы буенча докторлык диссертациясе яклый һәм зур монография яза.

1945 нче елда археологларның Бөтенсоюз киңәшмәсендә Казан тарихчылары алдына Татарстанның археологик картасын төзү бурычы куела. Н. Ф. Калинин җитәкчелегендә Татар археологик экспедициясе республикабыз җирләрен тоташтан өйрәнә башлый: Казан артының Ашыт, өлешчә Казан суы, Мишә һәм Кама буйлары, Тау ягының Зөя, Кама аръягының Бездна, Актай елга буйлары тикшерелеп, 200 дән артык болгар-татар археологик истәлеге табыла.

## АРХЕОЛОГИЯ ҺӘМ БОРЫНГЫ БОЛГАР ҖИРЛӘРЕ

Моннан 1400 еллар элек, ягъни VI йөздә Азак (Азов) һәм Түбән Дон буенда «Бөек Болгар» дигән дәүләт оеша. «Бөек Болгар» озак яши алмый, VII йөздә үзеннән көчлерәк булган хазарлар тарафыннан җиңелә һәм таркалуга дучар ителә. Болгарларның Аспарук җитәкчелегендәге бер төркеме хәзерге Болгар халык республикасы урнашкан Дунай буена китә һәм шундагы көньяк славяннарны үзенә буйсындыра. Әмма алар күп санлы славяннар арасында әкренләп йотылалар, һәм ул болгарларның бары тик исемнәре генә сакланып кала. Икенче төркем Азактан Төньяк Кавказга таба күченә. Хәзерге көндә анда яшәүче балкарларны шул болгарларның токымнары дип уйлыйлар. Өченче төркем безнең якларга — Урта Идел һәм Түбән Кама буена таба юнәлә. Алар монда утракланып калалар, һәм килүләренә берничә гасыр үткәч, IX йөз ахыры — X йөз башларында болгарлар башлыгында төньяк-көнчыгыш Европада тарихта беренче феодаль дәүләт барлыкка килә. Бу дәүләтнең кыскача башлангыч тарихы моңарчы кайбер язма истәлекләргә таянып яктыртылды, һәм бу тарих күпләргә таныш. Әмма язма истәлекләр генә безнең бабаларыбыз тарихына кагылышлы сорауларга җавап биреп бетерә алмыйлар. Менә шунда инде археология ярдәмгә килә.

1950 нче еллар ахырында Казан археологлары тарафыннан Тәтеш районы Олы Тархан авылында казылган борынгы каберлекнең бу якларга килеп чыккан болгарларга караганлыгы ачыкланды. Иделнең сул ягында, Утка елгасы буендагы Танкеевка авылында табылган каберлек тә Болгар тарихының беренче чорына карый. Ләкин бу

---

[1] 1924 нче елда яңа хәбәр тарала — Көнчыгыш Иранның Мәшһәд шәһәре китапханәсендә Ибн-Фадланның моңарчы югалган дип саналган китабы табыла. Мәшһәд китапханәсенә бу кулъязма 1656—57 нче елларда Ибн-Хатун атлы бирәү тарафыннан тапшырыла. Аның ерак бабаларыннан берсе Якут файдаланган Мәрв китапханәсенең хуҗасы булган. 1935 нче елда шушы язмаларның фотокопиясе Иран хөкүмәте тарафыннан СССР Фәннәр академиясенә тапшырыла һәм илебезнең күренекле мөстәшригы А. П. Ковалевский тарафыннан тәрҗемә ителеп чыгарыла (Путешествие Ибн-Фадлана на Волгу, М.-Л., 1939). Шулай да Мәшһәд кулъязмасы Ибн-Фадланның үз кулы белән язылган нөсхә булмый, чөнки XII йөздә Ибн-Фадлан язмаларының күчермәсен биргән Нәҗип Һәмадани һәм XVI йөз күчерүчесе Әмин Рази китапларында Мәшһәд язмасында очрамаган хәбәрләр дә бар. Шуларны истә тотып, А. П. Ковалевский 1956 нчы елда Мәшһәд кулъязмасы, Якут сүзлегенә кертелгән кулъязма, Һәмадани һәм Рази күчермәләре нигезендә, Ибн-Фадлан «Рисалә»сенең төп нөсхәсенә якын тәрҗемәне бирә (А. П. Ковалевский. Книга Ахмеда Ибн-Фадлана о его путешествии на Волгу в 921—922 гг., Харьков, 1956).

зур каберлек Олы Тархан каберлегеннән аерыла. Танкеевка каберлеген калдырган кабиләләрнең Болгар дәүләте тарихына ни дәрәҗәдә кагылышлы булуы әле ачыкланып бетмәгән. Тарих фәннәре докторы Альфред Халиков фикеренчә, бу каберлек безнең бу якларга болгарлардан элегрәк күченеп килгән икенче бер төрки кабиләнеке булса кирәк. Әмма ул заманнарда Урта Иделдә яшәгән кабиләләр болгарлар житәкчелегендә аерым бер культура һәм дәүләт төзегәнлектән, бу дәүләтнең халкы да болгар исеме белән йөртелә башлаган.

Безгә, республикабызның археологик картасы белән бергә, Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгының археологик истәлекләре картасын да төзү кирәк иде. Шуңа күрә 60 нчы елларда Татарстан җирләрен археологик яктан өйрәнү моңарчы булмаганча көчәеп китте. Бүгенге көндә Урта Идел һәм Түбән Кама районында йөз елдан артык эзләнүләр нәтиҗәсендә 1435 болгар археологик истәлекләр: шәһәр һәм авыл урыннары, каберлекләр, кабер ташлары, хәрби ныгытмалар, акча яки әйбер хәзинәләре мәгълүм. Менә шуларның 1152 се Бөек Ватан сугышыннан соң Казан археологлары тарафыннан табылды һәм аның да 760 ы 60 нчы елларга туры килә. Соңгы ике-өч ел эчендә бу мәкаләнең авторы тарафыннан Кама аръягы, ягъни монголларга кадәрге Идел Болгарының үзәк җирләре тикшерелде һәм бу тикшерү фән өчен күп кенә материал бирде. 1964 нче елда миңа борынгы Болгар, Суар, Бүләр шәһәрләре тирәләрен: Утка, Бездна буйларын, Майна һәм Кече Чирмешәннең югарыгы һәм урта өлешләрен аркылыга-буйга йөреп чыгарга туры килде. 1965 нче елда экспедиция Татарстанның, Ульяновск һәм Куйбышев өлкәләренең тагын да көньяктарак һәм көнчыгыштарак урнашкан районнарына үтеп керде. Без моңарчы археолог аяк басмаган Кече Чирмешәннең түбәнге өлешен, Олы Чирмешән, Зәй, Шушма буйларындагы истәлекләрне өйрәндек. Шушы ике елда гына да 479 археологик истәлек, шул исәптән, 18 шәһәр һәм 260 авыл урыны табылды. Бу саннар үзләре генә дә әлеге җирләрдә болгарларның бик тыгыз утырулары, алар тормышының бик җанлы баруы турында сөйли булса кирәк. Шул ук вакытта 1964—65 нче еллардагы археологик тикшеренүләр Идел — Чулман буе болгарларының үзәк җирләрен һәм Болгар дәүләтенең көньяк-көнчыгыш чикләрен билгеләү өчен хәлиткеч мәгълүматлар бирде. Соңгы елларда җыйналган материаллар шулай ук безнең борынгы җиребездә феодаль мөнәсәбәтләрнең кайчан, ничек формалашуы мәсьәләсенә дә ачыклык кертәләр. Экспедиция туплаган коллекцияләрне, бигрәк тә керамиканы, ягъни балчык савыт-сабаларны элегрәк башка районнарда җыйналган материал белән чагыштырып карагач, аларның бер үк типта икәнлеген аңлау кыен түгел. Димәк, Казан артында да, Тау ягында да, Кама аръягында да — бөтен Болгар җирендә материаль культура бер үк төрдә булган дип әйтергә безнең тулы нигезебез бар.

Түбәндәге рәсемдә Болгар һәм Казан ханлыгы үзәк җирләренең археологик картасы бирелә. Картага бары тик халыкның утрак тормыш белән бәйле истәлекләре генә: шәһәр һәм авыл урыннары, ташлы яки ташсыз каберлекләр һәм аерым кабер ташлары гына кертелде. Картаны артык чуарламау өчен, күп сандагы аерым табылдыклар һәм төрле хәзинә урыннары күрсәтелмәде[1].

Болгар дәүләтенең төп халкы монголларга кадәрге чорда (X йөздә һәм XIII йөзнең I яртысында) хәзерге Татарстанның көнбатыш Кама аръягында[2] һәм Тау ягының Зөя суы урта агымында[3], өлешчә Каманың уң ягында, шулай ук хәзерге Ульяновск, Куйбышев өлкәләрендә һәм Чувашстан АССРның көньяк-көнчыгыш почмагында яшәгән.


Чорның беренче яртысында, ягъни X—XI йөзләрдә Болгарның төньяк чикләре Кама елгасының уң як яры буйлап (Кама кушылдыкларының түбән агымнарын да

---

[1] Болгар һәм Казан ханлыгы археологик истәлекләренең тулы картасын төзү өчен авторга соңгы көннәргә кадәр үткәрелгән барлык экспедицияләрнең материалларын карап чыгарга, шулай ук йөз ел буена тупланып килгән һәм Мәскәү, Ленинград, Казан, Куйбышев, Ульяновск, Пенза, Чабаксар музейларында урын алган барлык болгар-татар археологик истәлекләрен җыйнарга туры килде. Картага шулай ук Хельсинки музеенда тупланган һәм 1961 нче елда Альфред Халиков өйрәнеп кайткан күп санлы аерым табылдыклар да кертелде. Бу тулы карта югарыгы рәсемдә күрсәтелгән картадан зуррак һәм аңа, үзәк җирләрдән башка, халык сирәгрәк утырган көньяк һәм көнчыгыш районнарның истәлекләре дә керә.

[2] Куйбышев, Алексеевск, Әлки, Аксубай, Норлат, Чистай районнары.

[3] Буа, Тәтеш районнары.


Идел-Кама Болгары
һәм Казан ханлыгы
үзәк җирләренең
археологик картасы
Масштаб
Шартлы билгеләр
Шәһәр урыннары
Авыл урыннары
Каберлекләр, зиратлар
Кабер ташлары сакланган зиратлар
Аерым кабер ташлары
Монголларга кадәрге чор истәлекләре (X–XIII гасырның I яртысы)
Алтын Урда чоры истәлекләре (XIII г. II яртысы – XV г. I яртысы)
Ике чорга да караган истәлекләр
Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чоры истәлекләре
Казан ханлыгы чоры истәлекләре
Татарстан АССР чикләре
Иң әһәмиятле болгар-татар шәһәрләре
1. Болгар
2. Тукчин
3. Суар
4. Нократ
5. Булəр
6. Җүкәтау
7. Тубылгытау
8. Ашлы (Ошель)
9. Кашан
10. Казан
11. Иске Казан
12. Арча
13. Кирмәнчек
14. Алабуга (Шайтан шәһәре)
Идел
Кама (Чулман иделе)
Вятка (Нократ иделе)
Чувашстан АССР
Була
Зөя
Майна
Мишә
Агыйдел

кертеп), хәзерге Алабуга шәһәренә кадәр кутәрелгән. Ул урында болгарлар үзләренең төньяк-көнчыгыш чикләрен саклау өчен терәк пункт — шәһәрчек корганнар; бу шәһәрчекнең калдыгы фәндә «Шайтан шәһәре» («Чертово городище») исеме белән мәгълүм. Борынгы Болгарның көнчыгыш чикләре Зәй елгасының түбән агымыннан Шушма елгасына таба һәм Шушманың урта агымы буйлап үткән. Көньяк-көнчыгыш чикләр Олы Чирмешәннең югары агымыннан елга буенча түбәнгә таба сузылган һәм Идел буйлап бераз көньяккарак дәвам иткән дә Самар тугае белән чикләнгән. Биек Жигули таулары белән капланган һәм Иделнең зур борылышын эченә алган Самар тугае Болгар җирләрен көньяк күчмә кабиләләр һөҗүменнән саклау өчен бик уңай хәрби район булган. Монда, билгеле, хәрби ныгытмалар гына түгел, халык яши торган зур шәһәрләр, авыллар да урнашкан булган. Шулар арасыннан 1928—29 нчы елларда профессор В. В. Гольмстен тарафыннан казылган һәм үзенең зурлыгы буенча Суар шәһәре мәйданына якын торган «Муром шәһәре»н күрсәтеп үтәргә була.

Болгарның X—XI йөзләрдәге көнбатыш чикләре Самар тугаеннан Идел буйлап югары күтәрелгән дә, Зөянең урта агымына кадәр килеп җиткән. Зөянең сул як кушылдыклары — Цильна, Карлы һәм Була буйларында болгарларның иң көнбатыш истәлекләре урнашкан. Тагын да көнбатышка табарак, ягъни хәзерге Чувашстан җирендә болгар истәлекләре юк. Сүз уңаеннан чувашларның Болгарга ни дәрәҗәдә катнашы булу-булмау мәсьәләсенә тукталып китик.

Чувашстан территориясен археологик яктан начар тикшерелгән дип әйтеп булмый, киресенчә, анда инде озак еллар буена археологик эзләнүләр алып барыла. 20—30 елларда Ленинград, 40—60 нчы елларда Мәскәү һәм Саратов археологлары, ә соңгы 1964—65 нче елларда Казан археологларыннан Һарун Юсупов, П. Н. Старостин һәм бу юлларның авторы тарафыннан тикшеренүләр ясалды. Археологик тикшеренүләрнең нәтиҗәсе шуңа кайтып кала: болгарлар Чувашстан АССРның көньяк-көнчыгыш өлешендә генә яшәгәннәр[1]. Шушы Була елгасы буенда болгарларның утрак тормышына бәйле булган 18 археологик истәлек бар. Барлык болгар истәлекләренең 1435 икәнлеген, шуларның 1145 енең хәзерге Татарстан җирендә урнашканлыгын искә төшерсәк, Болгар культура мирасының татарларгамы яки чувашларгамы карагаилыгын аңлавы кыен булмас кебек[2]. Шулай ук эпиграфик материалның, ягъни кабер ташлары сакланган зиратларның һәм аерым кабер ташларының урнашуына игътибар итсәк тә, шактый гыйбрәтле нәрсә күзгә ташлана. Мәсәлән, Болгарга караган 78 эпиграфик истәлекнең бары тик өчесе генә Чувашстан — әлеге дә баягы шул Була елгасы буена туры килә. 72 истәлек Татарстанда, берәр истәлек Киров, Ульяновск өлкәләрендә һәм Башкорстанда. Казан ханлыгы чорына караган эпиграфик истәлекләрнең барысы да Татарстан җирендә табылдылар (картаны кара). Галимнәр, әлеге кабер ташларының композициясе һәм стиль үзенчәлекләрен тикшереп карагач, татар эпиграфикасының болгар эпиграфикасы нигезендә үсүен ачыклый алдылар. Монда тагын шуны да истә тотарга кирәк: корьән сурәсеннән өзекләр язылган бу кабер ташлары мәҗүсилек динендә булган чувашлар каберенә түгел, бәлки ислам динендәге болгарлар һәм татарлар каберенә куелган булганнар.

Кайбер чуваш тарихчылары, бөтен Чувашстан җирендә борынгы болгарларның «яшәгәнлеген» исбат итәргә теләп, ачыктан-ачык тенденциоз юлга басалар. Алар Чуваш республикасының үзәк һәм төньяк районнарында урнашкан берничә археологик истәлекне IX—X йөзләрдәге болгарларныкы итеп күрсәтәләр. Әлеге археологик истәлекләрдән җыелган коллекцияне былтыр җентекләп тикшереп караганнан соң, аларның борынгы болгарларга бернинди катнашы булмавы ачыкланды. Болгар — XIII—XV йөзләргә караган җирле культурага, ягъни чувашларга кагылышлы истәлекләр.

Хаклы рәвештә шуны әйтергә мөмкин: археология материаллары болгар культура мирасының чуваш культурасында дәвамы турында сөйләми. Кечкенә Була елгасы буен-

---

[1] Тагын бер шәһәр калдыгы Татарстан һәм Чувашстан чигендә, Әлмән исемле зур татар авылы янында, ә бер авыл урыны Чувашстанның төньяк-көнчыгышында, Идел буенда табылган. Бусы болгарларның Идел буендагы аерым сәүдә пункты булган. Мондый сәүдә урыннары хәзерге Горький шәһәре тирәләренә кадәр барып җиткәннәр. Ләкин теге яки бу халыкның килеп чыгуы мәсьәләсенә бу аерым-аерым утырган шәһәр һәм авылларның бернинди катнашы юк.

[2] Болгар археологик истәлекләренең калган өлеше Ульяновск, Куйбышев өлкәләрендә, берничә истәлек Башкортстан һәм Мари республикаларында урнашкан.

дагы истәлекләрне искә алмаганда, Чувашстан җирендә монголларга кадәрге чорның да, Алтын Урда чорының да болгар истәлекләре юк. Була буендагы берничә хәрби ныгытма һәм дистәдән артык авыл урыннарына килгәндә, аларны болгарларның тирә-як халыкларга, шул исәптән чувашлар арасына үтеп керүе һәм теге-бу формада йогынты ясавы белән аңлатырга кирәк. Гомумән, мари, мордва, чуваш, удмурт һәм башкорт халыклары болгарларның политик, экономик һәм культура йогынтысында булганнар. Бу йогынты шулай ук русларда да күренә. Кайбер халыклар, мәсәлән, буртаслар болгарларга ясак та түләп торганнар. Мордваларның ике зур төркемгә бүленеп, Пуреш исемле би җитәкчелегендәге көнбатыш төркеменең руслар йогынтысында, ә Пургас би җитәкчелегендәге көнчыгыш төркемнең болгарлар йогынтысында булуы мәгълүм. Шәрык географларының күрсәтүенчә, көнбатыш башкортлар да болгарларга буйсынганнар. Үзләренә буйсынган халыкларның җирендә болгарлар, югарыда әйтелгәнчә, хәрби һәм сәүдә пунктлары кора торган булганнар.

Болгарлар биләгән уңдырышлы җирләр иген игү өчен бик уңай була. Болгар авыл хуҗалыгында игенчелек тора-бара төп тармакка әйләнә. Болгарлар тире, күн, балык, агач, керамика белән генә түгел, ашлык белән дә сату итәләр. Мәсәлән, рус елъязмаларыннан күренгәнчә, 1024 һәм 1229 нчы елларда Владимир-Суздаль җирендә ачлык куркынычы килеп тугач, болгарлар русларга ашлык сатканнар. Әйтергә кирәк, ашлык җитештерү соңга таба да Болгар экономикасының нигезен тәшкил иткән. Атаклы совет галиме, көнчыгыш илләр белгече А. Ю. Якубовский Болгарны бөтен Алтын Урданың иң бай икмәк районы булган, ди. X йөздә яшәгән шәрык географларының язуларына караганда, болгарлар бигрәк тә бодай, арпа, тары чәчкәннәр. Соңгы еллардагы археологик казулар бу хәбәрнең дөреслеген раслыйлар. Сакланып калган орлыклар арасында иң күбе бодай орлыгы икәнлеге билгеле булды.

Бодай, билгеле булганча, кара туфраклы җир таләп итә. Урта Идел географик районының туфрак картасына күз салсак, иң уңдырышлы, кара туфраклы җирләрнең урман-дала һәм даладан торган Көнбатыш Кама аръягына һәм Зөя суының урта агымына («Буа далалары»на) туры килгәнлеген күрербез. Бу районнар, югарыда күреп үтелгәнчә, Болгар иленең үзәк җирләре.

Болгарның үзәк җирләре игенчелек өчен уңай булуы белән генә аерылып тормый. Монда Көнчыгыш Европаның иң зур сәүдә юллары булган Идел белән Чулман бергә кушыла. Биредә төрле яклардан килгән төрле илләрнең сәүдәгәрләре очрашкан. Болгар дәүләте шәрык дөньясының руслар һәм төньяк халыклар белән сәүдә юлларын үз кулында тоткан. Шәһри Болгар һәм аның тамгасы (пристане) Агабазар иң зур елга портларыннан исәпләнгән. Бүләр һәм Суар аркылы кәрван юллары үткән.

Менә шушы санап үтелгән уңайлыклар Болгар дәүләтенең үсүендә, көчәюендә хәлиткеч рольне уйнаганнар.

XII йөздә һәм XIII йөз башларында Болгарның дәүләт чикләре тагын да киңәя төшә. Моны бу вакытларда Болгарның халыкара хәле ныгуы, шулай ук социаль-экономик һәм культура йогынтысының көчәюе белән аңлатырга кирәк. Болгар территориясе, башлыча, көньяк-көнчыгыш дала җирләре хисабына киңәйгән. Бу җирләр элек я бөтенләй буш торганнар, яки анда күчмә кабиләләр яшәгән. Рус елъязмасының хәбәр итүенчә, Болгар җирләре көнчыгышта Агыйдел буена кадәр барып җиткән [1]. XIII йөз башларында, ягъни монгол яулары килер алдыннан, Агыйдел буенда болгарларның яшәве турында татар халкының «Хан кызы Алтынчәч» исемле легендасы да бик яхшы сөйли. 50—60 нчы еллардагы эзләнүләр нәтиҗәсендә Агыйдел һәм Ык елгаларының түбәнге өлешләрендә XIII йөзгә караган берничә археологик истәлек тә табылды.

Болгарның көньяк-көнчыгыш чиге XIII йөзгә таба Җаек (Урал) елгасының урта агымына, хәзерге Оренбург тирәләренә кадәр сузылган булган. Бу турыда моңарчы рус елъязмалары буенча язып килделәр. Мәсәлән, Лаврентьев елъязмасы 1229 нчы елда болгарларның Җаек буенда монголлардан үз чикләрен саклаулары турында хәбәр итә. 1966 нчы елда миңа Археология институтының Ленинград бүлеге архивында булырга туры килде. Шунда мин Самар суы башланган җирдә (Җаек буенда) болгар

[1] Агыйделнең түбән агымын күздә тотарга кирәк.

археологик истәлекләре турында мәгълүматлар таптым[1]. Бу истәлекләр 1927 нче елда Самар археологик экспедициясе тарафыннан тикшерелгән һәм бу турыда моңарчы матбугатта язылмаган иде.

Агыйделгә һәм Җаекка кадәр сузылган җирләрне халыкның азрак урнашкан районнары дип уйларга кирәк. Үзәк территория булып болгарларның X—XI йөзләрдә билгән җирләре саналган.

XII йөз ахырында һәм XIII йөз башларында Тау ягында болгарлар төньяктарак һәм төньяк-көнчыгыштарак урнашкан районнарны били башлыйлар. Зөянең түбән агымында, аның уңъяк кушылдыклары булган Үләмә, Коры Үләмә буенда, мәсәлән, шәһәр һәм авыл калдыклары табылды. Япанчы, Чүри-Бәрәш, Олы Кариле янындагы шәһәр калдыклары[2], Түбән Барыш, Олы Күккүз, Бәки янындагы авыл урыннары шул турыда сөйли. Бу чорда Казан артының Мишә һәм Казан суы буйларына да болгарлар үтеп керә башлаганнар. Иске Казан урыныннан җыелган керамика һәм Мишә буендагы аерым табылдыклар моңа дәлил булып тора. XII йөз ахыры — XIII йөз башларында Казан артында болгарларның ни дәрәҗәдә таралган булуын әлегә өзеп кенә әйтүе кыен, чөнки бу җирләр археологик яктан тоташтан тикшерелеп бетмәгән. Ибн-Рустә язмалары буенча билгеле булган бөрсула исемле болгар кабиләсен Н. И. Ашмарин Каманың уң кушылдыгы Бөрсет елгасы белән бәйли. Рус кнәзе Всеволодның 1184 нче елда Буләргә һөҗүме вакытында бу шәһәргә ярдәмгә килгән саба, күли, тәмтез исемле болгар кабиләләрен С. М. Шпилевский, топонимика мәгълүматлары нигезендә, шушы ук Казан артының Мишә елгасы буена урнаштыра.

Менә шуларның барысын да истә тотсак, Казан артында болгарларның монголларга кадәрге чорда да яшәгәнлекләрен аңлап була. Киләчәктә бу археологик тикшеренүләр белән дә расланыр дип уйларга ныклы ышаныч бар.

Тагын бер нәрсәне искәртеп үтәргә кирәк. Ул заманнарда хәзерге кебек ныклы дәүләт чикләре булмаган, әлбәттә. Төрле кабиләләр арасындагы ызгышлар, феодаль сугышлар нәтиҗәсендә чикләр үзгәреп торган. Югарыда танышып киткән чикләр болгарларның үзләре яшәгән территорияне генә үз эченә ала.

Төньяк-көнчыгыш Европада бердәнбер феодаль дәүләт булган Болгарның политик, экономик йогынтысы көнбатышта Сура, аерым вакытларда — Үкә (Ока) елгаларына тикле, көнчыгышта исә Урал тауларына кадәр сузылган. Хазар каганаты яшәүдән туктагач, болгарларның тәэсире көньякта тагын да ераграк җәелгән. Мәхмүт Кашгари үзенең атаклы сүзлегендә Каспий диңгезен «Болгар диңгезе» дип атый.

## МОНГОЛЛАР КИЛГӘЧ

XIII йөзнең 20—30 нчы елларында Евразия халыклары тарихында кара көннәр башлана. Чыңгыз хан армиясе ташкын булып көнбатышка таба ыргыла. Урта Азияне, Иран, Азербайҗанны басып алганнан соң, монголлар 1223 нче елда Кавказдагы Ширван тарлавыгы аша кыпчак далаларына килеп чыгалар һәм Калка елгасында рус — кыпчак гаскәрләрен тар-мар итәләр. Шуннан соң монгол армиясе Болгар чикләренә юнәлә, ләкин уңышсызлыкка очрый. Ибн-әл-Әсирнең язуына караганда, болгарлар монголларның гаскәрен кырып салалар. Монголларның болгарларга һөҗүме 1229, 1232 нче елларда да кабатлана, ләкин алар барыбер уңышка ирешә алмыйлар. Бары тик Европаны яулап алу планы җентекләп тикшерелгәч кенә һәм империянең төп көче шушы якка юнәлдерелгәннән соң гына, монголларның атаклы гаскәр башлыгы Субутай җитәкчелегендәге армиясе 1236 нчы елны Болгар җирләрен басып ала. Ул заман вакыйгаларын үз күзләре белән күрүчеләрнең язмаларына караганда, монголлар яулап алынган җирләрдә коточкыч җимерүләр һәм җәзалаулар алып барганнар: чәчәк атып утырган шәһәрләр, авыллар талангач, яндырылган; сугару системалары, чәчүлек җирләр, бакчалар җимерелеп, тапталып беткәннәр.

Менә шушы вакыйгалардан соң болгарлар үзләренең элекке урыннарыннан төньяктагы тынычрак, урманлырак җирләргә күчеп китә башлыйлар. Болгарларның бер төркеме рус кнәзе Юрий Всеволодович җирләренә сыенып урын эзләп килә. Болгар халкы

---

[1] СССР Фәннәр академиясе Археология институтының Ленинград бүлеге архивы, ф. 44, № 5, лл. 33—38, № 8, лл. 376, 380—384.

[2] Шәһәр һәм хәрби ныгытма урыннары халык телендә «кала-тау» дип йөртелә.

Казан артына күпләп күчеп утыра. Монголларга кадәрге чорда төзелгән Кашан шәһәре зурая, Чулман һәм Нократ иделе (Вятка) кушылган җирдән ерак түгел Кирмәнчек шәһәре үсеп чыга. Казан суы буенда да шәһәрләр барлыкка килә. Урмәт авылы шәһәргә әйләнә, аңа каршы елганың икенче ягында, хәзерге Камай авылы янындарак ныгытма төзелә. Шушы ике өлештән торган Иске Казан шәһәренең зиратында 1281 нче елгы кабер ташы саклансан. Бүгенге Казанның селекция станциясе янындагы иске каберлектән 1297 нче елгы кабер ташлары табылуы күпләргә мәгълүм. Бу ташлар Алтын Бөртеге исемле кыз һәм Хәсән бәк исемле болгар бәгенә куелган булган. Каберлек белән янәшә, Кабан күле буенда, кечкенәрәк кенә болгар шәһәре дә булган. Аның ныгытмалары әле дә бар. Татар халык риваятьләре буенча, Кабан — шәһри Болгардан күчеп килгән болгар бәге булган. Шәһәрчек тә, шәһәрчек янындагы күл дә аның исеме белән аталып йөртелә башлаган.

Әмма Алтын Урда чорының беренче яртысында, ягъни XIV йөзнең урталарына кадәр, болгарларның күп өлеше үзләренең элекке җирләрендә яшәүләрен дәвам иттерәләр. Болгар дәүләте Алтын Урда составына кергәч һәм яулап алу сугышлары тынгач, халыкның тормышы яңадан җанлана башлый. Йөз ел буена Алтын Урда көчәю һәм тыныч яшәү чорын кичерә. Үзбәк хан заманында (1312—1342 нче еллар) Алтын Урда үзенең иң югары ноктасына ирешә. А. Ю. Якубовский әйтүенчә, бу дәүләтнең бөтен территориясендә — Харәземнән алып Кырымга кадәр — Үзбәк ханның авторитеты нык һәм көчле була. Болгар өчен дә бу — тынычлык һәм чәчәк ату чоры. Болгарның рус дәүләте белән дә мөнәсәбәте әйбәт һәм уңай шартларда бара. Кама аръягындагы элекке зур шәһәрләр Бүләр һәм Суар яңадан торгызыла, Бүләрдә хәтта акча да сугыла башлый. Җүкәтау, Түбылгытау исемле шәһәрләр үсеп китә. Шәһри Болгар иң нык көчәю, баю чорын кичерә. А. П. Смирнов тикшеренүләре күрсәтүенчә, бу шәһәрнең җир астында калган иң калын культура катламы шушы вакытка туры килә. Болгарда сакланган барлык архитектура истәлекләре дә (Җәми мәчет, Кече манара, Кара сарай һ. б.) XIII йөзнең ахыры — XIV йөзнең беренче яртысына карыйлар. Соңгы еллардагы тикшеренүләр нәтиҗәсендә Кама аръягында Алтын Урда чорына караган 50 дән артык авыл урыны табылды. Һарун Юсупов эзләнүләре күрсәтүенчә, XIV йөзнең беренче яртысына караган болгар ташларының күбесе шулай ук Кама аръягында.

Тау ягында да болгарлар яшәүләрен дәвам иттерәләр. Зөянең түбән агымы, Үләмә, Идел буйларында яңа шәһәрләр, авыллар барлыкка килә. «Мең өйле Шунгат» (Олы Әтрәч), Тәтеш, Әлмән, Тау иле, Япанчы, Танай-Турай, Бәрәш бу якларда урнашкан зур шәһәрләрдән саналганнар.

Соңгы вакытта А. П. Смирнов һәм В. Ф. Каховский чуваш культурасында болгар культурасы элементларының сакланмавын Иделнең уң ягында болгар шәһәрләренең «булмавы» белән аңлатырга тырыштылар. Бу дөрес түгел. Беренчедән, мондый кала-тауларның саны Тау ягында — Татарстанның көнбатышында шактый күп (картаны кара). Икенчедән, әлеге тарихчыларга Чувашстан җирендә болгар шәһәрләренең булмавы белән акланырга кирәк иде; татарлар яши торган урыннардагы кала-тауларның чувашларга бер катнашы да юк, лабаса!

---

Алтын Урда чорының икенче яртысы, ягъни 1360—1440 нчы елларны эченә алган йөзьеллык — Көнчыгыш Европа халыклары, шул исәптән болгарлар тарихында зур үзгәрешләр дәвере. Үзбәк ханның улы Җанибәк хан үтерелгәч, 1350 нче еллар азагында Алтын Урда башкаласы Сарай шәһәрендә чуалышлар башлана. 1359 нчы елда Җанибәкнең улы Бирдебәк хан үтерелә һәм бу ел бөтен Урдада тәртипсезлек, үтерешләр, фетнәләр, ызгыш-талашның башлану елы булып исәпләнелә. 1361 нче елда кайбер әмирләр үзәк дәүләттән аерылып чыгалар. Шул ук елны Булат Тимер Болгарны үз кулына ала [1]. 1388 һәм 1391 нче елларда Алтын Урда ханы Туктамышның

[1] «Азат хатын» журналының 1966 нчы ел 11 нче санында Д. Зөбәерованың «Болгар һәйкәлләре» дигән бер мәкаләсе чыкты. Шунда 1361 нче елда Алтын Урда ханы Аксак Тимер Болгарны талап китә дип язылган. Бу дөрес түгел. Беренчедән, Аксак Тимернең бервакытта да Алтын Урда ханы булганы юк. Ул үзе Алтын Урданы тар-мар китерә. Икенчедән, Аксак Тимер Идел буена 1391 нче елны гына килеп чыга. Шушы елны ул Туктамыш белән сугыш вакытында Кондырча елгасыннан да югары күтәрелми. Ә 1361 нче елда Болгарны алган Булат Тимер белән Аксак Тимер арасында бернинди уртаклык юк. Гомумән, бу мәкаләдә ялгышлар тулып ята.

Аксак Тимергә каршы сугышлары болгарларның да бик күп материаль һәм кеше көчен суырып ала. Русларның төньяк һәм төньяк-көнчыгыш өлкәләрендә елга юлбасарлары (ушкуйниклар) азынып китәләр. Кострома, Углич, Нижгород кебек рус шәһәрләре белән берррәттән, алар болгар шәһәрләрен дә талыйлар. 1359—1409 нчы еллар арасындагы 7 тапкыр һөҗүм нәтиҗәсендә юлбасарлар Болгар, Җукәтау, Кирмәнчек, Кашан шәһәрләренә зур зыян китерәләр. Рус кнәзе Федор Пестрый 1431 нче елда шәһри Болгарны соңгы тапкыр басып ала һәм бу данлы кала тарих битләреннән сызып ташлана.

Менә шундый бәла-казалар һәм халыкара хәлнең кискенләшүе Болгар экономикасына зур зыян китерә. Болгарның төп халкы төньяк районнарга — Идел, Кама һәм Вятка арасындагы «Казан арты»на, өлешчә Тау ягына һәм Вятка аръягына күчә. XIV йөзнең икенче яртысында Кама аръягында болгарлар күмеп калдырган күп санлы акча һәм әйбер хәзинәләре халыкның бу урыннарны ташлап китүләре турында сөйли. XIV йөзнең икенче — XV йөзнең беренче яртысына караган кабер ташлары Кама аръягында юк. Әйтергә кирәк, гомумән, шул заман социаль-экономик шартлар тәэсирендә болгарларда таш кую гадәте вакытлыча туктала. Андый ташлар сакланган зиратлар берничә генә һәм алар Казан артында табылдылар.

Болгар иленең политик, экономик һәм культура үзәге Казан артына — Мишә һәм Казан суы буйларына күчә. Иске Казан шәһри Болгар ролен үзенә ала һәм ул Яңа Болгар дип йөртелә башлый. Иске Казан биләмәсе болгарларның яңа җирләрдәге үзәк әмирлегенә әверелә. Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларын яктыртучы иң әһәмиятле елъязма булган Никонов елъязмасында «Казанлылар дип аталучы болгарлар» дигән сүзләр кызыл җеп булып сузыла. XVI йөз татар тарихчысы Хисаметдинның әйтүенә караганда, болгарлар Аксак Тимер һөҗүменнән соң Кама аръягыннан Урал буйларына, кыргыз далаларына, Идел алдына, бигрәк тә Казан артына күченеп утыралар. Бирерә Лаеш, Мамадыш, Алат исемле болгар бәкләре үзләренең яңа шәһәр-авылларын төзиләр. Хисаметдин шулай ук XIV гасыр ахырларында хәзерге Татарстанның иң төньяк елгасы булган Шушма буенда Хәсән Шәех, Балтач, Салавыч, Исмагыйль исемле болгар шәехләренең каберләре булуын яза[1]. «Янмый торган кыз» риваятендә һәм Иске Казан турындагы риваятьләрдә шәһри Болгар җимерелгәч, Алтын-бәк һәм Галим-бәк исемле угланнар җитәкчелегендәге болгарларның хәзерге Казан артына күчеп килеп, Иске Казанны салулары турында әйтелә. Шундый ук хәбәрләр Ибраһим Хәлфинның 1819 нчы елда басылган «Чыңгыз хан һәм Аксак Тимер хәлләре» җыентыгына һәм Каюм Насыйриның «Казан тарихы» кульъязмасына кертелгән татар риваятьләрендә дә бар. Мондый риваятьләр тарихи дөреслектән беркадәр читкә китсәләр дә, аларның һәркайсы болгарларның Казан артына күчеп утыруларын күрсәтүләре һәм бу хәлне XIV йөз ахыры белән бәйләүләре бик кызыклы.

Болгарларның бу якка күчеп килүләре археология мәгълүматлары белән дә раслана. Татарстанның төньягындагы Ашыт елгасы буенда XV йөзгә караган кабер ташлары табылды. Мишә елгасы буенда һәм Каманың уң як кушылдыклары буенда XIV—XV йөзләргә караган авыл урыннары шактый күп очрый. Ләкин Казан артының Алтын Урда чорына караган археологик истәлекләре, гомумән алганда, күп түгел. Моны борынгы болгар авылларының хәзерге татар авыллары астында калулары белән аңлатырга кирәк. Иске Казан[2], Казан кремле[3], Чаллы, Өтернәс шәһәр калдыклары һәм Казан суы, Мишә, Ашыт буендагы хәзерге татар авыллары моның ачык мисалы булып тора. Шуның белән бергә, Казан артының археологик яктан әле тулысынча өйрәнелмәвен дә истән чыгармаска кирәк.

Алтын Урда чорындагы Болгар тарихы турында сүз йөрткәндә, тагын шуны да әйтеп үтик. Ул заманда болгарлар барысы да төньякка күчеп беткәннәр һәм Кама аръягы бөтенләй бушап калган дип уйларга ярамый. Шәһри Болгар политик, эконо-

---

[1] Шул исемдәге татар авыллары Шушма буенда әле дә бар.

[2] Иске Казан соңгы тапкыр рус елъязмаларында 1535 нче елда искә алына.

[3] Хәзерге Казан урынында болгарларның ике шәһәрчеге булган. Берсе — югарыда телгә алынган Кабан шәһәрчеге, икенчесе — бүгенге Кремль урынында. Хәзерге Казан Иске Казан, Кабан шәһәрләреннән соңрак барлыкка килгән һәм XV йөзнең 40 нчы елларыннан Казан ханлыгының башкаласына әверелгән. Болардан башка Елан тавы дигән җирдә дә болгарлар яшәгән.

мик һәм культура үзәге ролен югалтса да, шулай да бөтенләй үк яшәүдән туктамаган. В. Н. Татищев 1480 нче елда русларның Урда ханы Әхмәт белән бәрелешләре вакытында Болгарга да керүләре, әмма анда халыкның инде аз булуы турында әйтә. XVI йөз татар шагыйре Мөхәммәдьяр үзенең «Нуры Содур» исемле поэмасын 1542 нче елда Болгарда яза. XVII йөз шагыйре Мәүла Колый да үзенең шигырьләрен 1617 нче елда Болгар тирәләрендә язуын әйтә. Европа сәяхәтчесе Олеарий 1637 нче елда безнең бу якларда булганда, Болгарны күрсәтеп үтә. Суар шәһәре яшәүдән туктагач та, аның берникадәр халкы шәһәрдән 3—4 чакрым читтәрәк аерым авыл корып яши биргән. Бу авыл урыны XIV—XVII йөзләргә карый. Чирмешән, Майна, Актай елгалары буенда утырган Алпар, Борнай, Чиябашы, Аппак, Парау, Кизләү, Иске Рәҗәп, Йорткүл, Янбакты, Салман кебек авылларны Болгар дәүләте чорыннан калган авыллар дип исәпләргә кирәк. Бу турыда без археология, тел һәм фольклор материаллары буенча беләбез. Әлеге авылларның болгар авыллары өстендә утырулары, аларның зиратларында XIV йөз болгар ташларының саклануы, халкының теле, борынгы болгар бабайлар турындагы риваятьләр — боларның барысы да моның ышанычлы дәлиле була ала.

## ИСКЕ КАЗАННАН ЯҢА КАЗАНГА

Мәгълүм булганча, Казан әмирлеге җирлегендә XV йөздә ханлык төзелә. 30—40 нчы еллардан башлап, ягъни Алтын Урда ханы Олы Мөхәммәтнең улы Мәхмүт Казанны басып алгач, бу ханлык рәсми рәвештә Казан ханлыгы дип атала башлый. Эчке чуалышлар һәм Аксак Тимернең хәлиткеч һөҗүмнәре нәтиҗәсендә Алтын Урда дәүләт буларак яшәүдән туктый.

Аерым тарих китапларында: Казан ханлыгы, Алтын Урда җирлегендә төзелгән дәүләт булганга күрә, аның халкы да Алтын Урда белән идарә иткән монгол-татарлар дип язып килделәр. Казан ханнарының Алтын Урда ханнары политикасын дәвам иттерүләре моңа дәлил булып тора дип аңлаттылар. Ләкин халыкара тормышта бер дәүләтнең икенче дәүләт политикасын дәвам итүе халыкның килеп чыгуы мәсьәләсен хәл итә алмый һәм идарәче даирәләрнең политикасына карап кына бөтен бер дәүләтнең халкы юкка да чыкмый, икенче халыкка да әйләнми. «Гражданлык җәмгыяте, гомумән, дәүләт тарафыннан тудырылмый һәм билгеләнми». (К. Маркс, Ф. Энгельс. Сайланма әсәрләр, II том, Казан, 1949, 368 бит.)

Казан ханлыгының территориясе Алтын Урда чорының икенче яртысында болгарлар яшәгән территориягә — Казан артына һәм Тау ягының төньяк-көнчыгыш өлешенә тәңгәл килә. Бу турыда без эпиграфик истәлекләр һәм Казан ханлыгы авылларының картасы[1] буенча белә алабыз. Казан ханлыгы Иван IV тарафыннан яулап алынганнан соң үткәрелгән сан алу кенәгәләре нигезендә эшләнгән бу картада 700 гә якын татар авылы бар. Аларның төп өлеше Казан артында (500 гә якын), өлешчә Тау ягында (150 чамасы), 20 авыл Кама аръягында һәм 10 авыл Вятка аръягында, ягъни Алабуга ягында. Бу җирләрдә татар авылларының шулай күп булуы әүвәл-әүвәлдән болгар авылларының яшәп килүе турында сөйли.

Иван Грозный армиясе 1552 нче елда Казанны басып алыр алдыннан, Казан артына да һөҗүм ясала. Шул җирләр турында Андрей Курбский болай дип яза: «Ул якларның һәр җирендә гаҗәп уңдырышлы һәм һәртөрле уңышларга бай кырлар күп. Әмир һәм байгураларның йортлары гаҗәеп матур һәм сокландыргыч; авыллар анда бик куе утырганнар. Ул җирләрдә чәчелгән ашлыкларның күплеге күктәге йолдызларга тиң; шулай ук анда терлекнең саны хисапсыз күп һәм кыргый җәнлекләрдән алына торган табышның күләме зур: сусар, тиен һәм тире яки ит өчен аулана торган башка киек. Янәдән ул җирләрдә кешләрне күп аулыйлар, бал җыялар»[2].

---

[1] Картаны СССР Фәннәр академиясе Казан тел, әдәбият һәм тарих институты өлкән гыйльми хезмәткәре Е. И. Чернышев төзеде. Карта институтның тарих секторында саклана.

[2] А. М. Курбский. Избранные сочинения, Спб., 1902, 21 бит. Шуңа охшашлы хәбәрләр XVI йөзнең I яртысына караган тагын ике истәлектә — «Казан тарихы» исемле китапта һәм Көнбатыш Европа сәяхәтчесе С. Герберштейн язмаларында да бар.

Казан татарларының шул замандагы тормышын һәм ул җирләрнең байлыгын сурәтләгән шушы кызыклы хәбәрдән без татарлар тормышында болгар культурасының һәм болгар көнкүреш традицияләренең дәвам итүен күрәбез. Монда да болгардагы кебек еш утырган авыллар, болгар экономикасында һәм сәүдәсендә зур роль уйнаган шул ук сусар (Ибн-Рүстә), кеш (Ибн-Фадлан), болгарларның яраткан азыгы, эчемлеге булган бал (Ибн-Фадлан, Мәхмүт Кашгари). Иң әһәмиятлесе — экономиканың нигезен тәшкил иткән һәм киң мәйданга таралган игенчелек. Боларның барысы да — болгар-татар культура һәм экономикасының бер-береннән аерылгысыз өлешләре.

Археологик картага күз төшергәч: ни өчен шәһәр калдыклары болгар чорында бик күп, ә Казан ханлыгы чорында, киресенчә, аз? дигән сорау туарга мөмкин. Моңа шулай җавап бирергә туры килә. Кама аръягындагы һәм Зөя суының урта агымындагы шәһәр урыннары бу якларга XVI—XVIII йөзләрдә, ягъни болгарлар күченеп киткәч килгән рус, мишәр-татар һәм чуваш авыллары астында күмелеп калмаган. Ә Казан артындагы һәм Тау ягының төньяк һәм көнчыгыш өлешендәге Казан ханлыгы чоры торак пунктлары, югарыда әйтелгәнчә, элекке болгар шәһәрләренең, болгар авылларының дәвамы булып торалар. Тора-бара бу шәһәрләрнең ныгытмалары, соңыннан барлыкка килгән йортлар һәм сукаланган бакчалар астында калып, тигезләнеп беткәннәр.

Мәсьәләнең тагын шул ягы бар — М. Г. Худяковның бик дөрес күрсәтеп үтүенчә, Казан ханлыгы заманы өчен гомумән ачык, ягъни хәрби ныгытмалары булмаган шәһәрләр хас. Иске Казанның төп өлешен (1 200 000 $м^2$) биләгән Үрмәт авылы урыны моның ачык мисалы булып тора. Шул ук вакытта XV—XVI йөзләрдән калган Казан кремле, Камай, Арча, Чаллы, Иске Җөри, Өтернәс, Тангачы, Пимәр шәһәрләре һәм шәһәрчекләре болгар хәрби ныгытмалары традициясендә төзелгән һәм аларның күбесе болгар шәһәрләренең дәвамы булып исәпләнелә. Н. Ф. Калинин җитәкчелегендә Казан кремлен казыганда болгар шәһәр төзү осталыгының Казан татарларында дәвам итүен күрсәтә торган кызыклы материаллар табылды. Архитектор Фуат Вәлиев һәм шушы мәкаләнең авторы тарафыннан 1960 нчы елда Касыйм шәһәрендәге XVI йөз татар архитектура истәлекләре өйрәнелде һәм аларның болгар истәлекләре белән бик охшаш икәнлекләре ачыкланды. Казан ханлыгында, бигрәк тә аның башкаласы Казанда булган сарайлар, мәчетләр һәм мунчалар [1] — болар барысы да шулай ук болгарлардан килә торган осталыкның гүзәл җимешләре. XIX йөз сәяхәтчесе А. Бар Казан тирәсе авылларының берсендә сакланып калган XVI йөз таш мәчетнең рәсемен төшереп ала [2]. Бу мәчет үзенең төзелеше һәм стиль үзенчәлекләре белән шәһри Болгардагы Җәми мәчетенә һәм башка биналарга бик охшаш.

Йомгак рәвешендә шуны әйтергә була: археологик тикшеренүләр болгар-татар материаль культурасының бердәмлеге турында сөйлиләр. Бу, беренчедән, ювелир әйберләренең, эш һәм сугыш коралларының, хәрби ныгытмаларның, архитектураның, орнамент, керамика, эпиграфиканың, сынлы һәм гамәли сәнгать төрләренең охшашлыгында һәм бердәмлегендә, икенчедән, болгар шәһәрләренең һәм авылларының Казан ханлыгы чорында татар шәһәрләре һәм авыллары булып үсеп китүендә күренә.

Археология мәгълүматларын топонимика мәгълүматлары тагын да ныграк тулыландыра. Кама аръягы, Тау ягы, Казан арты һәм Вятка аръягындагы бик күп авыл, тау, елга, үзән исемнәре һәм башка төрки топонимнар бер-беренә охшаш һәм бер-берсен кабатлыйлар.

И. Хәлфин, К. Насыйри, Г. Әхмеров, С. Вахидов тарафыннан тупланган риваятьләр болгар-татар культура бердәмлеге мәсьәләсен яктыртуга зур өлеш кертteләр. 1966 нчы елда күренекле фольклорчы Х. Х. Ярми Мари АССР Бәрәңге районы Куян авылы шәҗәрәсен табып кайтты. 1909 нчы елда Җәгъфәр әл-Болгари, әл-Казани дигән кеше тарафыннан төзелгән бу шәҗәрә 17 буынны эченә ала [3]. Әл-Болгари эпитетының

---

[1] Рус елъязмалары һәм А. М. Курбский хәбәрләре.

[2] Рәсемнең күчермәсе Казан тел, әдәбият һәм тарих институты гыйльми хезмәткәре Фуат Вәлиевтә саклана.

[3] Казан тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклар секторында саклана. Исемнәр: Үрмәт — Әҗмәт — Солтанай — Ярыслан — Яңгырчы — Укачы — Котлы — Вәлит — Мәкәй — Рафик — Ислам — Габделгазиз — Габдрахман — Габдессәлам — Насретдин — Хафизетдин — Җәгъфәр әл-Болгари, әл-Казани.

элекке гасырларда гына түгел[1], XX йөз башында да кулланылуы Казан татарларының үзләрен элекке болгарлар дип йөртүләренә матур дәлил булып тора.

Ләкин Казан татарларының культурасын һәм килеп чыгышын бары тик болгарлар белән генә чикләү дөрес булмас иде. Болгарның үз тарихы башта Хазар белән, соңыннан ике йөз ел буена Алтын Урда белән тыгыз бәйләнгән. Болгар культурасы үзе Хазар каганатына һәм Алтын Урдага кергән башка халыкларның, шулай ук чит илләрнең культура йогынтысын татыган. Болгарларга Харәзем, Кавказ, Мисыр культура элементлары үтеп кергән (мәсәлән, ялтырабыклы керамика, архитектура, сынлы сәнгатьнең аерым төрләре һ. б.). Болгар һәм Казан ханлыгы җирләренә төрле тарихи чорларда кыпчаклар, угызлар һәм башка төрки халыклар күчеп утырганнар һәм татарларның этногенезына үз өлешләрен кертканнәр. Лингвистик мәгълүматлар безнең телебезнең кыпчак теленә тугандаш булуын күрсәтәләр. XIII йөз ахыры — XIV йөз башларының ядкаре булган «Коман мәҗмугасы»ндагы («Кодикус куманикус») сүзләр, грамматик формалар, халык авыз иҗаты үрнәкләре (табышмаклар) бүгенге татарларның теленә бик якын. Болгар һәм кыпчакларның телләре буенча бер-беренә тугандаш халыклар булуы турында кайбер борынгы язма истәлекләр сакланып калган. 1183 иче елда бөек князь Всеволод Киев кнәзе Святославка язган хатында болгарларга каршы сугышта кыпчаклардан ярдәм ала алмаячагыннан зарлана, чөнки болгарлар һәм кыпчаклар туганнар һәм бер телдә сөйләшәләр, ди. Безнең XIII—XV йөзгә караган әдәби истәлекләребез (Кол Гали, Харәзми, Саяди, Сәеф әс-Сарай һ. б. әсәрләре) шушы болгар-кыпчак телендә язылганнар. Нипаять, галимнәр хәзерге татар теленең формалашуында Орхон-Енисей язмалары һәм Мәхмүт Кашгари хәбәрләре буенча билгеле булган «татар» дигән төрки кабиләләрнең дә катнашы барлыгын әйтәләр. Димәк, бүгенге татар халкының формалашуы, татар теленең, культурасының тарихы ул гаять катлаулы процесс булган. Менә шушы катлаулы, озын тарихи юлда болгарлар аеруча күренекле урын алып торалар һәм алар Казан татарлары этногенезының нигезен тәшкил итәләр.

— — □ — —

[1] Мәсәлән: Ибраһим ибн-Иосыф Болгари (XII йөз), Хуҗа Хәсән әл-Болгари (XIII йөз), Гали Болгари (XIV йөз), Мөхәммәдьяр Мәхмүт углы Болгари, Хисаметдин бине Шәрәфетдин әл-Болгари (XVI йөз), Утыз Имәни Болгари (XVIII йөз), Габделкаюм әл-Болгари (Каюм Насыйри, XIX йөз).

*Дәүләт премиясе лауреаты, Үзбәкстанның халык шагыйре, академик Гафур Голәм — үзбәк совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе иде. 40 еллык иҗат гомерендә ул күп санлы шигырьләр һәм поэмалар, хикәяләр һәм повестьлар иҗат итеп калдырды. Аның күпчелек әсәрләре СССР халыклары телләренә, шулай ук чит телләргә дә тәрҗемә ителгән.*

*Гафур Голәм татар әдәбиятының зур дусты, ялкынлы пропагандисты булды. Габдулла Тукай, һади Такташ, Муса Җәлил һәм башка татар шагыйрьләренең иҗаты белән үзбәк укучысы башлап Голәм тәрҗемәләре аша танышты.*

*Әле узган ел гына Гафур Голәм Татарстанда булган һәм Габдулла Тукайның тууына 80 ел тулуга багышланган тантаналы кичәдә речь сөйләгән иде. Үкенечкә каршы, бу аның соңгы речe булып калды. Казаннан Ташкентка кайтуга күп тә үтми шагыйрьнең тынгысыз йөрәге тибүдән туктады.*

*Журналыбызның бу санында Гафур Голәмнең «Шагыйрьнең мәңгелеге» исемле мәкаләсен урнаштырабыз. Күренекле шагыйребез Муса Җәлил истәлегенә багышланган бу мәкалә «Шәрык йолдызы» журналының узган елгы 2 санында басылган.*

*Гафур Голәм*

# ШАГЫЙРЬНЕҢ МӘҢГЕЛЕГЕ

Мин бала чагымнан ук китапка хирес идем. Әти-әниләремнән яшьләй ятим калганга күрә, китап сатып алу минем өчен кыен бер эш булды. Минем туганнан-туган абыйларым байлар, аларның шәһәр җирендә үзләренең магазиннары бар. Кышны кичләрне алар үз тиңнәре — бай бәтчәләр белән карта уйнап уздыралар. Мин исә аларга йомышчы малай булып йөгергәләп йөрим. Аларның берәрсе картада отса, мин ятимгә дә биш-ун тиен чәйлек эләккәли. Ә мин, иртәгесен үк, бу акчага китап ала торган идем.

Иске Ташкентта ике махсус китап кибете бар иде, берсе — хәзерге «Хәмзә» театры каршында... Икенчесе — Чарсуда. Моннан башка тагын иске-москы китап сатучылар да бар, алар йөзләрчә.

Теге ике кибеттә Истамбулдан, Каһирәдән, Тәһраннан, Бомбейдан, Калькуттадан, Бакча Сарайдан, Тифлистан, Бакудан, Казаннан килгән төркичә, фарсы-гарәпчә «яңа заман» китаплары һәм дәреслекләр сатыла иде.

Бу китап сатучылар мине яхшы таныйлар, ятимлегемне дә беләләр. Әгәр сатып алган китабымны ертмыйча, керләндермичә аларга китереп бирсәм, алар аны ярты бәясенә миннән кире кайтарып алалар. Шуңа күрә мин алган китапларымны бик саклап кына укый торган идем. Бу китаплар аз нөсхәдә чыгарыла, шулай булуга карамастан, сатучылар, китапның сатылмый калуыннан шикләнеп, аның битләрен кисмичә куялар. Янәсе, сатылмаса, һич югы, кәгазе әйбер төрергә ярасын. Мин андый китапны укыганда бик азаплана идем. Ләкин берни дә эшләр хәл юк, чөнки ун тиенлек китапны мин биш тиенгә алып укыйм бит.

Минем яратып укыган китапларым Казан, Оренбург, Бакуда басылган була иде. Мин бигрәк тә Казан китапларын кызыксынып укыйм. Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан, Риза Фәхретдин, Галимҗан Ибраһимов һәм башкаларны шул чагында ук танып калган идем. Казан минем күңелемдә кагъбәдән югары булып күренә иде.

Һади Такташ белән 1919 елларда Ташкентта таныштык: ак чырайлы, зәңгәр күзле, саргылт чәчләре җилкәсенә кадәр төшкән, миннән бер-ике яшькә кечерәк, чандыр

гына бер татар егете иде ул. Без икебез дә дәртләребез ташып торган, типсә тимер өзәрдәй егетләр идек.

Ниһаять, озак еллар буе хыял итеп йөргән теләгемә 1928 елда ирештем. Без Зыя Сәид белән икәүләшеп Казанга киттек. Юл уңаенда Оренбургта туктадык. Урал елгасы буендагы авылларның берсендә татар крестьяннарының сабан туе бәйрәме бара икән. Оренбургтагы дусларыбыз безне шунда алып киттеләр. Менә кайда икән тамаша! Бер урында шомартылган озын колганың башына бер пар итек элеп куелган. Кем дә кем колгага үрмәләп менеп шул итекне ала алса — итек аңа була. Икенче җирдә чүлмәк вату уены... өченче җирдә тагын башка төрлесе... Шулай итеп без, исебез китеп, мәйданда күп санлы халык уеннарын карап йөрдек.

Өч көннән соң Казанга килдек. Безне өлкән язучылар рәтендә каршы алып, бик зур кадер-хөрмәт күрсәттеләр. Газеталарда рәсемнәребез басылды. Мин «Татарстан» газетасы, «Чаян» журналы өчен нәрсәләр язып та бирдем. Казанда мин үземнең яшьлек дустым Такташны очраттым. Ул безне шәһәр белән таныштырды, аның тирәсенә алып чыгып, матур табигатен күрсәтеп йөрде.

Шулай итеп, Такташ безне шактый күп язучылар белән таныштырды: Гадел Кутуй (хәзер Рөстәм Кутуй имзасы белән яза торган егетнең әтисе), Демьян Фәтхи, Шамил Усманов, Афзал Шамов, Кави Нәҗми һәм башкалар. Шул танышкан язучылар арасында озынча йөзле, 22—23 яшьләрендәге Муса Җәлил дә бар иде. Һади Такташның, аны минем белән таныштырганда:

— Менә бу — киләчәге уттай балкый торган яшь шагыйребез, безнең аңа өметебез зур, — дигәне хәтеремдә.

Әй, гомер дигәнең шулай сизелмичә үтә дә китә икән! Шул көннәрдән соң 38 ел вакыт үткән!

Әгәр Муса Җәлил фашист балтасы астында һәлак булмаган булса, хәзер аңа да 60 яшь тулып, дуслары уртасында ай кебек балкып утырыр иде.

Муса Җәлил... Әгәр аның тормыш юлын язсаң, ул зур эпоска, берничә томлы романга, калын-калын энциклопедияләргә җитәрлек булыр иде. Аның батырлыклар белән бизәлгән, кайнап торган тормышы турында карт Гомер әсәр язарга уйласа, үзенең «Одиссея» һәм «Илиада»лары янына тагын бер эпопея кушкан булыр иде. Шунысына без бик шөкер итәбез: Мусага тиешле булган «Шаһнамә»ләр урынына без хәзер «Мәрднамә»ләр (батырлык китабы) яза алабыз.

Үзенең «Бәхет» дип атаган беренче шигыренә «Кечкенә Җәлил» имзасы куйган Муса бүген дөньяга мәгълүм зур шагыйрь Муса Җәлилгә әйләнде.

Бөек Ватан сугышы башлану белән, Муса, аягына обмотка урап, бер кулына мылтык, икенчесенә каләм тотып, дошманга каршы сугышка китте. Сугышның фаҗигаләре барыбызга мәгълүм. Башта дәһшәтле чигенү еллары булды. Муса шул чагында чолганышта кала. Аны фашистлар таш зинданга ташлап эзәрлеклиләр, газаплыйлар. Яраларыннан кан агып, тәннәре телгәләнеп бетсә дә, Муса вөҗданын, Ватанын, җырларын һәм үзенең матурлыгын дошманга сатмады.

...Әнә ул бөтен тамырлары белән җиргә кереп тәпләнгән мәһабәт чинар кебек басып тора. Канэчкечләр аннан сорау алалар. Мусаның иреннәре «газап чиксәм дә юлымнан кире кайтмыйм» дигән сыман кыймылдый кебек. Әгәр бөгәсең икән, корыч та сынып китә. Кеше корыч түгел. Ләкин Муса Җәлил кебекләр корычтан да чынырак, чыдамлырак.

Муса — ул фашистлар кулында тоткын, ләкин фашистлар аннан куркалар. Җәлладларда корал бар, Мусаның кулында — каләм. Аның күңелендә көчле сөю һәм нәфрәт утлары.

Ул үзенең фронттан язган хатында болай ди: *«Мин үлемнән курыкмыйм, бу коры сүз генә түгел. Без үлемгә чиркаnып карыйбыз, дип әйтәбез икән — бу, чыннан да, шулай. Ләкин үлгәннән соң да яшәү бар. Үлгәннән соң да халык күңелендә, халык аңында яши торган хәят бар. Әгәр мин исән чагымда берәр изге эш эшлим икән — икенче тапкыр яшәргә, үлгәннән соң да гомеремне дәвам иттерергә хокук алам. Дөньяда шулай итеп яшәргә кирәк ки, үлгәннән соң да үлмәслек булсын!»*

Муса Җәлил Моабит төрмәсенең ялгыз камерасында тоткын хәлендә 94 шигырь язган. Йөрәк каны белән язылган шул шигырьләрнең һәрберсе шагыйрь хаятының үлем алдындагы аерым-аерым бабларының берсе дияргә була...

94 шигырь... алар шомлы кичләрдә, үлем кулагаләре үрмәләп торган дәһшәтле төннәрдә туган ялкынлы шигырь юллары... Шуларның 67 сен Муса Җәлил, үлемгә хөкем ителгәннән соң язып, килер буыннарга васыять итеп калдырган. Менә шул шигырьнең аерым юллары:

Үлгәндә дә йөрәк туры калыр
Шигыремдәге изге антыма.
Бар җырымны илгә багышладым,
Гомеремне дә бирәм халкыма.

Муса тоткында чакта да үлем турында уйламый. Күршелы язны күз алдына китерә. Яфраклар коела торган чакны түгел, балкып торган гөлләрне уйлый. Кан тамырларында шигырь юллары кайнап тора. Ләкин аларны язып калдырырга кәгазь юк. Йөрәкнең ташкыны андый-мондый кәгазь кисәгенә генә сыймый. Ул ике кечкенә дәфтәр кисәге таба. Менә шулар инде Моабит дәфтәре булып тарихка кереп калалар.

Муса Җәлил төрмәдә чакта: йөрәктәге шигырьләремне кәгазьгә төшереп бетерә алмыйм, алар минем белән бергә үләләр, дигән. Безгә Мусаның Моабит шигырьләреннән 94 е килеп житте. Калганнары, мең еллар узса да череми торган Нилүфәр орлыклары шикелле, шагыйрьнең үзе белән бергә җирдә ятачак. Ул орлыклар кайчан да булса башка бер шагыйрьнең күңел бакчасында яңа гөлләр булып шытып чыгачак.

Туфрак күмәр тәнне, күмә алмас
Ялкынлы җыр тулы күңелне.
«Үлем» диеп әйтеп буламы соң
Җиңеп үлгән мондый үлемне.

Кешенең уйлары секунды белән йолдызларга барып җитә. Кешенең хыялы бихлә ишекләрдән үтеп керә ала. Мусаны уйласам, мин аның тынчу диварлар эчендә ялкынланып шигырь язып утырган соңгы минутларын күз алдыма китерәм:

Соңгы җырым палач балтасына
Башны тоткан килеш языла.

Юлиус Фучик та дар агачы астында, муенына элмәк эленгән минутларда: «Сез минем өчен җирдә яшәгез», дип кычкыра. Муса Җәлил дә шундый сүзләр әйтеп дөньядан китте. Без, аның ватандашлары, үзебез өчен генә түгел, бәлки аның өчен дә җирдә яшибез. Николай Тихонов та аның турында: «Ул үзенең шигырьләре белән поэзиянең батырлык иканен расләп китте»,— ди. Мин дә каләмдәшләремнең бу сүзләренә тулысынча кушылам. Мин Муса Җәлилгә аның исән хәлендәге 60 яше алдында бөек ихтирам белән башымны иям.

Мин ант иттем җанны кызганмаска,
Саклар өчен халкым, илемне,
Пөзәү булса гомерең, син барысын да
Шушы юлга бирмәс идеңме?!

Муса Җәлил тоткында торып үзенең дустына шулай дип мөрәҗәгать итте. Бу мөрәҗәгать безнең барыбызга да карый.

Бу — Юлиус Фучик, Муса Җәлил кебек үз Ватанын, халкын гаҗәеп бер самимилек белән сөя торган җырчыларга карап әйтелгән сүзләр.

Муса Җәлил: «Үлгәннән соң да яшәү бар», дигән иде. Бу, димәк, озын-озын гомернең бары тик беренче алтмышы гына.

Муса Җәлилнең хаяты һәм поэзиясе мәңгелек ул.

Үзбәкчәдән М. НОГМАН тәрҗемәсе.

— — □ — —

### Төрлесеннән

# Татарстан тарихы буенча чит илдә чыккан бер китап турында

Чит ил тарихчылары, төрки телләрдә сөйләшүче СССР халыкларының тарихын өйрәнгәндә, Татарстан һәм татар халкы тормышына да зур игътибар бирәләр. Ел саен диярлек дөньяның төрле илләрендә безнең республикабыз тарихы буенча язылган китаплар һәм мәкаләләр чыгып тора. Соңгы елларда чыккан шундый хезмәтләрнең берсе «Россия мөселманнарының милли хәрәкәтләре. Татарстанда «солтангалиевчелек» дип атала. 1960 елда Парижда чыккан бу китап Татарстан тарихының шактый зур чорын яктыртуга багышланган. Авторлар үз хезмәтләрендә Казан ханлыгы Россиягә кушылган чорлардан алып XX йөзнең 50 елларына кадәр булып үткән тарихи вакыйгалар турында сөйлиләр.

Авторларның берсе — Александр Беннигсен Франциядә танылган исламчылардан санала, 1957 елда Парижда басылып чыккан «Ислам буенча энциклопедия»нең авторы. Аның күпчелек хезмәтләре СССР территориясендә яшәүче төрки халыкларның милли азатлык хәрәкәтен өйрәнүгә багышланган. Шанталь Келькеже да безнең республика тарихын өйрәнү буенча аерым хезмәтләр язган кеше.

Аларның бу хезмәте күп еллык эзләнүләр нәтиҗәсендә язылган булса кирәк. Китапта кузгатылган мәсьәләләр буенча авторлар байтак кына мәкаләләр дә чыгарганнар. Алар совет тарихчыларының хезмәтләреннән иркен файдаланганнар. Китап ахырында китерелгән киң библиография әнә шул турыда сөйли. Анда ТАССР Верховный Советы сессиясе материаллары, милли мәсьәлә буенча КПСС Үзәк Комитеты һәм Татарстан өлкә комитеты карарлары, Татарстан тарихына кагылышлы документлар җыентыклары һәм башка материаллар бар. Беннигсен һәм Келькеже безнең заман тарихчыларының иң соңгы хезмәтләре белән дә танышып барганнар. Библиографиядә М. К. Мөхәррәмовның, Р. И. Нәфиговның, И. М. Ионенко һәм башкаларның хезмәтләрен күрәбез.

Шулай да, авторлар 20 еллар тарихчыларының хезмәтләрен артыграк күрәләр, ул хезмәтләрне үзләре өчен кыйммәтлерәк саныйлар. Әлбәттә, без элекке тарихчыларның хезмәтләре белән исәпләшәбез. Тик шулкадәресен әйтеп китәргә кирәк: ул заман тарихчыларының күбесе марксистик-ленинчыл методологияне үзләштереп җиткермәгәннәр иде. Өстәвенә аларның хезмәтләрендә архив материаллары да аз кулланылган.

Авторлар социалистик революциягә каршы көрәшкән һәм соңыннан безнең илдән сөрелгән татар буржуаз милләтчеләренең «хезмәтләрен» һәм «истәлекләрен» ышанычлы чыганаклар итеп файдаланалар. Шундый ук ышаныч Америка фальсификаторы Зеньковскийга һәм немец авантюристы фон Мендега күрсәтелә, төрле антиленинчыл элементлар, милләтчеләр зур авторитетлар булып йөртеләләр. Шул рәвешчә, алар файдаланган чыганаклар үзләре генә дә сагаерга мәҗбүр итә, бу хезмәтнең фәннилек дәрәҗәсе турында шик уята.

Китап өч бүлектән, һәр бүлек үз чиратында кечкенә-кечкенә аерым бүлекчәләрдән тора. Беренче бүлек «Октябрь революциясенә кадәр татар милләтчелеге» дип аталган. Монда авторлар татарларның төрле чорларда патша дәүләтенең руслаштыру политикасына каршы алып барган көрәшенә тукталалар. Авторлар уенча, ул көрәшне «ассимиляция», «хезмәттәшлек» һәм «яңа киеренкелек» исемле чорларга бүләргә мөмкин (1860—1905 еллар). «Политик тормышның башлануы» дип исемләнгән бүлекчәдә татар җәмгыятенең төрле катлауларының, ягъни эшчеләр, крестьяннар һәм «бай класслар»ның хәле анализлана. Шунда ук «революцион группаларның» һәм «уртача буржуазия» группаларының эшчәнлеге тикшерелә. Аннан соң авторлар 1917 елның февраленнән октябренә кадәр чорда «власть өчен көрәш»не сурәтлиләр. Монда 1917 елның җәендә үткәрелгән мөселман съездлары турында сөйләнә.

«Коммунистлар партиясендә татар милләтчелеге» дип аталган икенче бүлектә революциядән соңгы еллардагы Татарстан тормышы күзәтелә. Ләкин авторлар Коммунистлар партиясенең һәм Совет дәүләтенең төп линиясенә каршы көрәше белән даны чыккан Солтангалиевнең «эшчәнлеген» як-

тыртуда аеруча зур тырышлык һәм юмартлык күрсәтәләр. Шушы милләтче исеме астында алар бөтен бер эпохадагы «халык хәрәкәте»н күрсәтергә омтылалар. Бүлек 1917—1923 елларны үз эченә ала һәм ВКП(б) ҮКның төрле национал-уклонистларны тәнкыйть иткән карарын искә төшерү белән тәмамлана.

Китапның өченче бүлегендә Беннигсен һәм Келькеже татар халкы тормышындагы һәрбер вак фактан «милләтчелек рухы» табарга тырышалар. Француз буржуаз матбугаты тарафыннан югары бәя алган бу китапның кыскача эчтәлеге менә шундый.

Бу мәкаләдә без Беннигсен һәм Келькеже китабында яктыртылган барлык мәсьәләләргә дә тукталмыйбыз. Хезмәтнең төп тенденциясен ачардай аерым урыннарын гына карап китәбез. Әйтергә кирәк, безнең өлкә тарихының 20 йөзгә кадәрге чорлары турында сөйләгәндә, авторлар нигездә рус галимнәренең хезмәтләреннән файдаланалар. Дөрес, алар күбесенчә фактик материаллар гына алалар, ә нәтиҗәләрне үзләре ясыйлар. Татар халкының патша хөкүмәте алып барган руслаштыру политикасына каршы авыр көрәшен авторлар бик кызык аңлаталар. Бу күп еллык көрәштә татарларның «сирәк очрый торган ялагайчәнлек» һәм «какшамас ихтыяр көче» күрсәтүләрен билгеләп, Беннигсен һәм Келькеже татар хезмәт ияләренең рус һәм үз милли помещиклары, дворяннары һәм буржуазиясе изүенә каршы сыйнфый көрәшен читләтеп узарга тырышалар. Хәлбуки, тарихи фактлар рус һәм татар крестьяннарының, үз интересларын яклау өчен, бергәләп, кулга-кул тотынып көрәшүләре турында сөйли. Рус һәм татар пролетариаты да капиталистларга һәм фабрикантларга каршы бергәләп көрәште. Татарстан тарихының Октябрьга кадәрге чорын яктыртканда, Беннигсен һәм Келькеже татарлар арасында революцион хәрәкәтнең үсешен бозып, кечерәйтеп күрсәтергә тырышалар. Алар татарлар арасында марксизмның «бик аз» таралуын һәм татарларның социал-демократик хәрәкәттә бик йомшак катнашуын исбат итмәкче булалар. Аның каравы, авторлар һәрнәрсәдән милләтчелек, панисламизм һәм пантюркизм идеяләрен казып чыгаралар. Француз белгечләре рус һәм татар революционерларын узара каршы куярга азапланалар. Мөселман Комитетының[1] эшчәнлегенә багышланган бүлекчәләр шул турыда сөйли.

Хәзерге заман тарих фәне 1917 елның апрелендә күренекле революционер М. Вахитов һәм башка татар большевиклары тарафыннан оештырылган Мөселман социалистлар комитетының татар крестьяннарын һәм эшчеләрен революцион хәрәкәткә тартуда зур уңай роль уйнавын раслады. Беннигсен һәм Келькеже совет тарихчыларының хезмәтләрендә китерелгән фактларны кире кага алмыйлар. Мөселман социалистлар комитетының зур эш башкаруын таныйлар һәм ул «Казан большевикларына бик нык ярдәм итте» дип язалар[2]. «Кызыл байрак» газетасы: «Вакытлы хөкүмәтне каты тәнкыйтьләп, сугыш хәрәкәтләренең тукталуын, җирнең крестьяннарга бирелүен һәм бигрәк тә властьның Советларга тапшырылуын таләп итеп, гадәттә большевиклар юлыннан барды», — диләр авторлар. Шуңа да карамастан, алар, үз-үзләренә каршы килеп, Мөселман социалистлар комитетын Казан большевикларына каршы куярга тырышалар. Алар Мөселман социалистлар комитетында татар большевикларының роле кечкенә булды, Казан большевиклары белән элемтә очраклы иде небегрәк карашлар үткәрәләр. Алай гына да түгел, авторлар Мөселман социалистлар комитетына «мөселман җирләрен руслар хакимлегеннән азат итү теләге» шинелле чынбарлыкка бөтенләй туры килми торган бурычлар тагалар. Беннигсен һәм Келькеже бу комитет «милли социализм» төзергә, ахырдан аны дөньяның башка ислам илләренә таратырга теләде дип раслыйлар. Мондый «кыю нәтиҗәләр» нәрсәгә нигезләнгән соң? Әлбәттә, Мөселман социалистлар комитетының программасында булсын, ул башкарган чараларда булсын, мондый тенденциянең эзе дә юк. Укучыны коры сүзләр белән генә ышандырып булмаслыгын аңлап, авторлар үзләренең уйдырмаларын төрле авторитетлар белән ныгытмакчы булалар. Заманында И. Рахматуллин, Мөселман социалистлар комитеты татарлар арасында эшләү белән генә канәгатьләнеп калмады, ә «социализм идеяләрен бөтен ислам илләренә» таратуны үзенә максат итеп куйды, дип язган иде[3]. Билгеле, И. Рахматуллин сүзләрендә Беннигсен һәм Келькеже расларга теләгән фикерләрнең эзе дә юк. Алар бу әсәрләрендә Мөселман социалистлар комитетының эшчәнлегендә күренгән кайбер җитешсез якларны бик күпертеп күрсәтсәләр дә, комитет эшенә уңай бәя биргән бүгенге хезмәтләрне күрмәмешкә салышалар. Хезмәтләренә заман рухы кертү һәм объектив күренергә тырышу теләге белән булса кирәк, алар тарих фәннәре докторы М. К. Мөхәррәмов монографиясеннән дә өзекләр китерәләр[4]. Тик аның белән килешмиләр генә. Авторлар Р. И. Нафиговның М. Вахитов турында язылган соңгы әсәрләре белән дә яхшы таныш. Ә бит Нәфигов китабы, яңа документлар нигезендә, Мөселман социалистлар комитетының һәм М. Вахитовның Казанда Октябрь революциясен әзерләү һәм үткәрү эшендә, татар хезмәт ияләрен оештыру һәм

[1] Мөселман социалистлар комитеты 1917 елның апрель башларында М. Вахитов инициативасы белән төзелә. РСДРП(б)ның Казан комитеты җитәкчелегендә, бу комитет татар хезмәт ияләрен большевистик лозунглар тирәсенә тупларга булыша, буржуаз милләтчеләргә каршы актив көрәш алып бара.

[2] A. Bennigsen et ch. Quelquejay. Les mouwements nationoux cher les musulmans de Russie. Le „sultangallevisme" an Tatarstan. Paris. Француз телендә. 1960 ел 75 бит.

[3] И. Рахматуллин. Мулланур Вахитов. Казан. 1923. 35—36 битләр.

[4] М. К. Мухарямов. Октябрь и национальный вопрос в Татарии. Казань. Рус телендә. 1958 ел.

аңлату, алар арасында социализм идеяләрен тарату эшендәге зур ролен ышандырырлык итеп исбатлады [1].

Беннигсен һәм Келькеже Казан большевиклар оешмасының интернационал характерын шик астына алалар. Алар аны саф рус оешмасы итеп күрсәтергә тырышалар. Авторлар: җирле большевик җитәкчеләре үз сафларына татар эшчеләрен алырга никадәр генә тырышмасыннар, Октябрь революциясенә кадәр большевиклар партиясендә татарлар бик сирәк очрый иде, дип язалар. Шушы позициядән чыгып, алар Казанда Октябрь революциясен «тик руслар ясады» дип аңлаталар, татарларның революциядә катнашуларын кечерәйтеп күрсәтергә, юкка чыгарырга маташалар. Бу чит ил тарихчылары күренекле большевик Якуп Чанышевның «Армия һәм Октябрь» дигән хезмәтендә китерелгән фактларны шик астына алалар, Чанышев Октябрь социалистик революциясен хәзерләүдә «үз ватандашларының ролен» арттырып күрсәтә, диләр. Аларга җавап итеп без Октябрь вакыйгаларында катнашкан рус иптәшләрнең бу мәсьәләгә карата әйткән сүзләрен китерә алыр идек. Мәсәлән, Н. Ежов, Масальский, Грасис Октябрь революциясен хәзерләүдә татар пролетариатының роленә югары бәя бирделәр. Бу иптәшләрнең хезмәтләрендә әйтелгән ул фикерләрне, билгеле, Беннигсен белән Келькеже дә белә. Шуңа күрә авторларның мәсьәләне хәл итүдә гадел булуларын шик астына алырга безнең тулы хакыбыз бар. Россиянең барлык почмакларында яшәүче хезмәт ияләре кебек үк, татар хезмәт ияләренең дә революцион юлындагы зур ролен совет тарих фәне инде күптән исбат итте. Партиябезнең XII съезды милли мәсьәлә буенча резолюциясендә болай диде: «Бу теләктәшлек һәм ярдәм итү Октябрь көннәрендә безнең партиябезнең җиңүен тәэмин итүче хәлиткеч моментларның берсе булды».

Татар халкының автономияле милли дәүләт төзү тарихы да китапта берьяклы күрсәтелгән. «Татар-Башкорт Совет республикасы турында» положениенең басылып чыгуын Беннигсен һәм Келькеже интервенция башлану белән бәйле дип саныйлар. Моңдый шартларда, янәсе, Совет власте аларның «милли таләпләренә каршы тора алмады» [2].

Бу китапка рецензия язган белгечләрдән Максим Родинсон мәсьәләне тагын да куертып җибәрә. Ул колчакка каршы көрәштә татар хәрби частьларының «зур ролен» күрсәтә дә, Совет хөкүмәте ниндидер мәкерле нияtләрдән чыгып кына Татар-Башкорт республикасы төзергә вәгъдә бирде, дип ышандырмакчы була [3]. Ә инде 1919 елда БАССР һәм 1920 елда ТАССР төзелүне ул: акчехларны һәм Колчакны җиңгәннән соң, русларның «Волга һәм Урал буе мөселманнарының ярдәменә мохтаҗлыгы кимү» белән аңлата.

Билгеле булганча, Татар-Башкорт республикасы төзү фикере 1918 елның февралендә үк туган иде. Республика төзү турындагы положение шул ук елның 22 мартында басылып та чыга. Ә империалистлар тарафыннан оештырылган акчехлар фетнәсе 1918 елның май ахырларында гына башлана. Шулай итеп, Француз белгечләренең Татар-Башкорт республикасы төзү турындагы мәсьәләне акчехлар фетнәсе һәм Колчакка каршы көрәш белән бәйләп аңлатулары һич кенә дә нигезле түгел. Киресенчә, әлеге республиканы төзү, гражданнар сугышы башлану аркасында, тормышка ашырылмый кала.

1919 елның октябрь аенда В. И. Ленин: партиянең Үзәк Комитеты татар һәм башкорт автономияле республикаларын хәл итү мәсьәләсе бу халыкларның үз теләкләреннән чыгып каралачак, дип белдерде [4].

Татар һәм башкорт автономияле республикаларын төзегәндә Совет хөкүмәте, бу халыкларның һәркайсына үз дәүләтләрен булдыру мөмкинлеген биреп, һәр милләтнең үзбилгеләнү хокукы турында марксистик-ленинчыл тәгълиматны практикада тормышка ашырды.

Беннигсен һәм Келькеже исә, татар һәм рус халыклары арасындагы тарихи дуслыкны бозып күрсәтеп, безнең ил тормышының бүгенге чынбарлыгына пычрак ташламакчы булалар. Чын тарих безнең халыклар арасындагы дуслыкның ерак гасырлардан килә торган бай традицияләре булуы турында сөйли. Бу дуслык патша самодержавиесе, помещиклар һәм капиталистларга каршы, чит ил басып алучыларына каршы алып барылган авыр көрәшләрдә туган. Октябрь революциясенә кадәр үк татар халкының күренекле вәкилләре безне рус халкы белән берләшергә чакырдылар. Совет кешеләре, нинди милләттән булуларына карамастан, бердәм теләкләр һәм максатлар белән яшиләр. Аларны буржуаз дөньяга хас милли дошманлык хисләре аермый. Халыкларның интернационал гаиләсендә безнең татар халкы да үз бәхетен тапты.

**Р. ХӘЙРЕТДИНОВ.**

[1] Р. И. Нафигов. Мулланур Вахитов. Казань. Рус телендә. 1960 ел.
[2] Шунда ук. 120—121 битләр.

[3] M. Rodinson. Communisme et Tiers Monde: sur un précurseur oublié. „Les Temps Modernes." Француз телендә. 1960—61 ел.
[4] В. И. Ленин и Татария. Казань. 1964. Рус телендә. 268 бит.



сатира
һәм
юмор

*Фатих Хөсни*

# БАР ИДЕ БАЛТАЧТА БЕР ӘТӘЧ

*(Хикәя түгел)*

Узган ел май азакларында, табигатьнең шау чәчәктә чагында, әдәбият Атналыгы уздыру максаты белән Балтач районына юл тоттык. Әле генә башланган эш түгел, Татарстанның бөтен районнарын дигәндәй йөреп чыккан кешеләр, өстәвенә Мәскәү, Ленинград кебек олы җирләрдә дә булганыбыз бар, Төмән, Пермь, Оренбург өлкәләрен дә кыдырып кайттык, рәтен беләбез, нәрсәсен сузып торырга, китәргә диделәр, — киттек.

Безнең алдан йөрүче администраторыбыз белән район агайлары маршрутны без барганчы ук билгеләп куйганнар иде инде. Район клубында, тантаналы шартларда, Атналыкны ачып җибәргәннән соң, иртәгесен, ике группага бүленеп, бер группаның башына безнең мәгълүм Озын егетебезне бастырып, икенчесен, бик үк теләп алмаса да, шагыйрь Җәүдәт Ганиев итәгенә тагып, чыгып киттек авылларга. Чыгып киттек һәм шул китүдән атна буена кайтып кермәдек... дисәк, ай-һай, сез дә, без дә ансат котыласы идек кана! Юк, без бу юлы башка төрлерәк планлаштырдык. Колхозларда машиналарның күплеген исәпкә алып, аннары тагы, эшебезне эшләгәч, куну-йоклау яклары белән колхозчыларны мәшәкатьләмәскә булып, барыннан да бигрәк, районның Кунак өендәге урын-җирнең бик чиста, матрац сиртмәләренең тирбәтеп торуын искә алып, кунуын район үзәгенә кайтып кунарга дип сөйләштек. Бер караганда, моннан да шәбрәк уйлап чыгаруның булуы мөмкинме! Иртәнге салкын белән чыгып китәсең, кичке салкын белән кайтып егыласың. һәм эшемне кырып кайткан пәһлеваннардай гырлап йоклап китәсең... дип уйлыйсыз инде сез. Шулай булмаган кая! Хәер, алга йөгермик, барысының да үз вакыты бар.

Кыскасы, ул көнге эшебезне бетереп, район үзәгенә, Кунак йортына кайтып җиткәндә, вакыт төнге беренче иде инде. Озакламыйча, Озын егет группасы да кайтып төште. Машиналар борылып кайтып киттеләр, без үзебез генә калдык. Эшләнгән эштән барыбыз да бик канәгать, күргән сый-хөрмәттән — әйтеп тә торасы юк, мактанмыйча телләрне тотып булмый иде.

— Әй, без булган авылдагы үзешчәннәрне күрсәгез иде сез, — дип кереште Озын егет группасыннан берәү. Икенче бер теленә салынганы:

— Теге чәчен толымлап үреп салган Каракүзне әйтәсеңме? Тавышы да тавышы, малай, сандугачларың бер якта торсын, — дип кыздырып җибәрде.

— Сандугачың бер якта торса торыр, ә мин бер якта тора алмыйм, — дип күтәреп алды өченче бер кызган баш, — җырлаганда күзләре гел миндә булды. Һич югы, күзенә багышлап бер шигырь язмый булмас, ахры.

Ике якта ике группа: чынын-куыгын очыра-очыра сизми дә калганбыз: таң атып килә, әкәмәт. Ул арада шунда, безнең астан гына, дөньяны кикриге белән чөеп атардай булып, шырылдап әтәч кычкырып җибәрде... Монда мин тәмам теңкәбезгә тигән ул әтәч турында ныклабрак сөйләмичә булдыра алмыйм, егетләр, гаепләштән булмасын. Мин үзем, мәсәлән, авылны күргән, әтәчләрне шулай ук күргән кеше, әмма ләкин менәтерәк мондый әтәчне һич күргәнем юк иде, җанкисәкләрем. Тавышы булса да булыр икән! Кайда ул безнең Язучылар союзы әтәчләренә болай кычкыру!!! Аның бик тә хәтәр ягы тагын шунда: башка әтәчләр кайдан булса да югартын, кунакчадан яки булмаса киртә башыннан кычкырсалар, бу әкәмәт астан, без яткан өйнең нәкъ астыннан разбой сала. Башыңа төшкәч беләсең, вәхаләнки, моның үзенә күрә бер тарихы бар, имеш. Без яңа өй, нарат исе аңкып тора, сәламәтлеккә сәбәп, дигән булып, Кунак өенең әле тик стеналары гына өелеп, түшәмесайгагы гына җәелгән яңа ягына урнашкан идек, ә аның асты хәзергә ачык, имеш. Җитмәсә тагын күз-колак булырга якын, дип хуҗа хатын анда тавыклар ияләштергән булган. Ә кайда тавык — шунда әтәч, ул ягын үзегез беләсездер. Кыскасы, бу беренче төнне безгә тамчы да йокы эләкмәде. Элек, беребез икенчебездән уздырырга тырышып, үзебез сайраштык, аннары әтәч сайрарга тотынды. Көн яктырып, кояш шактый күтәрелгәч, инде чак кына черемгә китәбезме дип ятканда, хуҗа хатынның биш яшьлек чәтердән малае кереп җитте. Һәм тотынды ул сайрарга. Сәбәбе дә бар икән, хәер. Иң элек ул малайның өч яшькә хәтле теле ачылмаган булган, хәзер шуның ачуын кайтарып, элек сөйләшми йөргәне өчен дә сөйләшә, имеш. Икенчедән — бусы инде бик нигезле сәбәп — шул без барып урнашасы көннәрдә генә аның әнисе «чишмәдән чиләккә салып» тагын бер малай бәби алып кайткан. Анысы шулаен шулай да, ә малайга эшнең ничек торганлыгын — «чишмәдән бәбинең ничек кайтканлыгын» тиешенчә аңлатмаган булганнар. Безнең агай-энегә тагын җитә калды. Төрле яклап, теге малай алдында «аңлату эшләре» алып барырга тотындылар. Кыскасы, без ул төнне тамчы да йокламаган кейгә тәки иртәне җиткердек. Шулай да бу иртәнең, калган иртәләргә караганда, бер өстенлеге булды: кешеләр барысы да үз урыннарында иделәр, иртәгесен икенче колхоздан алмага машиналар килгәч, кешеләрнең кайсын кайдан җыеп, эзләп йөрергә туры килмәде.

Ә менә икенче, өченче иртәләрне... О, гаҗәеп мәгърур тавышлы ул әтәч белән бәйләнешле кыйссаларны бик озынга да сузарга булыр иде, ә минем сузасы килми. Икенче, өченче көннәрне һәм төннәрне, кайбер вак-төяк үзгәрешләрне искә алмаганда, шул ук тарих кабатланды диярлек. Озын егет группасы үз маршруты белән, без үз юлыбыз белән башкарасы эшләрне башкарабыз. Колхозга барып төшкәч, «тукта, чәк кенә форсат... төнлә йоклап булмады, әтәч йокы бирмәде» дип торып булмый бит! Мәктәбендә дә булабыз, җәйләвенә дә барып чыгабыз, кичен клубта, шау-гөр килеп, колхозчылар белән дә очрашабыз, китап та сатабыз һәм болардан соң, һәр бирмеш кичне, сый-хөрмәт...

Ә өйгә кайтып егылдыкмы, теге әтәч шундамы шунда: тотына кычкырырга һәм бөтен кешене аякка бастырганчы авызын япмый, үләт тәгәрәткере.

Шагыйрьләр булсак та, без дә кешеләр бит, өченче-дүртенче төннәргә киткәч, безнекеләрнең дә нервлары какшый башлады. Бер көнне иртә белән карыйбыз, үзенең сиртмәле караватында берәү дә йокламаган. Ә тиздән колхозлардан алмага машиналар килергә тиеш. Тотындык кешеләрне җыярга. Берәвебез, тавык ите ашарга һәм аннан

соң борчак сибәргә аеруча гайрәтле бер шагыйребез, ерак йөрергә авырсынып булса кирәк, күрше йортның печәнлегенә менеп йоклаган. Икенчебез таныш кешесенең өенә «кунакка киткән». Өченчебезне, гадәттә үзенең балыкчылык һөнәре белән бик тә мактана торган, ак чәчле, кызыл чырайлы, гаять сәламәт шагыйребезне «балыкка киткәндер» дип уйлаган идек, тәки шулай булып чыкты. Җыелып җиткән хәтлебез, шаугөр килеп, Шушмага су коенырга барганда, күзебезгә күренәме дип торабыз, бу кайтып килә. Иңендә кармак таягы, өсте-башы ватылган, мыек бер якта, ачуы икенче якта, йокламаганлыктан күз төпләре күгәргән бичараның.

— Кайда соң тоткан балыгың, Михнәттәш? — дип сорыйбыз. Элекке фронтовик, дөньяны күргән кеше, алай да борынны бик салындырмаган бу. Хәтта юморы да үзе белән икән:

— Бар ул, бар балык, — дигән булды, һич сер бирмичә. Чалбарының сәгать кесәсендә казынырга тотынды: янәсе, бар балык, чыгарып кына булмый.

Чын аңлатмасын соңыннан ясады:

— Сезнең ул әллә кайчан тотып казанга саласы этәчегезнең разбоен тыңлаганчы, ичмасам, табигать кочагында илһам җыеп төн үткәрдем. Казанга кайткач, сагынырсың әле мондый төннәрне, — дигән булды.

Ә бер бик талантлы, бик яшь, бик «тиле» шагыйребезне эзләп-эзләп тә таба алмадык, килеп әйттеләр:

— Әнә анда, колхоз бакчасының коймасы буенда, бүкәнгә утырып бер егет йоклый. Сезнең кеше түгелме ул? — диләр. Барып карасак, чынлап та, безнең Рәис булып чыкты. Уяткач, сабый бала кебек, бөтен бите белән рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

— Кыз озатып куйган җирдән, малай... гаепләштән булмасын, туйган идем теге этәчегездән, саф һава сулап кинәнеп бер йоклаганмын, — дип аңлатып бирде.

Өйләнмәгән егет, ни ялганласа, шул килешә. Хәер, ялган булмавы да ихтимал, килеп төшүгә Балтачның менә дигән бер кызын кулга ияләштерә башлаган иде ул.

Әдәби атналыкны ябу тантанасында мин үзем катнаша алмадым. Чөнки нәкъ шул йомгак ясаласы көнне мине күрше Саба районына алып киттеләр — анда безнең икенче бригада Атналык уздырып йөри иде, шул уңайдан минем бер әсәр буенча укучылар конференциясе билгеләнгән булган икән.

Соңыннан, барыбыз да Казанга җыелгач, Балтач группасындагы иптәшләр миңа сөенечле хәбәр җиткерделәр: теге безгә йокы бирмәгән этәчне, ниһаять, суйганнар. Шулай булмыйча соң, язучы барып төшсә, районда бөтен кеше җанын ярып куярга әзер, ә ул кызыл кәпәчнең гамендә дә юк — акырыпмы-акыра. Менә инде икенче барганда акыра алмас.

——□——

# КИРӘКЛЕ ӘСӘР

Хөрмәтле Ибраһим ага!

Сезнең «Малайлыкта кунакта» дигән автобиографик хикәягезне укып, бала чакта Алиш хикәяләрен укыгандагы рәхәтне, Тукай тормыш юлын укыгандагы тирән газапларны кичердем. Артистка Орлованың бер үк кинода ике рольне башкаруын күреп исем киткән иде. Бу хикәягездә Сез дә шундый катлаулы рольне оста башкардыгыз. Үзенә генә хас алым, үзенә генә хас тел, ничек шулкадәр оста язарга өйрәндегез икән! Хәзерге авылның җитешсезлекләрен язуыгызга да, башка телләр өйрәнү буенча әйткән фикерләрегезгә дә рәхмәт. Ләкин шуларны искә дә алсыннар иде!

Малай чакта кунакта хәтәр йөргәнсез икән. Хикәягезне укыганда шул малайны тотып алып юындырасы, киендерәсе, ашатасы, чын-чын кунак итәсе килә. Сезне Гөлниса белән яшәтәсе килгән иде дә, булмады.

Хикәягезне укып чыкканнан соң, берсеннән-берсе татлы һәм газаплы мең төрле сорау туа. Күзгә йокы керми. Әйтерсең, укучы Сезнең белән бергә уйнап үскән, Сезнең тормышны бәйлисең, сүтәсең. Мондый рәхәт минутлар бик сирәк булалар. Язучы бу әсәрен нигә болай соң язды икән! — дип сорадым да, абый һәм җиңгәләре исән чакларында аларны борчырга теләмәгән, мәрхүм булуларын көткәндер, дип җавап бирдем.

Сезне 60 елыгыз белән котлыйм, иҗат эшегездә уңышлар һәм картаймавыгызны теләп калам.

Сөембикә ИХСАНОВА,
Пермь өлкәсе.

«Казан утлары» журналының узган елгы унынчы санында С. Таҗетдиновның «Үлемнән яшәүгә» исемле документаль повесте басыла башлаган иде. Әсәрнең ул санда басылган өлешен укучылар җылы каршыладылар. Һәм, түземсезлек белән көтеп алып, аның дәвамын да яратып укыдылар. Аннары Оренбургта яшәүче С. Таҗетдинова, аның әсәрен укыганнан соң күңелләрендә туган фикерләрен әйтеп, авторны үзләренә очрашуга чакырып, укучылардан бик күп хатлар килә башлады. Алар барысы да диярлек повестьның үзләренә бик нык тәэсир итеп, күңелләрен җилкендереп җибәрүе хакында язганнар иде. Һәм бу бер дә гаҗәп хәл түгел, чөнки повесть чыннан да мөһим темага багышланган, чынбарлыкка хилафлык кылмыйча, автор вакыйгаларны ничек булган — шулай сурәтләгән.

Бу тарихи повестьның темасы әдәбият өчен яңа түгел. Совет кешеләренең фашистлар тоткынлыгында көрәшен сурәтләп язылган китаплар утыздан артык. Әмма «Үлемнән яшәүгә» аларны кабатламый, ул әлеге китаплар арасында үзенә аерым урын алып тора.

Совет кешеләренең үлемне җиңеп яшәргә омтылуын, фашистлар тарафыннан туктаусыз кимсетелеп, җәберләнеп торуларына карамастан, югары мораль һәм политик сыйфатларын саклап калуын күрсәтү — әсәрнең лейтмотивы менә шул.

«Кешеләр икәнлегегезне онытыгыз. Сез — коллар!» «Дахау» концлагере капкасы өстенә менә шул сүзләр язылган. Повесть авторы, башка иптәшләре белән бергәләп, әнә шул лагерьда ике ел буена яши һәм иреккә чыгу өчен актив көрәш алып бара. Бик күп әсирләр, «Дахау» капкасыннан тышка чыга алмыйча, я фашистлар кулыннан, яки ачлыктан һәлак булып кала.

Туктаусыз рәвештә күзәтү астында яшәсәләр дә, совет әсирләре антифашистик группа оештырырга кирешәләр һәм ул группа эшенә коммунистларны гына түгел, бәлки политик көрәштән ерак торган партиясез чит ил тоткыннарын да тарталар.

Әсирлек — каты, рәхимсез рәвештә кешеләрнең рухи сыйфатын сынау ул. Югары мораль сыйфатларга ия булган кешеләр мондый шартта тагын да ныгып, әйбәтләнеп һәм сафланып калалар, гомуми эш өчен җаннарын да кызганмыйлар алар.

Әсәрдә сурәтләнгән генерал-майор Иван Андреевич Пресняков, бригада комиссары И. С. Вдовин, тарих фәннәре кандидаты (хәзер МДУ доценты) М. М. Шейман, полковник Тарасов, подполковник Мөсәгыйть Хәйретдинов әнә шундый корыч ихтыярлы кешеләр.

Ә менә вак җанлы, бары тик үз мәнфәгатьләре өчен тырышучы адәмнәрнең чын йөзләре әлеге кыен шартларда тагын да тулырак ачыла. Ихтимал, тыныч тормыш вакытында алар гадәти кешеләр битлеге астында рәхәтләнеп яшәрләр иде. Әмма анда, лагерьда, ккейөзләнәнеп, алдашып озак йөрәп булмый шул, анда кемнең кем булуы бик тиз беленә. Моның шулай икәнлеге С. Таҗетдинов повестенда шактый тулы һәм ачык итеп күрсәтелгән. Антифашистик группа башкарган күп төрле эшләр дә реаль картиналар аша сурәтләнгән.

Повестьның тагын бер кыйммәтле һәм мөһим ягы шунда, анда төрле милләт вәкилләренең үзара дуслыгы, ирекка чыгу максаты белән бергәләп көрәше бик матур чагылдырылган. Бу — автор тарафыннан уйлап чыгарылган нәрсә түгел, бу — тарихи чынбарлык.

Нинди генә кимсетүләргә, җәберләүләргә дучар итмәсеннәр, фашистлар «Дахау»дагы антифашистик группаны үз алларында тез чүктерә алмыйлар. Әсәр тоткыннарның ирекка чыгуы белән тәмамлана.

Авторы профессиональ язучы булмаса да, повестьның теле дә укышлы чагыштыруларга һәм сурәтләүләргә шактый бай. Автор табигать күренешләрен тоткыннар халәтенә контраст итеп сурәтли һәм, шулай итеп, әсәрнең укучыга тәэсир көчен тагын да арттыра төшә.

Шул ук вакытта повесть кимчелекләрдән дә азат түгел. Анда кайбер артык кабатлаулар, стиль кытыршылыклары да очраштыргалый әле.

Әмма бу кимчелекләр генә повестьның кыйммәтен төшерми. Бигрәк тә яшь буын өчен әһәмияте зур бу әсәрнең. Алар хәзерге матур, мул тормышның нинди кыенлыклар белән яулап алынганлыгын белергә һәм шул юлда корбан булган батырларны хөрмәт белән искә алырга тиешләр.

Йомгак итеп шуны әйтәсе килә: С. Таҗетдиновның «Үлемнән яшәүгә» повесте тизрәк аерым китап итеп бастырып чыгарылсын иде.

М. МОХТАРОВА,
Оренбург шәһәре.

Кадерле редакция!

Без, Башкортстанның Әлшәй районы Гайнәямак авылы пионерлары һәм комсомолецлары, Сәгыйть Таҗетдинов абыйның «Казан утлары» журналының узган елгы 10—12 саннарында басылып чыккан «Үлемнән яшәүгә» дигән повесте буенча укучылар конференциясе үткәрдек. Бу әсәр безгә бик ошады. Аны укып, бик күп нәрсәләр аңладык. Без ул әсәрдә сурәтләнгән кешеләр кебек түземле булырга һәм авырлыкларны җиңеп чыгарга тырышабыз. Повесть геройлары концлагерьда бик авыр шартларда булсалар да, үз туган илләре өчен немец фашистларына каршы көрәш алып барганар. Үзләре ач булсалар да, авыру иптәшләренә ярдәм итәләр, үзләре ач калсалар да, үз өлешләрен иптәшләренә бирәләр. Генерал Вишневскийга алар бәрәңге, чөгендер һ. б. нәрсәләр алып киләләр. Аны ничек тә сакларга тырышалар. Бу повестьта без совет кешеләренең генә түгел, ә башка ил кешеләренең дә дус булуын, бер-берсенә ярдәм итүен күрдек. Без Сәгыйть абыйның повестен китап итеп бастырып чыгаруыгызны сорар идек. Китап булып чыкса, повестьны күбрәк кеше укыр иде. Аны укыган кешеләр нык укуларына үкенмәс дип уйлыйбыз.

ГАЙНӘЯМАК СИГЕЗЬЕЛЛЫК МӘКТӘБЕ
ПИОНЕРЛАРЫ ҺӘМ КОМСОМОЛЕЦЛАРЫ.

— — □ — —

# Укучыларыбызга җавап

Без татарча концертлар һәм гомумән татарча радиотапшырулар тыңларга телибез. Әмма Казан радиостанциясенең эш сәгатьләрен һәм тапшырулары нинди дулкыннарда алып барылуын белмибез. Шунлыктан журналыгыз аша Татарстан радиостанциясенең кайсы сәгатьләрдә һәм нинди дулкыннарда эшләвен хәбәр итүегезне үтенеп калабыз.

**ХӘМИТОВ Нәриман,**
Омск шәһәре.

Бу сораулар бер Хәмитовны гына түгел, бәлки илебезнең төрле почмакларында яшәүче башка күп кенә укучыларыбызны кызыксындыра торгандыр дип, түбәндә без Казан радиосының кайсы сәгатьләрдә һәм нинди дулкыннарда татарча тапшырулар алып барылуын күрсәткән белешмә урнаштырабыз:

### ИРТӘНГЕ ТАПШЫРУЛАР:

7 сәгатьтән яки 7 сәгать 10 минуттан 8 сәгатькә кадәр — 1181 метрлы дулкында алып барыла.

### КӨНДЕЗГЕ ТАПШЫРУЛАР:

16 сәгатьтән 18 сәгатькә кадәр 1181 метрлы һәм 4,44 метрлы ультра кыска дулкыннарда алып барыла.

### КИЧКЕ ТАПШЫРУЛАР:

19 сәгатьтән 21 сәгатькә кадәр 1500 метрлы һәм 4,44 метрлы ультра кыска дулкыннарда алып барыла.

——□——

# Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары

## ЗУР БҮЛӘК

Бөек Октябрь идеяләрен гәүдәләндерүче совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм коммунистик төзелешкә, совет халкының фашизмны җиңүенә совет язучылары керткән зур өлешне искә алып, СССР Верховный Советы Президиумы СССР Язучылар союзын **Ленин ордены** белән бүләкләде.

## СОВЕТ ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ IV СЪЕЗДЫ

22 май көнне күп милләтле совет әдәбиятының танылган вәкилләре, дөньяның бик күп илләреннән килгән кунаклар Кремльнең Зур сараена җыелдылар. Биредә СССР язучыларының IV съезды эшли башлады.

Ленин орденлы СССР Язучылар союзы үзенең чираттагы съездына зур иҗат уңышлары белән килде. III съездан соң узган еллар эчендә совет әдәбияты дөньядагы иң алдынгы әдәбиятка әверелде, хезмәт ияләрен коммунизм идеаллары рухында тәрбияләүдә куәтле чарага әйләнде. Партиялелек һәм халыкчанлык лозунгларын байрак итеп алган совет язучылары дистәләрчә талантлы әсәрләр иҗат иттеләр, бүгенге чынбарлыкның байлыгын ачып бирергә, совет кешеләренең уйларын һәм эшләрен тагын да тулырак, кыюрак сурәтләргә өйрәнделәр. Безнең язучылар хәзер бүгенге тормыштагы яңа процессларга һәм күренешләргә, актуаль темаларга күбрәк мөрәҗәгать итәләр, теләбрәк алыналар.

Безнең язучылар һәрвакыт ил, халык белән бергә булдылар, һәрвакыт партиянең даими кайгыртучанлыгын тоеп яшәделәр, иҗат иттеләр. КПСС Үзәк Комитетының IV съездда укылган котлавында совет язучыларының мактаулы һәм җаваплы хезмәтенә гаять югары бәя бирелә. «Тарихның барлык этапларында, — диелә анда, — тыныч иҗат елларында да, сугыш елларында да — ул (совет әдәбияты — ред.) героик заманның чын елъязмасы, яңа җәмгыятьнең җиңүе өчен көрәштә актив катнашучы, яңа кеше формалаштыруда куәтле чара булды... Моңа кадәр аяк басылмаган бу юлда без зур җиңүләр шатлыгын татыдык. безнең югалтуларыбыз, вакытлы уңышсызлыкларыбыз һәм ялгышлыкларыбыз да булгалады. Ләкин тарих безнең Коммунистлар партиясе, безнең халык сайлап алган юлның яңа җәмгыять төзүдә бердәнбер дөрес ленинчыл юл икәнлеген раслады, һәм әдәбият бу юлны үз халкы белән бергә намуслы үтте».

Мәгълүм булганча, язучыларның IV съезды Совет дәүләтенең ярты гасырлык юбилее якынлашып килгән көннәрдә узды. Бу исә аның әһәмиятен бермә-бер күтәрде, зурайтты.

Съездны, коммунистик җәмгыять төзүдә совет әдәбиятының роле турында кереш сүз сөйләп, СССР Язучылар союзы идарәсенең беренче секретаре К. Федин ачты. Аннары СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре Г. Марковның проза әдәбияты турындагы, М. Дудинның поэзия буенча, А. Салынскийның драматургия турындагы, Л. Новиченконың тәнкыйть һәм әдәбият белеме буенча һәм С. Михалковның балалар әдәбияты турындагы докладлары тыңланды.

Докладлар буенча фикер алышуларда союздаш һәм автономияле республикалардан, киң илебезнең күп өлкә һәм шәһәрләреннән килгән күренекле әдипләр катнашты. Докладларда һәм чыгышларда күп милләтле совет әдәбиятының 50 ел эчендә ирешкән уңышларына, бүгенге торышына, әдәбияттагы аерым жанр һәм тармакларның үсешенә төпле бәя бирелде. Съездда гомумән Язучылар союзы һәм һәрбер аерым әдип алдында торган актуаль мәсьәләләр, хәл итәсе әйберләр, мөһим бурычлар турында җитди һәм эшлекле сөйләшү барды.

Чит ил кунаклары совет язучыларына үз халыкларының кайнар сәламен тапшырдылар, каләмдәш дусларына яңа иҗат уңышлары теләделәр.

Съезд СССР Язучылар союзы идарәсенең яңа составын сайлады, Язучылар союзы уставына кайбер үзгәрешләр кертте.

• • •

СССР Язучыларының съездында Татарстан язучылары исеменнән М. Әмир, Х. Туфан, Г. Бәширов, Х. Госман, С. Хәким, Х. Вахит, Л. Ихсанова, З. Нури һәм А. Булгаков катнашты. Татарстан Язучылар союзы идарәсенең председателе М. Әмир речь белән чыкты. Ул татар язучыларының казанышлары турында сөйләде, алда торган бурычларга тукталды.

## ЛАЕКЛЫ АЛМАШ ҮСӘ

КПСС өлкә комитетының политик мәгариф йорты биш көн буе гөрләп торды: әдәби бәхәсләр, җанлы әңгәмәләр, кызыклы очрашулар... Бирегә Идел буе автономияле республикаларыннан килгән яшь язучыларның зона семинары барды.

Яшьләр иҗатын бәяләргә Мәскәү, Ленинград, Уфа, Чабаксар һәм башка шәһәрләрдән тәҗрибәле каләм осталары чакырылды. Алар арасында РСФСР Язучылар союзы идарәсенең секретарьлары Ф. Таурин, А. Кешоков, Татарстан Язучылар союзы идарәсенең председателе М. Әмир һәм Д. Кугультдинов, П. Хузангай, М. Гали, Ә. Бикчәнтәев, Ф. Хөсни, Ә. Еники, Ә. Исхак кебек танылган әдипләр бар иде.

РСФСР Язучылар союзы һәм ВЛКСМ Үзәк Комитеты оештырган бу семинарда рус, татар, башкорт, чуваш, калмык, удмурт һәм башка телләрдә иҗат итүче 50 дән артык яшь шагыйрь, прозаик һәм драматургларның әсәрләре тикшерелде. Яшь авторлар арасында төрле профессия кешеләре — журналистлар, укытучылар, эшчеләр, авыл хезмәткәрләре — бар иде. Аларның әдәби стажлары да төрлесенеке төрлечә. Берәүләр әле әдәбиятта тәүге адымнарын гына атлыйлар, икенчеләре исә 2—3 җыентык та чыгарып өлгергән. Шулай да һәрберсенең диярлек үз тавышлары, үз омтылышлары, кызыклы тормыш юллары бар.

Бу көннәрдә барган сөйләшүләр һәр яшь әдипне тирән уйланырга мәҗбүр итте. Алар үз иҗатларында нәрсәгә күбрәк игътибар итәргә, нинди кимчелекләрдән арынырга кирәклеген төшенделәр, үз замандашларының, башка өлкәләрдә яшәүче каләмдәш дусларының әсәрләре белән таныштылар.

Семинарда удмурт язучысы А. Серов, калмык шагыйре Д. Насунов, башкорт шагыйрьләре Ә. Гыйззәтов һәм Р. Шакиров, М. Ильбаев һәм С. Әлибаев, мари шагыйре С. Николаев һәм башка яшьләр иҗаты турында күп җылы сүзләр әйтелде. Татарстан вәкилләренең әсәрләренә дә әйбәт бәя бирелде. Н. Беляев, Ф. Шәфигуллин, Т. Миңнуллин, Ф. Яруллин иҗатлары аеруча күп макталды. Фәнис Яруллин иҗатын тикшергәндә, семинар җитәкчеләре яшь авторның квартирасына бардылар. Шагыйрьнең көчле рухлы булуы, тырышып иҗат итүе һәркемне таңга калдырды.

Семинар җитәкчеләре аеруча талантлы яшьләрдән берничә кешене СССР Язучылар союзына членлыкка тәкъдим итәргә, икенче берәүләрне М. Горький исемендәге Әдәби институтка җибәрергә, дигән фикергә килделәр. Талантлы авторлардан берничә кешенең әдәби җыентыклары үзәк һәм өлкә нәшриятларында басылып чыгачак.

## МУЗЫКАБЫЗ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

6 майда КПСС өлкә комитетының Политик мәгариф йортында республикабызда музыка сәнгатенең үсеше һәм аны пропагандалау мәсьәләләренә багышланган киңәшмә булды. Анда композиторлар, музыкантлар, әдипләр, артистлар, партия, совет, профсоюз оешмалары вәкилләре, матбугат, радио һәм телевидение хезмәткәрләре катнашты.

Киңәшмәдә куелган мәсьәлә буенча КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев доклад ясады. Фикер алышуларда Татарстан Композиторлар союзы председателе, СССР ның халык артисты Нәҗип Җиһанов, ТАССР Министрлар Советы янындагы радиотапшырулар һәм телевидение комитеты председателе урынбасары Ф. Фазылҗанов, шагыйрь Сибгат Хәким, Татарстан җыр һәм бию ансамбленең художество җитәкчесе Ә. Абдуллин, ТАССР дәүләт симфоник оркестрының художество җитәкчесе, СССРның халык артисты Натан Рахлин, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрының баш режиссеры Г. Кушаков, культура министры Б. Гыйззәтуллин, Татарстан китап нәшриятының баш редакторы Х. Гобәйдуллин, композитор Җәүдәт Фәйзи һәм башкалар катнашты.

## ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯ

Моннан биш ел элек Союз күләмендә милли театрлар эшчәнлегенең кайбер проблемаларына багышланган конференция уздырылган иде. Анда аерым республика театрларының үсеше, алда торган бурычлар турында сүз барды. Шул вакытта ук инде барлык милли театрларның үзара элемтәсе турында җитди сөйләшү кирәклеге әйтелде. Һәм менә 20 майда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында «РСФСР халыклары театр культураларының үзара элемтәсе һәм үзара баетышуы» дигән темага фәнни-иҗади конференция ачылды. Конференциядә, РСФСРдагы милли театрлар вәкилләреннән тыш, союздаш республикалардан килгән режиссерлар, артистлар, театр һәм сәнгать белгечләре катнашты.

Конференцияне кыскача кереш сүз белән ТАССР культура министры Б. М. Гыйззәтуллин ачты. Берничә көн буе барган бу конференциядә театр сәнгатенең актуаль мәсьәләләренә багышланган бай эчтәлекле, кызыклы докладлар тыңланды, ул докладлар буенча фикер алышулар уздырылды.

Конференциядә безнең республиканың театр белгечләре дә актив катнашты. Сәнгать фәннәре кандидатлары Р. Усманова һәм И. Илялова ясаган докладлар тыңлаучыларда аеруча зур кызыксыну уятты.

Р. Усманова үзенең докладында татар театр сәнгатенең РСФСР халыклары театрлары белән элемтәсе турында сөйләде. Татар театрына башка театрларның йогынтысына, аның төзелүендә һәм формалашуында рус театр культурасының тоткан роленә тукталды.

И. Илялованың докладына татар һәм үзбәк театрлары арасындагы дуслык, үзара ярдәмләшү мәсьәләләренә багышланган иде.

## ТУКАЙ ӘСӘРЛӘРЕ — КАЗАКЪ БАЛАЛАРЫНА

Казагыстанның «Язучы» нәшрияты Габдулла Тукайның балалар өчен язган шигырьләрен казакъ телендә аерым җыентык

итеп бастырып чыгарды. Җыентыкка бөек шагыйребезнең «Шүрәле», «Су анасы», «Туган тел», «Эш беткәч, уйнарга ярый» һәм башка күп кенә шигырь-поэмалары кергән. Тукай әсәрләрен танылган казакъ шагыйре Җакан Сыздыков тәрҗемә иткән. Китапның тиражы 10 000 данә.

## БАРИ РӘХМӘТНЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

19 майда язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында күренекле балалар язучысы Бари Рәхмәтнең туувына 70 ел тулуга багышланган кичә уздырылды.

Кичәдә балалар язучысы Җәвад Тәрҗеманов яшь буынны тәрбияләү эшенә зур иҗади гомерен багышлаган әдип турында кереш сүз белән чыкты. Язучы Г. Бакир Бари ага хакында истәлекләр сөйләде, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор Заһид Хәбибуллин скрипкада Бари Рәхмәт сүзләренә иҗат иткән әсәрләрен уйнап күрсәтте.

Бари Рәхмәт истәлегенә багышланган бу кичәдә республика Мәгариф йорты каршындагы үзешчән сәнгать түгәрәге членнары һәм 80 мәктәп укучылары да чыгыш ясады. Соңыннан Татар дәүләт филармониясе җырчыларыннан Зәйтүнә Әхтәмова, Таһир Якупов, җырчы Ф. Сөләйманова, үзешчән композиторлар Ф. Әхмәдиев, Ә. Хәйретдинов иптәшләр катнашында күңелле концерт булды.

## МУЗЫКАЛЬ ФЕСТИВАЛЬ

СССР Композиторлар союзы һәм СССР Министрлар Советы янындагы радиотапшырулар һәм телевидение комитеты, Совет властеның 50 еллыгына багышлап, күп кенә шәһәрләрдә «СССРның музыкаль культурасы» дигән фестиваль үткәрделәр. Бу фестиваль 12 һәм 13 майда Казанда дәвам итте.

Фестивальдә катнашу өчен, шәһәребезгә күренекле композитор, СССРның халык артисты, Ленин премиясе лауреаты Арам Ильич Хачатурян да килде. 13 майда Казан дәүләт консерваториясендә А. Хачатурян республикабызның культура хезмәткәрләре, консерватория укытучылары һәм студентлары белән очрашты. Бу очрашуда Арам Ильич музыка сөючеләрнең бик күп сорауларына җавап бирде. Сораулар совет музыкасының торышына, милли музыкаларның үсеш юлларына, композитор А. Хачатурянның чит илләргә сәяхәтенә кагылышлы иде. Аннары концерт булды. Концертта композитор Нина Макарова, РСФСРның атказанган артисткасы Н. Поставничева, В. Добрин, В. Громова, Ю. Челкаусказ чыгыш ясадылар.

12 һәм 13 майда шәһәр сәхнәләрендә симфоник концертлар, камера музыкасы һәм җыр авторлары концертлары булды. Аларда Ленинград академия кече опера һәм балет театры дирижеры Ю. Темирканов җитәкчелегендәге Бөтенсоюз радио һәм телевидениесенең зур оркестры, композиторлар Арам Хачатурян, Нина Макарова, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Борис Терентьев, Чечен-Ингушия АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Оскар Фельцман, Мәскәү театрлары артистлары, шагыйрьләр катнашты.

## МАЙ ЙОЛДЫЗЛАРЫ

«Май йолдызлары» фестивалендә катнашу өчен, РСФСРның халык артисты Фәхри Насретдинов, Татарстанның халык артисткасы Венера Шәрипова, Татарстанның атказанган артистлары Әлфия Афзалова, Илһам Шәкиров, Гали Җәмлиханов, баянчы Фәйзи Садыйков, биюче Ибәтуллиннар ватаныбызның башкаласы Мәскәүгә чакырылган иде. Концертларда шулай ук Чувашиянең атказанган артисткасы Тамара Чумакова, эстрада артистларының Бөтенроссия конкурсы дипломанты Измаил Рәхимов, Юрий Меньшиков, Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенең эстрада оркестры, яшь композитор Ренат Еникеев һәм концертмейстер Николай Алексеевлар да катнашты.

Татар артистлары чыгыш ясаган Мәскәү эстрада театры залы тамашачылар белән һәрчак тулы булды. Концертларны Германия Демократик Республикасы, Франция һәм бүтән илләрдән килгән күп санлы туристлар да тыңлады. Башкала тамашачылары лирик җырларны да, романсларны да, халкыбызның шаян җырларын һәм биюләрне дә бердәй яратып каршыладылар.

Башкала кешеләре концертларда катнашучы һәркемне кайнар алкышладылар, артистларга яңа иҗади уңышлар теләделәр. Безнең артистларны сентябрьдә булачак РСФСР халыклары сәнгате фестивалендә катнашырга чакырдылар.

## ЧЕХОСЛОВАКИЯ ЖУРНАЛИСТЛАРЫ КАЗАНДА

Казанда Чехословакия Социалистик Республикасы журналистлары делегациясе булып китте. Аның составында «Правда» газетасының җаваплы секретаре (Братислава) Юлиус Крайчи, «Репортер» (Прага) журналы сотрудникы Иржи Румл һәм «Правда» (Пльзень) газетасы бүлек мөдире Вацлав Шнебергер бар иде.

Аэропортта Чехословакия кунакларын Татарстан Журналистлар союзы, матбугат, радио, телевидение һәм Совет-Чехословакия дуслыгы җәмгыяте вәкилләре каршылады.

Беренче көнне чех дусларыбыз Татарстан дәүләт музеенда Казан университетында, Горький музеенда булдылар, шәһәр белән таныштылар, Спорт сараенда хатын-кызлар арасында РСФСР беренчелегенә баскетбол ярышлары карадылар. Чехословакия журналистлары шулай ук Куйбышев исемендәге химия заводында булдылар, Казан журналистлары белән очраштылар, Совет-Чехословакия дуслыгы митингысында катнаштылар. Бу митинг Совет Армиясенең Чехословакияне фашистлардан азат итүенең егерме ике еллыгына багышлап уздырылды.

Җаваплы редакторы **Рафаэль Мостафин.**


Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев.**

Производствога бирелде 15/V-1967 ел. Басарга кул куелды 22/VI-1967 ел. Кәгазь форматы $70\times108^{1}/_{32}$. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 56 000 экз. Заказ № М-862. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1967 ел.

# ЯШЬЛЕК ДУСТЫМА

МИРСӘЕТ ЯРУЛЛИН музыкасы,
ИЛДАР ЮЗИЕВ сүзләре.




Ядкәр булсын бу җырым, дустым,
Китәм ерак якларга.
Яшьлегеңне искә төшерерсең
Бик ямансу чакларда.
Онытма син: гел бергә йөрдек,
Аерылмас дус идек,
Каршыладык күпме таңнарны,
Бергә сөйдек ярларны.

Ядкәр булсын ялкынлы яшьлек,
Эзе калсын елларда.
Онытмасна сүзләр куешып без
Кузгалабыз юлларга.
Җырла син дә бу моңлы җырны,
Көннәрең булсын нурлы.
Мәңге сакла дуслык сүзләрен,
Җирдә калсын эзләрең.

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

*Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал*

# КАЗАН УТЛАРЫ

(ОГНИ КАЗАНИ)

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

Индекс 73210